www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Разил ВӘЛИЕВ. Тамырымда мәңге калырмын. *Шигырьләр*. ....3
АХИР. Мөхлис һәм иблис. *Рок-н-роллы бәян*. ....9
Илшат ВӘЛИУЛЛА. Мең төсмерле җиһан үзе... *Шигырьләр*. ....54
Фәния ГАБИДУЛЛИНА. Вакыт ага үз иркенә. *Шигырьләр*. ....85
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Боссоойко. *Хикәя*. ....88
Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА. Офыкларда ал таң ата... *Шигырьләр*. ....102
Кадрия ХӘСӘНОВА. Сандык биге. *Хикәя*. ....105

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Сагынган чакларымда... *Драма*. ....57

*100 нче бит:* Кадрия ФӘТХУЛЛОВА. Ана теле сагында. ....100

ЮБИЛЕЙЛАР

Азат АХУНОВ. Галим, остаз, шәхес *(Нурмөхәммәт Хисамовка 80 яшь)*. ....109

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Шагыйрь эзлим *(2016 ел поэзиясенә бер караш)*. ....114

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Шагыйрьләр солтаны. ....136

*Әдәби хәзинәләребез:* Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Пар гына күкеләр чакырганда... ....138

ПУБЛИЦИСТИКА

Газинур МОРАТ. Ирек дигән татлы сүз... *(Татарстан референдумына 25 ел)*. ....146

ФӘН

Гүзәлия ХАҖИЕВА. Татар кушаматлары. ....153
*Истәлекләр:* Фәрит ХАТИПОВ. Балачак хатирәләре. ....158

*Юбилейга барышлый.* Афзал ШАМОВ. Журналның бер нөсхәсе. ....163

*Кайтаваз*. Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА. Күңелемә хуш килгән әсәр. ....164

«ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА

Лира ИБРАҺИМОВА.Мизан бураны. *Хикәя*. ....165

АК ҖИЛКӘН

*Бәләкәйләр:* Әзһәр ШАКИРОВ. Бәләкәй Әзһәр. ....172
Хикәя яза аласызмы? *Ф.Мәрданова, Н.Вәлиева, Р.Арифуллин, Л.Әблиева, С.Шәрипова хикәяләре*. ..179

*Табигать һәм мин:* Илдус ДИНДАРОВ. Матуркай балык тота. ....187

«Казан утлары» архивыннан. ....112
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Рәзилә Хәйретдинова, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер)**.**

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.02.2017, график буенча 28.02.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-504. Тираж 5250.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 2017 ел



Разил
Вәлиев

# ТАМЫРЫМДА МӘҢГЕ КАЛЫРМЫН

## Үзгәрергә!

Җанны талкый һаман заман уе,
Төште инде сагыш йөзләремә...
Яшәп булмый элек яшәгәнчә, –
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!

Яшәп булмый элек яшәгәнчә.
Таң шәфәгы минем күзләремдә.
Нур өстисем килә туар көнгә...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Нур өстисем килә туар көнгә,
Нур саласым килә сүзләремә.
Итәгемнән тарта үткән төннәр...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Итәгемнән тарта кара төннәр...
Ышаналмыйм кайчак түзәремә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Басмак булам заман эзләренә.
Алдан бара әйдәп фидаилар...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.

Алдан бара әйдәп фидаилар.
Ияртерләр микән үзләренә?
Җанны талкый һаман заман уе:
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!

---

Разил ВӘЛИЕВ (1947) – *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә чыккан күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Һәйкәлләр

Күңелләргә сыймый дала моңы,
Җырларга ул ничек сыйсын ди?!
Һәйкәл булып өстән карый шагыйрь,
Булмаса да зурдан буй-сыны.

Без бөек тә, таш һәйкәл дә түгел,
Без бу җирдә – гади кешеләр.
Дус-дошманга ачык күңелебез...
Без – акыллы һәм без – шыр юләр.

Урамнардан җырлап узабыз без,
Юллар безнең арттан иярә...
Ай-йолдызга менеп булмас, ахры...
Безнең язмыш гади иярдә.

Без – кешеләр, гади кешеләр без.
Без очрашкан мәлләр – шәп мәлләр!
Ә бөекләр һәйкәл булып калган...
Тик очраша алмый һәйкәлләр.

## Моңсу шаяру

Мин күмәч тә пешермәдем,
Күккә акча чөймәдем,
Кемгәдер баш та имәдем…
Мин бары җыр көйләдем.

Сату-алуны белмәдем.
Егермедә өйләндем.
Дошманнар гайбәт сөйләде…
Мин бары җыр көйләдем.

Пегаска да атланмадым,
Парнаска да менмәдем.
Йөрәкләрне дә ватмадым…
Мин бары җыр көйләдем.

Алар бергә учак якты,
Мин ялгызым көйрәдем.
Хорда җырлап булмас, ахры…
Мин ялгыз җыр көйләрмен.

***

Язлар миңа сине китермәде.
Хәбәр бирми үтте җәйләр дә.
Ничәнче ел инде бу йөрәгем
Җир тирәли ялгыз әйләнә.

Бураннардан табармын күк сине
(Юраганга, диләр, юш килә).
Яз гөлләрен күкрәгенә тезеп
Тәрәзәләр, әнә, төш күрә.

* * *

Һәр көз саен таллар телсез калган,
Телсез калган юкә, имәннәр:
Яфракларын җилгә чәчә-чәчә
Язга кадәр алар үлгәннәр.

Яфраклары үлгән, карлар күмгән,
Җир җылыткан ләкин тамырын...
Көзге җилләр телем алсалар да,
Тамырымда мәңге калырмын.

## Яз

Утызы да тулмый, февраль киткән...
Урамнарга шыплап март тулган.
Агачларның саллы җәясенә
Ук түгел лә... яфрак тартылган.

Каргалар да безгә каркылдамый...
Без мәңгелек инде бу җирдә.
Бер туйганчы күккә карыйк әле,
Ике кулны куеп бөергә.

Кайгыларны салыйк гөрләвеккә,
Тургай итеп чөйик шатлыкны!
Яз хәбәрен ишетеп, барча кошлар
Безнең якка таба ашыкты.

Такса таксын дошман төрле исем...
Бар табигать безне үз итә...
Безне сагынып, кошлар килә бүген,
Күңелләрдә бүген боз китә.

## Көтү

Әнисеннән ул елмаю көтте,
Әтисеннән – киңәш,
Дошманнардан иң көчлесен көтте,
Дусларыннан – тиңдәш.

Болыт килсә, ул кояшны көтте.
Аяз булса – болыт.
Юкәләрдән һаман алма көтте,
Тупыллардан – шомырт.

Шагыйрьләрдән акыллы сүз көтте,
Музыканттан – зур хис.
Кешеләр аннан көлеп сөйләделәр:
«Ул көтәргә хирыс...»

Ә хатыны тап-тар бүлмәсендә
Көтте кара малай.
Язмыш көтте, җилдән бишек асып
Кәкре карамага.

## Яңа «карурман»

Кара да гына урман, караңгы төн,
Юл читендә юк шул маяк та.
Иһаһайлап чапкан кашкаларың
Көчкә басып тора аякта.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Бал кортлары чәчәк табалмый.
Чишмә кипкән, агачлары корыган,
Бушап калган инде тау алды.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Әй яктыра инде, яктыра...
Бары үлгән, бары сорыланган,
Тик күңелдә генә ак тора.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Хатирәләр генә ак тора.
Һәр яз саен сандугачлар килеп
Авылыма мине чакыра.

## Иң беренче тирәк

– Эшлә, – дисең. Кулларыма минем
Тоттырасың көрәк.
Эш – мәңгелек, эш ул – тамак ялы.
Миңа бәхет кирәк.

– Чокыр казы. Менә шушы төшкә
Утырт, дисең, тирәк.
Утырттым ди. Үсә бирсен әйдә...
Миңа бәхет кирәк.

– Төбен йомшарт, яраларын бәйлә,
Суын сипмә сирәк.
Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

– Үскән инде. Калдыр тирәгеңне.
Ары киттек тизрәк.
Үстер, дисең, бакча. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

– Хәзер инде шушы һөнәреңне
Башкаларга өйрәт.
Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.

...Эш күрсәтеп, кулларына бирдем
Балта, пычкы, көрәк.
Кабатлады алар, миңа кушылып:
«Безгә бәхет кирәк».

Сорадылар аннан: «Бәхет ни?» – дип,
Ярсып типте йөрәк...
Сүз тапмадым. Искә төште шулчак
Иң беренче тирәк.

## Чәчәк бәйләме

Язмыш мине алга әйдәде дә...
Гомер бирде, чәчәк бәйләмедәй.

Яңгырларда калдым, күрдем карны.
Гөлләремне юлга сибеп бардым.

Килеп җиттем инде җир читенә.
Ялгыз бару юлда, һай, читен лә.

Үткәннәргә борылып карадым да...
Чәчәк эзләп, кире барам менә.

Кайда соң син, кайда, умырзаям?
Үткән мәллә яшь гомерем зая?

Кайда соң сез, кайда гөләпләрем?
Үтәлгәнме олы теләкләрем?

Бәхетлеме соң мин, әйт, ромашка!
Хыялларым чынга ашканнармы?

Язмыш мине тагын алга әйди,
Чәчәкләрдән бәйләм бәйли-бәйли.

## Сагынам

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Тәрәз каршындагы өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый,
Мин кышларда сине сагынам.

Карашыңдай җылы, аяз көннәр,
Җилләр исә синең ягыңнан.
Гөрләвекләр булып кайтыр идем...
Мин язларда сине сагынам.

Бөтен дөнья бүген шау чәчәктә,
Арынган җир хәсрәт-кайгыдан.
Шатлык тәяп кайтып килер идем...
Мин җәйләрдә сине сагынам.

Синең сагыш әллә күчкән инде? –
Урманнарга сары кабынган.

Күзләремдә яшьме, яңгырмы ул? –
Мин көзләрдә сине сагынам.

Офыкларга карап, һәр көн саен
Сине уйлыйм, сиңа табынам.
Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк, –
Сине, әнкәй, сине сагынам.

## Сөембикә

*Резеда Ахиярова музыкасы*

Казаныма төннәр иңсә,
Сине эзләп карыйм күккә.
Зәңгәр күктә Ай моңлана,
Моңлана күк Сөембикә.

*Кушымта:*
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.

Сине уйлап үтә язлар,
Сине уйлап көзләр җитә.
Яңгыр булып көз еламый,
Син елыйсың, Сөембикә.

*Кушымта:*
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.

Сагышларны сүтә-сүтә
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.

*Кушымта:*
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә!



Ахир

# МӨХЛИС ҺӘМ ИБЛИС

РОК-Н-РОЛЛЫ БӘЯН

*Мөхлис. Син милләтең белән кем, урысмы, әллә татармы?*
*Иблис. Мин урыс та, татар да түгел.*
*Мөхлис. Нишләп?*
*Иблис. Мин изге җан, милләтем юк...*

*Рок-н-ролл (инглизчә – rock and roll, туры мәгънәсендә – селкен һәм бөтерел) – узган гасырның илленче елларында АКШта барлыкка килгән популяр джаз музыкасы стиле.*

## 1. Мөхлис уяна һәм...

Мөхлис, йокы аралаш, каты итеп йөрәге чәнчүдән, аркасы сызлаудан әрнеп, талпынып куйды. Ирексездән, ул каткан буыннарын, ипсез ятудан оеган аякларын урын өстенә сузып, җәеп җибәрде. Аннан... ...аннан ул күзен ачты: башы тубал булып каткан, авызыннан күңел болгаткыч тәмәке исе, махмыр сасысы аңкый...

Япь-яшь егет – махмырдан интегә! Андый вакытта ул үзен гел үлем белән яшәү арасында хис итә һәм иң аянычы – үз-үзенә хуҗа була алмый иде...

– Ү-ү-ү-лә-ә-ә-әм!!!

Җанда бушлык, чиксез бушлык. Питер каласының тау-чокырлы җирендә урнашкан ике катлы кирпеч йортның флигель бүлмәсе (авылдагылар аны чарлак, диләр!), гадәттәгечә, шомлы вә караңгы иде. Урам һәм балкон ягына карап торган бердәнбер тәрәзә кара калын пәрдә белән капланган, ул бик сирәк ачыла, шуңа күрә хәзер төнме, көнме икәнлеген тәгаен генә белеп тә, сиземләп тә булмый. Кайчандыр ул кояштай якты фатирда яшәде. Бай атасы: «Улым, студент еллары бер генә була, кадерен белеп, кешечә укы, кешечә яшә!» – дип

Ахир (Хәбир Ибраһим) (1958) *– язучы, драматург, «Ялгыз тәкърлек», «Газиз ярым», «Төпчек малай маҗаралары» һ.б. китаплар авторы; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш һәм Ш.Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

аны, үгет-нәсихәтләр биреп, өч бүлмәле яхшы һәм җайлы фатирда урнаштырып калдырган иде. Ләкин атасының фатирга түләргә дип калдырган акчасын тиз генә туздырып аткач, ул хәзер үзен шушы шалама алачыкта, ягъни чарлакта яшәргә дучар иткән иде. Тиздән аны моннан да куарлар, чөнки аның шуңар түләрлек акчасы да калмаган иде инде...

Мөхлис язу өстәлендә торган абажурны кабызды. Абажур кара төстә иде. Кискен ут яктысыннан әрнеп әчеткән күзенең кырыен көч-хәл белән ачып, башы яньчек түп-түгәрәк будильникка күз ташлады. Идәнгә атып бәрсәң дә йөри торган сәгать, ни хикмәт, инде йөрми, туктаган, сары күгәрек йөгергән калын телләре күптәннән алтынчы яртыны күрсәтә иде. Билгеле ки, бу дөрес вакыт түгел, күңел сиземләве буенча, хәзер төн урталары булырга тиеш. Ул гел шулай: гулянкадан кайтып егыла да шундук йокыга тына һәм инде, йә башы, йә йөрәге сызланып, төн уртасында уяна…

Киң агач караватка... кәгазь, дәрес әсбаплары, юылмаган савыт-саба, каткан ашамлык кисәкләре белән тулы язу өстәле, кулдан буялган кием шкафы (ике ишегенең берсе юк!), берничә урыннан купкан паркет идән, ислөнгән швабра, памуй чиләге һ.б. Болар әлеге шыксыз вә котсыз чарлакның интерьерын хасил итәләр иде. Обойлары саргайган, чатлары чатнаган иске дивар түрендә рок-н-ролл короле Элвис Преслиның сурәте төшерелгән календарь, каршы ягында кыллары өзелгән, грифы ярык гитара, ә чатта исә борынгы зур бер көзге һәм яшеле уңып, ниндидер куркыныч төс алган берничә вак шәмаил эленеп тора иде. Шәмаилләрне ул үз кулы белән элде.

Мөхлис кабат караватка ятып дүнмәкче генә иде, кинәт шуның башында торган магнитофон акырып уйнарга тотынды. Егет артка мәтәлгән чагында аркасы белән ялгыш кына магнитофон төймәсенә яткан, шуңар күрә дә ул уйнарга тотынган. Бүлмәдә рок-н-ролл хакимлек итте. Рок-н-роллдан тыш ул башка берни дә тыңламый иде. Рок-н-роллга булган мәхәббәтне аңарда сөйгән кызы Лулу тудырды, Лулу Бөгелмә «общепит»ында бердәнбер рок-н-ролл җырлаучы булып саналды. Аны тыңларга дип бөтен Бөгелмә бомонды җыйнала иде. Мөхлис аңа беренче күрүдә үк гашыйк булды, үзеннән бигрәк – җырлау сәләтенә. Чөнки «попса»ны теләсә кем җырлый ала, ә менә рок-н-роллны бик сирәк җырчылар гына башкара. Аны башкару өчен шайтан көче кирәк, күрәсең.

Караватка, өстәл өсте һәм идән рок-н-ролл башкаручыларның альбом дисклары белән тулган, әгәр дә бер кырып-себереп, бөтен чарлакны актарып чыксаң, монда The Animals, John Lennon, Little Richard, Aerosmith, Robert Gordon, Susi Guatro, Elvis Presley, Zz Top, Bobby Dey, Carl Perkins, Wanda Jacson, Dire Straits, Los Lobos һәм хәтта Chauck Berry язмаларын да табарга мөмкин булыр иде.

Мөхлис магнитофонын сүндереп тормады, чөнки бу шайтани көйгә күнеккән иде инде. Ул аның әзрәк тавышын гына басты. Аннан ул көзге каршына килеп, озак кына үзенең ягымсыз чыраена карап торды. Йөзе саргайган, өметсез. Касмакланып каткан пычрак чәч берничә җирдә үрә баскан, күз төпләре кара янып, кызарып, хәтта шешеп чыккан. «Абау, минме бу?!» – Мөхлис үзенең «рок-н-ролл»ы кыяфәтеннән куркынып кисәк кенә артка чигенде һәм чытырдатып күзен йомды. Төшенә генә кермиме, янәсе?! Кабат күзләрен ачты һәм кабат бакты, тик көзгедәге алама сурәт берничек тә үзгәрмәде, ул ничек бар шулай калды. «Мин икән... Кая булдым соң мин кичә? Карарлык җирем дә калмаган... Ярар, әле хет исән кайтканмын! Бер генә түгел бит... Туктарга вакыт, дускай, туктарга...»

Хәл, чынлап та, кискен, хәл аяныч иде. Акча юк, университеттан куарга

торалар. Сессиясен ябалмады. Тагын кемнән ярдәм сорарга да кемнән әҗәткә акча алырга? Әҗәткә ала-ала болай да муеннан бурычка батты бит инде. Үзеннән һәм Бөгелмәдә яшәүче бай атасыннан башка аңар хәзер беркем дә ярдәм итә алмас. Ләкин ул атасына шалтыратырга һәм аңардан ярдәм сорарга курыкты. Әйе, аның атасы бай, ул – банкир, ләкин шактый усал, хәйләкәр адәм. Әгәр дә хәзер атасына исәп-хисап бирергә туры килсә, аның бик күп зур-зур һәм дә вак-вак җинаятьләре ачылачак. Кырыс атасы кичермәячәк.

Башта дуслар шактый булды, күп иде, Питердан да, башка шәһәрләрдән дә. Алар аңарда кунып, ашап-эчеп, күңел ачып яттылар (Мөхлис хисабына, билгеле!), ләкин хуҗа егетнең хәлләре мөшкелләнеп, булган бар запасы эреп юкка чыккач, шул дус дигәннәре дә каядыр югалышып, таралышып бетте. Шулай шул… Ирексездән, бөек шагыйрьнең бөек сүзләре искә килеп төшә: «Акча барда бар да дус та, бар да яр, акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!»

«Ярар... күңелне төшерергә ярамый, хәлләр мөшкел булса да, баш исән бит әле, баш!» – дип үз-үзен тынычландырган булды ул. Соңгы вакытта (янда беркем дә калмагач!) ул шулай гел үз-үзе белән сөйләшергә өйрәнгән иде.

– Бичара! – дип эндәште шулчак караңгылык. – Әгәр кирәгең булмаса, исән каласың юк иде!

– Кемгәдер кирәкле була алу зур бәхет инде ул. Тукта! Мин кичә кайда булдым соң әле? Төне буе кайда йөрдем?

Сөйләшү дәвамлы булды:

– Кайда?! Картёжный салонда! – дип кабатланды шул ук калын басынкы тавыш.

– Әйе, әйе, искә төште. Тик нишләдем мин анда? Кемнәр белән булдым? Хәтерләмим...

– Кәрт суктың, аракы эчтең, крупьеларга бәйләндең. Сине кыйный башладылар, башыңны чак кына унитазга тыгып куймадылар.

– Хәтерлим кебек... алар миннән акча таләп иттеләр, ә акча юк, бетте... кәрт уйнап, оттырып бетердем...

Ул өч-дүрт мәртәбә картада куш, ягъни зур акчалар отып, мизгел эчендә баерга һәм бар булган бурычларын каплап бетерергә өметләнгән иде. Тик, ни кызганыч, аның ул өметләре акланмады. Ул фәкать кызык һәм күңел ачу өчен генә уйнаган калын кесәле көндәшләре алдында үзенең бәясен бик нык төшерде. Комарлы уеннар ул фәкать байларга гына килешә, ярлыларны, акчасызларны нигәдер үз итми, якын итми. Ни әйтсәң дә, Бөгелмә түгел шул бу, егетем, Санкт-Петербург була бу, миллионлы кала!

– Оттырдым, әйе... әмма исән калдым... Кем коткарды соң мине?!

Үз-үзе белән сөйләшү бер генә минутка да тукталмады.

– Синең кебек үк яшь, матур егет, – дип җавап бирде усал караңгылык. – Ресторанда бер өстәл янында утырдыгыз...

Егет, сөенеченнән хәтта ки кычкырып ук куйды.

– Ә... әйе... тук чырайлы, кылыч борынлы... Менә шул чибәр егет котыртты да инде мине, шуның аркасында гына... Үз-үземә күпме әйткәнем булды – сөйләшмә таныш булмаган кешеләр белән, аралашма, дип... Юк бит, шуңа ихтыяр көчем җитмәде...

Кара пәрдә капланган тәрәзә янында нидер селкенгән, кыштырдаган кебек булды. Бу алама чарлакта ни генә булмас та, ни генә йөрмәс... Тычкандыр, күседер, бәлкем...

– Ялгышасың, – дип телгә килде каһәр суккан тәрәз буе. – Әгәр ул булмаса,

башың беткән иде. Сине шул кичне эзләп таптылар. Син Марк Захарыч атлы эшкуардан бурычка акча алып торгансың, ике ай эчендә кайтарам, дигәнсең. Вәгъдәңдә тормадың. Миллиардерлар артында һәрчак бандитлар тора, ансыз Рәсәй яши алмый. Бандитлар сиңа счёт ачтылар, алган акчаңны, тиешле процентларыңны ике көн эчендә түләп бетермәсәң, башыңны борып атачаклар, бөтен бурычыңны Бөгелмәдә яшәүче бай атаңнан түләтәчәкләр!

– Нәрсә, үлем көтәме инде мине? Үләсе килми, мин бит әле яшь, шундый яшь! Егерме бер яшьтә кемнең үләсе килсен икән?! Тик кем... кем миңа ярдәм итәр?

– Мин! – дип эндәште ягымлы балкон ягы. – Сине генә түгел, атаңны һәм хәтта мәрхүмә анаңны да яхшы беләм. Син миңа рәхмәт әйтергә тиешсең, мин сине үлемнән коткарып калдым!

– Рәхмәт... кем соң син…

Мөхлис, башын тотып, мендәргә капланды. Азып-тузып, эчеп-исереп йөргәннән соң, аңарда гел шундый галлюцинацияләр башлана торган иде. Үз-үзе белән генә түгел, әллә кемнәр белән сөйләшә. Менә хәзер дә... Әгәр дә тормышын яңадан башларга туры килсә, ул бүтән аракы эчмәс, авызына грамм да капмас, кәрт уйнаудан туктар, азып-тузып та йөрмәс иде кебек... «Валлаһи, дим! Аллам сакласын!»

Шул сүзләрне әйтүгә үк, бүлмә эче яктырып киткән кебек булды. Караңгы урыннар, чат-чатлар, пәрдә өсләре яктырып киткән кебек булды, рок-н-роллы абажур яктысыннан әзрәк читтә торган, кургашын болытка охшаган озынча кара күләгә дә тәэсир итү көчен югалтты сымак. Бертуктамый чыңлап, сызлап торган башын төзәтер өчен шайтанга җанын бирергә дә әзер Мөхлис өстәлдәге шакшы фужерда су шәйләп алды һәм шул суны йотыла-йотыла эчте. Җылымса су нык тәмсез, күңел болгаткыч бернәрсә булып чыкты, ул чак кына космады. Шыксыз көз айлары җитсә дә, йорт әле һаман да җылытылмый, бүлмә эче сизелерлек салкын иде. Егет, юрганга төренеп, карават чатына сөялде. Кинәт ул туңып китте, калтыранды, дерелдәде. Атасы алдында оят иде аңа. Ул аның алдында гел яхшы булып күренергә, үзенең җитешсез якларын яшерергә тырышты, ләкин ул, атасы уйлаганча, алтын бала түгел иде. Үзен үзе генә белә иде егет…

«Да... дело дрянь! – дип изаланды ул. – Мине аңлый алырлык, ярдәм итәрлек бирәр адәми зат бармы соң бу таш калада? Юк бит, юк! Шайтан алгыры!»

– Мин бар! Мин! – Баягы саллы тавыш тагын кабатланды.

– Кем соң син?

– Синең күптәнге дустың, адашың, чакырсаң, шундук килеп җитәм!

– Уф... тагын башланды...

– Ялгышасың, – дип каршы төште тавыш. – Галлюцинация түгел бу, без инде күптән сөйләшәбез. Мин сине өч бармагым кебек яхшы беләм.

– Ә мин сине белмим дә, күрмим дә, – дип зарланды тегесе. – Дус булсаң, хет чыгып күренер идең, ятмас идең качып! Их... әгәр дә...

– Әйе?!

– Әгәр дә мине...

– Әйтеп бетер... – Түземсезлек хәтсез иде!!!

– Әгәр дә мине, – дип көчәнде Мөхлис, – шушы коточкыч хәлдән коткаручы табылса, җанымны шайтанга, иблискә сатарга да разый булыр идем…

Әйтте генә, шундук өйдә ду купты! Нидер шартлап коелды, әйтерсең, җир убылды! Авиабомбардировка диярсең! Гадәттә, күктән бомбалар коелганда шундый гарасат кузгала. Кинода күрсәтәләр бит әле – дөньясы тетрәнә! Билгеле

ки, бу очракта исә ярык түшәм дә, начар сыланган штукатур да коелмады, берни дә ишелмәде һәм хәтта берни дә купмады, ә бәлки коелган, ишелгән һәм купкан сыман тоелды гына. Давыл түгел, хәтта тузан да купмады, идән ярыкларына кереп кысылган зарарлы тараканнар да җир тетрәгәндә генә була торган гайрәти чайкалуларны сизмәделәр…

Бүлмәнең баш-башларында ак сакаллы ике скрипкачы пәйда булды. Ни хикмәт, алар смычокларын нигәдер кире башы белән тотканнар иде. Тик шулчак бар көченә стереомагнитофон акырырга тотынды, рок-н-роллның иң хәтәре һәм иң әшәкесе яңгырады, скрипкаларын көйләп, уйнарга гына торган шәүләләр тиз арада күздән югалды. Ләкин алар бар көченә яңгыраган рок-н-ролл тавышыннан куркып түгел, ә кемнеңдер, югалыгыз, дип әмер бирүеннән югалдылар кебек. Мөхлис әлеге ишарәне үз күзе белән күрмәсә дә, аны арка мие, ягъни күңел күзе белән сизде. Магнитофон ничек каты итеп үкерә башласа, ул шулай кисәк кенә тынды да. Баядан бирле психопат кебек селкенеп, тетрәнеп торган карават, тукталышка килеп туктаган автомобильдәй, кинәт кенә калтырануыннан туктап, кабат урынына кайтып утырды. Өстенә яшел мамык юрган бөркәнгән Мөхлис кабат күзгә каршына килеп басты. Ул бүген чишенмичә генә яткан иде. Кешелеккә дип тоткан соры кәчтүме, инде «кешелеген» югалтып, берничә җирдән ертылган, казинога барыр алдыннан гына үтүк белән «стрелка» ясаган чалбары хәтәр бөгәрләнгән, замогыннан киткән чалбар ерымы, өй ишеге сымак, яртылаш ачык калган, әйтерсең, анда кемнеңдер кулы уйнаган иде. Шулчак бүлмәдә кот очарлык бер күренеш пәйда булды: егет күзгедән үз артында басып торган бер адәми затны шәйләп алды. Өстенә кара фрак кигән, башында цилиндр, һәм ул гел карадан киенгән, әйтерсең, ул күмердән яралган. Борынгы кино кадрларыннан күчеп, шушы караңгы чарлакка килеп утырган диярсең. Аягындагы ботинкасына хәтле кара төстә, тик ул фасоны белән нигәдер дуңгыз тоягын хәтерләтә иде. Ыспай үзе, пөхтә, элегантлы. Күзенә генә күренәме әллә дип, ул артына борылып карады, ләкин ошбу манзара үзгәрмәде. Әйе, бу кеше иде, аның өендә кунак бар. Ләкин сәер кеше һәм сәер кунак. Егет кунакның кыяфәтеннән бигрәк күзләренә игътибар итәргә өлгерде. Аның күзләре нигәдер дөрес түгел, икесе ике төрле төстә, икесе дә туры карамый, ә төрле якка карый иде. Карашы салкын, битараф, хәер, ул үзе дә нәкъ шундый бер тәмуг кисәве иде.

– Куркыттың, әй! – дип кычкырды аңар Мөхлис. – Кем соң син?

– Кичәге дустың, киңәшчең вә фикердәшең, – диде аңа кунак, тыныч һәм басынкы тавыш белән.

– Кичер, танымадым, – дигән булды егет. (Дөресен әйткәндә, аның бу көтелмәгән кунакны күргәч, коты ботына төшкән иде.) Ике аягы да, паралич суккандай, селкенмәс хәлгә җитте, боз кебек катып калды.

– Кичә син кеше танырлык түгел идең шул! – дип елмайгандай итте кунак, ләкин ул чын, ихластан түгел, ул хасталы кешенең үлем алдыннан якыннары белән хушлашкандагыча моңсу елмаюга охшаш бер нәрсә иде.

– Әйе, кичә бик тә күңелле узды... Кабатланыр микән бу кичә, китмим әле шуны белмичә? Карале, кичә атнаның кайсы көне иде? Җомга түгелме?

Кунак, җомга сүзен ишетүгә, куырылды. Борынгы комод каршында торган имгәк урындыкка, исән-имин сөялеп, егеткә шундук нотация укый башлады. Ул аңа «җомга» сүзен, әлеге изге сүзне башка кулланмаска һәм аны, гомумән, кычкырып әйтмәскә киңәш итте. Кунакның исә иң яраткан һәм иң уңышлы булып саналган көне сишәмбе көн булып чыкты. Чөнки сишәмбе көнне, дини легенда буенча, нниндидер изге пәйгамбәрне җәзалап үтергәннәр...

– Эш-гамәлләремне фәкать сишәмбе көн генә башлыйм, – дип аңлатты ул Мөхлискә, – яңа планнар корам, яңа дуслар белән танышам. Синең белән дә без кичә кич күрештек, чөнки кичә сишәмбе көн иде. Ха-ха-ха!

Кунак кеткелдәп көлде, йөрәкне өшетерлек итеп көлде. «Мин бер нәрсәне беләм, исән калуың белән иң элек син миңа бурычлы!» – дип искәртте ул соңыннан.

– Үлгән булсам, әйбәтрәк тә буласы икән, – дип еламсырады Мөхлис. – Болай да үлем чигендә тора идем бит, үлем белән яшәү арасында...

– Үлем кеше өчен нормаль халәт, ул туугa ук үлүгә таба бара, кеше өчен бәхет – ул үлем, – дигән фикер атты кунак.

Кембридж университетыннан качкан берәр галим кәмәше, философия фәннәре кандидаты яисә профессор түгел микән дигән уйлар да килде Мөхлиснең башына шулчак.

– Философиядә «ман» дигән бер төшенчә бар, немец сүзе ул, – дип дәвам итте кунак, – татарның «моң» сүзе сымак, башка бер телгә дә тәрҗемә ителми. Экзистенциализм юнәлешенең төп төшенчәсе булып санала. Кыстати... Хайдеггер дигән бер җүләр саткан адәм керткән аны. Ман дөньясында яшәүчеләр барысы да бертөрле уйлый, бертөрле хис йөртә һәм бертөрле гамәл кыла һәм, иң аянычы, берәү дә үзенең чын юлын эзләргә теләми. Шул җүләр саткан философның әйтүе буенча, мондый дөнья, мондый халәт кешегә, гомумән, зыян гына китерә, кешелекне югалта һәм ирекне чикли. Шушы читен халәттә ирек яулар өчен, кеше үзен үлем белән яшәү арасына куярга тиеш. Бары тик үлем куркынычын сизгәч кенә, шәхес әнә шул ман халәтеннән котыла, үзен ирекле итеп сизә һәм кылган гамәлләре өчен дөнья каршында җавап тота ала. Синең ыслучайга туры килә бу мисал, дускай, бик туры килә!

– Белмим, – дип шик белдерде егет, – аннан котылу юк сыман...

– Бар! – дип тынычландырды аны кунак.

– Кая? Ничек? Бурычка акча биреп торасың мәллә? – Кунакны шаклар катырып, ул кинәт кенә аның алдына тезләнде. – Бир, үтермә! Бурычымны кайтарырмын! Ай эчендә, ышанасеңме, әтидән булса да алып бирермен! Бир!

– Ноу проблем! – дип кысык кына елмайды кунак. – Бурычыңны кайтармасаң да була...

Кунакның соңгы сүзләре егетнең йөрәгенә май булып ятты. Ул бик дулкынланып, дәртләнеп китте һәм могҗизаи акробатик алымнар ясап, башта җүләрләнеп биергә, соңрак аркасы белән идәнгә ятып, бер кулына таянган хәлдә, зырылдап әйләнергә тотынды. Егетнең зиһене, акылы бөтенләй әзәйде кебек, ә рок-н-роллның тавышы тагын да көчлерәк, зәһәррәк яңгырады. Хәтта бу дөньяда күпне күргән һәм күпне белгән сәер кунак та аның бу шайтани биюенә исе китеп, кызыксынып карап торды. Оста биючегә кул чабып: «Афәрин!» – дип кенә кычкырасы калды. Билгеле, Мөхлисне дә аңларга була, аның бәхете тулып ташыган, көтелмәгән ярдәмгә, изге җанлы кунакка рәхмәтләрен яудырып, сөенеченнән бии иде бит ул! Ләкин изге җанлы кунакның дөньядагы барлык кемсәләргә дә (бигрәк тә сәнгатькәрләр арасында!) хас бер гадәте бар, ул башка кешенең бәхетенә сөенә алмый һәм, гомумән, кемнең дә булса уңышын күтәрә алмый торган иде.

– Тик минем кечкенә генә шартым бар! – Ул тамагын кырып куйды: тавышы калын булып, карлыгып чыкты. Бию бетте, рок-н-ролл сүнде һәм егет тә түнде.

– Нинди шарт, шайтан алгыры?! Бу хәлемдә мин теләсә нинди шартны да үтәргә риза. Әйт, нинди шарт?!

– Син әле генә, әгәр дә миңа акча белән ярдәм итүче табылса, җанымны иблискә сатарга да риза, дип әйттең...

– Мин шулай дип әйттемме? – дип шаяртты Мөхлис. Ул гел шулай, эшнең кая барганын аңласа да, җүләр булып кыланырга ярата иде. Атадан калган хата бу һәм ул аңардан берничек тә азат түгел иде.

– Нәкъ шулай дип әйттең! – Кунак имән бармагын югарыга күтәреп эндәште һәм шуның белән әйткән сүзенең әһәмиятле булуына ишарәләде.

– Ә мин чуты... хәтерләмим, – дип җүләр саттты Мөхлис һәм, нәүмизләнеп, җилкәсен генә җыерды. – Соңгы вакытта мин депрессиядә утырам, бик каты депрессиядә... шуңар күрә ни генә сүләмәм…

– Кыек-мыек сөйләшергә кирәкми! – дип җикеренде шулчак кунак һәм, үз чиратында җенләнеп, урыныннан торып басты. – Җавап бир – әйттеңме-юкмы?

– Минем авыздан чыккан сүзгә ошамаган, Аллам сакласын! – Ни әйтсәң дә, таныш кеше түгел бит, ә андыйлардан сак булырга кирәк.

– Алдашма, егет! – дип кычкырды аңа кунак. – Синең әйткән сүзләреңне бөтен халык, бөтен гавам ишетте! – Егет, кашларын җыерып, җилкәсен генә сикертте, янәсе, нинди халык, нинди кешеләр? – Әнә, кара тәрәзәдән! – дип акырды кунак һәм кулы белән кара пәрдә корылган тәрәзәгә төртеп күрсәтте. Ул төртеп күрсәткән кара пәрдә күз алдыннан каядыр очып юкка чыкты, тәрәзә рамында көн һәм кояш яктысы түгел, ә йолдызлар галәме ачылды: күп иде алар, миллионлаган иде... Галәм иде бу, космик галәм иде. – Әйттеме? – дип кычкырып сөаль куйды кунак йолдызлы галәмгә. «Әйтте, әйтте!» – дип җавап бирде аңар кайтаваз…

«Бетте баш! Кем соң бу? Мин кем белән бәйләндем?!» – дип уйланды Мөхлис. Ләкин аның бу сорауга җавап бирүчесе юк иде шул…

Шулчак күктә юка гына бер якты сызык пәйда булды, ул метеорит койрыгы булып чыкты. Менә ул, тау ташыдай кискен генә аска таба томырылып, атмосферага килеп керде. Коточкыч шартлау тавышы яңгырады. Мөхлис башы белән идәнгә мәтәлде һәм шундук аңын да җуйды...

## 2. ...белән таныша

Егет, аңына килгәндә, карават астында аунап ята иде. Сүндерелми калган супермагнитофон әкрен генә рок-н-ролл уйнап тора, анда «Pockin Pobbin» (Bobby Day) композициясе яңгырый иде.

Гомер юылмаган шакшы идәнгә борынын төртеп, мәтәлеп яткан Мөхлис туктый алмыйча төчкерергә тотынды. Төчкереп туйгач, ул карават астыннан чыкты һәм акрын гына торып басты. Бая гына күргән коточкыч хәлләр, галәмәтләр төшенә генә кергәндер дигән уй белән яшәде ул. Ләкин төтен исенә баткан бүлмә эчендә кабат шул теге сәер кунак күренгәч, Мөхлиснең йөрәге өшеп киткәндәй булды һәм ул әлеге күзгә күренүләрнең төш кенә түгеллеген, ә гап-гади чынбарлык икәнлеген аңлап алды. Хәзер инде туп-туры күзгә-күз карашып, сөйләшеп аңлашуның кирәклеге көн кебек ачык иде...

– Кем соң син? – Мөхлиснең тавышы калтыранып, ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты.

– Иблис.

– Ә мин – Мөхлис.

– Беләм.

– Нишләп соң син иблис, ә?!

– Нишләп син Мөхлис?!

– Да... чынлап та... Нишләп син иблис, ә мин Мөхлис?

– Җавабы гади, – диде кунак, – Мөхлис булган җирдә – иблис, иблис булган җирдә Мөхлис бар.

– Мин Гаян малае, ә син кем малае?

– Наян малае! – дип көлде Иблис.

– Фамилияң?

– Шайтанов.

– Таныш булыйк... Айтуганов...

– Нәрсә, Айтуганов! – дип дәште ул коры гына. – Ризамы минем шартыма? Аңлатыргамы?

– Иптәш Шайтанов, – дип ялварды егет, – син миңа уйларга вакыт бирсәң иде. Мин бик нык уйлап, төпле бер фикергә килергә тиешмен...

– Мин түземле, чөнки беләм үземне! – Кунак китәргә дип урыныннан кузгалды.

– Яратмыйсың... да?!

– Кемне?

– Теге җен саткан фәйләсуфны?! Хайдегеррны?

– Киресенчә, хөрмәт итәм. Ул безнең философ...

Әйе, ул хаклы. Җеннәрнең, шайтаннарның да үз акыл ияләре була. Бөтен дөньяны астын-өскә китергән Адольф Гитлерны гына алыйк. Аның яраткан философы – Ницше. Әлеге фәйләсуфның «өстен кеше» (сверх человек) теориясенә нигезләнеп, Гитлер да үзенең куркыныч тәгълиматын тудырган һәм аны фанатларча тормышка ашырырга тотынган. Шөкер, ахырына тиклем җиткерә алмаган, чөнки җиңелүгә дучар булган, Берлиндагы рейхстаг өстендә Кызыл Совет байрагы җилфердәгән...

Кунак ничек тиз пәйда булса, шулай тиз югалды да. Бу куркыныч адәмнең югалуы аңа әзрәк җиңеллек алып килсә дә, шатланырга иртәрәк иде әле. Мөхлис аның кем икәнлеген әлегә аңлап җиткермәсә дә, аның белән бәйләнешкә кермәскә һәм аңардан ерак торырга кирәклеген күңеле белән сизенә иде. Ләкин сизенү генә аз, үз-үзеңне саклап калу өчен хәзер нәрсә дә булса эшләргә кирәк. «Нишләргә? Теге бандитлар озак көттермәсләр, акча даулап килеп җитәрләр. Килсәләр, эзләп тапсалар, исән калырмын димә, – «хана»! Бәлкем, килмәсләр дә, ә?! Бәлкем, ул алардан котыла да алыр?! Юк, тик торырга ярамый, нидер хәл кылырга кирәк. Әйе, әйе, теге бәдбәхетләр килгәнче, бу каһәр суккан чарлактан чыгып качуың яхшырактыр...»

Мөхлис, бар булган мөлкәтен ялтырап торган крокодил күнле чемоданга тутырып, бүлмәсеннән йөгереп чыкты һәм текә баскыч буйлап аска төшеп китте. Баскыч буйлары бик караңгы, анда урам уты яктысы гына сизелеп тора. Инде тәмам төшеп җитеп, подъезд ишегеннән урам якка сикерәм дигәндә генә, ул кинәт баскыч төбендә абынып егылды. Үзе мәтәлмәде, кемдер аңар аяк чалды. Өстенә кара төстәге күн тужурка кигән бер амбал аны егылган җиреннән тартып торгызып, йодрыгы белән каты итеп эченә сукты. Мөхлис, хәле бетеп, бөгелеп төште, ә чемоданы исә, кулыннан ычкынып китеп, эчендәге әйберләрне, ягъни «эчәгеләрен» як-якка чәчә-чәчә, каядыр бушлыкка мәтәлде...

– Ну, ты чё?! – дип үкерде амбал. – Убежать хотел?!

– Юк... а чё!?

– Гони, давай!

– Нәрсә?

– Бабки!

– Күпме?

– Тысяча баксов!

– Мин сездән биш йөз генә алдым...

– Запомни, урод, если завтра в одиннадцать не принесёшь, то пеняй на себя! Понял, да?!

– Да...

– Чухнул?

– Чу...ха...ны...

– Выбирай выражение, коз-з-зёл!

Амбал инде аңар кул күтәреп азапланмады, эченә генә типте. Тал чыбыгыдай бөгелеп төшкән Мөхлис, авызын ачып, аңар бер сүз дә әйтә алмады – сулышы капты, сеңе катты...

– Ты понял меня, нет?!

– По...нял...

– В одиннадцать, значит...

– Кайда?

– В офисе... адрес... запомни... да... Невский проспект, 66 дом, фирма «Дьяволиада» ...Запомнил?

– Да... а если...

– Ты не жилец! Ищи или займи!

– Каян... алыйм...

– Не понял...

Мөхлис, авыртуга түзә алмыйча, тешен кысып, идәнгә тезләнде. Аннан курка-курка, баскыч тоткасына таянып, акрын гына күтәрелә башлады, ләкин кулы шуып китеп, бөтенләй икенче якка – баскыч кырыена очып төште. Шунда аның кулы бер зур тимер кисәген шәйләп алды, ул төзүчеләр калдырып киткән калын арматура кисәге булып чыкты. Үлем исереклегендә йөргән һәм ахыр чиккә җитеп ярсыган Мөхлис, талпынып, әнә шул арматура белән амбалның муен тамырына тартты. Бар көченә һәм шактый каты итеп! Амбал гөпелдәп авар да акырып егылыр дип көткән Мөхлис ялгышты – әзмәвер (ни гаҗәп!) шундук күз алдында эреп юкка чыкты. Кая китте ул? Исән калса да, яраланса да, нишләп җавап кайтармады, кабат аңар ташланмады? Сизде ул, күңеле белән сизде, аны кыйнаган әзмәвер чын кеше түгел, ул бер кеше рәвешендәге шайтани затка охшаган иде. Табигый заттан барыбер нинди дә булса ис килә: йә тән, йә ислемай исе, йә сарымсак, йә аракы исе. Ләкин аңардан бер төрле дә ис килмәде, кыскасы, аны кыйнаган сәер зат кеше түгел иде булса кирәк. Мөхлис, ирексездән, бая очрашкан сәер кунак турында уйлап куйды, уйлап кына алган иде, ул шундук пәйда да булды. Кунак баскычның өске ягында басып тора иде һәм ул кулы белән ишарә ясап, аны өске катка чакырды...

– Нишләп уйга баттың?

– Уйлыйм, – диде Мөхлис, үзенең мескенлеген һәм чарасызлыгын яшерә алмыйча. – Кайчан килерләр дә, кайчан...

– Уйлау гына аз, дускай, чарасын күрергә кирәк.

– Ярдәм...

– Анысы әйе, хак йөзендә.

– Ә бәлкем син...

– Ни өчен яныңнан китмичә шушында басып тораммы, – диде егетне ярты сүзеннән аңлап торган иблис. – Сиңа ярдәм итү теләге белән янганга күрә...

– Рәхмәт... яхшы сүзең өчен...

– Чын дус һәрчак сүзендә тора, кил, калма караңгыда, мен минем янга!

Мөхлис текә баскычтан бүлмәсенә көч-хәл белән генә менеп җитте. Йә хикмәт! Өстәл өстендә яткан бер күч яшел долларларны күреп, ул бик зур гаҗәпсенү кичерде. Каян килгән бу хәтле акча аңарда?

– Ал! – диде Иблис.

– Нәрсә бу? – дип аңламаган булып кыланды егет.

– Акча танымыйсыңмы?

– Таныйм, тик...

– Сорадың түгелме?

– Минме?

– Юк, күршең! – Шаярткан була тагын!

– Ә... әйе... шу-у-улкадәр күпме?!

– Сораган хәтле...

– Мин сиңа суммасын әйтмәдем бит...

– Күпме кирәген күзеңнән күреп торам...

– Да...

Сөенечен яшерә алмаган Мөхлис шакшы кулын шул яшел күчкә тыкты. Шытырдап торган яшел доллар акчалар аның уч төбен көйдереп, яндырып алды. Менә кайда ул байлык, менә кайда бәхет! Шатлан, сөен, сикереп бие! Ә юк, бу егет бар нәрсәгә ышанучы, һәр нәрсәгә бер сүзсез, бер карусыз риза булучы ахмак кеше түгел, хәйләкәрлек, мәкерлек җитәрлек иде аңарда, шуңар күрә дә ул башта яңа танышын сынап карарга һәм аның белән мөмкин хәтле озаграк уйнарга булды.

– Ә... болар ни...

– Нәрсә?

– Ялган түгел микән, дим... фәл...шивый...

– Ышанмыйсыңмы?!

– Юк, юк, ышанам, мин сиңа чиксез рәхмәтлемен, син миңа зур изгелек кыласың. Шулай да тикшереп карау комачау итмәс иде. Үпкәләмә, алдаучылар күп булды...

– Яхшы! – диде Мөхлиснең шикләнүеннән инде саруы кайный башлаган шайтан. – Тикшер! Тик ничек?

– Аны тикшерүе бик тә җиңел... – Егет бер йөз долларлы банкнотны лампа яктысына китерде. – Анда президентның сурәте булырга тиеш...

– Президентның?

– Америка президентының...

– Бармы?

– Бар, бар! Пеләше дә бар! – диде Мөхлис, долларны бертуктаусыз кулында әйләндереп. – Болай чынга охшаган. Тик менә бер әйбер күңелдә шик тудыра...

– Нәрсә?

– Монда дуңгыз тоягы да күзгә чалына димме...

– Илегез шундый...

Мөхлис шайтанның чираттагы сафсатасын тыңлап, вакыт уздырып торырга теләмәде, аның хәзер үз кайгысы кайгы һәм үз уе уй иде. Ул өстәлдә күче белән яткан яшел долларларны берәм-берәм кесәсенә тутыра башлады, тыйнаклык саклап түгел, билгеле, комсызланып тутырды. Кәгазь акчалар кәчтүм һәм чалбар кесәләренә генә сыймый башлагач, ул аларны күлмәк эченә, корсак астына да тыкты. Ул шул эш белән бик мавыгып китеп, янында басып торган

кунакның барлыгын да онытты һәм инде, эшен бетергәч үк, ишеккә атылды. Иблис кисәк кенә аның юлын кисте...

– Шарт?

– Нәмә әле ул? – дип белмәмешкә сабышты егет.

– Өч тамчы кан.

– Нигә?

– Шартнамәне ныгытыр өчен.

– Өч тамчы... өч тамчы кан, дисең инде...

– Ничек?

– Бирермен, ә нигә бирмәскә! Жалкы мәллә өч тамчы кан?! – дип сөйләнде ул. – Өч тамчы кан нәрсә инде ул?! Мәктәптә укыганда, чирек литр да биргән бар анысы!

– Чирек литр?! – Иблиснең күзе шар булды.

– Ие... мин почётлы донор идем!

– Нигә бирдең?

– Кан бирсәң, ни... өч көн укытмыйлар һәм йөз тәңкә акча бирәләр. Шул йөз тәңкәгә мин өч пицца алып ашый идем, чөнки кан биргәннән соң, шактый хәл китә, организмны көрәйтергә кирәк...

– Чирек литр кан өчен йөз тәңкә акчамы?! Бу бит талау, кычкыртып талау! – дип ярсыды шайтан. Ниһаять, иблиснең дә намусы уянды, империя вазгыяте белән яшәгән, үз халкын үзе җәфалаган мәнсез илгә, тиңсез властька аның ачуы кабарды...

– Нишлисең... иле шундый булгач...

Бәхәс шактый озакка сузылды. Мөхлиснең өч тамчы кан бирергә әзер торганлыгы тәгаенләнгәч, шулчак шактый четерекле мәсьәлә килеп туды: канны ничек алырга? Иблис бу юлы да эшне озакка сузмады, ул каяндыр бер тылсымлы портфель өстерәп чыгарды. Дуңгыз тиресеннән ясалган дүрт кырлы дипломатның ялтырап торган алтынсу төймәсенә басты, футляр шалт-пылт килеп ачылды. Аның эчендә хастаханәләрдә кулланыла торган кан алу приборлары җәйрәп ята иде: шприц, тишкеч, жгут...

Эшнең уңайга барганын сизенгән шайтанның кәефе шактый күтәренке иде. Ул борын астыннан сәер көй көйләп, футлярны күкрәк турына кыскан хәлдә, шатлыгыннан биеп тә алды...

Өч тамчы кан,
өч тамчы кан,
там, там, там...
Өч тамчы кан, кан, кан,
өч тамчы кан,
там!

– Кабереңне! – дип аты-юлы белән сүгенде Мөхлис. – Каян аласың?

– Ничек каян?

– Бармактанмы, венаданмы?

– Каян телисең, шуннан. Әзерме син?

– Мин әзер, – диде коты чыга башлаган егет. – Канны бармактан гына бирергә булдым, ыслушай.

– Нигә?

– Өч тамчы кан өчен вена тиштереп торасым килми...

– Бармактан тек бармактан! – дип хихылдады җен. – Куй бармагыңны!

Мөхлис, нәҗесләнгән өстәл кырына сул терсәген терәп, имән бармагын өскә күтәрде. Ике бармак арасына юка һәм үткен тишкеч кыстырган канәчкеч җен шундук егет каршына килеп басты. Мөхлис, укол ясатудан курыккан сабый бала сымак, чытырдатып күзен йомды...

– Ә спирт?! Мамык?! – дип кычкырды ул, кан алучы җен тишкеч очын аның бармак башына китереп терәгәч. – Стерильныймы?!

– Спирт исен күтәрә алмыйм! – дип мыгырданды шайтан. – Башлыйк!

– Йә Ходам, үзең сакла! – Иблиснең (каушаудан, күрәсең!) кулыннан бармак тишкече төшеп китте. Мөхлис, кешечә кан да ала белмисең, кулыңда җүнләп инструментыңны да тота алмыйсың, дип, ярсып-ярсып, мәлсез шайтанны сүгәргә тотынды. Иблис, аңсызланып, озак кына өнгә килә алмыйча торды, әле телгә килгәч тә, җеннәргә, фәрештәләргә хас булмаганча, шактый тотлыгып сөйләште. Мөхлис тантана итте!

– Ни...

– Ни?

– Зинһар...

– Әйе?

– Зинһар, – дип ялынды шайтан, – минем алда аның исемен искә аласы булма!

– Кемнең?

– Аның? – Кунак бармагын өскә таба күтәрде.

– Аллаһыныңмы?! – дип баш чайкады егет. – Син атеистмы?! Хәер, дөньяда динчеләр ишәйгәч, атеистлары да булмыйча калмас шул. Философия... Закон отрицания отрицаний... Палач син... әйдә... тиш...

Мөхлис сафсата саткан арада шайтан аның бармагына теге тишкечнең башын чәнчергә өлгерде. Мөхлис, авыртудан шашып, акыра-бакыра, урыныннан сикереп торды да җәлладның чак кына ияген сугып ярмады, аның сугарга дип күтәрелгән уң кулы һавада эленеп калды...

– ...бени! Ү-ү-үтерәсең бит!

– Шуңа да түзмәскә! – дип хихылдады шайтан. – Китер бармагыңны! Кан... кан... өч тамчы кан...

Иблис, Мөхлиснең бармак башыннан кысып, берничә тамчы кан сыгып чыгарды. Кан алгач, гадәттә, үтә күренмәле махсус пробиркага җыялар, ләкин җеннәрнең үз фишкасы икән: ул канны бала учына гына сыярлык имән чикләвеге эченә җыйнады. Чикләвек яртылай киселгән һәм аның эчендәге сыекча, әзрәк чайпалтыбрак җибәрсәң, түгелергә дә мөмкин иде. Шуңа күрә аны кунак бик зур саклык белән генә кулында йөртте, чикләвек эчендә чайпалган канга сокланып карап торды, ут яктысыннан качып, аны хәтта иснәп тә, тел очы белән ялап та карады. Бу хәлгә тыныч килеш кенә карап тору мөмкин хәл түгел иде һәм әлеге кыргый процедурадан тәмам гарык булган Мөхлис кан күреп шашкан кунакка үзенең китәсен, бандитлар белән исәп-хисап өзәргә вакыт җиткәнен белгертте...

– Эшнең яртысы гына тәмам, – дип туктатты аны кунак.

– Тагын нәрсә уйлап чыгардың инде?! – дип чиләнде егет.

– Синең белән килешү төзисе бар, кәгазьдә, билгеле...

– Нинди килешү? Шартнамә мәллә?

– Ничек телисең, шулай аңла.

– Тексты нинди булачак? Минем аны язарга башым җитми!

– Утыр өстәл янына, аңлатырмын...

– Мин берни дә аңламыйм...

– Студент! – дип иренен сытты кунак. – Шпаргалка сырлый беләсең, башкага башың җитми. Утыр!

– Утырдым...

– Менә сиңа кәгазь! – Ул Мөхлиснең алдына ике данә чип-чиста ак кәгазь китереп куйды.

– Нишләп ике? Берсе дә җитәр!

– Килешү ике нөсхәдә төзелә. Килешүнең берсе синдә, икенчесе миндә кала. Ферштейн?

– Ферштейн...

– Кулыңа каләм ал!

– Алдым... – Мөхлис кулына каз каурыен хәтерләткән тимер очлы үткен каләм алды. Ул өстәл кырында өелгән тузанлы кәгазь өемнәре астында аунап ята иде. Тик ни белән язарга? Кара савытында караның исе дә калмаган, савыты каткан – коп-коры...

– Яз! Мин әйтеп торам...

– Ни белән языйм? Кара беткән...

– Мә, менә! – Кунак аның алдына кан савытын (сак кына тотып!) китереп куйды. – Менә шуңар манып яз...

– Кангамы?

– Әйе...

– Бу бит минем кан! – дип кычкырды аңар Мөхлис һәм кабат урыныннан сикереп торды. – Үз каным белән үземә үлем карары язарга мин бит сиңа совет солдаты түгел!

– Утыр! Яз! – дип боерды аңа кунак. Аның кычкырып әйткән сүзе шактый үтемле яңгырады һәм аңар буйсынмыйча да мөмкин түгел, һәрхәлдә ситуация шуны таләп итә иде.

– Тыңлыйм... иптәш генерал...

– Дөнья яралганнан бирле иблис кылган явызлыклар, яманлыклар һәм аның гөнаһсыз вә гөнаһлы корбаннары санап бетергесез, ягъни иксез-чиксез, – дип сүз тотты кунак. – Әйтик... тукта! Яздыңмы?

– Юк, өлгермәдем...

– Дөрес, ашыгырга кирәкми. Болай дип яз: «Мин, Гаян улы Мөхлис, каршы яктан зур суммада акча алып тору һәм өч көн рәттән аның фидакарь хезмәтеннән файдалану сәбәпле, һәм дә ки, бу дөньяви яшәешемдә мине фәкыйрьлеккә төшергән дәүләттән, мине дөньяга тудырган атам-анамнан, шулай ук башка изгелекләрдән ваз кичеп, иблис туган, синең кылган яхшы гамәлләреңне истә тотып, сиңа гомерем буе хезмәт итәргә, тулысынча синең карамакка күчәргә, син кушканны гына үтәргә ант итәм...» Яздыңмы?

– Яздым... кебек... тик...

– Нәрсә?

– Текстка төзәтү кертергә кирәк. Ант итәм, дигән сүзне вәгъдә итәм яки вәгъдә бирәм, дигән сүзгә алыштырып булмас микән?

– Нишләп?

– Туган илең яки атаң-анаң алдында гына ант бирергә була.

– Исеңдә тот...

– Әйе?

– Синең хәзер атаң-анаң да, туган илең дә мин. Аңладың?

– Аңладым...

– Булдымы?

– Юк, булмады... уф...

– Яз! «Шушы килешүнең төп кагыйдәләрен исбатлау нигезеннән, каршы як куйган шартларны кабул итү йөзеннән һәм дә сиңа, иблис туган, җанымны бирү ниятеннән шушы шартнамәгә кулымны куям...» Яздыңмы?

– Яздым...

– Кулыңны куй!

– Куйдым...

– Ничек?

– Мөхлис дип куйдым... Айтуганов...

– Яхшы. Шартнамә булгач, шартнамә булсын. Мин болай дип яздым, тыңла...

– Тыңлыйм...

– «Мин, Иблис, Мөхлис әфәнденең килешүен раслап, аңа өч көн, өч төн рәттән хезмәт итеп, аның бар булган икътисади вә әхлакый ихтыяҗларын үтәргә сүз биреп, ошбу кулымны куям. Иблис». Булды.

– Өч көн? Ә өч көннән соң нәрсә?

– Өч көннән соң, шартнамә буенча, син тулысынча минеке буласың, мин синең белән нәрсә телим, шуны эшләргә хаклы булам.

– Өч көн? Бик аз түгелме соң?!

– Белмим, әйтә алмыйм, – дип хәйләле елмайды кунак. – Килешү төзелгән, куллар куелган. Килешүнең берсе синдә, икенчесе миндә кала...

Иблис (кайчан язарга өлгергән диген!) аның алдына үз кулы белән язган шартнамәнең бер нөсхәсен китереп салды. Язылган текст астында шайтанның буталчык кулы куелган һәм дә ки законлы мөһере дә сугылган. Мөһер нигәдер икесе ике якка тырпаеп торган дуңгыз тоягын хәтерләтә иде. Мөхлиснең бу турыда хәзер тавыш чыгарып, сүз кузгатып торасы килмәде, билгеле. Күктән төшкән бәхетенә чиксез сөенгән, канатланган егет, акчаларны эләктереп, үзе әйтмешли, «гулянка»га чыгып чапты, ә гыйш-гыйшрәт (вампирлар бәйрәме) алдыннан берике яшь баланың башына җитеп, шуларның йөрәк майлары белән сыйланасына өметләнгән Иблис галиҗанәпләре исә чарлакта бер ялгызы гына утырып калды...

Тик ул ялгызлык озакка сузылмады.

## 3. Варвара һәм гөберле бака койрыгы

Чарлакка бер марҗа хатыны килеп керде. Керде дип әйтү дөрес булмас, өстерәлеп менде, икенче каттан. Җен урынына симергән һәм шуның нәтиҗәсендә шактый юанайган, бар җирен май баскан марҗа текә баскычтан, тирләп-пешеп, көч-хәл белән генә күтәрелде. Ул керүгә үк, чарлакны тынчу тән исе, кеше исе камап алды. Дөньядагы барлык исләрдән мәгълүм булган шайтан да, бу ят истән тәмам буыла язып, борынын өч бармаклы учы белән кысарга мәҗбүр булды. Марҗа Варвара исемле урта яшьтәге бер хатын иде. Ул кайчандыр химзаводта хезмәт иткән, болганчык еллар башлангач, заводтан китеп, вак-төяк сату эшенә күчкән. Ул вокзал каршында бәлеш яисә мантый, йә берәр урам кырында арзан ювелир әйберләре, ваклап кием-салымнар сата торган иде. Бүген исә сәүдә эше начар барды. Кеше берни дә алмый. Юеш салкында өшеп, җанын шайтанга сатырга әзер торган марҗага Мөхлис яшәп яткан йорт каршында гына әнә шушы ир заты очрады. Тормыштан зарланып торган марҗага иблис заты, әллә кызганып, әллә мыскыл итеп, кат-кат төрелгән бер кәгазь төргәк тоттырып

калдырды һәм соңыннан: «Байыйсың килсә, менә шушы төргәкне каты итеп селке, селкегән саен шуннан акча коелыр!» – дип әйтеп-аңлатып китте. Чынлап та, төргәкне селкегән саен учка акча коелды, шактый күп җыйналды, бу марҗа шатлыгыннан айга менәрдәй булды. Ләкин кызыксыну хисе нигәдер учка коелган акчадан, ягъни хөсетлектән өстенрәк булып чыкты. Ә мосафир ир аңар: «Тик бер шарты бар: төргәкне сүтеп, ачып карый күрмә!» – дип атап әйткән иде. Юк, түзмәде, сүтте, ачты! Җү-ү-үләр! Сүтеп ачса! – акча урынына аннан ниндидер килбәтсез нәрсәләр – бака койрыгы, эт, мәче һәм аю тырнаклары коелды. Хикмәт шунда: алдан алган акчалар да каядыр эзсез югалдылар. Шундый мыскыллы хәлгә калган марҗа хатыны, бу хикмәтне аңларга теләп, ошбу йортка әлеге дә баягы шул каһәр суккан мосафирны эзләп кергән иде...

– Ә! Менә кайда син! – дип кычкырды ул, караңгыда эзләгән кешесен шәйләп алгач. – Дөрес килгәнмен икән! Синең монда кергәнеңне күреп калдым...

– Сез кем? – дип, коры гына каршы алдылар аны.

– Танымаган булып кыланма, сатучы апаң мин... Варвара... Фонтанкада киемнәр сатам...

– Таныдым, ни йомыш? – Шул минутта ук Варвара аңа барысын да сөйләп бирде.

– Мин сиңа нәрсә дидем?

– Төргәкне ачма, сүтмә, дидең...

– Ачасың юк иде, үзең гаепле.

– Ачтым шул...

– Шуның белән син килешүнең шартын бозгансың...

Марҗа кычкырып еларга тотынды. Алар шулай инде, марҗалар, еласалар, гел кычкырып елыйлар! Аны кабат кызганырлар да кабат акчалы төргәк китереп тоттырырлар дип уйлаган марҗа тагын ялгышты, бу юлы аңардан рәхәтләнеп, шаркылдап көлделәр генә...

– Карале, энем, тагын шуны кабатлап булмыймы? – дип үтенде аңардан хатын. – Биреп кара миңа тагын бер шанс, чынлап әйтәм, ачып карамас идем бүтән... Ярдәм ит! Өйдә өч укучы балам, гарип ирем ята... урында...

– Яхшы...

– Ай, рәхмәт яугыры! – дип сөенде марҗа. – Әйдә, яса тагын бер кат төргәгеңне, яса!

– Сабыр...

– Әйе?!

– Сине башкача сынап карарга булдым, – дип, кабат кармагын салып, ятьмәсен үрде шайтан. – Син кием-салым гына түгел, көмешкә дә сатасың бугай әле?

– Каян белдең?

– Анысы мөһим түгел. Табыш керәме көмешкәңнән?

– Так кына инде! – дип кул селтәде бичә.

– Мин сиңа шундый бер порошок бирермен, шуны кушсаң, көмешкәңнең күләме бермә-бер артыр, ә градусы беркайчан да кимемәс.

– Кая, бир!

– Мә! – Иблис марҗага ак төстәге порошок төрелгән бер чеметем кәгазь кисәге чыгарып тоттырды. Марҗа, аның белән нишләргә белмичә, кәгазь чатыннан коелгалап торган шул ак порошокны иснәп карады һәм ләчкелдәп төчкерергә тотынды. Төчкергәндә исә ул каты итеп төкерекләрен чәчте һәм аның көмешсу төчкерекләре шайтанның аксыл чыраена сибелде. Иблис чырайсыз калды.

Шулчак «авторежим»да торган магнитофон, бар көченә акырып, рок-н-ролл чәчәргә тотынды, аның да әле иң җитезен һәм дә иң кәттәсен – Jaihouse Rock (Elwis Presley)! Порошок иснәү нәтиҗәсендә шактый хушланып, дәртләнеп киткән хатын, чарлакның сынык идәннәренә каты итеп баса-баса, гаҗәеп рәвештә биеп китте. Бер центнерлы гәүдәнең биюеннән бөтен чарлак дер селкенде. Урындык-өстәлләр, карават-тумбочкалар һәм хәтта түшәмдәге абажур марҗага кушылып биегәндәй тоелды, өстәл өстендә яткан киң аш тәлинкәсе исә, атылып китеп, шайтанның баш очыннан очып узды. Аннан ул диварга бәрелеп чәлпәрәмә килде. Марҗа хатын туктый алмыйча биеде. Ул чарасыз иде. Иблис (мыскыл итәргә аны куш!), көлә-көлә, кул чабып торды. Нәкъ менә шулвакыт Мөхлис яшәгән чарлакка Татарстан җөмһүриятеннән Гаян белән Фәния килеп төштеләр. Гаян Мөхлиснең үз әтисе, ә бичә аның яңа гына өйләнгән яшь хатыны иде.

Музыка бертуктаусыз үкерде. Бәхетсез марҗа, тыпыр-тыпыр килеп, каядыр юкка да чыкты...

## 4. Гаян гаҗәеп ачыш ясый

Гаян илле яшен тутырып килгән, озын, төз гәүдәле (фитнес клубтан башы чыкмый!), ак чырайлы, кара көдрә чәчле, заманча уйларга һәм яшәргә күнеккән күренекле бер ир заты иде. Акчалы, тормышы җитеш, Бөгелмә шәһәрендә банк филиалын җитәкли. Туган шәһәрендә аның йөз дә илле квадрат метрлы өч катлы кирпеч ташпулаты, үзәктә заманча җиһазланган өч бүлмәле зур фатиры бар, ә ике яруслы гаражында өч яхшы чит ил машинасы тора. Акчалы, бай кеше булса да, ул тормышта үзен тыйнак тота, бер дә юкка шапырынып йөрергә яратмый иде. Сак һәм шуның өстенә астыртын кеше иде ул. Шактый еллар бергә гомер иткән хатыны Гадилә үлеп киткәч, ул бер елдан соң Фәния исемле яшь һәм чибәр кызга өйләнде. Рәсми төстә түгел, әлегә никах белән генә яшиләр. Кызның паспортына язылышу мөһерен суктырудан курыкты банкир, чөнки хәзер яшь кызларга бик ышанып бетеп тә булмый, аерылышып, байлык бүлешеп, соңыннан адәм хурлыгына калдырырга да мөмкиннәр. Ул булачак хатыны белән фитнес клубта, тренажёрда мускулларын ныгыткан чакта танышты. Кызның акылына да, зиһененә дә кызыкмады, иң элек ул аның сылу тәненә, матур фигурасына, яшьлегенә кызыкты. Акыл ягыннан аның элеккеге хатыны һәрчак югары булды, алар бергә (Гадилә үлгәнче!) бер банкта эшләделәр. Табигате белән кызу канлы, тиз үпкәләүчән, югары амбицияле Гаянны Гадилә яшьтән үк гел куктән җиргә төшерә торды. Ирне, кеше буларак, хатыны тәрбияләде дисәк тә ялгыш булмас. Шуңар күрә дә ул хатынын, бик алай үлеп-бетеп яратмаса да, һәрвакыт хөрмәт итте. Бүгенге көндә Гаян ирешкән дәрәҗәдә, Гаян туплаган байлыкта исә мәрхүмәнең өлеше әйтеп бетергесез иде.

Мөхлис Гаянның бердәнбер улы һәм ышанычы иде. Анасы улын бик нык яратты. Баласын иркәләп-назлап, гел аның җаена гына торды. Ананың артык йомшаклыгы, бала нәрсә теләсә, шуны үтәргә тырышуы, баланың холкын шактый бозды булса кирәк, ул тора-бара, әзергә бәзер генә яшәүче «барчук»ка, ягъни иркә угланга әйләнде. Баланы артык яратырга ярамый, яратсаң да, яратуыңны бик сиздермәскә, аңа мөстәкыйльлек бирергә кирәк. Гаян да бердәнбер улының бәйсез булуын, бай атасына гына ышанмыйча, үз проблемаларын үзе хәл итәрлек чын ир-егет булып үсүен теләде. Шуңа күрә дә ул аны артык иркәләп ятмады, анасы үлгәч, Санкт-Петербургка престижлы

югары уку йортына укырга җибәрде. Кертте, өч бүлмәле яхшы фатирда урнаштырып калдырды. Яшүсмерне тәрбияләүдә ул американнар ысулын кулланырга теләде. Янәмәсе, бала үсте, ул инде ата-анасыннан, нинди генә бай булсалар да, көтеп ятарга түгел, ә үз юлын үзе табарга тиеш. Ләкин яшьтән үк анасы тарафыннан иркәләп үстерелгән бала укуга, белем алуга битараф калган һәм хәтта семестрларын да япмаган. Дус ахирләре белән шау-шулы күңел ачулар оештырып яткан Мөхлисне, ай-ваена да карамыйча, атасы урнаштырып киткән фатирдан куып ук чыгарганнар һәм ул бичара менә шушында, шушы караңгы чарлакка, җеннәр оясына килеп елышкан. Бу чарлакның адресын аңар деканатта очраклы рәвештә генә таптылар...

Улының шушы тәмуг оясында көн күреп ятканына бик нык рәнҗеде Гаян. Аның хәтта күзеннән яшьләр килде, йөрәге әрнеде, сулышы кысты. Җитмәсә, үзе әнә өйдә дә юк, аның урынында нindidер кеше белән исәнләшә дә белми торган бер сәер кунак утыра. Әрсез, салкын күз карашы һаман да яшь хатында булды һәм шуның белән ул болай да үз-үзен кая куярга белмәгән Гаянның нәфрәтен генә уятты...

– Хатыныгыз шундый яшь...

– Әйе, – дип тупас кына эндәште Гаян. – Мөхлис шушында торадыр бит?

– Шушында.

– Кая соң ул?

– Тиздән кайтыр дип өметләник.

– Сез кем буласыз?

– Аның дусты. Евгений Ваганович.

– Узарга ярыймы? – Ләкин узыгыз, дип тә әйтүче булмады. Улы аркасында ерак юллар аша газап чигеп килгән ир белән хатын, бер мескен кешеләр сымак, ишек катында басып калдылар...

– Ул сезнең килүегезгә ышанмый.

– Ә без менә килдек әле, – дип йомшарды Гаян, аңар хәзер, ничек тә булса, килеп туган киеренке хәлдән чыгарга кирәк иде. – Мин – банкир, бер айга ял алдым. Билгеле, ял йортына барырга да мөмкинлек бар иде, әйтик, Таиландка, Карловы Варыга, ә без менә, хатын белән уйлаштык та, Питерга, улыбыз янына килергә булдык. Бер очтан Эрмитажны, Пушкин музеен, Петропавловск крепостен да карап кайтырга уйладык... Ие... тәк... ярар, болай бусагада басып торып булмас, эчкә узыйк! Фәния, чәй көйләп җибәр, күчтәнәчләрне чыгар... әйдә... Малай кайтып җиткәнче, табын әзерләп, капкалап алыйк...

Фәния, көзге каршына басып, башта үзен көйләгәндәй итте – чәчләрен тарады, өсте-өстенә кершән сылады. Аннан, чыраен ертып, иске чүпрәк белән шакшы өстәл өстен сөртте. Килгән күчтәнәчләр берәм-берәм өстәлдә үз урынын алды. Хатын электр чәйнегендә су яңартып, чәйнең яңасын куеп җибәрде, ул чыж-пыж килеп, әкрен генә кайнарга тотынды...

– Мөхлис авырмый торгандыр бит? Укыйдыр? – дип сорады Гаян.

– Укый...

– Лекцияләргә йөри инде?

– Йөри... – Иблиснең бу коры сүзләрендә киная шактый җитәрлек иде, билгеле.

– Евгений Ваганович!

– Әйе? – Гаян иблисне Фәниясе маташкан табын яныннан әзрәк читкәрәк алып китте.

– Сүзем улым Мөхлис турында, билгеле. Бар курыкканым шул: акылына

зәгыйфьлек килмәсен дим, якын кешем буларак, улым өчен борчылам. Соңгы ике-өч ай эчендә аның белән бөтенләй арабыз суынды...

– Аның телефонын урладылар...

– Исән микән инде? Кая йөри? Евгений Ваганович, сез мине аңлагыз, ул бит минем бердәнбер якын кешем, газиз балам. Аның да миннән башка якын кешесе юк...

– Анасы вафат, шулаймы?

– Каян беләсез? Ә... әйе... Аңлыйм... Мөхлис әйткәндер инде...

– Беренче хатыныгыз Гадилә моннан өч ел элек кенә вафат булган.

– Әйе... Авыр туфрагы җиңел булсын. Хатынымны бик нык ярата һәм хөрмәт итә идем. Нишлисең бит, язмыштан узмыш юк, диләрме әле?!

– Тик ятмыйсыз...

– Аңламадым?

– Яшь хатын алгансыз.

– Әйе, – диде Гаян, берникадәр уңайсызлану һәм шул ук вакытта горурлык хисе дә кичереп. – Улымнан биш яшькә генә олы.

– Бәхетле кеше!

– Әйе, мин хатыннардан уңдым.

– Хатыныгыз төшегезгә кермиме?

– Керә, еш керә... Ә нәрсә?

– Беләсезме, – дип серле генә эндәште шайтани зат, – мин, сез уйлаганча, гади кеше түгел, мин – парапсихолог, маг, күрәзәче. Сезнең өчен яңалык әйтә алам...

– Нинди? – Алар инде, сөйләшә-сөйләшә, Фәния чәй пешереп маташкан табын каршына килеп үк басканнар иде.

– Сезнең беренче хатыныгыз Гадилә исән.

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәниянең кулыннан чәшкәсе төшеп китте, ул бик нык аптырап, бер иренә, бер Иблискә карап катты. Гаян, хатынын шушы чарлакка алып керүгә үк, бер сәер нәрсә сизенде: Фәния Евгений Вагановичтан һич кенә дә күзен ала алмады, аларның күз карашлары бер-берсенә берегеп каткан кебек тоелды. Яшь хатынының чит ирләргә битараф булмаганын белгән Гаян бу юлы тагын аптырашта калды. Евгений Ваганович карап торырга күренекле кеше булса да, инде шулхәтле күз төшәрлек, үзенә бер күрүдә үк гашыйк итәрлек ир заты түгел иде кебек. Сыек чырайлы, салкын канлы һәм үзеннән йөз чөерә торганрак адәм иде ул. Шулай да...

– Исән?! – дип кычкырды Гаян.

– Мөхлиснең анасы Гадилә ханым исән.

Ир белән хатын аптырашта калды. Гаян шуны аңлады: Гадиләнең исән булуы турындагы хәбәр Евгений Вагановичның авызыннан фәкать Фәнияне котыртыр өчен генә яңгырады кебек. Һәрхәлдә, аңар шулай тоелды. Билгеле ки, Фәния котырмады, ләкин күңеленә шик корты бәреп керде.

– Гаян! – диде аңа хатын, – син миңа әлегә кадәр хатыным үлде, дип әйтә килдең! Ялганладыңмы? Кая ул, әйт миңа дөресен?

– Сез нәрсә! – дип чәчрәде ир. – Гадиләм минем күз алдымда үлде. Мин аны үз кулларым белән җирләдем, ул бит...

– Сез үлемнән куркасызмы? – дип, кинәт кенә сүзне икенчегә борды иблис.

– Курка идем, – диде ир, – ә хәзер юк, курыкмыйм...

– Нишләп?

– Барыбызга да шунда китәсе...

– Табышмак...

– Әйе, табышмак, – дип алып китте ир. – Бу дөньяда ике зур табышмак бар: кеше үзенең ничек туганын хәтерләми һәм кайчан үләчәген белми...

Хикмәт монда Гаянның үлемнән курку-курыкмавы түгел иде, билгеле, Гаян яшьтән үк сәламәт булмады, бөер авыруы белән интекте һәм ул гомере буе вакытсыз үлүдән куркып яшәде. Хатыны үлгәч, ул берникадәр дингә бирелде. Көнгә биш мәртәбә намаз укымаса да, җомга намазларын үтәп, сәдака бирмичә калмый иде. Ул шулай итеп күңеленә тынычлык тапты, үлем турындагы сагышлы уйларын каядыр еракка, читкәрәк этәрә алды...

– Хатыным Гадилә турында сез шаярттыгыз гына, шулай бит?! – дип сорап куйды аңардан Гаян.

– Шаярттым, – дип төче елмайды иблис һәм серле генә тынып калды...

Фәния аларны табын артына чакырды. Утырыштылар. Ханым башлары кителгән ике шыксыз бокалга чәй ясап, шуларны ирләрнең каршысына китереп куйды. Гаян бик тәмләп чәй эчәргә тотынды, ләкин кунак чәйгә кагылмады.

– Евгений Ваганыч, әйдәгез, авыз итегез! Монда менә казылык та бар, Бөгелмәдән алып килдек! – дип кыстады аны бер катлы хатын.

– Аппетит качты, – диде иблис.

– Үлем турында уйлыйсыз, димәк, шуңар кәефегез дә юк?! – дип төрттерде Гаян.

– Ә сез юкка газапланасыз, – дип телләнде Фәния ханым. – Әтием әйтә торган иде, кызым, үлем турында уйларга ярамый, уйлаган саен, ул якыная гына, дип... Аңардан бик куркырга да кирәкми, үлем ул бары тик караңгылык кына, шулай бит?!

– Юк, матурым, син дөрес уйламыйсың, – дип бүлде аны ире. – Үлем ул яшәү дигән сүз. Кеше көнгә бер генә мәртәбә булса да үлем турында уйларга тиеш. Уйлый икән, димәк, ул – кеше, димәк, ул яши...

– Фәлсәфә коруы җиңел, – дип астыртын гына елмайды кунак. – Үлем якаңнан тотып алса, бөтенләй икенче төрле сайрый башлыйсың. Юк! Үлемнән куркырга кирәк, курку хисе – иң бөек вә иң олуг хисләрнең берсе ул. Ха-ха-ха!

Иблиснең шулай кинәттән генә көлеп җибәрә торган гадәте бар иде. Ул бу юлы иң арттагы теш казналарына хәтле күрсәтеп көлде. Аның бу хайвани көлүе өйдәгеләрне тетрәндерде. Җан түренә тоташ шом бәреп кергән Гаянның маңгаена тир бәреп чыкты...

– Мисал, – дип мәкерле уйларын уйнатып алды иблис. – Әйтик, сезнең улыгыз тиктомалдан гына сезгә мылтыктан атса, ягъни мәсәлән, сезне үтерергә җыенса...

– Улым? Минеме? – дип, бик нык гаҗәпсенде ата кеше.

– Улыгыз!

– Бу мөмкин хәл түгел!

– Сез аны изге җан иясе дип уйлыйсызмы?

– Белмим, әйтә алмыйм, тик шуны яхшы беләм: минем улым беркайчан да андый коточкыч һәм мәгънәсез җинаятькә бармас!

– Тормышта моңа мисаллар күп: атасы – улын, улы атасын үтергән очраклар шактый. Адым саен...

– Тик минем улым...

– Улыгыз сезнең теләсә нинди явызлык кылырга әзер. Явызлык дөньясына тәүге адымын ясарга өлгерде инде...

– Булмас! Булмас гамәл бу! Сез кем соң?!

Алар, күңел кызулыгы белән, икесе дә берьюлы торып бастылар, менә күз

карашлары очрашты. Гаян имәнеп китте: аның каршында җан һәм тән җылысы саркып торган адәми зат түгел, ә ниндидер бер үзгә зат, иссез-төссез җансыз курчак басып тора иде.

– Кем... сез?

– Явызлык вә яманлык илчесе.

Шулчак Гаян иблиснең аягына күз төшерде. Ялтыравыклы ботинканың баш-башлары ярылып, ачылып киткән һәм аннан дуңгыз тояклары күренеп тора иде...

– Фәния! Укы! Укы белгәнеңне! – дип кычкырды ул бар көченә. Ир һәм хатын, бер-берсе белән ярышкандай, бар белгән сүрәләрне укырга керештеләр. Үзен Мөхлиснең дусты дип таныткан һәм Евгений Ваганович дип таныштырган шайтани зат кинәт, зилзилә сымак, бөтерелергә, зырылдап әйләнергә тотынды. Үкерде, акырды, чинады (рок-н-роллның куркыныч дәвамы иде бу!)...

– О-о-о! Ухү-ху! Ха-ха-ха! У-ху!

Бу шайтани биюдән, иләмсез көлүдән өй ду купты, чарлакның тәрәзәсе ачылып китте, черек рамнары дер селкенде. Тирә-якка төрле төстәге зәһәр утлар чәчрәде, кыска ялганышка дучар булган абажур, вак-вак очкыннар чәчкәләп, гөпелдәп сүнде. Иблис югалды – очып юкка чыкты, чарлак эче күз күрмәслек тирән караңгылыкка чумды...

## 5. Ата һәм бала

Мөхлис төнге бердә генә кайтып керде.

Бүлмәдә тыныч, салмак блюз уйнап тора. Җылы юрганга төренеп, караваt кырыена авышкан, ерак юллар үтеп, бик нык арыган Фәния шундук йокыга киткән иде. Гаянны йокы алмады, ул ике кулын аркасына чалыштырып, бертуктаусыз бүлмә буенча йөренде һәм кайчан да булса улы кайтып керер дип көтте.

Мөхлис (күрәсең, күңелле мәҗлестә булган!) кызмача кыяфәттә иде. Малай шактый суырылган, яңаклары эчкә баткан, хәлсезләнгән, йончыган иде. Ул улын танымыйча торды. Ләкин бала да атасының килүенә бик исе китмәде, хисләнмичә, салкын гына күреште. Әйе, бу бала чын-чынлап юлдан яза башлаган иде...

– Килдеңме?

– Килдем, улым, сине күрергә дип килдем...

– Иртәрәк килергә иде...

– Нишләп?

– Соңга калмадың микән...

Атасы баласының соңгы сүзләрен аңлап бетермәде, җылы урында рәхәтләнеп черем итеп яткан хатынын уятмас өчен, ул улын читкәрәк алып китте һәм алар, этелә-төртелә, балконга чыктылар. Монда һава да җиңелрәк, дөньясы да киңрәк булып тоелды.

– Атаңны оныттың, улым, акча кирәк чакта гына искә төшерәсең, – дип шелтә белдерде ул улына.

– Акча бар ла, кесә тулы! – Гаян мондый туры җавапка бик нык гаҗәпсенде. Чөнки улы, килүгә үк, аңардан акча сорап интектерер дип көткән иде. Шуңа күрә дә ул аңа дигән тиешле сумманы әзерләп, аерып куйган иде. Ә малай әнә ничек сөйләнә! Миллионермыни?!

– Каян килеп?

– Сэкономил...

– Ничек?

– Супермаркетта йөкче булып йөрдем...

Җиңел эштә генә сикереп йөрергә яраткан улының ниндидер супермаркетта йөк ташып йөрүенә ышанырлык түгел иде, әлбәттә. Нәрсәдер яшерә иде улы аңардан. Йә ул начар компаниягә ияргән, йә бик күп акча оттырган, йә тагын башка нәрсәдер шунда... Йә инде (бусы иң аянычы!)... җанын шайтанга саткан...

Гаян күңел түрендә кайнаган уйларын улына да җиткерде.

– Каян чыгып әйтәсең? – дип сорады улы аңардан.

– Төсеңә чыккан!

– Чыгып нишләгән?

– Чыраеңда иблис чалымнарын күрәм, күз карашың кеше куркытырлык...

– Каян? Ничек күрәсең син аны?

– Теләсәң, санап китә алам...

– Нәрсәне?

– Ислам динен үз итә башлагач, улым, – дип дәвам итте атасы, – мин демонология, ягъни мәсәлән, иблисиада фәне белән кызыксына башладым. Аны фән дип тә әйтеп булмый, кәнишне, фәннең бер тармагы дияргә була. Анда шайтан коткысына бирелгән адәмнең яшәү рәвеше унбер төрле пункт аша билгеләнә. Аның барысын да истә калдырып булмый, шуңа күрә дә мин аны иблисиада китабыннан, студентлар сымак, конспект рәвешендә күчереп алдым. Кызыкмы сиңа, укыйсыңмы? – Мөхлис, белмим дигәндәй, җилкәсен генә җыерды.

Гаян кесәсеннән өчкә бөкләнгән кәгазь кисәге чыгарды һәм шуны Мөхлискә сузды. Төн, караңгы... Тик ни хикмәт, кәгазьдә язылган җөмләләр җен күзе кебек ялтырап тора һәм аларны, бер дә төртелмичә, рәхәтләнеп укырга була. Иблис коткысына бирелгән адәми зат әлеге кәгазьдә болай дип шәрехләнгән иде:

1. Иблискә (шайтан) сатылганын кеше үзе үк дәлилләсә, ягъни инкарь итмәсә.

2. Бозык тормыш алып барса.

3. Ялгыз яшәсә һәм кешеләрдән качса.

4. Йокысызлыктан интексә, зыяндаш авыруы (припадок) белән авырса яки ашамыйча косса.

5. Һәр сүзендә иблисне искә алса һәм Ходайга тел тидерсә.

6. Иблис белән килешү төзесә.

7. Явыз рухлар газапласа.

8. Чыраенда кешеләрне куркытырлык билгеләр пәйда булса.

9. Өметсезлеккә бирелгәндә, күңелсезлектән, җан бушлыгыннан зарланса.

10. Сугышса, талашса һәм дә ки чыгырыннан чыкса.

11. Кыргый җәнлек, кош яки ерткыч булып тавыш бирсә, акырса һәм бакырса...

Мөхлис бу конспектны бик теләмичә, үз-үзен көчләп кенә укыды. Атасы аңа бу опусны махсус китереп тыкканын һәм укытканын сизенде ул...

– Әти, мин сине танымыйм, чамасыз динле кеше булып киткәнсең димме...

– Әйе, улым, синең атаң кайчандыр атеист иде, ә хәзер мин Ходайның барлыгын таныйм, мәчеткә йөрим...

– Модамы?

– Юк, мода түгел, бу – күңел таләбе. Коръәни Кәримне өйрәнеп, мин бу дөньяның, яшәешнең серенә төшенә башладым. Ә менә синең өчен мин бик каты борчылам, улым...

– Нигә?

– Сине юлдан яздырганнар...
– Каян чыгып шундый нәтиҗә ясадың?
– Менә син миңа карап торасың име, ә күзләрең туры карамый. Бер мәртәбә булса да син үзеңә көзгедән күз салганың бармы? Синең йөзеңә карарга да куркыныч бит, улым, шайтан чырае бит үзеңдә...
Мөхлис аңар каршы бер сүз дә дәшмәде. Атасы хаклы иде. Ләкин аның хаклыгыннан Мөхлискә бер дә рәхәт түгел, әле аның иблис белән килешү төзегәнлеге дә ачылса, сөйләшү бик каты булачак монда, әйтте диярсез!
– Евгений Ваганович кем ул?
– Нинди Евгений Ва...
– Без килгәндә, ул синең бүлмәңдә утыра иде.
– Кая соң ул?
– Каян белим. Тузга язмаган сүзләр сөйләде дә чыгып качты. Качты дип кенә әйтеп булмый, очты! Аңламадым, кеше булды микән ул?
– Белмим...
– Кем иде ул? Дустыңмы?
– Шайтан белсен...
– Әниеңне үлмәгән, ул әле дә исән, ди. Безне үлем белән куркыта, туктаусыз сине яманлый. Котырта безне. Дус, имеш! Кем ул?
– Шайтан белсен дим бит!
– Син нидер яшерәсең миннән, улым, әйт, сөйлә барсын да, аңларга тырышырмын...
– Синнән берни дә яшергәнем юк! – дип котырынды Мөхлис. – Бәйләнмә миңа! Тимә дустыма! Минем коткаручым ул!
– Коткаручың?!
– Әйе, ул – маг, ул – күрәзәче! Мин аңа гына табынам! Бары тик аңа гына! Ишеттеңме!?
Гаян улын кабат танымый торды. Табигате белән йомшак холыклы, яхшы күңелле булган улының шулай бер сәбәпсезгә котырынуы, кисәк кенә алышынуы, ярсып җикеренүе атасының күңеленә кереп оялаган шикләрен тагын да көчәйтте генә кебек...
– Сүзләреңдә шайтан каһәре яңгырый, күзләреңдә иблис уты ялтырый! Ни булды сиңа, улым? Әйт, сөйлә! Бәлкем, аңлашырбыз...
– Җитте! Тимә миңа! Калдыр безне, калдыр!
Җен урынына котырган Мөхлис кинәт кенә балкон кырына менеп басты һәм кулларын җәеп, парашютчы сыман, аска сикерде...
– Улым!!!
Өч катлы йортның чарлагыннан сикерү шактый хәтәр нәрсә, билгеле, ләкин җен көченә ия булган егеткә, үзе әйтмешли, «чуртым» да булмады. Җиргә очып төшүгә үк, ул, ут капкан кеше сымак, урам аша йөгереп чыкты. Гаян улын багана башыннан төшеп торган фонарь яктысында гына күреп калды...
Коточкыч төн иде бу. Балкон астында кемдер бик каты шаркылдап көлде, шомлы һәм шактый ямьсез итеп көлде...

## 6. Шайтан коткысы дәвам итә

Бу күңелсез инциденттан онытылып, әзрәк ял итеп алу өчен, Гаян һәм аның яшь хатыны бер көнгә Царское Селога, Әби патшаның аппартаментларын карарга киттеләр. Бандитлар белән арасын өзгән, картада откан бурычларын

кайтарып бетергән, кесә тулы акчасы белән масаеп йөргән Мөхлис кабат күңел ачарга карар кылды: ул чарлагына кунак кызлар алып кайтты. Студент кызларның берсе – Ольга, ә икенчесе Зина исемле иде. Өстәл өсте затлы шампан шәрабы, элитный кибетләрдә генә сатыла торган тәм-томнар белән тулды. Мөхлис, кызларның икесен берьюлы кочаклаган хәлдә, алар алдында мактанып, иләсләнеп утырды. Эчү-шаяруның очы-кырые булмады һәм, билгеле, магнитофонда бертуктаусыз рок-н-ролл уйнап торды. Бер җырны өч-дүрт мәртәбә кабатлап куйдылар, рэп һәм попса белән җенләнгән, рок-н-роллны бигүк яратып бетермәгән яшь, кыланчык кызларга бигрәк тә Elvis Precley, The Beatles һәм Carl Perkins композицияләре ошады. Дисктагы 66 һәм 99 нчы номерлы композицияләрне, ягъни «Blue Suede Shoes» (C.Perkins) һәм «Honey Bee» (Stevie Ray Vaughan)ны, кат-кат куеп, тыңлап туйганчы уйнаттылар...

– Ә син чынлап та Казан ягыннанмы? – дип сорады Мөхлистән назланып утырган Зина.

– Әйе, шуннан, Казан ягыннан. Шуннан, кыскасы...

– Үзең студент, ә акчаң бер букча, – дип кызыксынды Ольга. – Атаң бай мәллә?

– Мин үзем бик бай, шул тиклем бай, байлыгымны кая куярга белмим... Ха-ха!

– Син бәхетле...

– Юк, бәхетсез.

– Әкият сөйләмә инде, – дигән булды Ольга.

– Чын, истинный чын, – дип тәкрарлады Мөхлис. – Бу дөнья минем өчен буш. Минем бу дөньяны җимерәсем, ватасым, барысын бергә кырып себерәсем килә!

– Ярар, – дип килеште Зина, – тик безгә генә тимә!

– Минемчә, – диде дус кызы, – аңардан теләсә нәрсә көтәргә була.

– Юк... Булмас...

– Зина дөрес сөйли! – дип куәтләде егет. – Сез бит мине бөтенләй белмисез. Без сезнең белән очраклы гына очраштык. Мин, беләсегез килсә, минут саен иблис белән үлемне искә алып, аны туктаусыз чакыручы бер адәм...Телисезме, каршыгызга хәзер шайтанны китереп бастырам?!

– Кемне???

– Люциферны!

– Җитәр! Псих! – дип акырыштылар кызлар.

– Беләсезме, мин ни өчен бай? – дигән сөаль куйды Мөхлис һәм озак кына сүзсез торды. – Мин җанымны иблискә саттым. Әгәр дә минем кебек баерга теләсәгез, сез дә миннән үрнәк ала аласыз... Ягъни...

– Алла диген!

– Ә мин андый нәрсәгә бер дә ышанмыйм! – дип чәрелдәде Зинасы. – Шайтаннарга, җеннәргә! Чушь собачья!

– Сез?! Миңа ышанмыйсызмы? – дип шаккаткан булды егет. – Сез беләсезме соң, шайтан коткысына бирелгән адәми затка нинди асыл сыйфатлар хас булганын? Ә?! Беләсезме сез, юкмы?

– Юк, белмибез! Белергә дә теләмибез! – диештеләр кызлар.

– Телисезме, мин хәзер ерткыч җанвар булып аваз бирәм?!

– Бәлкем, теманы алыштырыргадыр безгә?! – диде Ольга, ләкин шулчак Мөхлис, үч иткәндәй, бүре булып уларга тотынды:

– У-у-у-у-у!!!

Ни хикмәт, каяндыр балкон ягыннан нәкъ шуңар охшашлы яман каты тавыш кабатланды. Мескен кызлар, куркышып, чәүмәлгән урыннарыннан сикереп тордылар.

– Концерт тәмам, туташлар һәм әфәнделәр! – дип шаркылдады Мөхлис һәм Зинага: – Син минем белән каласың! – дип әмер бирде. Ләкин аның, әллә кем булып, монда әмер биреп утыруы театр училищесында белем алган кыю кызларга һич кенә дә ошамады.

– Мин Зинаны синең белән калдырмыйм! – дип каршы төште Ольга.

– Нигә?

– Бергә килдек, бергә китәбез дә...

– Ничек инде? – дип кабарынды егет. – Ике атна хатын-кыз тәнен күргәнем юк! Сезне ни өчен монда алып кайтты дип уйлыйсыз?

– Ялгышасың, – диде Ольга, – без син уйлаган кызлар түгел, без тәртипле кызлар...

– Ха-ха! Әбиегезгә сүләгез әкиятегезне... яме... Кызлар, мин бит саран егет түгел, күпме кирәк, шулхәтле сезгә бирәм! Мә, менә алыгыз, ал! Ха-ха!

Мөхлис аларның алдына бер төргәк акча ыргытты, акчалар – мендәр башында гына яталар иде. Шулхәтле күп акча күреп, тәмам ушсыз калган студент кызлар, нишләргә дә белмичә, бер мәлгә дәшми тордылар. Монда хәзер курку гына түгел, ә кызыксыну, хәтта ки ымсыну, алгысыну хисләре дә өстенлек итте кебек. Акча бит инде ул – байлык, ә аңар кем генә кызыкмас та һәм аны кем генә теләмәс. Шулай да бу эшнең чиста түгеллеген сизенгән кызлар күктән төшкән акчага орынырга базмадылар...

– Үтенеп сорыйм, – дип ялынды егет, – мине ялгыз калдырмагыз! Ялгызлык – минем өчен газап, бик зур газап... Зина... Ольга... мин аңардан куркам... Куркам... ишетәсезме...

– Гафу ит, без синең янда кала алмыйбыз! – дип, ниһаять, телгә килде Ольгасы. – Бу шаяруларың безгә бер дә ошамый, ты какой-то псих!

– Без сине аңламыйбыз! – диде күзен һаман да акчадан ала алмаган Зина. – Безгә үпкәләмә, әгәр кешечә сөйләшсәң, бәлкем, яныңда калган да булыр идек... Киттек, Ольга!

– Туктагыз!

– Туктадык?! – дип икесе дә берьюлы кычкырды кызлар.

– Нишләп сез миңа ышанмыйсыз?! – дип ялварды Мөхлис. – Мин бит, чынлап та, иблискә җанымны саткан мәхлук. Ул хәзер минем анам да, атам да, бабам да... Әнә, мин сезнең белән сөйләшәм, ә ул артта: янымда гына утыра...

– Кайда? – дип куркышты кызлар.

– Әнә тегендә... караңгыда...

Әйтеп кенә бетерде! Шап! Караңгыдан иблис заты атылды да чыкты. Мескен кызлар шундук, котлары алынып, чырылдап, баскычтан аска ташландылар. Иблис, елмаеп кына, аларга бармак янап калды. Аның бу: «Юкка чабасыз, кызлар, миннән качып котыла алмассыз!» – диюен аңлата иде...

– Ничек?! – дип сәлам бирде аңа шайтан.

– Ярыйсы...

– Дустыңны онытмадыңмы?

– Кемне?

– Мине?!

– Юк...

– Маладис!

– Сине гел сагынып, искә алып торам...

– Син миңа ошыйсың, – дип мактады аны шайтан. Озак мактады. Күңелле иде аны тыңлап утыруы. Кеше, гомумән, мактау сүзенә мохтаҗ. Мактау сүзен ишетүгә үк эреп китә, шуның ялган һәм буш сүз икәнен аңласа да, мактау сүзен көтеп кенә тора. Ләкин мактаган кешедән кач, сүккән кешегә ишек ач, диләр бит! Яшәгәндә макталып килгән мактаулы шәхесләр вакыт узу белән юкка чыкты, аларның хәтта исемнәре дә калмады, ә сүгелеп, изелеп яшәгәннәре, үлгәч тә, кояш сымак калкып чыктылар, халык хәтерендә калдылар. Әнә шул ялган мактау да бер шайтан гамәле түгел микән әле? Мөхлис шуны күңеле белән сизенсә дә, шайтанның мактавын кире какмады. Аны тыңлау рәхәт иде аңа...

– Күңел ачасың, димәк?

– Үләр алдыннан, ичмасам, бер күңел ачып калыйм. Тиздән синең кул астына керәсе, җанымны синең карамакка тапшырам... хе... хе...

– Мин шат. Атаң-анаң кайда?

– Царское Селога киттеләр... Әби патшаның кышкы сараен карарга. Бер очтан иптәш Пушкин укыган лицейга да керәләр. Культурный поход, кыскасы. Ә мин менә күңел ачып утырам! – диде Мөхлис һәм әле яңа гына ачылган, авыз ителмәгән шампан шәрабына сузылды.

– Күңел ачуларны тәмамларга вакыт, дускай! – дип, якасыннан тотты аны Иблис. – Шартнамәнең шарты буенча, инде алган бурычыңны кайтарыр вакыт җитеп килә...

– Әйе, бушлай берни дә юк шул...

– Анысы дөрес.

– Нәрсә көтә инде безне?

– Яман каты эшләр, яман каты...

– Бар булган уең яманлыкта һәм дә явызлыкта гына бит синең!

– Яманлык, явызлык ул, беләсең килсә, дөньяны хәрәкәткә китерүче көч. Көч, яман вә явыз көч! Шуңа күрә дөньяда сугышның тынганы да юк. Һәм ул бервакытта да тынмаячак. Өстән шулай куелган. «Сугышсыз бер генә көн дә юк». Бу – өстән төшкән әмер, өстәгеләрнең дерективасы. Сугыштан туксан тугыз проценты интегә, бер проценты гына байый. Әнә шул бер процент өчен кирәк ул сугыш. Фетнәне дошманнар үзләре чыгаралар дип уйлый ахмак халкың, юк, ялгышасыз, аны без чыгарабыз, без...

– Кемнәр сез?

– Җеннәр...

– Сугыштан әле беркемнең дә файда күргәне юк.

– Сугыш кирәк, сугышсыз алга китеш юк. Ансыз булмый. Сугыш ул үтерүче генә түгел, ул әле чистартучы да, тазартучы да. Җирдәге халык санын тигезләп, тәртипкә китереп торучы да. Берәү терелә, ягъни мәсәлән, берәү үлә, берәү туа, берәү китә. Газраилга эш җитәрлек монда...

– Сузма, әйт сүзеңне!

– Тупас сөйләшергә өйрәндең син, дускай. Хәер, бу халәтең белән син миңа күбрәк ошыйсың, яралы һөҗүмче сымак, бернигә карамыйча, һаман алга ыргыласың, үләсеңне сизмисең, тискәре гамәл кылырга ашкынып торасың...

– Әйт!

– Тыңла, – диде ул серле тавыш белән. – Тиздән атаң кайтып җитәр. Үги анаң да. Алар кайткач, табын әзерләнер, чәе, мәе куелыр. Табынны үзең әзерләргә тырыш, ишеттеңме? Атаң эчкән савытка шушы сыекчаны салырсың. Менә ул...

Иблис нindидер иероглифлар төшерелгән карасу төстәге бер тимер савытны

Мөхлискә тоттырды. Мөхлис аны кулына алырга теләмәсә дә, шайтанның теләгенә каршы килә алмады. Ул хәзер сәгать саен, минут саен аның ихтыярына буйсынырга мәҗбүр иде. Иблис, кеше өстеннән өстенлек итү белән бергә, егетнең хәтта акылын вә уйлау фигылен үзгәртергә һәм чуалтырга да өлгергән иде.

– Нәрсә бу? – дип сорады аңардан егет.

– Зәмзәм суы! Ха-ха! – дип көлде шайтан.

– Агу түгелдер ич?

– Агу.

– Агу?! Син нәрсә, минем атамны, бердәнбер якын кешемне агулап үтерергә җыендыңмы?

– Мин түгел, ә с-с-син, – дип, елан сыманрак ысылдады шайтан. – Агуны с-с-син бирәсең, дус-с-скай...

– Юк, юк! – дип каршы төште аңа егет. – Без бит болай сөйләшмәгән идек, мин берничек тә бу агуны атамның чәенә сала алмыйм! Юк!!! – Мөхлис савытны кире өстәл өстенә илтеп куйды.

– Договор дороже денег, – дип елмайды тегесе. – Ничек сөйләштек без? Ничек килештек? Ярдәмемнән яхшы файдаландың, котылгысыз үлемнән котылдың, хәзер синең чират – ярдәм ит миңа.

– Да-а-а! Бер бәладән котылып, икенчесенә барып кердем. Юк, булмый... Нишләп соң әле мин әтине үтерергә тиеш? Ул бит минем әтием, ышанычым, таянычым...

– Ялгышасың, дускай, хәзерге вакытта синең таянычың да, ышанычың да фәкать мин генә. Мин – иблис.

– Юк, теләсәң нишләт, мин әтине үтерә алмыйм.

– Яратасыңмы атаңны?

– Әйе.

– Шул хәтлеме?

– Мөгаен...

– Акча биргән өчен, ярдәм иткән өченме?

– Юк, әти булганы өчен.

– Әйбәтмени соң атаң?

– Миңа аның, яхшылыктан башка, начарлык кылганы булмады. Нишләп син шулхәтле яратмыйсың атамны, аңламыйм?

– Аны ни өчен сөймәгәнемне киләчәктә аңлатырмын. Атаңны мактарга тырышуың ачуымны чыгара. Атаң синең, между прочим, кабахәт кеше! Ул...

– Әйтеп бетер, иблис токымы!

– ...ул синең анаңны үтерде.

– Анамны?

– Гадиләне...

– Юкны сөйләмә, ничек итеп минем әтием әнине үтерә алсын ди?! Алар бик тату яшәделәр, әти гомере буе әни сүзеннән чыкмады. Ни өчен үтерсен ул аны?

– Җавабы гади: ул аңар комачау итте. Атаңа Фәниягә өйләнергә кирәк иде. Яшь, чибәр хатынга...

– Ялган! Әни үлгәчтен дә әле әтием ел ярымнар өйләнмичә йөрде.

– Конспирация. Белмәгән нәрсәм юк: атаң синең анаңны үтерде.

– Тагын ялган! Минем әни бала тапканда үлде...

– Энеңне тапканда, шулаймы?

– Ул аны соңарып табарга булды. Әнинең яше бар иде инде. Табиблар тапмаска кушсалар да, әни барыбер тапты...

– Ялгышасың, синең анаң бала тапканда үлмәде. Анаң баланы табып, берничә көн үткәннән соң, атаң, явыз атаң табибларны сатып алып, анаңны да, энекәшеңне дә үтерттерде...

– Ничек?

– Шприцка агу салдырып...

– Юк, бу дөрес хәл түгел, мин моңа берничек тә ышанып бетә алмыйм. Син боларны каян беләсең? Син Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә яшәмисеңдер бит?!

– Иблис, дускай, бер Татарстанда гына түгел, ул Америкада, айда, хәтта космоста да яши. Әгәр син минем сүземә ышанмыйсың икән, без синең белән хәзер кечкенә генә бер эксперимент ясап карыйбыз. Син миңа әйт, ошбу минутта бу чарлакта нәрсә булачак?

– Каян белим, башны катырма...

– Уйла!

– Кайтса шул... әти кайтып керергә мөмкин...

– Юк, атаң кайтканчы бу бүлмәгә зур гына бер бөҗәк очып керер... Әйтик... шөпшә...

– Чынмы?

– Көтик...

Алар кара-каршы утырыштылар. Дивардагы сәгать телләре вакытны санап торды. Бераздан, нәкъ ул әйткәнчә, бүлмәдә шул шөпшә тәресе безелдәп оча башлады...

– Җиндең, – дип, җиңелүен танырга мәҗбүр булды егет. – Син – күрәзәче... димәк...

– Миңа ышанырга кирәк, шулай бит?

– Бәлкем...

– Ал савытны һәм эшеңне ахырына җиткер! – Мөхлис калтыранган куллары белән тимер савытка ябышты. – Тик кара аны, алдыйсы булма! Мин барсын да күреп, белеп торам, мине алдый алмыйсың. Хуш, уңышлар телим!

Мөхлис чарлакта ялгызы гына утырып калды. Аны әллә нинди авыр уйлар биләп алды. Нишләргә? Шайтанга сатылу аны менә нишләтте! Иблис белән мондый килешү төзеп, сүз куешканчы үлеп котылуың артыграк булган икән. Егет әле яши генә башлады, ә күпме хата ясады. Төзәтә алмаслык. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк: «Так мало пройдено дорог, так много сделано ошибок!» – кебегрәк була инде бу...

Ә бәлкем, иблис хаклыдыр, ә? Ул бит атасыныңниләр кылып йөргәнен белми, әгәр дә ул анасына карата шундый явызлык кылган икән, нигә артык уйлап торырга, тотарга да чәенә агу салырга!

Аның хәле чынлап та авыр иде. Сихерләделәр бугай үзен, бик каты сихерләделәр, ни кылганын да аңламый башлады, саташа бугай ул... Атасына кул күтәрергә ярамаганын күңеле белән аңласа да, иблис әйткәнне эшләүдән баш тартырлык көч бар микән соң әле аңарда?

## 7. Тәмле су

Сәяхәтчеләр төнлә генә кайтып керде. Ике шешә шампан шәрабын бушаткан Мөхлис бу вакытта изрәп йоклап ята иде инде. Аны уятырга теләмәделәр, ләкин ул үзе уянды. Бәдрәфкә чыгып йөгерде. Фәния, гадәттәгечә, табын әзерләде, чәй кайнатты.

– Улым, кәефең юк, ахрысы, агарынып киткәнсең, – диде аңа атасы. – Ни булды?

– Көне буе укыдым, конспект ятладым, – дип ялганлап котылды улы. – Тиздән имтиханнар башлана... Җә, сәфәрләр ничек узды?

– И-и! Безгә шундый ошады! – дип тел шартлатты Фәния.

– Пушкин укыган лицейда булдык, – дип сокланып сөйләнде Гаян, – бөегебезнең йоклаган бүлмәсен, утырган урындыгын, язу өстәлен күрү бәхетенә ирештек. Пушкинны урыс шагыйре дигән булалар, урысча язгач, урыс халкын данлагач, шулайдыр шул... Тик фотосурәтенә карасаң, чын африкан инде, әле мөселман ук булмаса?! Нинди генә милләт хезмәт итмәгән бу урыс халкына, ә! Саный китсәң... Бу нәрсә?

Гаян өстәл өстендә торган иероглифлы савытка төртеп күрсәтте. Мөхлис телсез калды, берни дә әйтә алмады. Гаян савытны алып, аны кулында әйләндергәләде...

– Нәрсә бу?

– Сок... – Мөхлиснең тавышы калтыранып чыкты, ул чак кына үз-үзен сатмады.

– Ә нишләп мондый савытта?

– Кибеттән сок алып кердем... Пакетның төбе тишелде... Шуңар... шушы савытка салып куйдым...

– Сәер... Эчсәң ярыймы?

– Ярый...

Мөхлис аңар: «Ярамый!» – дип кычкырырга теләсә дә, атасының теләгенә каршы килә алмады. Аңарда хәзер ике кеше яши иде, ике сыйфат, ике төс: берсе – ак, икенчесе – кара. Беренчесе икенчесеннән никтер өстенлек итә, акны томалап, аны гел каралтырга гына тора. Ике якка авышып, ике якны да тотып торырга теләгән Мөхлис шушы минутта атасын коткарып калуына ышанмый иде. Җанын шайтанга саткан адәмгә хәзер инде барыбер, диңгез тубыктан иде, ягъни...

Ә Гаян эчте, йотылып эчте. Эчкән әйберсе аның ирен кырыннан ияк асларына тиклем агып төште...

– Шулхәтле эчәсең килдемени соң, әти?

– Әйе... Тирләтеп җибәрде... натуральныймы бу? Чынмы?

– Чын... Натуральный... сок...

– Әйе, – дип сокланды Гаян, – бигрәк тәмле су булды бу...

Атасының шундук егылып үләсен көткән Мөхлис ялгышты, Гаянның бер кылы да селкенмәде, киресенчә, аның кәефе күтәрелеп киткән сыман тоелды. Атасының шайтан салган агулы суны шулай йотылып эчүе аңлашылып бетми. Әнисенең абыйсы, начар авырудан үлеп ятканда, Мөхлистән эчәргә су алып килүен сораган иде. Шулчак ул аңа кибеттән гел лимонад ташыды. Инде соңгы сулышын алганда да абзыйның: «Тәмле су бу, эликсир!» – дип сөйләнүләрен һәм шул гади лимонад суын шифалы су урынына эчүен һич кенә дә онытасы юк...

– Ярар, – диде Гаян, – мин әзрәк кенә ятып торыйм әле! – Һәм ул капылт кына караватк кырына барып ятты. Мөхлис шунда уйлап куйды: димәк, бу агу дигәнең кешегә тиз генә тәэсир итми, ә күпмедер вакыт узгач кына үзен сиздерәдер. «Йоклаган килеш кенә үлеп китсә ярар иде, торып, акырып кына йөрмәсен», – дип, «изге» теләкләр теләде аңа егет...

Балконга һава суларга дип чыккан Мөхлисне Иблис эләктереп алды. Ул кабат нидәндер канәгать түгел иде.

– Салдым, эчердем, – дип акланды егет.

– Эчердең, тик атаң исән калды. Ул нәрсә, үлемсез мәллә?

– Ятты бит... бәлкем... дөмегер...

– Ничек?

– Үз вакыты белән...

– Юк, – дип кырт кисте шайтан. – Ул агулы суны эчүгә үк дөмегергә тиеш иде. Аңар кара чия ингредиенты белән буташтырып цианистый калий матдәсе салынган. Нигә үлмәде ул? Кеше үлемсез була алмый. Үлемсез – бер мин генә! – дип аптырады һәм күкрәк какты шайтан.

– Ә мин үземне үзем күрә алмыйм, син ул агуны миңа гына бирәсең калган!

– Әгәр шушы вакыт эчендә атаң үлмәсә, үзеңә үпкәлә!

– Куркытма, иблис токымы!!!

## 8. Гаҗәеп очыш

Мөхлис шайтанга катырак кычкырып җибәрде булса кирәк, шулчак балконга Фәния атылып чыкты. Гаянның улы яшәгән чарлакка кунакка килгәннән бирле бу яшь, чибәр ханым һич кенә дә күңеленә тынычлык табалмады. Үзен Мөхлиснең дусты дип, Евгений Ваганович дип таныткан бу сәер, салкын канлы адәмне кабул итеп бетермәсә дә, нигәдер ул да аның ихтыярына буйсынырга әзер тора иде...

Бераздан алар балконда икәү генә торып калдылар. Мөхлис барысына да кул селтәп, бүлмәгә кереп китте.

– Исәнмесез! – дип, кыюсыз гына сәлам бирде хатын кунакка. – Сез балкондамыни соң? Нишләп монда качып ятасыз?

Евгений Ваганович аңа бер сүз дә дәшмәде, хәтта сәлам дә бирмәде. Аның кулында кинәт кенә чәчәк бәйләме барлыкка килде, унөч данә кызыл роза төрелгән букет булып чыкты ул. Каян барлыкка килде ул розалар, Ходай белсен? Иблис букетны чибәр ханымга сузды...

– Сезгә! Чын күңелдән!

– Миңа? – дип шаккатты ханым.

– Сезгә!

– Рәхмәт... – Фәния, чәчәкне күкрәгенә кысып, бүләк итүченең күзенә турып карап, елмаерга ярата торган иде. Бу юлы чәчәк бүләк иткән джентльменның күзенә туры карарга да курыкты һәм хәтта елмаймады да. Сөйкемсез, җансыз адәм иде ул Фәния өчен. Җитмәсә, кулын үпкән була тагын! Фу!

– Мине ошатмадыгыз?!

– Әйталмыйм...

– Ошарга тырышмадым да... Сез мине бик каты гаҗәпләндердегез!

– Ни белән?

– Сез ирегездән егерме биш яшькә кече. Сезгә ул атагыз кебек. Аңламыйм, нишләп сез шундый олы кешегә кияүгә чыктыгыз?

– Мин иремне яратам, ул – акыллы, төпле кеше.

– Акчасына, байлыгына кызыккансыздыр инде, – дип сорау алуын дәвам итте шайтан. – Юк, моның өчен мин сезне гаепләмим, киресенчә, хуплыйм, сезнең кебек яшь, чибәр кызлар дөнья яратылганнан бирле шулай яши. Шулай булырга тиеш тә. Мәхәббәт, сөю кебек җүләр хисләр мәңгелек түгел. Мәхәббәт дип җенләнүдән бернинди дә мәгънә юк, акча һәм байлык гел кирәк. Сөю хисе ул язгы кар кебек, эри дә юкка чыга, ә байлык кала. Мәхәббәтсез яшәп була, тик бер генә көн ашамыйча

кара! Ачлык күргән буын түгел шул сез. Килер ул көн, килер һәм китерербез. Гасырга бер-ике мәртәбә кабатланмыйча калмый ул... цикл... ягъни мәсәлән...

Иблис шактый озак сөйләде. Фәния аны тыңласа тыңлады, тыңламаса юк. Чибәр ханым шайтан такылдаган вакытта үз уйларында йөзде. Ул күп балалы гаиләдә үсте. Биш кыз, бер ир бала. Аталары якты дөньядан иртә китеп барды, ул атасын бөтенләй хәтерләми. Атасыз үсте, ата назына сусап үсте һәм шуны ул Гаянда тапты кебек. Гаян аңар берьюлы әти дә, ир дә иде. Танышканда читенсенеп, теләмичә генә танышты ул булачак ире белән, ләкин Гаянның кайгыртучанлыгы, аңа булышуы үз эшен эшләде булса кирәк, бер-ике ай эчендә ул аның ягына авышты да куйды. Әйе, ул аны бик нык күтәрде, хәтта уку белән дә ярдәм итте, профессорларны да җайлады, затлы итеп киендерде, туган көненә өр-яңа чит ил машинасына хәтле бүләк итте. Тик шунысы бар: бер алырга өйрәнгән хатын-кыз һаман шуны гына көтеп тора, яраткан кешесе тагын бирәр затлы нәрсә бүләк итәр дип уйлый. Тик беркадәр вакыт узгач, Гаян аңа бушлай әйбер бирүдән туктады, хатыны акчаны үзе эшләп алуын теләде. Шулай итеп, ул хатынын эшмәкәрләр дөньясына кертеп җибәрде, акча биреп, бизнес ачты, ләкин, ни кызганыч, чибәр ханымның эшмәкәрлеге ташка үлчим генә булып чыкты. Бизнес туктады, биргән, салган акча суга акты. Хатынының бернигә дә ярамаганлыгын аңлап алган ир аның урынын бик тиз тапты – ул өй җыештыручы, өй караучы гади бер домохозяйка гына булып калды. Туган көнендә аңа ире кабат затлы әйбер (алтын, көмеш, бриллиант) бүләк итәр дип өметләнгән хатын ялгышты, Гаян аңа өр-яңа тузан суырткыч бүләк итте. Пылесос, чынлап та, кыйммәтле иде, идәнне су белән генә юдырып чистарта торганы...

– Ялгышасыз бугай! – дип кисәтте аны Ваганыч.

– Нәрсәдә?

– Ирең үлгән очракта аның байлыгы барыбер сезгә калмаячак, калса да бик аз өлеше генә калырга мөмкин. Мизер. Гаян үзенең бөтен байлыгын һәм йорт-җирен шушы җүнсез малае исеменә яздырган һәм, ул үлгәч, барысы да аңа калачак...

– Мөхлискәме?

– Аңа. Син әле яшь. Гаян озак яшәмәячәк. Аңарда нәселдән килә торган чир таптылар, ул аны сиңа әйтмичә, яшереп йөри. Тиздән үләчәк, сезнең балагыз да булмаячак. Син тол хатын булып калачаксың.

– Нишлим соң инде? – Фәния бу сүзләрдән соң бөтенләй коелып төште.

– Тәкъдимем бар...

– Нинди?

– Мөхлисне үзегезгә каратырга, үз ягыгызга аударырга кирәк. Ул сезне бәхетле итәчәк, син аңардан бала табачаксың, матур ир бала, сабый бала... Йә, ничек?

– Юк, сез нәрсә! – дип каршы төште хатын. – Мин мондый юлга бара алмыйм, юк! Иремә хыянәт итә алмыйм, мин ансыз яши алмыйм. Мин...

– Ашыкмагыз... – Кунак кисәк кенә аның муенына бриллиант муенса тагып куйды. Ул аны шулхәтле тиз такты ки, Фәния сизми дә калды. – Матурмы?

– Би-и-ик!

– Сөенмә, бушка түгел! – дип көлде шайтан. – Мин кушканны эшләсәң, бу матурлык синеке булачак. Бу асылташларны сатып кына да син үзеңә шәп ташпулат, зиннәтле сарай салдыра аласың, аңладыңмы?

– Бу...

– Бриллиант...

– Бриллиант?! – Фәния, өнсез калып, кулы белән муенсаны тотып карамакчы булды, ләкин Ваганыч аны секунд эчендә хатынның муеныннан салдырып та атты. Шуңар күрә дә ул бу матурлыкның тәмен һәм ләззәтен тоя алмыйча да калды. – Соңыннан, аңладыңмы, соңыннан...

– Аң...ладым, – дип баш чайкады әлегә берни дә аңлый алмаган бичә.

– Сиңа эликсир да бүләк итәчәкмен...

– Нәрсә ул?

– Аны эчсәң, мәңге яшь каласың, беркайчан да картаймыйсың.

– Андый эликсир бармыни дөньяда?

– Бар. Яңа туган сабый бала маеннан ясыйлар аны... Уйладыңмы?

– Яхшы... тырышып карармын...

– Афәрин! Бриллиант, һичшиксез, синеке булыр. Хәзер мине тыңла...

– Тыңлыйм... – Хатын аның бу сәер тәкъдимнәреннән тәмам сихерләнеп өлгергән иде инде.

– Гаян тиз генә урыныннан тора алмас. Мин Мөхлисне чакырып керәм. Син егетне ничек тә кызыктырырга тиеш...

– Ни белән?

– Ние белән кызыктыра ала ирне хатын-кыз?! Тәнең белән...

– Ничек?

– Салып ат бу итәгеңне!

Иблис бүлмәгә атылып кергәндә, төсе качкан, күзе акайган, бертуктаусыз учларын уып торган Мөхлис, үз-үзен кая куярга белмичә, әрле-бирле йөренә иде...

– Ни белән сөендерә аласың? – дип сорады Иблис аңардан.

– Әти исән, исән, ишетәсеңме!

– Исән?!

– Әйе, Аллага шөкер! – дип сөйләнде егет.

– Чү! – дип кычкырды шулчак шайтан һәм каударланып кырыйга сикерде. – Күпме әйтергә була – минем алда аның исемен атама дип!

Иблис, каты итеп, тоягы белән Мөхлиснең эченә китереп типте. Әче авырту аның корсак астын кисеп үтте, ләкин сыгылып төшсә дә, ул барыбер егылмады...

– Әкренрәк... ярамый идеме?..

– Ярамый.

– Ыс...вулыч!

– Уен дәвам итә, дускай! – дип, тантаналы рәвештә дәште шайтан. – Бүген бөек көн. Төн уртасы җитүгә, бөек тамаша – гыйш-гыйшрәт башланачак, шабаш!!!

– Нигә... ул?

– Сиңа да кагыла. Сине дә шабашка алам. Син анда анаң Гадилә белән очрашырсың.

– Ай... Син тагын үзеңнекен тукый башладың...

– Анаң исән, тыңла. Сихерче, убырлы карчыклар җыенында аның белән очрашу бәхетенә ирешә аласың, ишеттеңме?

– Ишеттем... кайчан башлана ул... туй?

– Тиздән. Тиздән минем сөекле убырлыларым, таякларына атланып, һавада очып йөри башлаячаклар...

– Карале! – дип, җитди кыяфәт чыгарды егет.

– Тыңлыйм?

– Син милләтең белән кем, ә?

– Аңламадым?

– Урысмы син, татармы?

– Мин урыс та, татар да түгел, – дип, сабыр гына җавап бирде иблис.

– Нишләп алай?

– Мин изге җан, милләтем юк...

Мөхлиснең бар булган уе ничек тә шушы иблис коллыгыннан котылу иде. Ул бер әйбергә инанды: әгәр дә ул урыс милләтендәге шайтан булса, аңардан әле котылып булыр төсле иде, чөнки аның милләте дә, дине дә башка, ә менә татарныкы булса, шактый авырга туры киләчәк – татар бер каптырып алса, тиз генә котылам димә...

– Туйга Фәния белән бергә барырсың! – дип әмер бирде шайтан.

– Кем? Әтинең хатыны беләнме?

– Атаңның хатыны сиңа бу төндә сөяркә булыр.

– Без синең белән алай сөйләшмәгән идек.

– Мин генә түгел, Фәния үзе дә шуны тели.

– Фәния?! Юк, мин моңа ышанмыйм...

– Күрерсең һәм шуңар инанырсың...

Ул, җилтерәтеп алып, егетне балконга чыгарып бастырды. Аның каршына, фахишә сымак, киемсез Фәния килеп басты. Итәген салып ыргыткан, күкрәкләрен ачкан, гомумән, ояты качкан бу яшь хатынның!

– Кем бу? – дип артка чигенде Мөхлис.

– Бу мин – Фәния, – дип назлы итеп эндәште хатын. – Борчылма, Мөхлис, мин сиңа күптән әйтергә тели идем, бу тәүге адымымны мин кайчан да булса бер ясарга тиеш идем. Газаплама үзеңне, кил, кочыйм бер...

– Якын килмәгез, китегез! – дип кычкырды аңа егет. – Әгәр әти күрә калса...

Яшь бичә, тыгыз ак күкрәкләрен киереп, егет каршына килде. Куркудан, оялудан нишләргә дә белмәгән Мөхлис, каушап, артка чигенде, ләкин шулчак шайтан аны аркасы белән терәргә өлгерде. Егет ни артка, ни алга атлый алмады. Шундый чибәр хатынның аны кочакларга, үбәргә маташуы егетне берникадәр куандырса да, намусы аңар бу хатынның ымсындыруларына каршы торырга өнди иде. Атасының хатыны бит ул! Әйе, ошый иде аңа Фәния, ул үзе дә аңар битараф түгел иде, аңардан берничә яшь кенә олы булса да, атасын хөрмәт итү йөзеннән, ул Фәниягә «апа» дип эндәшә иде. Атасының яшь хатынга өйләнүенә ул сөенмәде, билгеле, ләкин аның теләгенә каршы килергә дә базмады. Яшь хатын аркасында атасы белән каршылыкка керү, аңар комачаулык ясау Мөхлиснең уенда вә гамәлендә дә юк иде...

– Оялыр идең... – Мөхлис хатынга бары тик шул сүзне әйтә алды.

– Мөхлис! – дип сайрады бичә. – Йөрәгемдә ташып торган хисләремне синнән яшерә алмыйм. Кал, китмә яннымнан...

– Кирәкми...

– Әй Аллам! – дип буталды Фәния, башын тотып. – Ни сөйлим мин, ә? Үземне үзем аңламыйм...

Шулчак шайтанның кулында кабат алтын муенса ялтырап алды һәм ул үз эшен үтәде: гыйшык көенә сайраган чибәр хатын Мөхлисне кочаклап та алды...

Шулчак эчке бүлмәдә нидер чылтырап коелды һәм гөрселдәп ишелде. Теге каһәр суккан магнитофон кабат үкерергә тотынды. Elvisның атаклы «Jaihouse Rok» композициясе яңгырады. Күрәсең, үлем исереклеге белән саташкан Гаян, белештермичә, урыныннан сикереп торган, нәрсәләрнедер аударып, ялгыш

магнитофон төймәсенә баскан. Бераздан, мәтәлә-мәтәлә, Гаян үзе дә балконга атылып чыкты. Шайтан эчерткән агудан гаҗәеп хәлдә исән калган абзыйның карар җире дә юк: чырае таш астында үсеп яткан үлән тамыры сыман агарган, башындагы сирәк чәчләре әтәч кикриге сымак үрә торган, күз бәбәкләре акаеп чыккан иде. Бертуктаусыз укшый, коса. Күз аллары караңгыланган, күзенә һәрнәрсә ике булып күренгән ирнең үз хәле хәл иде. Ләкин хатынының улы белән кочаклашып, үбешеп торганын күреп алгач, ул имәнеп китте. Гаян бар көченә кычкырмакчы булды, ләкин тавышы аңа буйсынмады, бик нечкә булып, зәгыйфь булып кына чыкты...

– Оят...сыз...лар... Нишлисез... сез...

Гашыйклар, корт чаккандай, кырыйга сикерделәр. Гаянның шулай кинәт кенә балконга килеп чыгуын беркем дә көтмәгән иде, агу ашаган тычкандай, әле озак кына караватында тәгәрәп, миңгерәп ятар дип уйлаганнар иде...

– Әти... кичер, – дип акланды улы, – мин моны үзем теләмәдем, мин гаепле түгел...

– Чурт бутады безне, Гаян, чурт! – дип такылдады хатыны.

– Оят...сызлар... Җир битләр...

Гаян каршында дивар сымак басып торган шайтанны кырыйга этмәкче булды. Ләкин дивар кымшанмады да. Соңгы көчен җыйнарга өлгергән Гаян, шайтанны әйләнеп узып, Мөхлискә ташланды. Тик шулчакны егетнең кулында карабин, ягъни мылтык пәйда булды. Бусы да шайтанның бер могҗизасы булды, күрәсең...

– Ат! – дип әмер бирде аңа Иблис. – Йә ул, йә син!!!

Мөхлис кулындагы карабинның затворын ачып-ябып, аны атасына төбәде. «Ат!» – дип кабатлады шайтан. Мөхлис коралның тәтесенә басты, ләкин мылтык атмады, осечка бирде. «Ат!» – дип җикеренде аңа шайтан. Мөхлис кабат атты, бу юлы пуля атасының иңбашын ялап, урамдагы багана башына очты. Гаян, иңбашын тотып, идәнгә тезләнде. Ату-ватулардан коты очып торган бичә чинап акырырга тотынды. Шулчак бу чинауларга ниндидер бәндә тавышларына охшамаган яман кыргый авазлар кушылды. Тирән көз айлары булуга да карамастан, кинәт кенә күк күкрәде, көчле һәм дәһшәтле давыл, гарасат купты. Мөхлиснең кулындагы карабины кинәт аның ике бот арасына кереп кысылды, Фәния шундук егетнең аркасына килеп ябышты. Озын булып үскән тупылларның башларын селкетеп, бөтерелеп искән көчле давыл, зилзилә Мөхлис белән Фәнияне, шул агым белән күтәреп алып, каядыр еракка, югарыга очыртып алып китте. Балкон эче бушап калды. Башын күтәрә алмыйча идәнгә тезләнгән Гаян, хәлсезләнеп, яны белән чарлак диварына ауды. «Өнемме бу, төшемме? – дип сызланды ул. – Тормышмыни соң бу? Тә-муг. Бердәнбер улы атасына мылтыктан ата, ә яраткан хатыны ире каршында зина кыла. Нәрсә соң бу? Ахырзаманмы? Кемнең каргышы төште соң миңа? Әйт, Тәңрем, аңлат, мин синнән җавап көтәм, җа-а-а-вап...»

Балкон артында кемдер ямьсез итеп кычкырып көлде.

## 9. Гыйш-гыйшрәт

Айлы, сихерле төн.

Карадагынай куе карурман, төнге алан. Сихерче хатыннар вә убырлы карчыклар җыела торган кыргый бер алан икән бу. Аланның берничә башында учак ягылган, тирә-ягында коточкыч ялкын һәм кап-кара төтен бөркеп торган карачкы факеллар тезелгән.

Менә шушында убырлар җыены, убырлар туе бара. Кушылып үскән бер гарип каен янында ике карт скрипкачы, кара-каршы басып, бию көен уйнап торалар. Ак йолдызлар сибелгән могҗизаи күктә аяк араларына таяк кыстырган убырлар очып йөри һәм алар, текә пике ясап, берәм-берәм, аланлыкка очып төшәләр. Ә аларны анда, килешенгәнчә, көтеп кенә торалар! Кара затлы фрактан киенгән кавалер егетләр, кызу гына эләктереп алалар да, җитез бию ритмында зырылдатып, әйләндереп алып та китәләр. Убырларның биегәндә башлары әйләнеп китә. Төнге алан эчендә исә биючеләрнең саны күбәйгәннән-күбәя генә бара, ул биюче парлар белән тула. Шунысы сәер: биюче парлар кешечә бер-берләренең күзләренә карашып түгел, ә бер-берләренә аркаларын терәп бииләр...

Инде бер атна аракыдан айный алмаган, каты махмырдан интеккән Сергей атлы бер урыс мужигы да әнә шушында, җен-пәриләр туена очып төште. Аны монда әле бер ай элек кенә танышкан, хәзер инде язылышмыйча гына Сергей фатирында яшәп яткан Катерина исемле сөяркәсе очыртып алып килде. Катяны ул вокзалдан табып алып кайтты, йортка кертте, үзенеке итте, соңыннан үкенде үкенүен, ләкин хәзер соң иде инде. Канун бар, тайпылышсыз тормыш кануны: кешенең кем икәнен белмичә, аны өйгә кертергә ярамый. Гомер аракыдан айнымаган һәм күзе ачылмаган Сергей аны башта җен хатыны дип башына да китермәде. Бу җен хатын аны бик тиз үзенә каратты. Хәер, Сергей да аны үз итте. Хатын аңар – Сергунь, ә Сергей Катюша дип кенә дәште. Менә хәзер алар туйда, җен туенда. Ләкин адәми зат нихәтле генә исерек һәм аңгыра булмасын, ул үзенең бер бүлмәле «хрущёвка»сы белән җен карчыклары, убырлар биеп йөргән ял урынын гына аерыр хәлдә иде әле...

– Катюш!

– Ау?

– Без кайда? – дип сорады бу сәер манзарага шаклар катып утырган Сергунь.

– Туйда без, дарагуй, туйда! – дип безелдәде җен хатын. – Сергуньчик, мы сегодня гуляем! От души, между прочим!

– Нинди туй? Кем туе соң бу?

– Ач күзеңне! Өйрәнгән – өч борынга! – дип ачы сүгенде марҗа.

– Әйбәт иде бит әле... Тыныч кына утыра идек өйдә... самагун йотып... Ничек килеп чыктык соң без монда? Уф! Бөтен тәнем кычыта, бөтен җирем майланган! Нинди май сөрттең син минем тәнемә, ә?!

– Хикмәтле май ул! – дип елмайды Катюша. – Менә шул очырта да инде безне...

Сергунь, тәненең кычытуына чыдый алмыйча, бик иләмсез итеп кашынырга тотынды. Катюша сөрткән май аның тәнендә кибә, тәнен корыта. Бу хикмәтле май турында бары тик шуны гына әйтергә була: ул иблис тарафыннан үтертелгән сабыйлар маеннан ясала иде. Убырлы һәм җен карчыклары үләксәне башта сулы бакыр савытка салып, бик шәпләп кайнаталар, соңыннан шуны сөзеп алып, тиешле урында саклыйлар. Менә шулай сакланган сыйфатлы майдан гыйш-гыйшрәт мае ясыйлар да инде. Аны ясаганда (рецепт буенча) – түндербаш, аю табаны, ак тирәк яфрагы кебек шифалы үсемлекләр белән төрле тәмләткечләр кушу да рөхсәт ителә. Шундый май белән сөртенү исә һәрбер убырлының зур хыялы булып санала. Җен карчыкларының һәрберсе, әнә шул тылсымлы май белән сөрткән таякларга атланып, төн уртасында, ай яктысында күкләргә күтәрелергә һәм, гыйш-гыйшрәт аланына очып төшеп, чибәр егетләр, кавалерлар кочагына керергә дип ашкынып торалар иде.

Музыка алышынды. Озын чәчле скрипачлар вальс көен уйнады. Көе

Штраусныкы иде булса кирәк, ләкин көйдә әзрәк көйсезлек, ягъни зур диссонанс булганга күрә, тулысы белән анык дип әйтеп булмый. Серле алан биюче парлар белән тулды. Алар барысы да битлек киеп бии һәм моның, билгеле ки, үзенә күрә бер сере дә бар иде. Бу үзенчә саклану чарасы. Кем генә килмәс бу җен туена да, кем генә күренмәс: анда күршеңне дә, дустыңны да, хәтта туган-тумачаңны да очратырга була. Җаннарын шайтанга сатып, убырлы һәм сихерче булып йөрүчеләр аз микәнни бу дөньяда?! Узган елда, мәсәлән, шушы җен туенда халыкка исеме бик яхшы таныш булган министрны һәм бер депутатны да күреп калганнар. Икесе дә, халык алдында «битлек» киеп туйгангамы, болар туйга битлек кимичә генә килгәннәр. Әлеге эксцесс эзсез калмады, билгеле: ул үзәк гәҗитләрнең берсендә баш мәкалә булып та чыкты. Ләкин бу инцидентттан алар әллә ни зыян күрмәде кебек, чөнки җеннәр туенда катнашкан министрны министр итеп башка урынга билгеләделәр, ә депутат яңадан сайланды. Югарыдан аларга бик зур булышлык күрсәткәннәр дигән сүзләр дә йөрде соңыннан, тик монда шайтан кулы уйнавын да инкарь итәргә ярамыйдыр, шәт.

Музыкаль диссонанс бераздан какофониягә әйләнде. Көйнең төзеклеге бөтенләй юкка чыкты һәм ул колакны бик каты яра башлады. Кавалерларның иңенә башын салып биегән убырлы карчыклар биюдән туктады, ә озын чәчле скрипкачылар бөтенләй икенче көй уйнарга тотынды. Көй дип әйтерлеге дә юк, ике зур агач чыраны бер-берсенә ышкып торсаң, нәкъ шундый ук шыгырдау барлыкка килергә мөмкин. Бик нык сәләмә киенгән, кыяфәтләре белән хәзерге сукбай хатыннарны хәтерләткән һәм инде парсыз калып, кырыйда басып торган ике убырлы карчык кинәт кенә уртада буш калган түгәрәк эченә йөгереп чыктылар да тыпырдап биергә тотындылар. Моны инде чын бию дип тә әйтеп булмый, бу биергә маташу гына иде. Тик симез арт саннарын күтәрә алмыйча, бер-берсенә бәрелешә-бәрелешә селкенгән убырлы карчыкларның бу галәмәтләре ни өчендер аландагыларның күңеленә хуш килде, гүзәл балериналарның биюенә соклангандай, аларга гөр килеп кул чаптылар. Нишлисең бит, халкы нинди – сәнгате шундый! Тегеләре дә, шуңа бик нык илһамланып, ниндидер аңлаешсыз сүзләр ата-ата, рәхәтләнеп сикерештеләр...

– Бум! Бум! Бум!

– Лә-лә-лә!

– Яшәүләре рәхәт лә!

– Яшәүләре күңелле лә!

– Лә-лә-лә-лә-лә-лә...

– Даң, даң, даң!

– Доң-доң-доң!

– Лә...лә...лә...

Бии-бии такмак сибүчеләр иблисне хөрмәтләп, бертуктаусыз аңа дан җырладылар, Ходайга тел тидерделәр. Шулчак бер убырлы карчык, ике бармагын авызына тыгып, яман каты итеп сызгырып җибәрде. Бу аның шул рәвешле ишарә ясап, туйга килүчеләрне табынга чакыруы иде...

– Та-бын-га! Та-бын-га!

– Хуҗа юк, үзе юк! – дип кычкырды икенчесе шундук. Сүз, билгеле ки, шайтанның (Люцифер) үзе турында бара иде.

– Ансыз гына башлыйк, ансыз гына! – диештеләр барысы да. Гадәтсез халык чөнки, ни дисәң дә, культура юк, барысы да әрсез, түземсез...

Алан кырындагы буйга сузылган шактый озын агач өстәлдә кунаклар өчен гаҗәеп бай табын әзерләнгән икән. Ни генә юк: кыйммәтле океан балыгыннан

алып кара һәм кызыл уылдыкларга хәтле бар. Тик әнә шул гаҗәеп тәмле итеп әзерләнгән, матур итеп сервисланган сый-азык арасында бозылган һәм ислэнгән ашамлыклар да шәйләнә иде. Әнә кыйммәтле, затлы океан уылдыгы янында гына берничә черек алма һәм черек груша кисәге ята, шундук дөньяның бөтен чебенен җыйнап, бер дәү хайван сөяге затлы табынның бар булган ямен җибәреп тора иде.

Табынның хуҗасы булмагач, мәҗлеснең яме дә, тәртибе дә булмады. Кунаклар, гадәтсезләнеп, ашау-эчүгә ябырылды. Барысы да үзен иркен тотты: кайсы шопырды, кикерде, борынын җиң очына гына сеңгерде, кайсысы ашап, ялап туйган азык калдыкларын каршы якта утыручыларга тондырды һәм шунда төбәп атты...

Фәния белән Мөхлис мәҗлескә соңга калып төштеләр. Мәҗлеснең беренче пәрдәсе, ягъни беренче бүлеге инде тәмамланган, ашау-эчү, банкет өлеше башланган иде. «Кая килдек без? Кайда без?» – дип сорады аңардан Фәния. «Гыйш-гыйшрәттә без, җеннәр туенда!» – диде егет җавабында. «Иблис эше генә бу!» – диде ханым. «Алдандык без, син дә, мин дә! Хәзер ни күзем белән күренермен әтиемә?!» – дип моңсуланды Мөхлис. «Ә мин иремә?!» – дип ачыргаланды тегесе...

Ниһаять, табын хуҗасы үзе пәйда булды! Хуҗа күренүгә үк барысы да тын калды. Бу юлы иблис ике юлдашын да иярткән, ике яшь кыз – икесе дә аның тарафыннан сихерләнгән. Мөхлис аларны бик тиз танып алды, болар аның белән чарлакта күңел ачкан студент кызлар иде: беренчесе – Зина, ә икенчесе – Ольга. Гадәттә, табын башында иблис үзе утыра, ул төрле кыяфәттә килә, хәтта кара төстәге дәү кәҗә кыяфәтендә дә булырга мөмкин. Сөйләүләргә караганда, мәҗлес ахырында аны кинәт кенә тәмуг уты камап ала, иблис бөтенләй янып бетә һәм коры көлгә әйләнә. Әнә шул шайтан янганнан соң калган көл серле һәм файдалы порошок булып санала, җеннәр мәҗлестән киткәндә шуны үзләре белән истәлеккә дип алып китәләр...

Иблиснең бүгенге мәҗлестә мөгезле эре хайван булып күренәсе килмәгән, күрәсең, ул матур фрак кигән итагатьле джентльмен ролен кулайрак күргән. Менә ул табынның түренә килеп урнашты, ике ягына ике студент кызны утыртты. Иблиснең яраннары, бер-берсен уздыра-уздыра, аңар бар булган мактау сүзләрен яудыра башлады. Бүләкләр тапшыру китте. Бер ялагае кара шәм китереп тоттырды, икенчесе сәер бер төргәк тапшырды. Ясак түләүчеләр иблисне үпкәндәй һәм кочаклагандай иттеләр, ләкин кешеләрчә битеннән яисә кулыннан түгел, ә нигәдер аның үбәргә ярамаган җиреннән үптеләр. Әнә берсе, көчәнә-көчәнә, хуҗа каршына бер бидон көмешкә китереп куйды. Бусы кайчандыр чүпрәк-чапрак белән сәүдә иткән, хәзер инде көмешкә куып, шуны сатып баеп яткан Варвара исемле хатын иде. Ул – тантаналы рәвештә, сөт сала торган ак бидонның тимер капкачын ачып җибәрде, табынга әче һәм авыр көмешкә исе таралды...

Мактый-мактый бүләк тапшырулар шактый озакка сузылды, шуннан соң иблис үзе сүз алды. Үзенең дәрәҗәсен белгәндәй, ул җитди кыяфәт белән, ягъни вәкарь генә урыныннан күтәрелде. Думадагы депутатлар трибунада чыгыш ясарга чыгар алдыннан әнә шулайрак кылана...

– Убырларым! Явызларым! Кансызларым! – диде ул. – Үземне әзрәк сырхау итеп сизсәм дә (ялганлый, билгеле, шайтан беркайчан да авырмый, ул, гомумән, үлемсез!), ел буе көтеп алган мәртәбәле форумга, сезнең белән бергә көрешү вә күңел ачу мәҗлесенә килмичә булдыра алмадым. Без – явызлык вә яманлык кылырга, барысын да сүгәргә, иманнан, изге рухтан көләргә, адәмнәрне ымсындырып, аларның башларына җитәргә тудырылган шайтани

вә ямани затларбыз. Әгәр дә без һәр бирмеш көнебездә берәр төрле явызлык вә яманлык кылмасак, безнең гомеребез бушка узган булып саналыр. Без явызлык кылмыйча тора алмыйбыз...

Әллә иблис артыгын сөйләп куйды, әллә аның сөйләве табын артында утыручыларның эчен пошыра башлады, шулчак арадан бер җен-әзмәвер торып, карлыккан тавышы белән бар көченә: «Рег-ла-мент!» – дип үкерде. Бу әлеге дә баягы шул исерек Сергунь булып чыкты. Кунаклар ах итте! Табын өстен шом каплады. Хуҗаны санламау һәм аңа каршы сүз әйтеп кычкыру үзенә үлем карары алып, тәмуг утында яну белән бер иде. Чыгырыннан чыккан Иблис дәшмәде, акырмады, ул имән бармагын алга сузып, аның ялкынлы речен өзәргә базган исереккә төртеп күрсәтте. Битлек кигән ике кавалер мескен Сергуньны, җилтерәтеп алып китеп, шундук аягыннан каенга асып куйдылар. Арада аны кызганучы һәм элмәктән азат итәргә теләүче табылмады. Тормышта аның өчен өзелеп торган Катюшасы да, хуҗаның фигылен хуплап, бу гамәлгә кул гына чапты. Ышан чит хатыннарга!

– Безнең максат, – дип дәвам итте хуҗа, – безне кўралмаган, безгә буйсынмаган, безгә сатылмаган, безне гел яман сүзләр белән искә алган, һәм дә ки безгә чын күңелдән ышанып, ярдәм көтеп яткан адәми затларның башына җитү, минут саен аларга яманлык вә явызлык гамәлләре кылу, аларны бозу һәм юлдан яздыру. Убырларым, явызларым, кансызларым, кайсыгыз нинди явызлык кыла алды, шуларның, кул күтәреп, хәзер үк тавыш бирүен сорыйм...

Табын артында утыручы убырларның барысы да бердәм булып кул күтәрделәр. Әйе, дөньяда кылынган явызлыкның очы-кырые юк, өскә күтәрелгән куллар шуның бер ачык мисалы иде.

– Мин! Мин! Мин!

– Күрәм, күрәм! – дип сөенде шайтан. – Уңышны бик мулдан җыйгансыз, тырышкансыз, афәрин! Сездән исәп-хисап алып торуның мәгънәсен күрмим, шулай булгач, ял итегез, ял! Туй! Туй дәвам итә! Шабаш!!!

– Ура! Ура! Ура!!!

Гыйш-гыйшрәт, ягъни җеннәр туе, ниһаять, үзенең югары ноктасына күтәрелде. Иблис янында гына утырган Ольга белән Зинаны, каты гына кысып, кочаклап алды, тегеләре исә чәрелдәп кычкырып куйдылар, тик соңыннан, назланып, боргаланып, шайтан кочагында иркәләнделәр. Кызлар белән кети-мети уйнап туйганнан соң, иблис олуг табынның иң аргы башында утырган Мөхлис белән Фәнияне шәйләп алды һәм аларны, кулы белән ишарәләп, үз янына чакырды. Иблис теләгенә каршы килеп булмый, билгеле, алар тиз арада түргә күчеп утырдылар. Түр башындагы Оля белән Зина Мөхлисне бөтенләй күрмәмешкә сабыштылар, әйтерсең лә алар аны бөтенләй белми иде. Билгеле, шундый бай һәм юмарт хуҗа янында назланып, күңел ачып утырганда, Мөхлис кебекләр кирәк түгел иде андый чибәрләргә...

Шулчак кунаклар арасында бер гаҗәеп хатын-кыз пәйда булды, ул битлек кигән, ләкин битлеге таныш кешенең йөзен хәтерләтә иде. Ба! Мөхлис шаклар катты! Бу битлек анасы Гадиләнең йөзеннән күчереп ясалган түгелме соң?! Нәкъ шул, тач-тач! Мөхлис аптырап бер «анасы»на, бер шайтанга карап куйды. Иблис, астыртын гына елмаеп, Мөхлискә күз кысты. Анасына охшаган әлеге хатын шулчак аның янына килеп басты.

– Әни, бу синме? – дип эндәште аңа улы. Хатын дәшмәде, тик кулын изәп, аны читкә чакырды.

– Мөхлис, барма аның янына! – дип кисәтте аны Фәния. – Алданма, ул синең анаң түгел... ял...ган... ул...

Ләкин бу сүзләр Фәниягә шактый кыйбатка төште. Ул соңгы сүзен әйтеп бетерә алмады, ярты сүздә аның авызы кыегаеп калды һәм ул бөтенләй сөйләшмәс хәлгә җитте. Шуның өстенә бер убырлы карчык йөгереп килеп, җен тизлеге белән аның затлы киемнәрен салдырып атты һәм аңар үзенең шакшы, сәләмә киемнәрен кидереп куйды. Фәния аңар каршы тора алмады. Сәләмә киемнәр эчендә калган чибәр ханым шундук үзгәрде: ул күзгә күренеп картайды, бар булган чибәрлеген, гүзәллеген югалтты һәм, үзеннән дә ямьсезрәк убырлы карчыклар белән кәмәхуа килеп, кызыл шәраб эчә-эчә, кызу гына биергә тотынды...

– Әни...

– Әү, улым?

– Син чынлап та минем әниме?

– Әйе, улым, бу мин, синең әниең! – дип тәкрарлады хатын. – Әйе, мин...

– Син! Син исән! – дип кычкыра-кычкыра сөенде Мөхлис һәм баладай хисләнеп, анасын кочаклап алды. Кочты, ләкин корт чаккандай, шундук читкә атылды, тәне боз кебек сап-салкын иде. Әйтерсең, җаны каядыр чыгып качкан иде. Сәер әни иде бу, үзе улы белән сөйләшә, ә үзенең күзе һаман да шайтан ягында иде. – Ни булды сиңа, әни?

– Йөрәгем туктаган, ә җаным каядыр очып йөри...

– Иблис сине исән дип әйтте...

– Ялгышасың, улым, мин – шайтан корбаны...

– Ничек?

– Ул гына җитте минем башыма, – дип тыныч кына аңлатты хатын. Ул хәзер беркемнән дә берни яшерми, хәтта иблистән дә, күрәсең, алар үзара килешкәннәр инде, һәрхәлдә егеткә шулай тоелды. Шайтаннан берни дә яшереп булмый, ул теләсә нинди сереңне дә ача, барысын да белеп, ишетеп тора. – Энең Азат тугачтын, баламны миннән тартып алырга теләде ул. Мин моңа бөтен көчем белән каршы тордым. Чөнки беләм, әгәр бала аның кулына эләксә, ул инде исән калмый...

– Менә кая ята икән аның сере, – диде Мөхлис, ниһаять, төшенеп. – Менә ни өчен иблис минем якамнан алган икән!

– Мин баламны бирмәдем һәм иблис шуннан соң мине харап итте! Бала да үлде... Атаң җирләгәндер дип уйлыйм... баламны... газиз баламны...

– Әни...

Ләкин Мөхлис анасына сүз кушарга да өлгерә алмыйча калды, шулчак ике арада иблис үзе пәйда булды. Анасы Гадилә булып сөйләшкән, баласын югалтканына сызланып вә җан атып торган бу хатын кинәт кенә битлеген салып атты һәм шундук аның кем икәнлеге, бу аның чын анасы түгел, ә ана ролен башкаручы дублёр булганлыгы ачыкланды. «Кайда иблис, шунда явызлык, шунда ялган, шунда алдау!» – дип сызланды егет...

Әллә кызык өчен, әллә йоласын китерү өчен, каенга аскан Сергуньны убырлар, көлешә-көлешә, элмәктән ычкындырып, хуҗа каршына китереп тезләндерделәр.

– Нишлисең килә? – дип сорады аңардан бөек явыз.

– Асый...сым! – дип өзгәләнде аягына да басалмаган исерек.

– Китерегез аңар ашарга! – дип әмер бирде хуҗа.

Мескенкәйне шундук табынга утыртып, алдына ризык куйдылар. Җиңел кулдан аңа бәрәңге боламыгы белән кыздырылган тавык боты эләкте. Ләкин комсызланып авызына ризык төя башлаган исерек, кинәт кенә чыраен сытып,

үзен ашатучыларга канәгатьсезлек белдерде. Боламыкның тозы юк иде. Монда азыкны тозсыз гына пешерәләр икән. Убырның: «Ни булды?» – дигән соравына ул: «Тозсыз ашый алмыйм! Кая тоз?!» – дип ыңгырашты.

Әле кайчан гына аның җан газапларына кул чабып торган һәм аны бер мизгелдә оныткан Катюшасы халат кесәсеннән шырпы тартмасы тартып чыгарды, ә ул тартмага тоз салынган иде. Ул аны өйдән үк кесәсенә салып чыккан булган, күрәсең. «Слава Богу, соль нашлась, соль!» – дип сөенеченнән кычкырды Сергунь. Сабый бала диярсең, билләһи! Ләкин аның бер мыскал тоз өчен Аллаһыны мактап искә алуы табындагыларны бер кавым ярсытып җибәрде. «Кем? Кем аны мактап искә алды?!» – дип кычкырды хуҗа. «Мин инде, мин, кем булсын! Тозсыз ашый алмыйм бит!» – дип акланды гурман.

«Бу узаманны хәзер үк юк итәргә, юк итәргә!» – дип боерык бирде шайтан үзенең яраннарына. Шуны гына көткәндәй, битлек кигән ике әзмәвер, ике кавалер шундук  Сергуньга ташланды. Кем белән сугышканын әле дә белмәгән, аңлашмаган исерек тегеләрне бер сугуда җиргә сеңдерде. «Русские не сдаются!» – дип акырды ул карлыккан тавышы белән. Бу минутта, әлбәттә, ул инде үзен җиңүче дип хис итте, чөнки кул сугышында урысларны сирәк дошман җиңә алган. Чирәмдә тәгәрәп яткан җеннәр торып, кабат Сергуньга ташландылар һәм инде аны канга батырганчы, каты итеп, типкәли-типкәли кыйнадылар. Бу канкойгыч туйның ни белән бетәсе әлегә беркемгә дә билгеле түгел иде, бәхеткә, шулчак офык читендә сызылып таң ата башлады һәм беренче әтәч тавышлары ишетелде:

– Кикри-күк! Кикри-күк...

Барысы да асты өскә килде. Убырлы карчыклар, кавалерлар һәм хәтта иблис тә каядыр очып китеп юк булдылар. Урмандагы алан, аландагы табын да күз алдыннан эреп юкка чыкты...

Балконлы чарлакта – башы китә язган Мөхлис һәм сачлары тузгыган, шыксыз сәләмә киемнән яшь бичә генә басып калды. Бертуктаусыз шаркылдап көлгән һәм цирк артистына охшаган Фәния күкрәкләрен, шәрә ботларын ачып, бөгелә-сыгыла, җүләр сымак идәндә аунады...

## 10. Имансызлар

Имансызлыкның чиге юк, дигән бер акыл иясе. Гаянны да шундый авыр уйлар биләп алды. Дөньяда бар нәрсәне дә кичереп була кебек, ләкин якын вә газиз кешеңнең сатылуын кичерү мөмкин нәрсә түгелдер...

Дөньясына кул селтәп, яраланган иңбашын ак простыня кисәге белән кысып бәйләгән Гаян түрдә боргаланып-сыргаланып биегән һәм кәмит ясап торган сәләмә киемле хатынны шәйләп алгач та, аның бу кыланышларына артык исе китмәде, битараф калды. Төнге фаҗига, төнге хыянәт аның дөньяга күзен ачкан иде инде. «Кем бу? Кешеме бу? Кеше дип әйтеп буламы моны?» Аның әлеге кыланчык хатынга әйткән тәүге сүзе шул булды. Сихер кочагында маймыраган хатын тыпырдап бии-бии Гаян каршына килеп басты, тезен чүгеп, ире алдында башын иде: «Кадерлем, ал мине кочагыңа! Кил, кочакла мине, үп! Ай... җаным минем... ай... кадерлем!»

Алышынган хатын бер Мөхлискә, бер Гаянга ташланды. Гаян, косардай булып, күз карашын читкә алды, Мөхлис ачу белән аны этеп җибәрде. Карап торышка ул чын-чынлап исерек хатынга охшаган иде.

– Әти, бу бит синең хатының Фәния!

– Фәния? Ә сез кем? – Әллә дөресен әйтә, әллә белмәмешкә генә сабыша Гаян.

– Улың Мөхлис.

– Юк...

– Ничек?

– Минем улым да, хатыным да юк.

– Бар... Менә алар синең каршыңда! Мин – улың, ә бу – синең хатының, никахлы хатының...

– Бар иде кайчандыр алар, ә хәзер юк...

– Нишләп юк?

– Мин аларның икесен дә күңел түремнән сызып аттым.

– Бәхетем... кил... ах... уй... уй... – Песи кебек сырпаланган Фәния бераздан гөпелдәп идәнгә ауды. Аның инде сикерер, хәтта селкенер хәле дә калмаган, ләкин ниндидер үзгә сихри көч аны һаман да шушы сәер гамәлләргә этәрә сымак иде...

– Тере кешене сызып ташлап булмый, әти! – дип үгетләде аны улы. – Син безне аңларга тиеш...

– Аңларга? Ничек? – Дөньяның, кешеләрнең әшәкелеген үз күңеле аша уздырган кешене инандыру мөмкин нәрсә түгел иде, күрәсең. – Улы атасының чәенә агу салса, аңар үлем теләсә? Никахлы хатының, якын кешең каршыңда ук зина кылса? Моны ничек аңларга була?

– Әти, син барысын да аңлыйсың...

– Кемдер миңа әти дип эндәште түгелме? Кем ул? Синме? Син дәштеңме?

– Әти, җүләр сатма инде! – дип кычкырды аңар Мөхлис. – Иң элек Фәниянең бу сәләмә киемнәрен салдырып ягарга кирәк. Әти, аңарда җен киеме! Салдыр!

– Ә бу кеше... тфү... Каян кайткан соң?

– Гыйш-гыйшрәттән, әти, җеннәр туеннан!

– Каян?

– Шабаштан!!!

– Мин шуңар ярдәм итәргә тиешме?

Мескен хатын, шуыша-шуыша, иренең аяк очына килеп сарылды, аягын кочып, аның тезеннән үпте. Гаян аны аягы белән этеп җибәрде, җен хатын арты белән идәнгә мәтәлде. Ләкин кылануыннан туктамады: кабат үрмәләп килеп, иренең аягына бәрелде, куллары белән аның күкрәгенә ябышып, акрын гына өскә күтәрелде. Шулчак Гаян, үз-үзен белештермичә, хатынның күкрәген каплап торган пычрак, сәләмә киемнәрне бар көченә ертып төшерде дә, башын аска иеп, кырыйга кагылды. Сәләмәләр берьюлы идәнгә коелды: хатын шәрә калды. Мөхлис, сүз дә дәшә алмастай, өнсез иде. Аның үз гомерендә мондый да сылу тәнле, мондый да матур мөчәле хатын-кызны күргәне булмады һәм ул, ирексездән, шундый гүзәллеккә ия булган газиз атасыннан көнләшеп куйды. Ә бит чынлап та көнләшерлек!

Хурлыклы киемнәреннән арынган һәм әле һаман да үз хәленә кайта алмыйча интеккән Фәния кинәт кенә тынычланып калды: куркып суырылды, җыерылды һәм үксеп еларга тотынды.

– Гаян... кичер мине... шайтан бутады мине, шайтан! – дип үкседе хатын.

– Оятсыз! – дип акырды ир һәм хатынына карават өстендә аунап яткан киемнәрен ташлады. – Бар! Киен! Җан көеге булып торма монда! Бүген үк өйгә кайтабыз һәм кайтуга ук аерылышабыз!

Фәния, үз киемнәрен эләктереп, коридорга чыгып чапты. Бөтен нәрсәсе асты-өскә килгән шыксыз чарлакта ата белән улы гына утырып калды.

– Фәния дөрес әйтә, – дип телгә килде Мөхлис. – Безне чынлап та иблис бутады, әткәй, шайтан бутады. Ул котыртты безне, ул...

– Акланыр чарагыз калмагач, хәзер нindидер шайтанга, иблискә сылтарга гына кала инде. Җиңел бит, ансат...

– Әти, син шуны аңла: һәр кешенең күңел түрендә ике «мин» утыра. Ул «мин» менә миндә дә бар...

– Анысы нәрсә тагын?

– Менә шул «мин» минем исемнән коточкыч җинаятьләр ясый, ә мин шул җинаятьләр өчен җавап бирергә тиеш. Тик ул свулыч үзе һаман да читтә кала. Ул минем уң канатым, дус-төстәшем генә түгел, ул әле минем зур дошманым да, көндәшем дә, беләсең килсә...

– Нидер бутыйсың син, башымны катырасың?!

– Аңла, әлеге җинаятьләрнең берсен дә мин кылмадым...

– Ә кем кылды?

– Минем икенче ягым, икенче яртым...

– Кайсы ягың?

– Шайтан ягым...

– Да-а! Син үз-үзеңә хуҗа түгел, димәк?!

– Мин аны тыя алмыйм, әти...

– Кемне?

– Икенче яртымны...

– Аңардан качып булмыймыни соң?

– Юк... Качтың исә, шундук...

– Нишли?

– ...аркага сикерә...

Яшәү дәверендә күп нәрсәләр күреп, күп читенлекләр кичергән һәм гаҗәеп зур кешеләр белән аралашкан Гаян өчен улы сөйләгән ошбу хикмәтләр кыргый һәм шул ук вакытта артык самими булып тоелды. Акча, бизнес һәм банк операцияләре тирәсендә чуалган банкир Мөхлиснең әлеге сафсатасын, тузга язмаган мәгънәсез, буш сүзләрен иң элек ул яшьлек җүләрлегенә сылтады. Ләкин үзен Мөхлиснең дусты итеп таныткан Евгений Ваганович дигән бәндәнең (улы сөйләве буенча!) кеше түгеллеге, ә иблис, шайтан булуына инана башлагач, Гаян да азрак уйлана калды. Моннан бер егерме еллар элек, «алласызлар» заманы чорында, ул мондый әкияткә ышанмаган булса, хәзерге чорда, дин көч алган чагында иблиснең, шайтанның барлыгын бөтенләй үк инкарь итә алмады. Ләкин монда аңлашылмаган нәрсәләр дә бар кебек. Атасы җибәреп яткан акчаларны укуга һәм фатирга тотасы урынга, улының бозык һәм азгын тормыш алып баруына бер шайтанны гына гаепләү дөрес булыр микән?

– Ярый, – дип нәтиҗә ясады атасы, – әйтик, сине шайтан котыртты, ди. Инде котырып алдың, җитәр, бәлкем, туктарга вакыттыр! Нәрсә, котыла алмыйсыңмы?

– Юк, әти, – дип борынын салындырды улы, – миңа аңардан котылу авыр булачак...

– Нигә?

– Гөнаһ шомлыгына каршы...

– Әйтеп бетер!

– Мин аның белән килешү төзегән идем.

– Ничегрәк төзедегез?

– Бер нөсхәсен мин аның юк иттем, ләкин икенчесе иблиснең үзендә калды.

– Юрист белән төзедегезме?

– Нәрсәне?

– Килешүне?

– Юк, билгеле!

– Беркайчан да килешүләрне юристтан башка төзергә ярамый дип күпме әйтәм эштәгеләргә дә, юк, аңламыйлар! Күрә торып үз-үзеңне алдау бит ул, үз-үзеңә үлем карары чыгару, – дип акыл өйрәтте банкир.

Тын гына, тавышын басып кына сөйләшкән Мөхлис кинәт кенә урынынннан торып басты һәм туктаусыз йөренә, үз-үзе белән сөйләшә башлады. «Мин ул иблисне барыбер җиңәм, җи-и-нәм!!!» – дип акырды ул. Акыруы булды – эчен тотып, егылуы да булды! Әйтерсең, аның эченә ат китереп типте – авызыннан кан һәм күбек китте...

– Улым, ни булды сиңа? – дип, ярдәмгә ташланды аңа атасы.

– Иблис... иблис үчен ала, – дип, ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады егет.

– Сихерләгәннәр сине, улым, сине Бөгелмәгә алып кайтырга кирәк! Сручны!

– Булмый, әти... Кая китеп олаксаң да... таба ул...

– Мулла алып киләм мин сиңа, мулла! Өшкерсен үзеңне...

– Мулла?! – дип, саран гына елмайды егет. – Питердамы?

– Питерда менә дигән мәчет бар. Пушкинодан кайтышлый, шул мәчеткә кереп, сәдака салып чыктык... хатын белән... Тфү... шул хатынны...

– Әти... – Мөхлиснең инде тыны кысыла башлаган иде.

– Әү?

– Лулу ничек анда?

– Кем ул Лулу?

– Луиза.

– Юк ул...

– Ничек?

– Үлде...

Мөхлис Лулуның нидән үлгәнен сорамады, ул яраткан кызының наркотиклар кулланганын яхшы белә иде. Наркотикны артык күп куллануудан үлгәндер, күрәсең. Бөгелмәдә рок-н-ролл җырлый алучы бердәнбер кеше иде ул, ләкин азгын һәм бозык иде. Улының шушы кыз тәэсирендә начар юлга басуыннан куркып, атасы юкка гына аны Бөгелмәдән Питерга сөрмәде. Ләкин бу сөрелүнең нигәдер файдасы булмады, киресенчә, ул аны һәлакәткә китереп җиткерде...

– Әгәр син мине Бөгелмәдән җибәрмәгән булсаң, – дип ыңгырашты Мөхлис, – Лулу исән калган булыр иде. Мин аны саклап кала алган булыр идем...

– Син кадерлеме миңа, улым, әллә Лулумы?!

Шулчак аның каршына Фәния чыкты. Киенгән, ясанган, тынычланган, алдагы юләрлекләреннән инде берни дә калмаган. Үзен бик нык гаепле сизгән хатын, ире алдында башын иеп, оялып басып торды:

– Кичер... мине...

– Әти... аның чынлап та гаебе юк... Шайтан... бутады аны... шайтан...

Гаян аның сүзләренә карап кына эремәде. Ул әле һаман да, үзен гаепле сизеп, башын аска иеп торган мескен хатынга: «Хәзер үк! Мәчеткә!» – дип кычкырды...

## 11. Варвара һәм акча янчыгы

Мөхлис, атасы белән үги анасы чыгып китүгә, аяк киемен дә салмыйча, караватка сузылып ятты. Хәлсез калган гәүдәсе каядыр төшеп югалгандай тоелды һәм ул изрәп йокыга киткәнен сизми дә калды. Йокысыннан уянып, күзен ачканда, аның каршында бер юан гына хатын басып тора иде. Бу – алыпсатар Варвара иде. Ул монда Евгений Вагановичны эзләп килгән икән. Хәерчегә җил гел дә каршы. Хәер, шактый әйбәт башланган ул. Варвара, Ваганычның киңәшен тотып, ул биргән серле порошокны су белән кушып, шуны сатып бик нык баеп киткән. Ләкин бер көннәре, Аничков күпереннән чыгып барганда, аның акча тулы янчыгын нindидер бер зәхмәти нәрсә кулыннан тартып алып, аны каядыр очыртып киткән. Бар булган байлыгы әнә шулай җилгә очкан, җүләр хатынның сөялле учында тиен акчалар гына калган...

– Апай, мин сиңа бер генә киңәш бирә алам, – диде аңа Мөхлис, марҗаның урланган акча янчыгы турында сөйләгән сүзләрен тыңлап арыгач. – Аллаһы Тәгалә сезгә кисәтү ясаган...

– Нинди?

– Сиңа сату-алу эше белән шөгыльләнергә ярамый, аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм...

– Аңласаң, хәзергә хушып тор!

– Рәхмәт киңәшең өчен, тик...

– Нәрсә тагын?

– Кызыксынуым бик көчәйде. Теге кеше кем иде ул, белсәң әйт әле?!

– Кемне дисең?

– Синең дустыңны... кем иде ул?

– Кеше түгел ул...

– Кем?

– Иблис иде ул, апай!

– Ә!!!

– Иблис...

Мөхлиснең әлеге сүзеннән коты очкан марҗа тиз-тиз генә чукына башлады. Гадәттә, христиан динендәгеләр иконага карап чукыналар, ә бу бүлмәдә андый нәрсә табылмагач, Варвара чебен тәрәтләгән саргылт көзгегә карап чукынды...

«Күренми теге, – дип уйлап куйды егет, марҗа чыгып югалгач. – Әллә Аллаһыны искә алуның файдасы булды микән? Бәлкем, ул мин уйлаган нәрсә дә булмагандыр, ә?! Ә кем? Кем дип... утопия...

## 12. Ике яклы килешү

Кая ул... Яман кеше белән бер бәйләнсәң, аңардан котылам димә икән! Әнә ул... артта... почмакта... кабат сүз алды:

– Вакыт килеп җитте, дускай, санаулы минутлар гына калып бара. Тиздән син тулысы белән минем карамакта булачаксың, мин синең белән ни телим, шуны эшләячәкмен. Сиңа җитәрлек хезмәт иттем. Иң элек үчемне акылсыз анаң, җүнсез атаң өчен алырга теләгән идем. Җәзаның да йомшагын әзерләдем. Тик син үзеңне бик начар кеше итеп таныттың, мине бик нык ярсыттың, чыгырымнан чыгардың. Шуның өчен сине җәзалап үтерәчәкләр! – Куркудан Мөхлиснең тәннәре калтыранды, күз бәбәкләре тартышты һәм тыны кысылды. – Әнә күрәсеңме!

Шулчак чарлакта озын чәчле ике абзый пәйда булды. Болар шайтанга ияреп йөрүче, шайтан туенда катнашучы баягы скрипкачылар, безнеңчә әйтсәк, мәшһүр сәнгать осталары иде. Әнә шул музыкантлар кулындагы скрипка уйнап җибәрүгә үк, Мөхлиснең гомере кыл сымак өзелеп төшәчәк. Иблис шулай дип аңлатты.

Менә музыкантлар скрипкаларын ияк белән кысып, смычокларын югары күтәрделәр һәм кырын күз белән иблискә карап куйдылар. Җәлладның үлемгә хөкем ителгән корбанын диварга терәп, мылтыктан атарга әзерләнүе белән бер иде инде бу. Мөхлис үзенең үлемен көтте, ләкин шайтан нигәдер музыкантларына уйнарга дигән әмерен бирмәде...

– Син минем кулда! Ха-ха! – Караңгы чат шаркылдап көлде.

– Сөенмә, иблис, – диде шулчак Мөхлис (үҗәтлек һәм кирелек җитәрлек иде аңарда!). – Бу гаделсезлектән, нәгъләттән мин ничек тә котыла алырмын...

– Котыла алмыйсың...

– Нигә?

– Ике яклы килешү төзелгән.

– Килешү? Ә кая ул?

– Оныттыңмы? Үз каның белән яздың син аны.

– Ә миндә юк ул, – дип җүләр сатты егет.

– Бар ул синдә, эзлә...

– Яндырдым мин аны!

– Ялгышкансың. Яндырып кына котылып булмый. Килешү ике нөсхәдә төзелде, ике экземплярда, ягъни. Менә ул, күрдеңме?! – дип, иблис аңар килешү нөсхәсен чыгарып күрсәтте. – Күрдеңме?!

– Күрдем... Тик ул дөрес килешү түгел...

– Ничек? Анда син язган килешү һәм синең имзаң тора...

– Анда җитешсезлекләр бик күп, – дип акыл сатты егет. – Ул килешүдә, шартнамәдә фәкать бер генә якның өстенлекләре каралган, синеке генә, ягъни! Ә кая ирек? Кая демократия? Мөстәкыйльлек, канса да кансув! Берсе дә юк, гел алдау, гел ялган, гел ышандыру! Бәдрәфкә чыгарга да ярамый торган бер әрәм кәгазь бит ул...

– Син!!! – Акыру гына түгел, бу – үкерү иде! Күрәсең, үз дөньясының иминлеге, бөтенлеге өчен борчылган һәм дә бөек яулау хисләре белән янган шайтанбаш, милләте булмаса да, Мөхлиснең әлеге фетнәле сүзләрен кимсетү вә янау кебегрәк кабул итте. – Шулай сөйләшәсеңме минем белән?!

– Ә ничек сөйләшим ди тагын?! Күпме кирәк сиңа ирек – шулхәтле ал, дип үзең үк вәгъдә бирдең! Алган гына идем, име, син шундук бугазыма ябыштың! Шушымы ирек? Шулмы демократия?

– Килешү төзегәндә, кая карадың?

– Законлы килешү түгел бу, бер буш кәгазь... Аннан ул...

– Нәрсә тагын? – дип шикләнде шайтан.

– Нотариуста расланмаган... Штампысы бармы?

– Нинди нотариус?! Власть та, нотариус та үз кулымда минем, аңладыңмы?!

– Юк, син нотариус була алмыйсың!

– Яхшы, – дип килеште иблис, – әгәр дә син шуны таләп итәсең икән, мин сиңа килешүне нотариус аша раслатырмын!

– Юрист аша да! – дип өстәде егет.

– Яхшы! – дип кузгалды шайтан.

– Тукта, иблис токымы! – дип кычкырды аңа Мөхлис. – Сизәм, миңа күп

калмады, бер тотынгач, башыма җитми калмассың инде. Бу ялгышларым өчен беркем дә гаепле түгел, фәкать үзем генә гаепле. Тик үтенеп сорыйм, әтиемә һәм аның хатынына орынма, яме! Аларның гаебе юк, гөнаһсыз алар...

– Гөнаһсыз? – дип астыртын елмайды шайтан. – Гөнаһсыз булулары белән гөнаһлы алар минем алда. Ха-ха!

– Әй, син, иблис токымы!

– Тыңлыйм?!

– Соңгы мәртәбә булса да синең арт сабагыңны бер укытып аласым килә!

– Ничек итеп?

– Мә!

Әйе, инде югалтыр нәрсә калмаган иде. Ишекне каты итеп ябып китәргә теләгән Мөхлис кул уңында торган бер дәү урындыкны күтәреп алып, иблиснең аркасына томырды. Шул хәлләрдән соң аның үзендә дә җен көче барлыкка килгән иде, күрәсең, шайтанга шактый каты эләкте һәм ул ава-түнә кабат караңгыга кереп югалды. Икенче урындыкны ул музыкантларга күтәрде, ләкин тегеләре хәлне шундук аңлап, тиз генә юк булдылар. Мөхлис кычкыра-кычкыра, саташа-саташа көлде:

– Ха-ха-ха! Бетте шайтан... Дөмекте! Ха-ха-ха! Бет-те...

Күтәрелгән урындык дивардагы көзгегә очты. Көзге, челпәрәмә килеп, коелып төште. «Минме соң бу? Минме?» – дип, сөйләнә-сөйләнә, ул аңын җуеп идәнгә егылды.

Иблис озак көттермәде: нотариуста расланган килешү кәгазенең икенче нөсхәсе түшәм ярыгыннан идәндә чалкан яткан Мөхлиснең өстенә очып төште...

Бу юлы рок-н-ролл яңгырамады, ә тын гына блюз уйнады. Elvis Presley... «Love Me Tender» ...мәхәббәт вә сөю... мәңгелек...

## 13. P.S.

Гаян улын Бөгелмәгә алып кайтты, шактый зур акчалар түләп, җирле институтка укырга кертте. Аны Питерда калдырудан мәгънә юк иде, чөнки ул анда бөтенләй юлдан язачак. Кайткан шәпкә үк улын кулга алды, дин әһелләре белән таныштырды, мәчеткә йөртте, үзе белән җомга намазыннан калдырмады. Мөхлис, баштарак киреләнеп маташса да, соңыннан күнде, чөнки күнмичә мөмкин дә түгел иде. Теге кәҗә кыяфәтле Люцифер, килешү кәгазен күтәреп, шактый озак кына аның яныннан китмичә йөрде. Бары тик мәчеткә барып, белгән сүрәләрен укыштыргач кына, ул шайтани зат күз алдыннан беразга гына булса да югала торган булды...

Шайтанны чакырырга ярамый, чакырсаң, ул килә дә җитә, диләр. Мөхлиснең дә соңыннан: «Иблис кайда да бар. Әнә хәзер ул минем артта гына утыра. Әнә, әнә... теге караңгы почмакта, чакыр, шундук каршыңа килә дә баса!» – дип сөйләнә торган бер яман гадәте барлыкка килде. Әйе, ул әллә кайда еракта түгел, ул һәрвакыт якында, янда гына, ләкин Мөхлис тә, Мөхлиснең атасы Гаян да бу дөньяда шайтанны, иблисне җиңәрлек көч барлыгын яхшы беләләр, ул – бердәнбер илаһи көч – иман.



Илшат
Вәлиулла

# МЕҢ ТӨСМЕРЛЕ ҖИҺАН ҮЗЕ...

## Ә беркөнне...

Ә беркөнне... алар безне «үткәндә яши», диделәр,
Ә без бары фасыллар агышында бераз уйландык.
Тик Әл-Гафур биргән карлар төшкәч учка чайкалышып,
Без әле бу җирдә гүзәл яңарыш барлыгын тойдык...

Ә беркөнне... алар безне «инде сизгерсез», диделәр,
Ә без  дөньядагы ак һәм карага бераз яраштык.
ТикӘн-Нур биргән йолдыз нурлары калебләргә үткәч,
Без яңа саф хыял-максатлар өчен янә уяндык...

Ә беркөнне... алар безне «инде сүлпәннәр», диделәр,
Ә без кайбер максатларга ирешмәүдәнме сүрелдек.
Тик бөек Аллаһ-Әл-Рәхиим безгә миһербанлы булгач,
Үсемлекләр белән бергә кояшка янә үрелдек...

***

Әйттеләр: карлар түбән оча, дип,
Ә дөресендә ак карларга таба оча икән
Мең төсмерле җиһан үзе...
Шәһәрләр, авыллар...
Адашып югалган ярымтукталышлар...

Илшат ВӘЛИУЛЛА (1967) – *шагыйрь, публицист; «Мәңгелек бәхет эзләреннән», «Һәр шагыйрь бер дәрья» исемле китаплар авторы. Кукмара районы Зур Сәрдек авылында яши.*

Һәм аларда без очабыз,
Безнең үзгәрмәүчән бетмәс хыял-теләкләр,
Безне тырышып ышыклаган агачлар, –
Безнең саваплар,
Әйтерсең лә аларга җитми аз гына ныклык...
Безнең гөнаһлар,
Әйтерсең лә аларга кирәк аклыкта юылу...

Әйтерсең лә безнең элеккеге пакь хыяллар,
Безнең беренче саф хисләр,
Мәхәббәтләр,
Иң матур теләкләр
Кайчандыр киткәннәрдер дә Күккә,
Янә җиһанга кайталар ап-ак карларга әверелә-әверелә...
Һәм дөнья күмелә янә ямьгә,
Матурлыкка, сафлыкка, эчкерсезлеккә
Һәм янә тәүбәгә,
Чистарынуга өзлексез
Чакыра...

## Өмет

Без дөньядан нидер өметләнеп көттек,
Ә дөнья бездән берни көтмәде,
Ә бары үзе белгән әкиятләрне
Яз, җәй, көз, кыш итеп көн дә сөйләде.

Без күкләрдән нидер таләп иттек һаман,
Күкләр исә бездән таләп итмәде.
Ә бары үзе белгән әкиятләрне
Яңгыр, болыт, карлар итеп җибәрде.

Без хыялда җирне еш оныта идек,
Ә җир безне оныта белмәде.
Ә бары үзе белгән әкиятләрне
Урман-кырлар, диңгез итеп бизәде...

***

Ә мин хыяллардан аерылмыйм әле.
Аерылсам хыяллардан, ни соң калыр?
Инде ирешелгән үрләр калырлар да,
Ирешелмәгән биеклекләр югалыр...

Ә мин өметләрдән аерылмыйм әле.
Аерылсам өметләрдән, ни соң калыр?
Җиңел чакта, билгеле, җиңел булыр ул,
Авыр чакта кайсы хис безне коткарыр?!.

Ә мин мәхәббәттән аерылмыйм әле.
Аерылсам мәхәббәттән, ни соң калыр?
Бу ярлар, билгеле, монда калырлар ул,
Тик, каршы ярга саф күперләр югалыр...

## Тәкъвалык

Күпме вакыт бу җир өстендә үтелгән,
Һәм узар әле тагын күпме вакытлар.
Тик матур вакыт булып искә алыныр
Тәкъвараклар тормыш итеп яткан чаклар...

Күпме еллар бу җир өстендә үтелгән,
Һәм узар әле янәдән күпме еллар.
Тик матур эзләрне яратып сакларлар
Тәкъвараклар басып узган кантар юллар...

Күпме көч бу җирдә инанып куелган,
Һәм куелыр әле янә күпме көчләр!..
Тик матур хисләр белән искә алыныр
Тәкъвараклар калдырган якты гамәлләр...

***

Бер-береңне аңлар өчен кайчак җитә мизгел дә,
Ә кайчак җитмәс төсле хәтта озын айлар.
«Аңларлармы микән болар бер-берен?» – дип уйланып,
Карап уза кебек адәмнәргә фасыллар...

Бер-береңә килешергә кайчак җитә бер адым,
Ә кайчак җитмәс төсле хәтта чакрымнар.
«Бер-беренә юл куярлармы икән?!» – дип сызланып,
Таңда сүнә төсле төнне кичкән утлар...

Бер-береңне аңлар өчен кайчак җитә бер сүз дә,
Ә кайчак җитмәс кебек озак аңлашулар.
«Берсе-берсен кичерсәләр иде...» – дип теләк теләп,
Күкләр укый төсле кешеләргә шигырьләр...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Айгөл
Әхмәтгалиева

# САГЫНГАН ЧАКЛАРЫМДА...

ДРАМА

*...Без сыерлы йортта туып үстек,*
*Ул бит безне исән саклады.*
*Сыер эзләренә баса-баса,*
*Безнең тыйнак бәхет атлады.*
*Балачакның шушы шәфкатьлесе*
*Тиң булмаса әгәр бер җырга,*
*Мин багышлап шигырь язмас идем*
*Шомырткайга – безнең сыерга.*
*Юкка әйтмәгәндер зирәк әткәм:*
*– Минем өчен СССР –*
*Чыжылдатып безгә сөтен биргән*
*Шушы юмарт Шомырткай-сыер...*
Зөлфәт

**2 ПӘРДӘ, 16 КҮРЕНЕШТӘ**

**К а т н а ш а л а р**:

Я ш ь Ш а һ и д ә – яшь кыз. Чая, нык холыклы.

К а р т Ш а һ и д ә – 90 яшьләрдә. Шактый нык күренә.

З ә к и я – яшь кыз, Шаһидәнең апасы.

Н и г ъ м ә т – 40 яшьләрдә, Шаһидәнең әтисе. Караңгырак чырайлы, бер кулы гарип, басынкырак табигатьле.

М ә р з и я – Шаһидәнең әнисе. Мулла кызы булганга, үз-үзен тотышында беркадәр зыялылык бар.

Ә ү х ә т – күрше егете. Шаһидәнең яшьтәше.

Г ө л с е м – 37-45 яшьләрдә, Әүхәтнең әнисе. Телчән хатын.

К а с ы й м – 40 яшьләрдә, Әүхәтнең әтисе. Ябык кына, чирләшкә генә кыяфәтле.

М ә р ф у г а – 40 яшьләрдә, авыл хатыны.

С ә л и м ә – 40 яшьләрдә, авыл хатыны.

С а б и р а – Сәлимәнең кызы, Шаһидәдән бер-ике яшькә кечерәк.

Х ә м и т – 40-45 яшьләрдә, авыл активисты. Әрсез, оятсыз, үзен власть иясе итеп хис итәргә, шуны башкаларга күрсәтергә яратучы бер адәм.

Ф ә н и я – Шаһидәнең төпчек кызы, 45 яшьләр тирәсендә.

Эпизодларда: яшь кызлар, авыл ирләре.

---

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА – *язучы, пьесалар һәм киносценарийлар авторы; «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. Чаллыда яши.*

*Вакыйга егерме беренче гасыр башында һәм 1935-1945 еллар тирәсендә бара.*

## 1 ПӘРДӘ

### 1 күренеш

*Безнең көннәр. Авыл өенең ишегалды. Ишегалдына өй ишеге, болдыр караган. Бер якта – капка, аның янында бүрәнә өеме, икенче якта ике сәндерәле эскәмия (аскы өлеше – эскәмия ролен, өске сәндерәсе кайбер күренешләрдә сәке ролен дә уйный ала). Койма башына чиләк эленгән. Эскәмиядә, таякка таянып, карт Ш а һ и д ә утыра. Озын итәкле аксыл күлмәк, аның өстеннән кыска җиңле камзул кигән. Сузып-сузып сыер мөгрәгән тавыш ишетелә, ул торган саен ерагая. Шаһидә бер учы белән авызын каплаган, әйтерсең, кулын төшерсә, менә-менә кычкырып елап җибәрер...*

Ш а һ и д ә *(капка ягына моңаеп карап тора, үзалдына)*. И Ходаем, сыйлы көнем – сыерлы көнемнән аерылгач, ни белән генә көн үткәрермен? *(Түзми, сулыгып кына үзалдына елап җибәрә.)*

*Шулчак болдырга Ф ә н и я чыгып баса. Кулында тас, анда юылган керләр. Әнисен бик кызганып карап тора, үзенең дә күңеле тула. Тик ничек тә сиздермәскә тырыша.*

Ф ә н и я . Әнкәй, йөрәгеңне бозып утырма инде, әйдә, кер. Мин дә җыенып беттем бугай.

Ш а һ и д ә . Күрчәле, яланаяк чыгып баскан, акыл кермәсә дә кермәс икән, агай. Фәния, сиңа әйтәм түгелме?

Ф ә н и я . Киям, киям, менә, синең башмагыңны кидем.

*Фәния кер эләргә бау суза. Яшел җирлеккә чәчәкләр төшкән җәймәләр элә.*

Ш а һ и д ә *(эскәмиядә утырган килеш кенә сөйләнә)*. Абыеңнар да, син дә, ничә кайтсагыз, «нигә сыер асрап интегәсез, кибет тулы сөте, мае», ди идегез, тынычланырсыз инде.

Ф ә н и я *(кер элә-элә сөйләшә)*. Соң, үзеңне җәлләп әйтәбез ләса. Кулларыңны кара, кәкрәеп каткан, һаман сыер дисең.

Ш а һ и д ә . Атагыз иртәрәк китеп барды. Икәү булсак, ничек тә теркелдәр идек әле. Сезнең сүзгә карап тормас идек. Булганны бетерүкәйләр бик тиз шул...

Ф ә н и я . Үзебезгә алып китәм дибез – тыңламыйсың.

Ш а һ и д ә . Таш калагызда тыным кысыла, кызым, ике көн дә тора алмыйм мин анда.

Ф ә н и я . Алып китәм дигәч, уртанчы абыйны да әрләп ташлагансың.

Ш а һ и д ә . Әрләми ни. Аның хатыны, җиңгәңне әйтәм, зарланудан башканы белми. Бу җире авырта, теге җире...

Ф ә н и я *(көлеп)*. Соң, әнкәй, пенсиядә бит инде ул, тагын ни эше булсын.

Ш а һ и д ә . Диванга кадакланып, көне буе тилебәдәр карап ятсаң, авыртмый нишләсен. Ике кулыңа эш табып, селкенеп торсаң, зарланырга вакыт калмый ул.

Ф ә н и я . Син генә ул, эшсез бер минут утыра алмыйсың.

Ш а һ и д ә . Эш тә калдырмадыгыз инде. Ул үзе юа торган машинасы җайлы нәрсә булса да, күлмәк-оегымны гына юып куймаска мин.

Ф ә н и я . Түзмәгәнсеңдер әле, менә боларны да кул белән угансың-

дыр. Юарга дип салдыртам – чипчисталар. Кире элмәдем, машинада чайкаттым инде.

Ш а һ и д ә *(кеткелдәп)*. Өченчекөн генә апаң белән җизнәң килеп, юып, үтүкләп, элеп киткәннәр ие.

Ф ә н и я . И... әйтәм аны... Әле дә алар күрше авылда гына, ике көннең берендә килеп әйләнәләр.

Ш а һ и д ә . Атлаган саен йөрмә дип тукыйм апаңа. Өендә килене, оныклары, алар янында ныграк кирәк бит ул. Яратмаслар.

Ф ә н и я . Кит, әнкәй, каенананың кунакка киткәнен кем яратмасын. Озаграк торса ярар иде дип, дога кылып утырадыр әле җиңгәчәй.

Ш а һ и д ә . Шулай инде, картларны кем сөйсен... Бар инде, караңгыга каласың. Кеше куян куа дип, машинага утырган булып... кайтсаң-китсәң йөрәгем алынып тора.

Ф ә н и я . Куян куам дип түгел инде. Бер өйрәнгәч, бик рәхәт, әнкәй. Киявеңә ялынып торасы юк. Утырам да китәм.

Ш а һ и д ә . Күрше Надир абыең, әнә, рульдәге хатын-кыздан абизьян дип көлә. Гранаты капкан абизьян диме шунда...

Ф ә н и я . Надир абый гына түгел, бөтен ир-ат шулай дигән була, хәчтерүшләр. Машина рулен генә түгел, тормышның бөтен тоткасын хатын-кызга тоттырды да үзләре.

Ш а һ и д ә . Без яшь чакта ярый инде, ир-ат сугышка китеп беткән ие, дөньясы хатын-кыз җилкәсенә калды. Хәзер соң... И, адәмкәйләр... Михнәткә чыдыйлар, рәхәткә түзә алмыйлар...

Ф ә н и я *(өйгә керергә бара, көлеп)*. Ай, тагын яшь чаклар дип сөйли генә башлама! Кырык ишеттем, әнкәй!

Ш а һ и д ә *(үзалдына әйткәндәй)*. Ишетсәң соң... Сагынган чакларымда искә төшерәм дә сөйлим инде.

Ф ә н и я . Сагынган чакларым, дисең. Үзең бер бөртек рәхәт күрмәгәнсең.

Ш а һ и д ә . Күрелгәне дә булды, Аллага шөкер, зарланмыйм. Мәгәр яшьлегем сагындыра! Ачлы-туклы булса да сагындыра! Михнәттә үтсә дә, үзәгемне өзеп сагындыра! Мәрүчкәгә тиклем сагынам!

Ф ә н и я *(өйгә үтешли)*. И әнкәй! Хан заманындагы сыерыгызны гына сөйли күрмә тагын.

Ш а һ и д ә . Олы абыең да миннән соңгы магикан дип көлә. Мин дә китеп баргач, кем ишеттерер, балам? Без күргәнне сезгә күрергә язмасын, улларыгыз, оныкларыгыз сугыш афәтенә эләкмәсен дип сөйлим. Тыныч дигән дөньясында да тынышалмый, тавышланып яталар бит әнә... Инәйләр баласын сугыш өчен дип үстерми...

*Фәния, башын чайкап, өйгә кереп китә, сумкаларын болдырга чыгара.*

Ш а һ и д ә . Фәния дим, идәнгә ике банка сөт куйдым, сөт өсте белән катык халадильникта онытылып кала күрмәсен. Йолдызымның соңгы ризыкларын авыз итсеннәр дип, күп итеп корт та әзерләгән ием, аны да алырсың.

Ф ә н и я . И әнкәй, үзеңә үзең мәшәкать тудырмасаң инде. Корт ясыйм дип, сөт кайнатып, сәгатьләр буе плитә саклаганчы… Без бит ач ятмыйбыз.

Ш а һ и д ә . Ярар, сөт-майны соңгы тапкыр апкитәсең, чәпчемә. Көз кайтуыгызда атагыз юк иде, бу кайтуыңда сыер юк, алдагысында мин булмам – Ходайныкын белмәссең.

Ф ә н и я . Теләсә нәрсә сөйләнмә әле, әнкәй. Саулыгың минекеннән ныграк, яшәргә дә яшәргә әле.

Ш а һ и д ә . Гомереңтүгәрәкләнеп килгәндә, көнеңне түгел, сәгатеңне саныйсың, балам.

Ф ә н и я . Ярар-ярар, дөбердәтеп сыер сауганда, яшеңне дә белмәдең, зарланма. Кызлар кебек әле син.

Ш а һ и д ә *(кулларын әйләндер-*

*гәләп, үзалдына көлеп)*. Дөбердәтеп сауганда дисеңме? И бала-бала... Гәзиткә төреп күкәй әзерләп куйдым. Чүпрәк сумкада апаңнарга дигәне. Аларга дигән сөтне шешәгә тутырдым.

Ф ә н и я . Элегрәк көлә идең, әнкәй, хәтереңдәме? Киткән кыздан, мине дә апкитмәсә ярар иде дип, почмактагы пумала куркып тора, ди торган идең. *(Әнисен кочаклап сөя.)*

Ш а һ и д ә *(кызының кул аркасына Шаһидәнең күз яшьләре тәгәри)*. Гомерем, җегәрем булганда, балаларымны сөттән өзмәм дигән сүзем бар иде бит, балам...

Ф ә н и я . Әнкәй, беләсең бит инде, авыл сөтеннән бизеп барабыз. Балалар да борын җыера, үлән исе килә, диләр. Кайчагында әрем тәме килгән кебек шул сөттән...

Ш а һ и д ә . Ашатырсың сыерга әремне, якын да бармый ул аңа... *(Авыр сулап.)* Адәм баласы дөньяның ачысын-төчесен татып караганнан соң гына әремнән бал тәме килгәнен аңлый шул, балам. Әрем ачысыннан күпкә ачырак сыйлары да бар язмышның, авыз иткәннәр үзләре генә белә…

*Моңсу көй яңгырый. Фәния юылган керне тартып куя, җәймәләр болдырны да, Шаһидә утырган эскәмияне дә каплап, болын кебек балкып күренә.*

**2 күренеш**

*Шул ук ишегалды. Тик ул хәзер су буен хәтерләтә. Бертөркем кызлар чишмәгә килгәннәр. Балаитәкле күлмәктән, канатлы алъяпкычлардан, арттан чөеп бәйләгән яулыклардан. Чырык-чырык киләләр. Араларында З ә к и я кебек җиткән кызлар да, С а б и р а , Ш а һ и д ә кебек үсмерләр дә бар.*

З ә к и я *(чәчен ике толымга аерып үргән, чулпылар таккан)*. Дөньяның матурлыклары, кызлар! Карагыз әле бу чәчәкләрне! *(Бауга эленгән җәймәләргә ымлый. Кызлар сокланалар, аһ-ваһ диешәләр.)*

С а б и р а *(Шаһидәгә)*. Бигрәк матур синең Зәкия түтәң, име? Гел карап кына торасы килә.

Ш а һ и д ә . Матур шул! Тик җебегән. Берәр авыр сүз ишетсә дә мәлҗерәргә генә тора. Миңа охшамаган.

С а б и р а *(пырхылдап)*. Син бит малайлар кебек. Әүхәт белән шәпиле уйнаудан кайчан гына туктадың.

Ш а һ и д ә *(кызарыбрак)*. Кит әле. Әллә кайчан бит инде ул.

1 к ы з . Кайтып китәсе дә килми, әйме, кызлар! Бигрәк ямьле инде безнең чишмә буе.

2 к ы з . Ямьле... мунчага шушыннан унбишәр көянтә су ташып карагыз, булыр ямьле.

3 к ы з . Сезгә инеш суы гына ярамыйдыр шул.

2 к ы з . Инәкәй бит. Чишмә суы тәнгә йомшак, ди.

1 к ы з . Синең инәң авылда бер бит, Латыйфа. Баскычыгызны да бишәр кат юдырта, дисең бит.

3 к ы з *(көлеп)*. Фатыйма апаның самавырны ничек чистартканын бөтен авыл белә, хи-хи-хи... Тышына катык сөртеп куеп, көн буе агарта... Ул көнне чәй суын казанда гына кайнатасыз, хи-хи-хи.

З ә к и я . Кызлар, куегыз әле шул самавырны.

2 к ы з . Ие шул. Минем әнкәйне чәйнәмәгез әле.

1 к ы з . Кеше сөйләгәнче, җырлыйкмы әллә, кызлар?

Ш а һ и д ә *(Сабирага)*. И, тагын тотынырлар инде. Ни кызыгын табалардыр. Әйдә, Сабира, кайтыйк.

С а б и р а . Әз генә тыңлыйк инде, Шаһидә.

*Кызлар шау-гөр килеп уен җырлары җырларга тотыналар:*

Алма бөреле, алма бөреле,
Алма бөреле була ул.
Җан яраткан, күңел тарткан
Яр бер генә була ул.

Ш а һ и д ә . Кыланчыклар! Бездән ике-өч яшькә генә олы инде үзләре. Егетләр турында җырлаган булалар... Һи..

*Сабира белән Шаһидә,*
*көянтә-чиләкләренә су алып,*
*кайтырга кузгалалар.*
*Ут сүнә. Яктыра.*

**3 күренеш**

*Нигъмәтләрнең өй эче. Ярлы гына өй. Тәрәзәгә чигүле пәрдә эленгән, сәкегә кулдан тукылган кечкенә палас җәелгән. Мич, почмакта агач кисмәк. Стенада агач шүрлек, анда гади генә табак-савыт күренә. Тәрәзә төбендә яран гөлләре. Н и г ъ м ә т артсыз агач урындыкка утырып, чыра телә. Өстендә озын җиңле, чалбар өстенә чыгарып салынган күлмәк. Аның бер кулы гарип. М ә р з и я сәкедә оекбаш ямый. Ике кыз әнисе булса да, зифа буйлы, яшь йөзле. Өйалдында көянтә-чиләк тавышы. Сулышына кабып, Ш а һ и д ә килеп керә.*

Ш а һ и д ә . Инәкәй, әтекәй! Әтекәй дим! Төштән соң, тург ясарга дип, кәнсәләрдән безгә төшәчәкләр!

М ә р з и я *(оекбашын куеп)*. Сулуың капкан! Рәтлерәк итеп сөйлә, нәрсә дисең?

Ш а һ и д ә . Әле судан кайтканда Фәһимә апа әйтте, кулга тотардай әйбер-караларын базга булса да күмсеннәр, диде. Он-мазарыгыз булса, анысын да яшерегез, диде. Уф! *(Кисмәктән агач чүмеч белән су алып эчә, лып итеп сәкегә утыра.)*

Н и г ъ м ә т . Ала-ай… Ала-ай… Үтмәс балта белән юнган калхузлары безнең сырган юрганга калды микәнни соң… *(Тынып кала. Иягенучлап утыра.)*

М ә р з и я *(рәнҗүле тавыш белән)*. Болай да күзгә кырып салырлык әйбер калдырмадылар бит инде, тагын ни генә эзләп төшәләр икән, җир йоткырлары?! Атасы дим, Нигъмәт, әйт инде берәр сүз!

Н и г ъ м ә т . Теге юлы калхузларына кермәгән өчен черки урынына канны эчкәннәр ие, хәзер кандала урынына ябышырга уйлаганнар инде алайса…

М ә р з и я . И Ходаем, шушы авылда яшәп, үзеңнекеләр шулай мыскыл итсен инде… *(Шаһидәгә.)* Зәкия түтәң кайда йөри?

Ш а һ и д ә . Ул чишмә буенда калды, кызлар белән. Без Сабира белән кайта торыйк дигән иек. Уф! Ярты суым түгелеп бетте.

М ә р з и я . Бар, балам, Зәкия түтәңә дә иплəп кенә әйт, кайтсын. Бирнә-сөлгеләрен булса да бакча артлатып кына әбиеңнәргә илтерсез. Теге убыр авызларны белмәссең, җан күек күргән, төн утырып чиккән тастымалыңны да тартып алырга күп сорамаслар.

*Шаһидә чыгып китә.*

Н и г ъ м ә т . Бу сәвит дигәннәре алты почмаклы өебезне дә, яңа салган келәтне дә, ихатадагы мал-туарны да талап алды бит инде.

М ә р з и я *(торып, өй эченә карана)*. Әйтәсең бармы. Ястык-мендәргә чаклы алып чыгып киттеләр бит!

Н и г ъ м ә т . Төртсәң аварга торган бу өйдән ни-нәрсәне тамаша күрсәтеп сатарга җыеналардыр.

М ә р з и я . Ярый әле, күрше авыл гаиләсен мыскыл иткән кебек, берәр кара мунчага күчермәделәр диген.

Н и г ъ м ә т . Хамсамул Нәкыйпнең

бу өе мунчадан кай җире белән артык... Һәр ярыгыннан җил өреп тора. Әй, Мәрзия, Мәрзия... бар, әйбер-караларыңны җыештыр...

Мәрзия *(өтәләнеп)*. Җыештырыр нәрсә бар дисеңме...

*Өйалдында лап-лоп атлаган аяк тавышлары ишетелә. Ишекне каерып ачып дигәндәй, Хәмит, аңа ияргән берничә ир заты килеп керә. Хәмит үзен хуҗаларча тота.*

Хәмит *(сәлам бирми. Иреннәрен кыеш-мыеш китереп, әле түшәмгә, әле идәнгә карана)*. Нәрсә, гөлләргә генә күмелеп утырабыз, ә? *(Мыскыллы елмаеп, тәрәзә төбенә килә. Гөл ботагын сындырып ташлый.)*

*Шулчак сулулары кабып Шаһидә белән Зәкия кайтып керә. Мич буенарак посалар. Зәкия яулык чите белән йөзен каплабрак тора.*

Нигъмәт. Хәмит түгел, аяклы каза, үзе бер кәмит булдың син, ә...

Мәрзия *(яулык чите белән авызын каплабрак)*. Кулым корыр дип тә курыкмыйсың, Хәмит!

Хәмит. Телләрегез озынайган бугай. Кыскартырбыз!

Шаһидә *(апасына пышылдап)*. Түтәй, толымыңдагы чулпыларны яшер инде, исәр, анавысы кыек танау, көмеш дип белеп, тартып алырга да күп сорамас. Чәй савытын кисә-кисә, тикмәгә генә тырышканыбыз булыр.

Хәмит *(гөл чүлмәге янында яткан, кәгазьгә урап ясалган кәтүкләрне ала)*. Язгыгыз: берсе кызыл, берсе сары ике кәтүк!

*Ирләрнең берсе кулындагы олы дәфтәрне ача.*

Шаһидә *(алга атылып чыга)*. Инәкәй, ул бит минем чигү җебе, аңа тимәсеннәр! *(Ике кулы белән чытырдап Хәмитнең җиңенә ябыша.)* Кәтүк түгел ул, мин аны әбекәйнең иске тастымалларын сүтә-сүтә, үзем ясадым. Абзыкай, алма минем җепләремне, бир!

Хәмит. Бу ирдәүкәгезне аяк астыннан алыгыз, кысылмасын! Ату тибеп очырырмын!

Нигъмәт. Синнән булыр, кыз бала дип тә тормассың. Кызым, мин сиңа базардан яңаны апкайтырмын, бар, апаң янында гына тор!

*Шаһидә, тешен кысып, Зәкия янына килә. Хәмит агач урындыкны сөйрәп, мич башына үрмәли. Андагы җилпучны күтәреп төшә.*

Хәмит. Ач тараканнар, шушымы бар оныгыз? Монда ике уч та юк бит! Ярар, ул сезне барыбер аяк сузудан коткара алмый! *(Ыржаеп көлгән җиреннән, уртын чәйнәп басып торган Нигъмәтнең ут карашы белән очрашкач, тамагына кылчык кадалгандай тотлыгып кала. Аннан кискен хәрәкәт белән җилпучны идәнгә әйләндереп каплый.)*

Мәрзия. Аһ!

Хәмит. Сез контрларны йә ачка, йә салкынга катырып кына үтерергә кирәк! Күзгә төтен җибәрмәкче буласыз, ә: имеш, хәерчеләр, имеш, бернәрсәләре дә юк! Алтын-көмешегезне кая яшергәнне барыбер әйттерербез! *(Идәнгә сибелгән он бөртекләрен күн итеге белән рәхәтләнеп таптый. Мәрзиягә.)* Бай кызы идең бит син, Нигъмәткә чыкканда, атаң сандык-сандык бирнә белән озатканны белмиләр дисеңме әллә?

Мәрзия *(яулык чите белән авызын капласа да, дуамалланып китә)*. Иманыңны иблискә саткан нәрсә булдың тәки, башта әткәйләргә каныгып, аларның соңгы юрганнарына тиклем талап чыктың, безне күпме тинтерәттең. Адәм талаучы, җирбит! Каян килеп бездә алтын-көмеш булсын, мич артындагы тараканнар гына алтынга әйләнмәсә…

Н и г ъ м ә т . Анасы, телеңне әрәм итмә. Ходай барысын да үзе күреп тора.

1 и р *(ишектән керә)*. Хәмит, анда халык җыелды җыелуын. Абзарда тургка куярдай мал юк, шул бер сыер гына.

Н и г ъ м ә т . Сыерны да алып, балаларны ачтан үтерергә телисезме?

М ә р з и я . Бирмим! Җан урынына күргән Мәрүчкәмне бирмим!

Х ә м и т . Синнән сорап торалар ди... *(Иргә.)* Көрәк-сәнәк алып, абзар артларын, тирес, саламнарын әйбәтләп тикшерегез. Яшерелгән маллары, ашлыклары табылмасмы...

*1 ир чыгып китә.*

Н и г ъ м ә т . Каян килеп? Аласы бөтен әйберне теге юлы талап чыктыгыз бит, оныттыңмыни?

Х ә м и т . Талап? Бу сүзең өчен төрмәдә черетә бит сине сәвит хөкүмәте. Авызыңны үлчәп ачарга өйрәтә!

*Урамда халык тавышы, гөжләгән, кычкырышкан тавышлар ишетелә. Сузып-сузып сыер мөгри. Мәрзия тәрәзәгә ташлана, алъяпкычы белән йөзен каплый. Ишектә К а с ы й м пәйда була. Ул бик ябык, чирләшкә кыяфәттә. Нигъмәткә гаепле йөз белән карап тора.*

К а с ы й м . Нигъмәт, күрше... Ни... сыерыңны без алдык... Рәнҗемә. Мәрзия, ни...

Х ә м и т . Нәрсә син анда контр сүзе сөйлисең, Касыйм? Нинди рәнҗү? Сәвит влачы сиңа мәрхәмәт күрсәткән икән – аңа рәхмәт укы, бу дошманнар алдында баш иеп йөрмә!

К а с ы й м . Нишләп дошман ди... Гомер буе терәлеп торган күрше булып яшәдек... *(Горык-горык ютәлли, башын иеп чыгып китә.)*

*Мәрзия сәкегә утырып, сыгылып төшеп елый. Кызлар да аның янына килеп утыралар. Нигъмәт уртын чәйнәп басып тора. Берничә ир-ат керә.*

1 и р *(ишектән кереп)*. Бөтен җирне актардык, бер әйбер дә тапмадык.

Х ә м и т *(җенләнеп)*. Әйттерербез! Кая яшергәнегезне берзаман үзегез үк йөгерә-йөгерә килеп әйтерсез! Сәвит законы әйттерә ул! Җыеныгыз! Районга аптөшәргә куштылар үзегезне!

Ш а һ и д ә . Әтекәй! Без дә сезнең белән барабыз!

М ә р з и я . Кызым, балаларым... *(Нишләргә белми, елый.)*

Н и г ъ м ә т . Кызым, без озакламабыз. Өйне тәртипле торыгыз.

Х ә м и т *(ыржаеп)*. Өй кайгысы берәүдә... әйдә, әйдә, атлагыз. Болай да озак кыштырдадык.

М ә р з и я . Алланың ачы каһәре төшсен үзеңә! Мәңге рәхәт күрмә!

Х ә м и т . Алла да, мулла да – Сәвит влачы хәзер. Авызыңны үлчәп ач, Мәрзия! *(1-2 ир Мәрзия белән Нигъмәтне терсәкләреннән тотып алып чыгалар.)*

З ә к и я , Ш а һ и д ә *(артларыннан икәүләп)*. Инәкәй, әтекәй!

Х ә м и т *(1 иргә)*. Бу асылкошларны колхоз келәтенә илтеп ябыгыз. Ата-аналарын исән күрәселәре килсә, байлыкларының кая качырылганын бик тиз әйтерләр...

*Ут сүнә.*

**4 күренеш**

*Караңгы. Сүрән генә ут төшә. Баягы ишегалды келәт эче ролен уйный. Идәндә тезләрен кочаклап Ш а һ и д ә белән З ә к и я утыра.*

З ә к и я . Абау, шушы караңгы келәттә төн кунарбыз микәнни?

Ш а һ и д ә . Мин караңгыдан курыкмыйм ла. Әнекәйләрне кайтарырлар микән, түтәй?

З ә к и я . Белмим, Шаһидә үскә-

нем, мин берни дә белмим... Беттек без, беттек... *(Елый.)*

Ш а һ и д ә *(караштырып килә. Тыныч тавыш белән)*. Зәкия түтәм, монда тычкан-мазар юк микән?

З ә к и я . Синдә тычкан кайгысы... *(Башын иеп елап утыра, кинәт сикереп тора, күлмәк өстендәге чигүле алъяпкычын салып ата. Аны кулында бөтергәли, ныклыгын тикшергәндәй, кат-кат тарткалап карый.)*

*Шаһидә шаккатып апасына төбәлә. Зәкия, кулы белән кармалана-кармалана, түшәм такталарын сыпыра.*

Ш а һ и д ә *(аны күреп)*.Түтәй, син нишләмәкче буласың?

*Зәкия келәтнең һәр тактасын, һәр бүрәнәсен барлап чыгарга җыенгандай, ашыга-кабалана, бер почмактан икенчесенә атыла. Аннан кычкырып еларга тотына.*

З ә к и я . Адәм көлкесе, ындыр табагы чаклы келәттә тырпаеп торган бер кадак кисәге булмасын инде… Яшим дисәң, яшәп, үлим дисәң, үлеп булмый дөньяларында.

Ш а һ и д ә . Түтәй, ычкындыңмы әллә, минем үләсем килми, өйгә кайтасым килә. Тамагым ачты. Әтекәйләр кайчан кайтыр икән?

З ә к и я *(яшь аралаш кызганыч елмаеп, Шаһидәгә карый)*. И апаем, син бәләкәйрәк, сиңа тимәсләр. Менә теге җирбит Хәмит мине мәсхәрәләп ташласа, ни кылырмын? Аны бит гел сөйлиләр...

Ш а һ и д ә *(аңа сыенып)*. Матур шул син, түтәй. Инәкәй күрмәгәндә, кашларыңны корым белән каралтып, бит очларыңа кишер суы да тигезгән булдың. Теләсә кем кызыгырлык.

З ә к и я . Хәмит ише бәндәгә матур ни, ямьсез ни, тора салып өстемә ябышса? Аннан суларга ташланырга гына кала бит миңа.

Ш а һ и д ә . Кит, исәр, тумаган тайның билен сындырып утырма әле. *(Бала итәкле күлмәгенең кесәсеннән кечкенә саплы пәке чыгара.)* Сиңа тиеп кенә карасын, шушының белән күзләрен чокып алырмын!

З ә к и я . Әтекәй гел әйтә бит сиңа, малай булып кына туасың калган дип. Булмышың белән гел малай шул син... Кесәңдә пәке йөртмәсәң...

Ш а һ и д ә . Әүхәтнеке ул, әллә кайчан инде шәпиле уйнаганда оттырган иде. Менә тиле!

З ә к и я . Телеңә ничек тилчә чыкмыйдыр, кызый, әле тиле, әле исәр… Бир әле, хет шуның белән ишекне ачып булмасмы. *(Пәкене алып, келәт ишеге янында кайнаша башлый. Бераздан, үртәлеп.)* И Аллам, бөтен кеше пәке белән тимер кисәр ие аны…

Ш а һ и д ә . Түтәй, исәр дими ни дисең инде сине. Кем инде шулай итеп тимер кисәргә маташсын. Анавысы йозакка туры китереп, тактаны җомрылатып чокып карале. Чокы да чокы инде, аннан каерып карарсың.

З ә к и я . Кайчагында акыллы сүз дә чыга шул үзеңнән... *(Тактаны каезлый башлый.)* Ачылды, үскәнем, ачылды! Әйдә, яхшы чакта котылыйк!

*Йөгерә-йөгерә чыгып китәләр.*
*Ут сүнә.*

**5 күренеш**

*Нигъмәтнең өй эче. Ш а һ и д ә белән З ә к и я шыпан-шыпан гына кайтып керәләр. Зәкия керосин лампасын кабыза, тәрәзәләрдә пәрдә юклыгын абайлап, лампаны идәнгә куя.*

Ш а һ и д ә . Синең пәкең безне төрмәдән коткарды дип сөйләсәм, теге капчык белән суккан ышанмас та әле, име, түтәй?

З ә к и я . Кемгә сукканнар дисең, бер сүзеңне аңларлык түгел! Инәкәй кебек, гел мәкаль белән сөйләшәсең!

Ш а һ и д ә . Суккан ди сиңа... Әүхәтне әйтәм, сабын куыгы очырасың дигән булыр әле.

З ә к и я . Әүхәт тә Әүхәт телендә. Әтекәйләр ни хәлдә икән анда? Җибәрсәләр генә ярар инде үзләрен, и Ходаем!

*Шулвакыт ишек ачыла, бик арыган кыяфәттә Н и г ъ м ә т белән М ә р з и я килеп керә. Кызлар аларны кочаклап ала. Ир белән хатын икәүләп сәкегә утыралар.*

Н и г ъ м ә т . Сезнең бәхеткәдер инде, балалар, дөньясында мәрхәмәтле җаннар да калган икән әле.

М ә р з и я *(өй эчендәге пыран-заран килгән дөньяга күз төшергәч, йөзе тартылып китә. Шаһидәгә)*. Балам, теге дәҗҗал таптаган онны канат белән ипләп кенә себереп ал әле, иләгәч, бер пычрагы да калмый аның, умач итәрбез.

*Шаһидә, каз канаты алып, иплəп кенә онны себерә. Бераздан кызлар да әниләре янына менеп утыралар.*

З ә к и я . Әле дә җибәргәннәр үзегезне, инәкәй!

М ә р з и я . Бер изгелек мең бәладән коткара дигәннәре хак икән.

Ш а һ и д ә *(аңа сыенып)*. Инәкәй, ә безне берәү дә коткармады, без үзебез качып кайттык, менәтрәк, вәт!

Н и г ъ м ә т *(шаккатып)*. Каян качтыгыз?

З ә к и я . Теге җирбит безне бит колхоз келәтенә яптырды.

Ш а һ и д ә . Әткәй, әткәй, беләсеңме, Зәкия түтәй...

З ә к и я *(аның ни әйтәсен чамалап, тиз генә бүлдерә, терсәге белән төртә)*. Шаһидәнең әле дә пәкесе булды, ишекне ачып кайтып киттек.

М ә р з и я . Кыз балалар дип тә тормый бит, дәҗҗал...

З ә к и я . Әтекәй, сөйлә инде, нәрсәләр булды районда?

Н и г ъ м ә т . Өченче ел буранда адашып, малае белән бер адәм кереп кунган ие бит, тикшерүче дигәннәре шул булып чыкты. Үзе танымаса, аны җүнләп карау да юк инде... «Сөт эчереп, сез генә исән калдырдыгыз безне», дип ике куллап күреште.

М ә р з и я . Өтермәнгә тыгарлар дип барган җиреңдә шулай каршы алсыннар әле, Ходаның хикмәте.

Ш а һ и д ә . Әйе шул! Әтекәй ул малайның кулларын-аякларын уып утырган иде.

З ә к и я . Ә без инәкәй белән сөткә мәтрүшкә салып кайнаттык.

М ә р з и я . «Улым өчен бик курыккан идем, коткардыгыз, мең рәхмәт сезгә!» дип саубуллашып киткән ие бит. Менә шул кешегә тап булдык, Алланың рәхмәте.

Н и г ъ м ә т . Бер җамаяк сөт анагыз белән мине өтермәннән коткарды, балалар.

*Әтәч кычкырганы ишетелә.*
*Мәрзия чәчрәнләп сәкедән төшә.*

М ә р з и я . Сыер саварга... *(Кинәт кенә исенә төшә. Сыгылып төшә, елый.)* Сыеркаем, сыеркаем...

Н и г ъ м ә т . Ярар, анасы, баш исән бит әле...

М ә р з и я . Баш исән дип кайчанга кадәр юанып яшәрбез соң, атасы?

Н и г ъ м ә т . Күрше урыс авылыннан кәҗә алып кайтырмын, ул да мал.

М ә р з и я . Кәҗә? И Ходаем... Бетебез белән түликме ул кәҗәсенә дә?

Н и г ъ м ә т . Юкка көймә. Алып кайтам дидем бит. Алып кайтам.

*Ут сүнә. Яктыра.*

**6 күренеш**

*Нигъмәтләрнең ишегалды. Читән койма. Мәрзиянең абзардан чыгып килүе. Кулында кечкенә калай бидон, беләгендә шадра сөлге. Койманың икенче ягында Гөлсем күренә.*

Гөлсем. И сыерыңның сөтеннән уңдык, Мәрзиякәем, бидрәм чүмәкәй булганчы савам бит. Иллә мәгәр холкы яман, койрыгы белән битемне кыйнап кына тора. Аптырагач, ботына бәйләп куйганыем, аягын күтәрә башлады.

Мәрзия *(кырку)*. Гомердә дә холыксызланмады.

Гөлсем. Сезне әйтәм, кәҗә алгансыз, дигән иде Касыйм, саудырамы? Шулай инде, ишле өйдә сөтсез буламы соң.

Мәрзия. Савам. Бик ипле. Сөте дә күп, Аллага шөкер.

Гөлсем. И-и, безне бәхет басты инде, Мәрзиякәем, басты...

Мәрзия *(ачы көлемсерәп)*. Ике карга талашса, бер козгынга җим төшәр, диләр бит. Кәнсәләрнең безнең дөньяны пыр туздыруы сезне ничек бәхетле иткән.

Гөлсем. Кәнсәләр дип... Касыйм бит... Нигъмәтләрнең Мәрүчкәсен үзебезгә алып чыгабыз, дип чата-карман килде, өзмәде-куймады...

Мәрзия. Рәхәтен күрегез.

Гөлсем *(уңайсызланыбрак китә)*. И Мәрзиякәем... *(Нидер әйтергә уйлый да кулын селтәп китеп бара.)*

*Мәрзия аның артыннан бик озак текәлеп карап тора. Керә китә. Култык астына бер-ике учма үлән кыстырган Шаһидә керә. Читәннең икенче ягында Әүхәт пәйда була. Ул – ачык йөзле, шат күңелле үсмер.*

Әүхәт *(читән аша)*. Шаһдә, Шаһдә дим!

Шаһидә *(читән янына килеп, егетнең борын төбендә йодрык күрсәтә)*. Исемемне бозма дип ничә әйттем, ә?

Әүхәт. Ярар инде, Шаһдә. Кайда йөрисең? Көтү әллә кайчан кайтты. Безнең сыерны юллыйсыңмы әллә?

Шаһидә. Сезнеке түгел, безнең сыер ул! Көтүдән кайтканда да инәң чыбык белән ярып кына алып керә ишегалдыгызга, ул туп-туры безгә кайта, менәтрәк, вәт! *(Әүхәтнең беләгеннән чеметә.)* Абау! Как сөяк – тач май, как сөяк – тач май!

Әүхәт. Ә сез хәзер кәҗә сөте эчәсез, фу-у! *(Кызны үртәп такмаклый.)*

> Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй,
> Имиләрең бәләкәй.
> Бер ыстакан сөт бирмисең,
> Каһәр суккан нәмәкәй.

Шаһидә. Инәкәй әйтә, кәҗә сөте сыерныкына караганда да файдалырак, ди, беләсең килсә!

Әүхәт. Сасы бит ул, аны ничек эчәсез? Фу-у-у…

Шаһидә. Булыр сасы! Безнең Әүхәдән мамык исе генә килеп тора!

Әүхәт. Диванадыр син, кем инде кәҗәгә шундый исем кушсын!

Шаһидә. Инәкәй әйтте, кышка аның бәкәйләре туачак, диде. Кәҗә тәкәсе туса, анысына бөтенләй Әүхәт диярмен әле, вәт!..

Әүхәт. Ярар. Безнең сыер бозауласа, мин аңа Шаһдә диярмен.

Шаһидә. Әйтеп кенә кара!

Әүхәт. Әйтәм! *(Як-ягына каранып, тавышын әкренәйтеп, елмаеп.)* Бозавын абзарыгызга кертеп куям. Сыер итеп үстерерсең *(Үртәп, бозау чакыргандай итеп.)* Шаһдә, туә-туә, Шаһдә, туә-туә...

Шаһидә *(йөзен балкытып елмая, тагын Әүхәтнең беләген чеметә)*. Менә тиле! Үгез бозау булса? Шаһдә, имеш...

Ә ү х ә т . Чеметмә әле! Шул гадәтең... Үгез булса да, Шаһдә, дим. Аңа ныграк та туры килә әле ул исем.

*Шаһидә ишек ачылган тавышны ишетеп, ялт кына читкә тайпыла, Әүхәткә йодрык болгый. Өйгә юнәлә. Әүхәт тә читәннән югала. Болдырга* Н и г ъ м ә т *чыгып баса. Карашы белән бер ноктага төбәлеп, уйланып тора, гарип кулына карый-карый, баскычка утыра. Уйга бата.* К а с ы й м *керә. Гаепле кешедәй көрсенеп кенә Нигъмәт янына килеп утыра. Тегесе башын гына күтәреп карый.*

К а с ы й м . Саумы, Нигъмәт? Син, ни, миңа ачу саклама инде, кордаш...

Н и г ъ м ә т . Бөтен кайгың шулмы, Касыйм?

К а с ы й м *(корк-корк ютәлли)*. Кайгы дип... Сөенерлек бернәрсә дә күренеп тормый шул.

Н и г ъ м ә т . Ала-а-ай... «матур тормыш» дип җырлап йөрисез түгелме соң?

К а с ы й м *(кул селтәп)*. Җырларсың *(ютәлли)*. Влач дигәннәренә җыен этрәк-әләм менеп кунакласын да...

Н и г ъ м ә т . Башны алып җир читенә олага торган да түгел, бу гарип кул белән кайда, кем көтеп тора.

К а с ы й м . Син кул дисең, мин... *(Бик нык ютәлли.)*

Н и г ъ м ә т . Бер дә ару күренмисең әле син, күрше. Үпкәңне әйтәм...

К а с ы й м . Үтәр әле... Кордаш, сыерың өчен рәнҗемә. Чит-ят кулына китеп әрәм булмасын, дидем. Заманалар болгана да, бер көн килеп тынмасмы әле... Үзеңә алып чыгарсың.

Н и г ъ м ә т. Нинди көнгә калдык.

К а с ы й м . Сөйләмә, кордаш!

Н и г ъ м ә т . Ачуың да килмәс иде. Син әйтмешли, җыен ялкау, җыен булдыксыз түрә булып йөрсен әле. Тир түгеп тапкан малыңны талап, сәвит төзиләр, имеш. Ичмаса, үзләрен влач дигәнче, талаучылар, караклар дисеннәр иде...

К а с ы й м . Кордаш, бик кычкырып сөйләшмә әле. Авылның кырык күзе, кырык колагы бар...

Н и г ъ м ә т *(кул селтәп)*. Сөйләшү түгел, сулыш алырга да өркәбез шул... Өрәкләр дөньясында үзебез дә өрәккә әйләнеп беттек...

*Ут сүнә. Яктыра.*

**7 күренеш**

*Нигъмәтләрнең өй эче.* М ә р з и я *гөлләрен карап, су сибеп, яфракларын өзгәләп маташа.* Н и г ъ м ә т *идәнгә утырган, сәламәт кулы белән капчык ямый. Йөгереп* Ш а һ и д ә *килеп керә, йөзе кызарган.*

Ш а һ и д ә . Инәкәй, Мәрүчкәне үгез сөзгән, җилене канга баткан!

Н и г ъ м ә т *(капчыгын куеп, торып баса)*. Үгез сөзгән?

*Мәрзия гөлләргә су сибеп маташкан җиреннән дертләп китә, әмма эндәшми.*

Ш а һ и д ә . Ишетмисеңме әллә, инәкәй, Мәрүчкәне сөзгәннәр, дим!

М ә р з и я . Хуҗалары бар бит, карарлар. *(Сул кулы белән йөрәген тота. Түзми, тәрәзәгә каплана.)*

*Берара өй эчендә үле тынлык урнаша.*

Н и г ъ м ә т . Көтүчесе ни караган-дыр, ә?!

М ә р з и я . Карга, казга охшыйм дип, ботын сындырган дигәннәре шушы була инде. Гөлсем бик хәтәр кыланып, сыер асрамакчы иде бит. Эт эченә сары май килешәме?

Н и г ъ м ә т . Мәрзия дим, күршеләр белән әчелешле булып йөрмә тагын. Гөлсем чәпчебрәк йөрсә дә, эчендәгесе тышында.

М ә р з и я . Сыер, сыер дигән булды... Харап итте Мәрүчкәмне, хараплар итте!

Н и г ъ м ә т . Мал аркасында бозылышып ята күрмә.

М ә р з и я . Мал, мал... Карый алмаслык булгач, кеше малына нигә килеп ябышырга?

Н и г ъ м ә т . Касыйм алмаса, башкасы алыр иде. Әнә теге кабихләрне әйт син, кеше кулы белән утлы күмер тотмакчы булалар. Күз яше өстендә төзелгән блачларының гомере булыр микән, ай-һай…

Ш а һ и д ә . Инәкәй, әйдә, Гөлсем апаларга керик әле, бәлки синең кулың килешер. Майлар сөртсәң, дим.

М ә р з и я . И балам... Мин хуҗамыни сыеркаема?

*Ишек ачыла. Кайгылы кыяфәттә Г ө л с е м килеп керә. Өйдәгеләр барысы да аңа текәләләр. Мәрзия күршесен ым белән генә сәкегә чакыра. Гөлсем башын иеп кенә килеп утыра. Алъяпкыч итәген кайтарып, битен каплый, елап җибәрә.*

Г ө л с е м . Каргагансыздыр инде, Мәрзиякәем, рәхәтен күрмәсеннәр, дигәнсездер.

М ә р з и я . Сине каргаганым юк, Гөлсем, синең ни гаебең бар?

Г ө л с е м . Сезнең сыерга тора салып кызыккан дисеңме? Кешегә сүләп җөрмәгәч ни… Касыймкаемның хәле хәл, үпкәсенең рәте юк бит. Кала брачлары көн саен сөт эчәргә кушып кайтарган булган. Каян алып эчерәем? Яз көне сыеркаемны үз кулыбыз белән җитәкләп калхуз фермасына илтеп бирдек бит.

Н и г ъ м ә т . Калхуз, дидегез шул... *(Өстенә юка камзулын элеп, чыгарга юнәлә.)*

Г ө л с е м . Бозаулагач, бозавын үзегезгә алырсыз дигәннәр ие дә, бирделәр, тот… Бер атналык бозауны ачка тилмертеп үтерделәр, адәм тәганәсе. Минем бит өй тулы малайлар, аларга көн саен ни ашатыйм, ни пешерим?.. Мәрүчкәңнең сөтенә тиендек дигән ием, бер бәхетең булмаса, җук инде, Мәрзиякәем, җук. Әнә, өйалдына ярты чиләк сөт кертеп куйдым, тоташ кан, аны ничекләр эчерәем Касыймга? Җан талашып көчкә ике имчәген саудым, җилене мендәр чаклы шешкән, Мәрзиякәем, нәрсә эшләргә дә белгән җук.

М ә р з и я . Калхузыгызның мал духтыры бар түгелме соң, нигә эндәшеп карамыйсың, бер-бер хәл кылыр ие.

Г ө л с е м . Духтыр... исеме генә бар. Пычагым белсенмени ул? Килде, сыер тирәли ике-өч тапкыр әйләнде дә җилкәсен сикертеп кайтып китте.

М ә р з и я *(сикереп тора, өстенә элә, яулыгын төшереп бәйләп, чыгарга юнәлә)*. Карыйк әле, Гөлсем, әйдә, Мәрүчкәне карыйк, дим!

Г ө л с е м . Карасаң-карамасаң, аякка басарлык түгелдер инде, Мәрзиякәем! Хараплар булды сыерыбыз, хараплар булды!

**8 күренеш**

*Нигъмәтләрнең ишегалды. Ш а һ и д ә белән З ә к и я көянтә күтәреп судан кайтып керәләр. Чиләкләрен эскәмиягә куялар.*

З ә к и я . Үскәнем, мин әбекәйләргә дә берәр көянтә су китерим әле, син боларны бушатып кына куй инде, яме.

Ш а һ и д ә . Әбекәйләргә? Әле иртән генә аларга дип суга бардың бит.

З ә к и я . Бер көянтә су каян килеп, кая китми инде ул.

Ш а һ и д ә . Алайса, мин дә синең белән барам!

З ә к и я *(ияртәсе килми)*. Син

арыгансыңдыр, үзем ялт кына урап кайтам.

Ш а һ и д ә *(чиләкне җитез генә өйдә бушатып чыга)*. Нишләп арыйм! Барам дигәч барам!

З ә к и я . Әбекәй нишләсен ул тиклем чишмә суы белән. Шуның хәтлене чәйгә тотарга... Иртәгә барырсың.

Ш а һ и д ә . Берүзе генә барыр иде. *(Авызын ерып.)* Белмиләр ди хәйләңне.

З ә к и я . Абау! Нинди хәйлә?

Ш а һ и д ә . Латыйфаның абыйсы без суга барганда карап кала, без судан кайтканда карап кала...

З ә к и я *(оялып)*. Китчәле, нишләп безгә карасын инде.

Ш а һ и д ә . Безгә түгел. Сиңа карый. Сүз катар иде – миннән шүрли!

З ә к и я *(көлеп)*. Синнән? Җегетләрне шүрләтерлек нишләдең ул тиклем?

Ш а һ и д ә . Эшләмәдем. Әйттем генә. Минем түтәй тирәсендә төлке кебек бөтерелмә, сине яратмый ул, дидем.

З ә к и я *(аптырап, күңелсезләнеп, сиздермәскә тырышып)*. Һай, телең... Әллә ниләр сөйләп йөри икән.

Ш а һ и д ә . Сөйлим шул. Күзе майлы аның. Сиңа да карый, бүтәннәргә дә. Менә сиңа гына карап торса, әллә әйтмәгән дә булыр идем.

З ә к и я *(күңелсезләнеп)*. Дөрес әйткәнсең, үскәнем, дөрес әйткәнсең... (Борылып, өйгә керергә җыена.)

Ш а һ и д ә . Бәй, чишмәгә бармыйбызмыни?

З ә к и я . Әбекәй суны күп тотмый ла ул, иртәнгесе дә бетмәгәндер әле. *(Кереп китә.)*

Ш а һ и д ә *(аның артыннан)*. Ну, Зәкия түтәм!

*Абзар буеннан М ә р з и я чыга, кәҗә сауган. Кулында кечкенә бидон, кечкенә сөлге.*

М ә р з и я . Шаһидә, бар әле, балам, калай кружкәне алып чык.

Ш а һ и д ә *(өйгә атлап)*. Кәҗә саварга гына кушма, инәкәй, калган бөтен эшне эшлим! *(Йөгереп кенә кружка алып чыга.)*

М ә р з и я *(бидондагы сөтнең беразын кружкага бушата)*. Бар, кызым, Касыйм абыеңа кертеп чык. Аңа дару, безгә савап булыр. *(Калай кружканы Шаһидәгә тоттыра.)* Аяк астыңа карап атла, әрәм итә күрмә!

Ш а һ и д ә *(бик гаҗәпләнеп)*. Инәкәй, нигә син аларга сөт бирәсең?

М ә р з и я . Әйтәм бит, Касыйм абыеңның үпкәсе чирле, килешсә сөт кенә килешә, ди.

Ш а һ и д ә *(ярсып)*. Алар безнең сыерны алып чыгып китте, алар безнең сыерны үтерде, инәкәй!

М ә р з и я . Безнең сыерны... алар үтермәде, кызым.

Ш а һ и д ә . Рәтләп карасалар...

М ә р з и я . Атаң дөрес әйтә, күршеләрнең бер гаебе дә юк. Заманасы шундый, ни хәл итәсең… Күрше хакы – Алла хакы, диләр, кителәсе дөнья бер җомры сөттән генә торып калмас. Аллаһ бәндәне авырлык белән сыный шул, балам, авырлык белән...

*Шаһидә кружкадан күзен алмый гына чыгып китә. Мәрзия аның артыннан карап кала.*
*Ут сүнә. Яктыра.*

**9 күренеш**

*Эскәмиядә карт Ш а һ и д ә нәкъ баягы халәтендә утыра. Әле генә исенә төшергәннәрдән күңеле тулган. Камзул кесәсеннән кульяулык чыгарып, күзләрен сөртә.*

Ш а һ и д ә *(таягына ике кулы белән таяна, ияген дә таякка тери)*. Гомеркәйләр, диген... Тегеләй яшәсәң дә узган, болай яшәсәң дә... Сагынган

чакларымда шулай артыма әйләнәм дә карыйм, әйләнәм дә карыйм... *(Башын күтәрә, муенына аскан сотовыен күзеннән ерагайтып, вакытны карый, аннан номер эзли, җыя.)* Фәния, Фәния, дим! Әле кайтып кердеңме? Урын эзлим, дисеңме? Нинди урын? Ә-ә, машина куярга, дисең... Шәһәрегездә машина куярга урын булмаганда, мине чакырып яткан буласыз... Юк инде, бәбекәем, синнән көлмим... Ярар, әйбәт булган, күңелем тынычланды. Мин соң ни... Эшем беткән. Утырам. Уйланып утырам. Банкадагы сөтеңне әйтәм, ачытма, әрәм итә күрмә!

## 2 ПӘРДӘ

*Баягы вакыйга кабатлана. Эскәмиядә карт* Ш а һ и д ә *нәкъ баягы халәтендә утыра. Әле генә исенә төшергәннәрдән күңеле тулган. Камзул кесәсеннән кульяулык чыгарып, күзләрен сөртә.*

Ш а һ и д ә *(таягына ике кулы белән таяна, ияген дә таякка тери).* Гомеркәйләр, диген... Тегеләй яшәсәң дә узган, болай яшәсәң дә... Сагынган чакларымда шулай артыма әйләнәм дә карыйм, әйләнәм дә карыйм... *(Башын күтәрә, кесәсеннән сотовыен ала, күзеннән ерагайтып, вакытны карый, аннан номер эзли, җыя.)* Фәния, Фәния, дим! Әле кайтып кердеңме? Урын эзлим, дисеңме? Нинди урын? Ә-ә, машина куярга, дисең... Шәһәрегездә машина куярга урын булмаганда, мине чакырып яткан буласыз... Юк инде, бәбекәем, синнән көлмим... Ярар, әйбәт булган, күңелем тынычланды. Мин соң ни... Эшем беткән. Утырам. Уйланып утырам. Ни уйлыйм, дип... Михнәткә түзелгән, менә рәхәткә чыдый алмыйм бит әле, шуңа аптырыйм. Ике кулыма бер эш юк... Ярар. Ярар... әйбәт булган... Банкадагы сөтеңне әйтәм, ачытма, әрәм итә күрмә!

*Шаһидә телефонын сүндерә. Баягыча таягына таяна. Үзалдына әкрен генә җырлый.*

Без барасы юлларның ла
Ике ягы канаулы.
Без моңаймый, кем моңайсын –
Безнең көннәр санаулы.

Атландым атның биленә,
Киттем герман җиренә.
Герман җире кара үлән –
Әллә кайтам, әллә үләм...

*Тагын уйга бата.*

### 10 күренеш

*Вакыйга Шаһидә хәтерендә җанлана. Сугыш еллары. Кыш. Бертөркем хатын-кызлар урман кисүдә. Алар арып-талып ялга туктаганнар. Бүрәнә өстенә тезелешеп утырганнар. Өсләрендә бишмәт, бияләйләр, киез итекләр. Араларында* Г ө л с е м *белән* М ә р з и я *дә бар. (Шактый олыгайганнар.)*

М ә р ф у г а . Каһәр генә төшсен бу Гитлерга! Каһәрләр генә төшсен!

С ә л и м ә . Чыкмаган җан гына калды бит, катыннар. Күпмегә түзәрбез?

М ә р з и я . Бүген тагын нурмыны тутырып булмастыр, кулларым өзелеп чыга бит инде.

Г ө л с е м . Ярар, каш ярылып күз чыкмаган, төнгә кадәр ничек тә тутырырбыз әле. Хәмит кенә иснәнеп йөрмәсен..

М ә р ф у г а *(кемнеңдер килгәнен күреп).* И-их, бәхетеңне кәҗә сөзсә... Әнә, килеп ята, иблис токымы.

*Кышкы киемнән* Х ә м и т *килеп керә. Ике кулын кесәсенә тыгып, үзалдына сызгыргалап, хатыннар тирәсендә сүзсез генә әйләнгәләп йөри.*

Х ә м и т. Я-а-ал итәбез, да?

М ә р ф у г а *(торып, ул да, нәкъ Хәмитчә кыланып, аның тирәсендә әйләнеп чыга)*. Иптәш быргадир, син бит, бер күзем бөтенләй күрми, дип сугыштан калган кеше, безнең бер минутка ялга туктаганны ничек күреп өлгерәсең, ә?

Х ә м и т. Ай-яй телләрегез озынайды!

С ә л и м ә. Синеке бик кыска ату. Хатыннар белән телләшергә генә җитә.

М ә р з и я. Үзебез монда, кызларыбыз ФЗӨ дигән эт олаккан җирдә тилмерә. Исемлекне син төзеп биргәнсең.

Х ә м и т. Яп авызыңны, кулак калдыгы! Каршы әйтеп тора ишшу... Икенче кызыңны да тотып озатырбыз! Үзеңнең генә бридетель булуың җитмәгән, боларны да сәвиткә каршы котыртасың һаман! Районга илтеп яптырам мин сине! *(Мәрзиянең беләгенә килеп тотына.)*

М ә р з и я *(селтәнеп)*. Канатларыңны җәймә, бригадир булдым дигәч тә.

М ә р ф у г а *(башыннан шәлен йолкып төшерә, җан әрнүе белән лып итеп җиргә утыра)*. Нигә Мәрзияне генә ди, безне дә илтеп яптыр. Ичмаса, бу кәтер эшеннән котылып, бер-ике көн булса да ял итеп кайтырбыз. *(Озын итәген җыера төшеп, аякларын җәебрәк куя, бөтенләй көтмәгәндә уенчак тавыш белән җырлап җибәрә.)*

Сания апа суга бара,
Яшел чиләген асып.
Сандугачлар чут-чут сайрый
Көянтәсенә басып...

Х ә м и т *(аяк астына черт итеп төкерә)*. Нәрсә монда җәмиләңне җәеп утырасың, сез тутырмаган нурмыны әллә мин килеп эшләр дисеңме? Себерелеп йөрергә беләсез.

М ә р ф у г а *(җитез генә сикереп тора, Хәмитнең йөзенә кизәнә)*. Хәшәрәт! Безнең ирләр ут эчендә йөри, син монда аларның хатыннарын басып рәхәтләнәсең! Кайтсыннар гына, фәлән җиреңне кисеп кулыңа тоттырырлар әле!

С ә л и м ә *(башын иеп кенә)*. Әйтмә! Бер бетмәсә бер бетәр сугышы да...

Г ө л с е м. Хатыннар! Сүз әрәм иткәнче, әллә соң шатырдатып бер кочаклыйкмы үзен? Җыйнаулашып, дим! Сөякләре коелып төшкәнче, ха-ха-ха...

*Хатыннар, аның сүзен куәтләп, Хәмитнең өстенә килә башлыйлар. Ул арткарак чигенә, бишмәтенең өске төймәсен ычкындырып, муенын ата каз кебек боргалагандай итә, кемгә тукталырга белмичә, кисәк Сәлимәгә текәлә.*

Х ә м и т. Боларны син котыртасың, мыштым, җавабын да син бирерсең! Былач кешесенә кул күтәрүнең ни икәнен күрсәтермен мин сезгә! *(Арты белән чигенә-чигенә чыгып китә.)*

М ә р ф у г а *(ачы тавыш белән кычкырып кала)*. Безгә күрсәтәсе килгән нәрсәңне авыл савитына үзебез дә күрсәтешербез, җәме. *(Сәлимәгә борыла.)* Кара, кызый, ниемә дип тота да сиңа бәйләнә соң ул, ә?... Йәле, йә...

Г ө л с е м. Бәйләнми ни, аңа әле һаман теше үтми бит...

*Хатыннар кычкырып көлеп җибәрәләр. Шулчак Сәлимә, учлары белән йөзен каплап, бүрәнә өстенә утыра, иңри. Тынлык.*

М ә р з и я. Ходаем икән лә... Син дә инде, Гөлсем, алдын-артын уйламый әйтеп куясың...

Г ө л с е м. И-и, Мәрзиякәем, мин бит синең кебек мулла кызы түгел, культур-мультур итеп сөйләшә белмим.

Мәрфуга. Туктагыз әле сез, кемәйләр... *(Йомшак кына итеп.)* Сәлимә, Сәлимә, дим... Менәтрәк, тынычлан әле син... *(Тегесе катырак мышкылдый башлагач, тавышын кинәт кырыслатып.)* Нәрсә җебеп утырасың соң?

Сәлимә *(кул аркасы белән йөзен сөртеп, кызганыч елмая)*. Бетте. Әллә нәрсә мәлҗерәдем шул.

Мәрзия. Минем гарип Нигъмәтемә тиклем трудармиягә дип апкиттеләр, типсә тимер өзәрлек бу нәмәрсәгә кагылучы юк.

Мәрфуга. Кагылырлар ие дә, агасы райкум тирәсендә утыра... Силсәвит Шәйдул да шуңа тел-теш тидерә алмый үзенә. Хәмит абзаң тиешле кәгазьләрен дә ясата белгән. Үзен колхоз рәисе йә сәвиткә куярлар иде дә – абзагызның грамыты җитеп бетми.

Гөлсем. Ул азгын синең дә капкаңны кактымы әллә?

Мәрфуга *(Сәлимәгә)*. Әйдә, тел яшереп маташма инде.

Гөлсем. Безнең ни, хәзер монда бары да, югы да уртак, сер капчыгын төйнәп утыра торган түгел.

Мәрзия. Ярар инде, Гөлсем, кешенең өстендә торма.

Сәлимә *(башын иеп утырганнан соң, кинәт усалланып)*. Ирем исән-сау гына кайтсын. Барысын да үз телем белән сөйләп бирәм.

Гөлсем. Нәрсәне?

Мәрзия. Тәки өзми-куймый бу Гөлсем.

Сәлимә. Кызымны ФЗӨгә китүчеләр исемлегенә язып куйган иде. Сыздыртам, авылда калдыртам, диде.

Мәрфуга. Кая калдыртсын, Сабирәңны да ат арбасына төяп озаттың бит.

Сәлимә. Озаттым шул *(елап җибәрә)*. Алдады, кабахәт. Үзем дә инде... Тәнем куырылып катты шунын янында. «Син ни, бүрәнә ни», дип чыгып китте...

Гөлсем *(бот чабып)*. Әйттем бит, сине генә урап узамы соң ул иблис?

Мәрфуга. Алла үзе кичерсен инде, кемәйләр, башларыбыз гөнаһка батып бетте.

Гөлсем. Башларыбыз, ди, хи-хи-хи...

Мәрзия. И чорсыз инде син, Гөлсем. Көләргә генә торасың.

Гөлсем *(көлгән җиреннән кинәт туктый)*. Йә көләсең, йә җырлыйсың инде. Җылыйсым килми. Касыймымның ярты җаны гына калды, кан төкерә. Кайчак аны кочаклыйм да котыра-котыра җырлый башлыйм. *(Ярсулык белән җырлап җибәрә.)*

> Салкын чишмә буйларында
> Атлар эчерсәң иде.
> Туган-үскән илләреңдә
> Гомер кичерсәң иде...

*(Җырдан кисәк туктап, тын тора.)* Әүхәтем ут эчендә йөри – аны уйласам да җырларга тотынам. *(Янә җырлый.)*

> Алмалар өзәр идем дә
> Җепләргә тезәр идем.
> Янмаса бу йөрәккәем,
> Сагынуга түзәр идем.

Җылыйсым килми, Мәрзиякәем, җылыйсым килми! *(Кинәт сулыгып-сулыгып еларга тотына.)*

*Хатыннар әкрен генә аның җырын бергәләп дәвам итәләр. Шулчак агачлар арасында кемнеңдер йөргәнен ишетеп алалар, сагаеп калалар, җырдан туктыйлар.*

Мәрзия. Һаман Хәмит иснәнеп йөриме?

Сәлимә. Безне тикшерергә дип авылдан урманга ат куып менә икән...

Мәрфуга. Кемәйләр, әллә соң чыннан да бергәләшеп дөмбәсләп атабызмы үзен? Без күрәсен эт күрмәс, беткән баш беткән.

Гөлсем *(читкәрәк барып карый)*. Катыннар, Хәмит түгел бу. Кеше булды бугай. Бәй, икәү бит болар. *(Агачлар арасыннан тоныК кына булып ютәлләгән тавыш ишетелә.)*

Мәрзия *(нидер сизенгәндәй, аның янына томырылып килеп баса)*. Ай Ходаем! Кинәт йөрәгем сикерә башлады...

Мәрфуга. Әйтәм бит, беткән баш беткән.

*Горык-горык ютәлләп, сәләмә киемнәргә, ертык шәлгә төренгән Зәкия, шундый ук кыяфәттә Сабира керәләр.*

Мәрзия *(үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып Зәкиягә ташлана, кызның шатланырга хәле юк)*. Балакаем! Зәкиям! Балакаем!

Сәлимә *(шаккаткан кыяфәттә кызына карап тора, учы белән авызын каплый)*. Са... Сабирам! Сабирам!

Сабира. Әнкәй... *(Кызганыч елмая, иреннәре күгәреп каткан, аның авырлы икәне сизелә.)*

Зәкия. Инәкәй! Без качып кайттык... *(Ютәлли.)* Ичмаса... өйдә үлим, дидем...

Мәрзия *(елый, кызын кочаклый, нишләргә белми, битеннән сөя)*. Балакаем! Ничекләр урманда адашып үлмәдегез? Ничекләр монда килеп чыктыгыз?

Сабира. Җәяү кайттык. Авылларда куна-куна... Зәкия апа бик авырый, юлда үлмәсә ярар иде дип котым очты.

Сәлимә *(һаман кызының корсагыннан күзен алмый)*. Бу нәрсә? Бу нәрсә?

Мәрфуга. Туктале, Сәлимә, дапрус алырга ашыкма.

Гөлсем. Әйе. Житешерсең. Балаларны тизрәк авылга аптөшәргә кирәк.

Мәрфуга. Мәрзия, әллә соң Шәйдулның өенә барып, сүз катып карыйсыңмы? Качып кайтканга бәла-казасы була күрмәсен, диюем... Хәзергене белмәссең...

Мәрзия. И Мәрфугакаем, шул сәвит Шәйдуллар, Хәмитләр төяп җибәрде бит инде безнең кызларны җәһәннәм тишегенә...

Зәкия *(ютәлләп)*. Инәкәй, сез ничек? Шаһидә өйдәме?

Мәрзия. Апаең сарык карарга керде. Көне-төне фермада балакаем. Атаңның хаты килеп тора, Аллага шөкер. Шахта чистартырга куйдылар, дигән. Син генә менә, чирләргә сабышкансың бит.

Гөлсем. Аякларына кара, чабаталары тетелеп беткән! И Ходаем...

Мәрфуга. Болай сөйләнеп торганчы, Гөлсем дөрес әйтә, балаларны тизрәк авылга алып кайтыйк, тотып асмаслар әле.

Сәлимә. Ничекләр авылга кайтасың хәзер?

Сабира. Әнкәй...

Зәкия. Сәлимә апа, Сабираның гаебе юк. Аны... Фзуда бригадир көчләгән...

Сәлимә *(иңрәп)*. Сабый гына бит әле ул, сабый гына...

Зәкия. Андагыларга барыбер. Әле барып төшкән шәйгә кызлар-егетләрнең барагы да упший иде, шаулаша торгач аердылар тагын. *(Ютәлли.)*

Сабира. Мунча керергә иде, әнкәй. Әйтергә дә оят, без бетләп беттек.

Сәлимә. Әйтергә генә оят булмас.

Мәрфуга. Сәлимә, кызыңның ярасына тоз сибеп торма әле. Буласы булган, чүбек чәйнәүдән файда юк.

Мәрзия. Әйдә, кызым, менә минем шәлемә төрен, аягыңа да шушы чүпрәкне булса да урап куйыйк. Күпкә түзгәнне азга түз инде, балам, түз инде, түз!

Сәлимә. Сабира! Мә... син дә төрен... кызым.

*Ут сүнә. Музыка. Яктыра.*

**11 күренеш**

*Мәрзияләрнең өе. Сәке өстендә ютәлләп З ә к и я ята. Ютәлләгән саен гәүдәсе урталай бөгелә, кыз җыерылып килә. Ш а һ и д ә аның янында утыра, апасының чәчен сыйпый.*

Ш а һ и д ә . Түтәй, тагын мәтрүшкәләп чәй ясыйммы әллә? Кишер чәе булса да, файдасы тияр, дим.

З ә к и я . Кирәкми, үскәнем, инде миңа бернәрсәнең файдасы булмас.

Ш а һ и д ә . Шулай дип ятсаң, булмый да булмый! Ә син тереләм дип эч!

З ә к и я . Шаһидә, шулкадәр яшисем килә, үскәнем! Шулкадәр яшисем килә! Җәй җитсә, көянтә-чиләкләремне алып, чишмә буена йөгерәсем килә.

Ш а һ и д ә . Йөгерерсең әле, түтәй, җәйгә тиклем ерак бит, аңынчы терелерсең...

З ә к и я . Җамаяк тутырып сөт эчеп торсам, әллә терелер дә идем.

Ш а һ и д ә *(күз яшен сиздерми генә сөртеп ала).* Фронтка ит кирәк дип, кәҗәләрне дә сөйрәп апчыгып киттеләр шул, түтәй...

З ә к и я . Шаһидә... Әүхәттән хат киләме?

Ш а һ и д ә . Килә, түтәй. Миңа да яза! Сагындым дигән була, менә исәр... Сугышып йөргән җирендә сагынырга вакыты бар микән.

З ә к и я . Күңелем сизә: синең бәхетеңә исән кайтачак ул. Менә мин әйтте диярсең!

Ш а һ и д ә . Кайтсын гына берүк, кайтсын гына! Түтәй... түлке син әнекәйгә ычкындырмый тор: без бит Әүхәт белән вәгъдәләштек! Мин аны көтәрмен дип антлар биреп калдым. Көтәм дә.

З ә к и я . Өй тутырып балалар үстерерсез, Алла боерса.

Ш а һ и д ә *(оялып).* Әй, Әүхәт тә шулай дигән була...

З ә к и я . Ул кайтачак! Ышан гына. Ә мин егетләр сөяргә дә житешә алмый калдым.

Ш а һ и д ә . Һи, өлгерерсең әле! Тумас борын картайган берәү...

З ә к и я . Карт кыз бит инде мин, үскәнем *(ютәлли).* Миңа карауччы да табылмас...

Ш а һ и д ә . Табылмый ни! Чибәр бит син, түтәй! Менә терелгәч, тагын мич артыннан корым алып, кашларыңны каралтып җибәрсәңме?

З ә к и я . И-и, терелсәмме...

Ш а һ и д ә . Зәкия түтәм! Син ни... Миңа ачуланма инде, яме...

З ә к и я . Нигә ачуланыйм?

Ш а һ и д ә . Теге чакны Латыйфаның абыйсы синең арттан күзен алартып калганда дим...

Зәкия *(көч-хәл белән елмаерга итә).* Булмаганны...

Ш а һ и д ә . Син дә ошаткан идең дә аны... Сакчы эт шикелле гел янында йөрдем, күзләре бигрәк майлы тоелды шул, синең өчен курыктым.

З ә к и я . Әйтәм аны чишмәгә бергүземне җибәрмәскә җан талаша идең...

Ш а һ и д ә . Аның үлгән хәбәре килгән. Кызлар кулы тотарга да җитешмәгәндер инде, бахыр...

З ә к и я . Үскәнем... Өстемә япчәле, бөтен тәнем калтырый...

Ш а һ и д ә . Бөтен җелегеңә үткән икән суык.

З ә к и я . Безне бит заводта эшләттеләр. Ни өскә, ни аякка кияргә биргән кеше юк. Киеп барган киемнәр тетелеп бетте. Ашарга юк. Соңгы айны ипи карточкасын урлаттым – Сабира белән аның валчыкларын бүлешеп ашадык. Баракта катып үлмәле, алай да бетләп беттек. Әтекәй элгәре хак әйткән икән: саласында да, каласында да шайтаннар хуҗа булган шул. *(Ютәлли.)*

Ш а һ и д ә *(апасының өстенә яба).* Түтәй, мин хәзер Сабираларга төшеп менәм, аларның сыеры бар бит, берәр чокыр сөт арттыра алмасလармы...

З ә к и я *(аны туктатып)*. Кирәкми, үскәнем, кирәкми... Инәкәйгә сиздерми тор. Сиңа әйтәм. Син көчле кыз, малайларга охшагансың. Мин авылга үләргә дип кенә кайттым, үскәнем. Чит-ят туфракта аунап каласым килмәде. Мине зиратның теге башына, наратлык каршына җирләрсез. Әтекәй исән-сау кайтса, баш очыма да берәр бәләкәй нарат утыртып куярсыз.

Ш а һ и д ә . Түтәй...

З ә к и я . Бүлдермә. Шуны да онытма: бу илкәйләрдә беркем дә беркемгә кирәкми икән, үскәнкәем. Хакыйкать бардыр, тәртип бардыр, хаклык бардыр дип алданып йөри күрмә. Үзеңә генә ышан!

Ш а һ и д ә . Түтәй, дим... Син тереләчәксең, ишетәсеңме, тереләчәксең! Мин сиңа сөт алып кайтам, түтәй, сөт алып кайтам! Син тереләчәксең!

З ә к и я . Шулкадәр яшисем килә дә соң, үскәнкәем, шулкадәр яшисем килә! *(Бөгәрләнеп ютәлли.)*

*Шулвакыт ишектән, шаулашып, Х ә м и т белән берничә кеше керә. Артларыннан ачыргаланып М ә р з и я йөгерә.*

Х ә м и т . Әһә, монда да бер качкын! *(Дәфтәренә нидер яза.)* Нәрсә, сугыш чоры закуннары синең өчен түгелмени? Качып кайткан өчен, беләсеңме, нәрсә көтә сине?

М ә р з и я . Бирмим! Кызымны берегезгә дә бирмим!

Х ә м и т . Синдә генә кыз... Әле сәвиткә рәхмәт әйт. Төрмәгә озатасы урынга, силсәвит Шәйдул качкыннарны кире җыеп ФЗӨгә генә җибәрергә кушты.

М ә р з и я . Үземне алып китсеннәр! Өтермәнгәме, җәһәннәмгәме... Кызымны бирмим! Тәнендә чыкмаган җаны гына калган.

Х ә м и т . Калган бит әле. Димәк, яши! Җыеныгыз! Атлар әзер.

Ш а һ и д ә . Түтәйгә кагыласы булма! Аның урынына мин барам!

З ә к и я . Юк! *(Башын калкыта, көчкә тора.)* Юк, үскәнем! Син ничек тә яшәргә тырыш! Инәкәйгә терәк бул!

Ш а һ и д ә . Юк, түтәй! Үзем барам!

Х ә м и т . Сиңа да чират җитәр, нигә кайгырасың... Бу юлы качкыннарны алып китәргә, диделәр! Җыен, дим!

*Зәкия ютәлли-ютәлли киенә. Мәрзия сыгылып төшеп елый.*

М ә р з и я . Балам! Балам! Кызыкаем!

З ә к и я . Инәкәй, сау бул! Бәхил бул, инәкәй!

М ә р з и я . Кызыыыым! *(Хәмиткә.)* Башың бетсен, бәдбәхет, каргышым тотсын! Болай да тере мәеткә әйләнгән кызымны тагын кая олактырасыз? Кабахәтләр, барыгызны бергә җир йоткырлары...

Х ә м и т . Кара, сәвит властен каргап торасыңмы? Үзеңне дә олактырыр җир табылыр, күп сөйләшсәң... *(Җиңенә килеп ябышкан Мәрзияне селтәп җибәрә.)*

М ә р з и я . Төкерәм мин сезнең влачыгызга! Беркемгә рәхәт күрсәтмәгән ул савитыгыз белән чукынышып китегез!

1 и р . Мәрзия, авызыңны үлчәп ач! Каторгыга китмиләр бит, кайтыр. Курчак уйнап утырыр яшьләре узган.

М ә р з и я . Чу-кы-нып ки-те-гез! Чу-кы-нып ки-те-гез! Кызым, балам...

Ш а һ и д ә *(әнисен кочаклап, нык-лык белән)*. Әнекәй! Сыгылма! Елама! Елама, зинһар! Мин еламыйм бит, күрәсеңме, мин еламыйм!

*Ут сүнә. Югалту ачысын чагылдырган үзәк өзгеч көй яңгырый. Яктыра.*

**12 күренеш**

*Ишегалды. Ш а һ и д ә баскыч төбендә утыра. Башына шәл ураган, бишмәтен җилкәсенә япкан. Г ө л с е м керә, кышкы киемнән. Шәлен урап бәйләгән.*

Г ө л с е м . Нишләп болай утырасың, Шаһидә? Катып үләсең киләмени? Тор әле, балакаем *(кызны култыклап торгыза)*.

Ш а һ и д ә . Туңганымны сизмим дә.

Г ө л с е м *(өйгә ымлап)*. Мәрзиянең хәле ничек?

Ш а һ и д ә . Көчкә йоклап китте. «Зәкиямне күрмәдеңме, түтәң кая чыгып китте» дип саташа кайчак. Әтекәй турында белгертмәдем, әйтергә куркам.

Г ө л с е м . Бала хәсрәтен күтәрергә тимер йөрәк кирәктер шул... Алла сакласын инде!

Ш а һ и д ә *(кулында бөгәрләнеп беткән кәгазьне җәеп)*. Бу хатны ташлыйм микән әллә дип бөгәрләгән идем, алайса, кая яшермим, инәкәй шуны эзләп табып укый да җылый, укый да җылый.

Г ө л с е м . Сабира язганнымы? Бичара, авырыннан котылган икән, станок ташыганда төште, дип язган анасына.

Ш а һ и д ә . Шул. «Зәкия апа килгәннең икенче көнендә үк җан бирде. Казанның Татар зиратына җирләделәр», дигән.

Г ө л с е м . Чәчәк кебек чагында, диген.

Ш а һ и д ә . Наратлык каршына җирләгез, дигән васыятен үти алмадым.

Г ө л с е м . Син гаеплемени, балакаем.

Ш а һ и д ә . Кем гаепле соң, Гөлсем апа? Бу мәхшәрнең барысына да кем гаепле?

Г ө л с е м . Сугыш бит, закуннары да коры.

Ш а һ и д ә . Сугыш? Ә мондагылар? Фашист, диләр, мондагыларның кай җире ким... Югыйсә, кешеләр бит алар, кешеләр! Нишләп Хәмит кебекләргә бер җәза да юк?

Г ө л с е м . Чү, Шаһидәкәем, алай кычкырып сөйләшмә берүк. Инде сине дә алып китсәләр, энкәңә тилереп үләргә генә кала, әйттем исә кайттым.

Ш а һ и д ә . Түтәйгә бер җомры сөт булса да кайнатып эчерергә җитешә алмый калдым.

Г ө л с е м . И бала, сөт кенә коткарыр иде, дисеңме...

*Еракта нindидер тавыш ишетелә. Шаһидә сискәнеп китә.*

Ш а һ и д ә . Нинди тавыш булды?

Г ө л с е м . Бүреләрдер ул. Мәрфуга апаң көндез генә әйтеп тора иде, Ташландык чишмә тирәсендә күбәйгәннәр, авылга төшә күрмәсеннәр, дип. Шул мәлгуньнәр тавышы булды бугай.

Ш а һ и д ә . Бүреләр? Ташландык чишмә янында?

Г ө л с е м . Ул тирәдә элек үләт базы иде бит, авылга якын дип күмдергәндәй иттеләр. Шуңа иснәнеп йөриләрдер.

Ш а һ и д ә . Абау, бигрәк куркыныч!

Г ө л с е м . Куркыныч булмый. Безнең кебек, алар да ач. Ач чагында үләксәни, адәм ни, каршыларына килеп чыкса, кешене дә өзгәләп кенә аталар.

Ш а һ и д ә . Уйласаң да котың очарлык...

Г ө л с е м . Чыгыйм әле мин. Мәрзиянең хәлен белим дип кенә керүем иде. Ике почмакта ике малаем ашарга сорап, күзгә карап тилмереп утыра. Как сәкедә җан биралмый Касыймым тилмерә... Чыгыйм, Шаһидә. Сезгә дә сабырлык бирсен Ходай.

*Шаһидә Гөлсемне капкага кадәр озата. Шул урында басып, бик озак бер ноктага карап тора. Х ә м и т килеп керә. Шаһидәгә карап тора.*

Х ә м и т . Кара, ирдәүкә, кеше белән исәнләшергә өйрәтмәделәрмени сине?

Ш а һ и д ә . Кеше белән исәнләшәм.

Х ә м и т. Мин ишетмәдем.

Ш а һ и д ә. Син бит кеше түгел.

Х ә м и т. Ну-ну... Кем димәкче буласың?

Ш а һ и д ә. Үтерүче син. Кеше үтерүче.

Х ә м и т. Аягөсте төш күрәсеңме әллә, авызың әйткәнне колагың ишетми.

Ш а һ и д ә. Минем Зәкия түтәмне син үтердең. Гарип атамның исемен трудармиягә алынучылар исемлегенә син өстәп яздыргансың. Өстенә шахта ишелеп үлмәде ул, аны син үтердең, син!

Х ә м и т. Вәт акылдан шашкан нәмәрсә!

Ш а һ и д ә *(күзләренә туп-туры карап)*. Хет бер сорауга яшермичә, боргаланмый җавап бирә аласыңмы: безнең гаиләдә ни үчең бар синең, сиңа ни зыяныбыз тигәне булды?

Х ә м и т *(авызын очлайтып, иреннәрен уңга-сулга йөртеп уйланып торгандай кылана. Аннан мыскыллы елмаеп)*. Яшермим, нигә яшереп торыйм, дөресен әйтәм. Яшь чагында Мәрзияне ни кыстадым миңа кияүгә чыгарга, көлде генә. Имеш, мин ялкау, мин булдыксыз, мин тегеләй... Йә, Нигъмәтне яратам, диде, аңа кияүгә чыгып ни отты? Ха-ха-ха... Кая мулла кызының кичәге байлыклары, ә?

Ш а һ и д ә. Без идек аның байлыгы, аңлыйсыңмы, без идек! Барысын да синең кебек кабихләр харап итте! Ю-ук, сугыш түгел, сез харап иттегез!

Х ә м и т *(уенда бөтенләй башка нәрсә)*. Карап-карап торам да, ирдәүкә дисәң дә, син дә кан кыздырырлык булып пешеп җиткәнсең түгелме? *(Биленнән эләктереп ала.)*

Ш а һ и д ә *(көчле селтәнеп, Хәмитнең йөзенә суга)*. Җирәнгеч бәндә!

Х ә м и т. Менә-менә, анаң да шулай ди иде! Тач шуның сыңары!

Ш а һ и д ә. Тырнак очың белән генә кагылып кара, чыраеңны умырып төшерермен!

Х ә м и т. Умырырга вакытың калмас, ирдәүкә! Мә, иртәгә иртән кәнсәләр каршына килеп баскан бул, шуннан җыелып китәсез. (Кәгазь кисәге суза.)

Ш а һ и д ә *(аптырабрак)*. Кая китәргә?

Х ә м и т. Урман кисәргә кеше сорыйлар. Авыл башындагы урманга гына түгел, бик еракка юлыгыз.

Ш а һ и д ә. Мин беркая да китмим. Өйдә инәкәйне берүзен калдыра торган түгел, ул авырый.

Х ә м и т. Ишеттем, акылы киткән, диделәр. Психлар бүлнисенә озатырбыз, шунда ятар.

Ш а һ и д ә *(аңа шаккатып карап тора)*. Юк, адәми зат болай булалмый. Кеше түгел бит син, чыннан да иблис!

Х ә м и т. Ә син миңа ошый башладың әле, ирдәүкә! Бик кайнар күренәсең. Ничава, урманда бик тиз суытырлар үзеңне, анда урыс мажиклары җитәрлек...

Ш а һ и д ә. Мин беркая бармыйм. Инәкәйне күрәләтә үләргә ташлап калдыралмыйм. Ассалар да, киссәләр дә бармыйм!

Х ә м и т. Бәйләп булса да апкитәләр. Синең ишене күрмәгәннәр ди.

Ш а һ и д ә. Хәзер үк силсәвиткә барам, Шәйдулла абыйга үзем аңлатам. Инәкәй терелгәнче мин авылдан киталмыйм!

Х ә м и т. Шәйдулны нишли ала дип беләсең... Сине мин генә алып калырга могу, ирдәүкә!

Ш а һ и д ә *(мыскыллы елмаеп)*. Син? Бригадир дигәч тә, кем соң син шулкадәр? Әллә авылда синнән олырак түрәләр юкмы?

Х ә м и т. Бар. Тик соңгы сүзне мин әйтәм!

Ш а һ и д ә *(нидер уйланып)*. Һе... Нинди инде ул синең «соңгы сүзең?»

Х ә м и т. Ирдәүкә... Аның ишене әйтмичә дә аңларга вакыт. *(Колагына иелеп пышылдый.)*

Ш а һ и д ә *(тагын баягы кебек йөзенә селтәнә. Ярсып)*. Ничек җир күтәрә синең кебекләрне – шунысына аптырыйм.

Х ә м и т. Ха-ха-ха. *(Кулыннан әләктереп ала.)* Димәк, җиргә минем кебекләр дә кирәк!

Ш а һ и д ә. Әгәр мин... *(Нидер уйлап.)* Риза, дисәм?

Х ә м и т *(учын учка сугып)*. Син – миңа, мин – сиңа. Бу кәгазьне вак-вак кисәкләргә тураклыйм да җилгә очырам.

Ш а һ и д ә. Инәкәй хакына... Бары аның хакына.

Х ә м и т. Яратам шулай сүзне кыска тотучыларны. Алайса, бүген төнлә капка келәгезне төшермичә генә ят. Урын тапмый калмабыз.

Ш а һ и д ә. Юк! Авылның кырык күзе бар. Төн дип тормаслар, берәрсе күреп калса... Исемемне урамга чыгарасым килми... Ташландык чишмәнең бурасы һаман исән. Шунда кил.

Х ә м и т. Синең дә акылың ычкынмагандыр бит? Урман очындагы чишмәне әйтәсеңме? Бер диванасы буралап куйган. Ул тирәдә бит элек үләт чокыры булган.

Ш а һ и д ә. Шуны әйтәм. Анда аулак. Кеше-кара килеп чыгар дип борчыласы юк.

Х ә м и т. Соң, соң... Шунда хәтле өстерәлеп йөрергә... син мине...

Ш а һ и д ә. Юк икән – юк инде. Кеше күзеннән куркам, башкача булдыралмыйм.

Х ә м и т. Вәт ирдәүкә... *(Икеләнеп тора.)* Кеше төсле генә кыланырга ярамыйдыр.

Ш а һ и д ә. Син кеше түгел, иблис, дидем бит! *(Хәмитнең күзенә ут чәчеп карый.)* Мин бары тик авыру әнекәем хакына гына риза, дидем, онытма!

Х ә м и т *(иягеннән тотып)*. Матри, ирдәүкә, әгәр хәйлә булса, кара таңнан өегезгә кереп, үзем бәйләп алып чыгам, үзем бәйләп озатам. Син урманнан кайтканда, анаңның кипкән сөякләре генә каршы алыр үзеңне!

Ш а һ и д ә. Кипкән сөякләр? *(Уртын чәйнәп.)* Киләм, дидем. Авыл йоклагач. Бура эчендә көт.

Х ә м и т. Матри, ирдәүкә!!! *(Бармак янап чыгып китә.)*

Ш а һ и д ә *(үзалдына)*. Бар, Хәмит, бар!.. Димәк, йә син, йә мин... Ходаем! Җир йөзен хет бер адәм актыгыннан чистартсаң иде!

*Ут сүнә. Шомлы музыка яңгырый. Яктыра.*

**13 күренеш**

*Язгы көн. Кайчандыр кышын авыл хатыннары урман кискән урын. М ә р ф у г а , Г ө л с е м , Ш а һ и д ә чүпрәк капчык тотып, кычыткан, яшел үлән җыеп йөриләр.*

Г ө л с е м *(үзалдына җырлый)*.

Алмалар өзәр идем дә
Җепләргә тезәр идем.
Янмаса бу йөрәккәем,
Сагынуга түзәр идем.

М ә р ф у г а. Гөлсем, сабыр бул инде, сабырлар бул! Үзең турында уйла.

Ш а һ и д ә. Гөлсем апа, болай булса, син дә инәкәй кебеккә әйләнәсең бит *(кочаклый)*. Түз, сабыр бул!

Г ө л с е м. Бөтенесе шулай, ди. Сабыр бул, диләр. Кайлардан алыйм соң ул сабырлыкларны? *(Елый.)*

М ә р ф у г а. Кайда йөри соң бу Сәлимә? Урман авызына менәбез, дигәч, көтегез, мин дә барам, дип калды бая. Йөри бугай, адашкан бәрән сыман...

Г ө л с е м *(җырлый)*.

Яр буенда салкын чишмә,
Агып төшә улакка...

М ә р ф у г а *(бүлдереп)*. Җитәр лә, Гөлсем! Әүхәтең турында уйлар иең. Ул кайтып керүгә, Шаһидә әйтмешли, син дә Мәрзия кебек булып куйсаң... Алла сакласын!

Г ө л с е м *(каядыр борылып, еракка төбәлеп тора)*. Өчесе тиң бергә яталар. Мин генә монда берүзем.

Иртән торам да тәрәзәдән зират ягына карыйм. Бәгырькәйләрем, өчесе тиң бит, өчесе тиң...

Мәрфуга. Синекеләр генәме... Ул шыткан бодай белән ярты авыл харап булды, тамак тәмугка кертә, диләр шул, ни хәлләр итәсең.

Гөлсем. Ике улым, буй җиткереп килгән ике балам... Җир идәнне тырный-тырный үлделәр бит, күз алкайларымда... Сөт эчергән булсагыз, исән каласылар иде, диләр... кайлардан алып, кайлардан алып? Сөт булса, Касыймым да кан косып үлмәс иде... Өчесе тиң бит, өчесе тиң... Ничекләр сабыр булыйм?

Шаһидә. Ничек тә яшәргә кирәк бит, Гөлсем апа...

*Сәлимә керә, ул да капчык тоткан.*

Мәрфуга. Теге очлар бөтен кычытканны җыеп бетерә бит инде. Кайда йөрисең шул гомер?

Сәлимә. Урта урам Гарифәгә пахарункы килгән, шуны илтсәм дә илттем, илтмәсәм дә юк. Кайлардан башымны тыктым бу пашталиун эшенә... көн туса, яман хәбәр ташудан арынмыйм... Капка төпләреннән биш әйләндем. Бер атна яшәп калган ие бит ире белән, бер атна!

*Хатыннар утырып дога кылып алалар.*

Сәлимә. И-и, башкайларымны әйтерием... Гөлсем апа, сиңа хат бар, Әүхәтеңнән!

Гөлсем *(сискәнеп кенә хатны ала, барысы да, сулышсыз калып, аның кул хәрәкәтенә, күз карашына карап торалар. Авыз эченнән генә иҗекләп укырга маташа).* Үзенең кулы! Исән икән, балакаем!

Мәрфуга. Көнгә бер яхшы хәбәр ичмаса... Аллага шөкер.

Гөлсем. Шаһидәкәем, укып бир.

Шаһидә *(укый).* «Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле әткәм Касыйм, әнкәм Гөлсем! Һәм дә яраткан энеләрем...» *(Барысы да елашалар, күз яшьләрен сөртәләр.)* Монда бөтен авылга сәлам тезелгән... «Минем үз хәлемә килгәндә, әле бу минутларда исән-сау. Тамагым тук, өс бөтен. Ике йөз грамм икмәк белән үтә күренә торган суда пешкән тары үрәсен ашавы, ашаганда бөтен кеше бер табактан кашыклар белән тары бөртекләрен куып йөрүләре шундый кызык, шундый күңелле. Аш алдыннан бисмилла әйтсәң, бәрәкәтле була, дигәнгә күрә, бисмилланы калдырганым юк. Кайчакта әгузесен дә әйтеп куям. Укымыш ярый бит ул бер урынга. Сез әгузе генә түгел, колхуалланы да укый торгансыздыр, сезгә дә җиңел түгелдер...»

Мәрфуга. И-и, җиңел буламы соң... Ат урынына хатыннар җигелергә калгач, каяннар җиңел булсын.

Сәлимә. Кара, Әүхәтне әйтәм, китап язган шикелле итепләр язган!

Гөлсем. Улыкаем... Хатына каршы ничекләр җавап языйм? Монда нимес атып тормаса да, авылның ачлыктан тилмергәнен, ике энекәшенең кар астында калган шыткан бодай ашап җан биргәнен, атасының үлгәнен ничек языйм? *(Елый.)*

Мәрфуга. Ил башына килгән хәсрәт, ни кыласың. Сыеры булганнарга гына бераз җиңелрәк.

Сәлимә. Өй тулы аяксыздан-кулсыз бала, мин дә әл дә сыеркаем бар, әл дә сыеркаем, дим! Шуңа гына карап торабыз.

Мәрфуга. Кемәйләр, артык сүз бозау имезә, ди. Булганын җыйыйк та кайтыйк. Аллага шөкер, кычытканы, кузгалагы баш төртте – ачка үлмибез, яшибез, кемәйләр, җан асрыйбыз!

Сәлимә. Яшибез дигәннән... Сез ишеттегезме соң, Хәмитне тапканнар бит!

*Шаһидә сискәнеп китә, әмма дәшми.*

Мәрфуга. Кит аннан! Ишетмәдек! Кайда йөргән?

Гөлсем. Ул иблискә ни-нәмәрсә булсын, диген.

Сәлимә. Хәмитне дип... Үзен түгел, сөякләрен!

*Хатыннар аһ итәләр, тиз-тиз генә битләрен сыпырып куялар.*

С ә л и м ә . Ташландык чишмә буенда кар эреп, кеше сөякләре килеп чыккан.

М ә р ф у г а . Әнекәем лә!

С ә л и м ә . Бүреләргә юлыккан ди. Итекләреннән танып кына Хәмит дигәннәр, андый көн итекне авылда Шәйдул киде дә Хәмит киде.

М ә р ф у г а . Кыш көне районнан тиклем килеп ни эзләделәр, Хәмит югалды дигәч, авылның астын-өскә әйләндергән булдылар.

Г ө л с е м . Эткә эт үлеме булган икән алайса.

М ә р ф у г а . И, үлгән кеше турында яман сүз сөйләмик инде, кемәйләр. Нишләп йөргән диген син аны, әҗәлен эзләп.

С ә л и м ә . Күрше авыл маржалары яныннан кайтып килгәндер, тагын кайда йөрсен...

М ә р ф у г а . Өстендә гел кеше каргышы булды, күз яше төшми каламы соң!..

*Ут сүнә. Яктыра.*

**14 күренеш**

*Көз башы. Мәрзияләрнең ишегалды. Көянтә-чиләк күтәреп, судан Ш а һ и д ә кайтып керә. Башында яулык, өстендә юка камзул. Чиләкләрен эскәмиягә куйганда, өй ишеге ачыла, М ә р з и я күренә. Ул бик бетеренгән, күзләрендә нур калмаган, яулык астыннан чәчләре тузгыган.*

М ә р з и я . Түтәң кая? Чишмә буенда калдымы?

Ш а һ и д ә *(аның янына килә, кочаклый)*. Инәкәй, әле әйбәт кенә утырып калган идең бит. Инде тагын...

М ә р з и я . Су буенда салкындыр. Бишмәтен илтеп бир. Мәле, мәле, менә яулыгымны да бир. Салкын тидерә күрмәсен.

Ш а һ и д ә . Ярар, әнкәй, ярар. Илтермен. Әйдә, син өйгә кер дә ятып тор әле.

М ә р з и я *(керергә теләми, болдырга төшеп утыра)*. Көн ятам, төн ятам. Тагын башым шаулый башлады.

Ш а һ и д ә . Керик, инәкәй. Яңа судан самавыр көйрәтермен. Гөлсем апаны да чакырырбыз. Бергәләп чәй эчәрбез.

М ә р з и я *(кеткелдәп)*. Атаң да озакламас, Касыйм абыеңны да дәш.

Ш а һ и д ә . Ярар, инәкәй, дәшәрмен.

М ә р з и я *(башын тотып, еламсырый)*. Эчендә утын кисәләрмени, әй гөжли башкаем...

Ш а һ и д ә *(әнисенең башын сыпыра, авыз эченнән генә дога укый, сыйпый)*. Бәләкәй чакта үзең өйрәткән догалар, инәкәй. Аллаһы Тәгаләдән гел сорыйм, терелтсә генә ярар иде үзеңне!

М ә р з и я *(бик гаҗәпләнгән кыяфәттә)*. Мин авырыйммыни?

Ш а һ и д ә *(моңсу елмаеп)*. Кайчагында башым авырта дисең бит.

М ә р з и я . Кулың шифалы синең, балакаем. Менәтрәк, авыртуы да бетеп киткәндәй булды.

Ш а һ и д ә . И инәкәй...

М ә р з и я *(урыныннан кузгалып, өйгә атлый)*. Бербөртегем бит син, балам. Шаһидәм, бербөртегем... *(Кереп китә.)*

*Шаһидә аның артыннан керергә атлый да кире борыла, лап итеп баскычка утыра. С ә л и м ә керә. Иңсәсенә почтальон сумкасы аскан. Читән койма аша Гөлсемнәр ягына карап тора. Баскычта башын иеп утырган Шаһидәне күреп ала.*

С ә л и м ә . Абау, Шаһидә, нишләп утырасың болай?

Ш а һ и д ә . Әәә, Сәлимә апа, син икән...

С ә л и м ә . Мәрзия нихәл? Шул көеме?

Ш а һ и д ә . Акыллы гына утырган

җиреннән көйсезләнеп тә китә, аннан тагын аңына килгәндәй була.

С ә л и м ә . Әйтмә инде, үскәнкәем. Андый авырудан терелә торган да түгел, диләр бит.

Ш а һ и д ә . Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында... Әллә миңа хат бармы, Сәлимә апа?

С ә л и м ә . Сиңа түгел, Шаһидә... *(Янына килеп утыра.)* Аптыраганнан монда кердем.

Ш а һ и д ә *(нидер сизенеп сискәнеп китә).* Яман хәбәр генә алып кермә.

С ә л и м ә . Үскәнкәем... Япь-яшь килеш син дә ниләр генә кичермәдең...

Ш а һ и д ә . Сузма, Сәлимә апа.

С ә л и м ә . Гөлсемгә... ничекләр бирим...

Ш а һ и д ә *(сикереп тора, үзе дә сизмичә, Сәлимәне җилкәсеннән җилтерәтә).* Тагын ни, тагын ни? Әүхәтме?

С ә л и м ә *(сумкасыннан кәгазь ала).* Әүхәт. Менә пахарункасы. Гөлсемгә әйтергә йөрәгем җитми.

Ш а һ и д ә *(җиргә чүгеп, тезләнеп, Сәлимәнең аякларын коча, үзе акылдан язгандай пышылдап кызу-кызу сөйләнә).* Әйтмә, Сәлимә апакаем, әйтә күрмә! Гөлсем апаның җаны болай да кыл өстендә эленеп кенә тора. Әйтә күрмә!

С ә л и м ә . Яшереп кала торган хәбәрме?!

Ш а һ и д ә *(тешләрен кысып, сыкранып, мизгел эчендә ярты картаеп).* Ялгыш хәбәр бу. Сәлимә апа, дөрес түгел! Әүхәт исән, күңелем сизә, исән ул! Әйтмик Гөлсем апага, белгертмик! Әйтсәк, шул минутта үзе егылып үлә бит! Бар өмете булып бер Әүхәт калды ласа!

С ә л и м ә . Бүген булмаса, иртәгә барыбер беленә бит, Шаһидә. Аннан мине винават итеп калдырырлар, Алла сакласын. Хатны тапшырмагансың, диярләр, башымны өтермәнгә илтеп тыгарлар.

Ш а һ и д ә . Хатыңны миңа бир, кирәк дисәң, үзем кул куям. Тик Гөлсем апага гына әйтмә!

С ә л и м ә . Үзем дә аптырыйм инде...

Ш а һ и д ә . Бу хат турында авылда тагын берәрсе ишеттеме инде?

С ә л и м ә *(аптырабрак).* Юк. Юктыр... Әле Шәйдулла да белмидер, силсәвиттә бүген эт җан да күренмәде.

Ш а һ и д ә . Шәйдулла абыйга да үзем әйтермен. Бир миңа хатны, Сәлимә апа!

С ә л и м ә *(кәгазьне биреп).* Без күрәсен кеше күрмәс... Син дә сабыр бул, Шаһидә. Сабыр бул, балакаем! *(Башын чайкап, чыгып китә.)*

Ш а һ и д ә *(кәгазьне әкрен генә ачып укый, бөгәрләп күкрәгенә кыса).* Юк! Ялгыш хәбәр бу! Әүхәт исән! Зәкия түтәм дә шулай диде. Кайтыр, көт, диде. Өй тутырып бала үстерерсез, диде. Ул кайтачак! *(Үзалдына иңри.)* Әүхәт, ишетәсеңме, син кайтырга тиеш! Тормыш гел үлемнән генә торалмый, ишетәсеңме, син кайтырга тиеш!

*Ут сүнә. Өмет белән сугарылган музыка яңгырый. Яктыра.*

**15 күренеш**

*Мәрзияләрнең өй эче. М ә р з и я яткан сәке чаршау белән бүленгән. Бертөркем кызлар, кабага йон бәйләп, җеп эрлиләр (1 күренештә чишмә буена килгән кызлар уйный ала). Ш а һ и д ә дә, С а б и р а да шунда. Бергәләп әкрен генә җырлыйлар.*

...Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

С а б и р а *(чаршау артына ымлап),* Шаһидә, Мәрзия апага комачауламыйбыз микән?

Ш а һ и д ә . Юк, юк, Сабира, хәзер бала йокысы белән изрәде ул.

3 к ы з . Сабира, калада күргәннәреңне сөйлә әле. ФЗӨ дигәннәре...

С а б и р а *(кырт бүлдереп)*. Искәйләремә дә төшермәгез! Әйдәгез, шыпыртлап кына йөзек салышлы уйныйк.

2 к ы з . Ватык тилифунлы гына уйныйк, ул кызыграк.

3 к ы з . Кызык дигәннән, кичә төнлә кәнсәгә кизүгә менгәч, Сәвиядән көлеп үлә яздык!

1 к ы з . Көлмәсәнә, соң, әнкәй бит, тилифунга шалтыратсалар, күп сүләшмә, бөтен кеше йоклый, диген дә тор, дип менгереп җибәрде.

2 к ы з . Әйтәм җирле ярты сәгать кенә сөйләштең.

3 к ы з *(Сәвия булып кыланып, кулын колагына китереп, телефоннан сөйләшкән кылана)*. «Әлү! Әлү! Бөтен авыл йоклый. Юк, мин йокламыйм... Фермада атлар бар әле. Әнкәйләр иртән сыерларны, атларны күтәреп торгызалар инде, ферма түшәменә бау белән асып куялар. Юк инде, нишләп муеннарыннан булсын... Корсакларыннан асалар...»

1 к ы з . Соң, теге кеше бит, әлләниләр сораша. Малларга ашатырга бармы, ди. Мин каян белим.

2 к ы з . Төн уртасында бөтен кайгысы шул булган икән, бичараның.

1 к ы з . Сезгә көлке, пулнамач булды микән әллә дип котым очты.

3 к ы з . Әй, кадалып китсен, әйдәгез, лутчы ватык телефонлы уйныйк инде.

Ш а һ и д ә . Кая, сездән булмас, бала-чагалар... Үзем башлыйм әле. *(Иң читтә утырган Сабираның колагына иелеп пышылдый, кызлар чиратлап бер-берсенә пышылдыйлар.)*

3 к ы з *(иң азакта утыра)*. Рәтләп әйтә белмисез, мин ишетми дә калдым.

2 к ы з . Калач!

1 к ы з . Агач, дидем мин сиңа, а-гач!

С а б и р а . Табагач иде бит! Мин белдем, хәзер мин башлыйм!

Ш а һ и д ә . Белдең ди... Абага, дигән идем мин... Ярар, башла әйдә... табагач...

3 к ы з . Табагач дигәннән... Безнең инәй мичтә тәбикмәк пешерә торган иде...

1 к ы з . Ашау сөйләмәгез әле.

2 к ы з . Их, менә монда бер олы калач булсын иде, әйме, кызлар! Безнең инәй әйтә, сугыш бетсә, он да булыр, авыз тутырып ипи дә ашарбыз, ди. Чынлап шулай булыр микән, кызлар?

С а б и р а . Сугышны бетә, диләр бит инде. Безнекеләр герман җиренә үк барып җиткән ди.

1 к ы з . Алайса, авылга солдатлар кайта башлар инде.

Ш а һ и д ә *(көрсенеп)*. Исән кешеләр бер кайтыр.

*Ишек артында Г ө л с е м н е ң үзәк өзгеч тавышы ишетелә.*

Г ө л с е м . Шаһидә-ә-ә! Шаһидә-ә-ә!

*Ишек шапылдап ачыла, Гөлсемнең иләсләнгән йөзе күренә. Яулыгы иңсәсенә шуып төшкән.*

Г ө л с е м . Әүхәтем! Әүхәтем!

Ш а һ и д ә *(аңа ташлана)*. Гөлсем апа! Сабыр бул!

Г ө л с е м . Кайтты, Әүхәтем кайтты! Балакаем кайтты бит, Шаһидә!

Ш а һ и д ә . Кайтты??? Ничек кайтты?

К ы з л а р *(чыркылдашып чыгып йөгерәләр)*. Әлләй, Әүхәт абый кайткан! Күрик әле!

Г ө л с е м . Әйдәгез, әйдәгез, балалар! Әүхәтем кайтты! *(Чыгып йөгерә.)*

Ш а һ и д ә *(ишек яңагына сарылып, күлмәк изүен йомарлап тота)*. Раббым, мең рәхмәт сиңа! Раббым, мең рәхмәт!

*Ут сүнә. Лирик көй ишетелә.*
*Яктыра.*

**16 күренеш**

*1 күренештәге ишегалды. Кер бавына чәчәкле яшел җәймә эленгән. Ш а һ и д ә белән Ә ү х ә т кулга-кул тотынып, бер-берсенә карап сөйләшәләр. Әүхәт солдат гимнастёркасыннан, башы бинт белән бәйләнгән.*

Ә ү х ә т. Шаһдә! Рәхмәт сиңа!

Ш а һ и д ә *(бәхетле елмаеп)*. Ни өчен рәхмәт әйтәсең, Әүхәт?

Ә ү х ә т. Барысы өчен дә. Әнкәйне ташламагансың, ике өйне бер итеп яшибез, ди.

Ш а һ и д ә. Без сине икәүләп көттек, Әүхәт! Мин исән дип ике генә сүз хәбәр бирсәң соң...

Ә ү х ә т. Госпитальдә озак аунадым, могҗиза белән исән калдым бит, Шаһдә!

Ш а һ и д ә *(күз яше аша елмая)*. Ә мин сине берәр марҗага өйләнеп, мине оныткансыңдыр, дигән идем.

Ә ү х ә т. Синеме? Белсәң иде ничекләр сагынганымны... Сине, чылтырап көлүләреңне – барысын, барысын... *(Кысып кочаклый.)*

Ш а һ и д ә. Абау, әллә тәмәке тартасыңмы? Кара, бөтен киемеңә сеңеп беткән.

Ә ү х ә т. Сугыш өйрәтте. Тәмәкесенә дә, аракысына да.

Ш а һ и д ә. Үләм! Оялмыйча, шуны әйтеп тора! Эчеп кенә кара! *(Белгән чеметә.)*

Ә ү х ә т *(елмаеп)*. Менә шушындый Шаһдәне сагындым инде мин. Егетләр кебек чатнап торган Шаһидәмне.

Ш а һ и д ә. Егет, димәсәләр дә, ирдәүкә, диләр инде. Үпкәләмим.

Ә ү х ә т. Шаһдә! Сугыштан төяп кайткан байлыгым юк. Яраларым белән үзем дә ике күзем. Шулар куркытмаса, ризалыгыңны бир!

Ш а һ и д ә *(ике күзен зур ачып)*. Нәрсәгә?

Ә ү х ә т. Никах укытырга.

Ш а һ и д ә. Кит, кем инде шулай итеп кызлар кулын сорый, ә?

Ә ү х ә т. Соң, мин бөтен тәртибен каян белим? Өйләнеп караганым юк бит.

Ш а һ и д ә *(җитдиләнеп)*. Әүхәт, мин бит үзем генә түгел. Авыру әнкәмне бер генә минутка да ялгыз калдыра алмыйм.

Ә ү х ә т. Мәрзия апаны бергәләп карарбыз, Шаһдә! Анысына борчылма.

Ш а һ и д ә. Дөньяда безгә дигән бер тамчы бәхет тә калган икән әле, Әүхәт!

Ә ү х ә т. Без бәхетле яшәрбез, Шаһдә! Өй тутырып балалар үстерербез!

Ш а һ и д ә *(оялып башын ия. Кинәт чаяланып)*. Исемемне бозма, димәдемме мин сиңа? *(Белгән чеметә.)* Шаһидә мин, Шаһдә түгел, Шаһидә!

Ә ү х ә т *(аны күтәреп әйләндерә)*. Өйләнешкәч, мин сиңа, беләсеңме, кем дип эндәшәм? *(Колагына пышылдый.)*

Ш а һ и д ә *(рәхәтләнеп бәхетле көлә)*. Карчык? Үлә-ә-әм, карчык, ди... Үләм...

*Ут сүнә. Лирик музыка яңгырый. Яктыра. Шул ук күренеш. Шаһидә күршеләр ягына бәхетле караш белән карап тора, башыннан яулыгын төшереп, аяк очында тыйнак кына бөтерелә. Шулчак Г ө л с е м нең читән койма аша үзенә елмаеп карап торганын күреп ала, уңайсызланып китә. Койма янына килә.*

Ш а һ и д ә. Гөлсем апа, сиңа сүзем бар иде... Гаепләсәң-гаепләмәсәң, әйтми калалмыйм.

Г ө л с е м. Һай, гаепләрлек үк сүзмени?

Ш а һ и д ә. Көз башында Сәлимә апа Әүхәтнең... пахарункы кәгазен китерде.

Г ө л с е м *(тавышын, төсен үзгәртми генә).* Шуннан?

Ш а һ и д ә *(аптырабрак).* Мин... сиңа әйтмәскә куштым. Кара пичәтле ул хәбәрне үземдә яшереп калдырдым.

Г ө л с е м . Нигә? Ни өчен?

Ш а һ и д ә . Курыктым. Йөрәгең күтәрмәс, дидем.

Г ө л с е м . Йөрәк дигәнең кайчак чыдаса да чыдый икән ул, Шаһидә. Күтәрде бит.

Ш а һ и д ә . Ничек инде?

Г ө л с е м . Сәлимәнең сезгә кергәнен дә күрдем, сөйләшкәнегезне дә ишеттем мин.

Ш а һ и д ә . Син... барысын да белеп тордыңмы, Гөлсем апа?

Г ө л с е м . Белдем.

Ш а һ и д ә *(шаккатып).* Гөлсем апа! Белгән килеш... ничекләр беркемгә сиздермәдең?

Г ө л с е м . Менә бу яңаклар нигә кибеп корыган дисең, Шаһидә? Тешемне кысып, телемне аркылы тешләп түзәргә тырыштым. Уртларымны чәйнәп түздем. Нишли ала идем? Елап күз яшьләрем кибеп беткән... Мәрзия кебек, акылдан язсам, мин кемнең кулына калыр идем? Тәүбә, әстәгъфирулла.

Ш а һ и д ә . Ышанырлык түгел!

Г ө л с е м . Мин дә ул хәбәргә ышанмадым. «Күңелем сизә – Әүхәт кайтачак!» дигәнеңне ишеттем дә шул сүзләргә ышандым, Шаһидәкәем.

Ш а һ и д ә . Безнең бәхеткә кайтты бит ул, кайтты! *(Оялып.)* Гөлсем апа, без бит вәгъдәләшкән идек. Әүхәт...

Г ө л с е м *(бүлдереп).* Анысын да беләм! Әнә бит, пыр тузып килен төшерергә әзерләнәм, тәрәзә пәрдәләрен селте суына салып куйдым...

Ш а һ и д ә *(көлеп).* Әүхәт әйтә, өй тутырып балалар үстерербез, ди.

Г ө л с е м . Бирсен Ходай! Тизрәк сугышы бетсен дә тамаклар туя ризыкка тиенсен! Сезнең балаларга ачлык афәтләре күрергә язмасын иде!

Ш а һ и д ә . Ә без сыер алырбыз, бәләкәй генә, сөтләч кенә! Балаларым булса, мин аларны беркайчан да сөттән өзмәм, Гөлсем апа! Алар ачка тинтерәмәс! Әүхәтебез исән бит, Гөлсем апа! Без шундый матур яшәрбез, Алла боерса!

Г ө л с е м . Бирсен Ходай! Бирсен Ходай!

*Койма аша кочаклашалар. Еракта Җиңү көе ишетелә, ул якынайганнан-якыная. Ут сүнә. Яктыра. Карт* Ш а һ и д ә *баягыча таягына таянып, эскәмиядә уйланып утыра.*

Ш а һ и д ә . И гомерләр, диген... бер оя балалар үстердек шул, ач итмәдек, Аллага шөкер... Аларны сөттән өзмәм дигән идем дә, менәтрәк, үз сүземә хилафлык китердем түгелме соң? Балалар сүзенә карап, сыеркаемны сатып җибәреп... Туктале... *(Сотовыен ала, күзләреннән ерагайтып, номерларны карый, кирәклесен эзләп таба. Яулыгының бер колагын ачып, телефоннан сөйләшә.)* Сабира, Сабира! Әлү! И-и, син миннән ныграк чукрак... Ишетәсеңме, дим? Соң, кычкырып сөйлим бит инде... Карале, кече киявеңдә сатлык бозау бар дип сөйләнгән иең теге юлы... Йозак, димим, бозау, дим, бозау! Үгезме, бикәчме? Бикәчме, дим! Ай Алла, колаккайларың... *(Йөзе яктыра.)* Шулаймыни? Карале, Сабира, берүк ныгытып әйт – читкә җибәрмәсеннәр, үзем алам. Үгез алам, димим лә, үзем алам, дим. Үзем! Ни дисең? Карамый ни, яшь бит әле мин, йөз дә тулмаган, бозау гына карамаска. *(Кеткелдәп көлә.)* Бәләкәй булса ни, быел бозау, ярәнгә тана, аннан, исән булсак, сыер дигән сүз бит ул, Аллаһ боерса... *(Урыныннан тора, үзенчә теркелдәп, күңеле күтәрелеп, капкага юнәлә.)*

*Лирик көй яңгырый.*
*Пәрдә.*



Фәния
Габидуллина

# ВАКЫТ АГА ҮЗ ИРКЕНӘ

## Җирсү

«Туган якка бик ешладың әле,
Сагынасың икән кемнәрне?» –
Дип сорыйлар миннән авылдашлар,
Сагынам мин газиз җирләрне.

Шушы җир бит безне берләштереп,
Якташ итеп туплый бер йортка.
Шул зур йортка илһам эзләп кайтам,
Көчем юкта кайтам, кот юкта.

Баш иягә кайтам остазларга –
Олы юлга мине чыгарган.
Кайтыр юлым озак төшми торса, –
Сагынуга, беләм, чыдамам.

«Миңештегә бик ешладың әле», –
Колагымда якташ сүзләре.
«Сезнең җирләр илһам чыганагы,
Монда калган Наҗар эзләре.

Шул эзләрдә үскән бәбкә үлән,
Кыр чәчәге бага күзләргә.
Күңелләргә моңлы бер җыр керә,
Җырламыйча ничек түзәргә?!

Монда һәр агачта пар сандугач,
Шагыйрь шуннан илһам алгандыр.
Илһам алгандыр да җырларына,
Безнең күңелләргә салгандыр.

Фәния ГАБИДУЛЛИНА – *шагыйрә; «Таң кызы», «Күңелем җимешләре», «Язмышлар ярында» исемле китаплар авторы. М.Гафури исемендәге әдәби премия лауреаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре. Уфада яши.*

Шушы җырлар, әнә, тынгы бирми,
Кагыла да күңел кылына,
Яңгыр булып күзләремә тула,
Шигырь булып тама юлыма.

Монда үскән агач-куакларга
Шагыйрь моңы әллә уралган, –
Юкәләрдән баллар тамган кебек,
Җыр-моң тама чәчкә-курайдан.

Миңештегә бик ешладым әле...
Моң чакыра, шигырь чакыра.
Һәр тереклек шагыйрь булып дәшә,
Тыңлыйм әле шуны чак кына.

Шагыйрь йөргән сукмакларны эзлим,
Аһ, үләне бигрәк куе ла!
Чәчәкләрнең орлыклары тулган:
Тубыкларга бәрелеп коела.

Шагыйрь чәчкән җыр орлыгы алар,
Шагыйрь чәчкән шигырь орлыгы.
Миңештегә җыр алырга кайтам, –
Җырлар белән монда кыр тулы.

## Тургай

Тәрәзәмнән тургай керде.
Кумадым, куркытмадым.
Алларына сибеп куйдым
Гөлҗимеш орлыкларын.

Чүпләп туйгач җим-ризыгын,
Томшыгын сөрткәләде.
Онытмады төзәнергә:
Йон-тунын төрткәләде.

Җылы йөгергәч тәненә,
Бүлмәне иңләп очты,
Тик җитмәде киңлек аңа:
Тәрәз яктысын кочты.

Артыннан гөл авып калды...
«Рәхмәтеңме бу ашка?!
Файдаңнан зыяның артык,
Күренеп йөрмә башка».

Әйттем дә телем тешләдем.
Туйгач очмый нишләсен?!
Адәмгә хас ул комсызлык,
Тик башына җитмәсен...

***

Мин гөл булып юлларыңда чәчәк аттым,
Син назладың минем таҗны җилләр булып.
Давыл купты шулчак минем җаннарымда,–
Син урладың ул давылны җилкән булып.

Мин ут булып кабынганда яңгыр булдың,
Сүндерден дә куйдың минем учагымны.
Ут шарыдай синең җанга атылганда,
Син яшердең миннән назлы кочагыңны...

Тиле яшьлек дулкын-дулкын бәргәләнсә,
Яры булдың минем күңел диңгезенең.
Кыя булып хисләремне тоттың тыеп.
Аңламадым мин ул чакта изгелегең...

Ә мин тиле көттем синнән яшен уты,
Әзер идем бер очкыннан кабынырга.
Әле булса өтә мине күз карашың:
Салдың ялкын... тик ник үзең калдың салкын?..

## Вакыт

Вакытны туктатып булмый,
Вакыт ага үз иркенә.
Ачык калган тәрәзәмнән
Өйгә яз исе бөркелә.

Ялындырып килде бу яз:
Йә эретте, йә туңдырды.
Яшьлектә җилкеткән җилнең
Картаюы шушыдырмы?

Туктатып булмый вакытны,
Вакыт ага үз иркенә.
Кайгы да юк, шатлык та юк, –
Ник соң күзгә яшь эркелә?

Ник өмет юк бу язларда,
Туар таңнан ник өркелә?
Ышанычсыз көннәр сөйрәп,
Вакыт ага үз иркенә...

Акма, вакыт, ашыктырма
Санап безнең гомерләрне.
Учагымда куз бар әле
Яндырырга күмерләрне.

## Курку

Ничә уздым икән шушы йорт яныннан...
Керфек сирпеп карарга да кыймый гына?
«Мәхәббәтең өчен кирәк көрәшергә», –
Дигән тәгъбир җанны хәзер кыйный гына...

Кыз баланы тыйнак бул дип үстерәләр,
Көрәшү дә, димәк, безнең эш түгел лә.
Еллар үткәч узам янә... Таныш йортка
Үпкә саклап күңелемнең иң төбендә.

Һаман әле таныш хисләр һич сүнмәгән, –
Аяк тавышын басып йөрәк какмасынмы!
Шуны ишетеп, яшьлек дустым чыгар сыман
Таныш йортның таныш «җырлы» капкасыннан.

Чыга калса, әйтер сүзләр күптән әзер.
Һәм яз саен ташкын судай арта алар.
(Ничә еллар кабатлана бу халәтем!)
Һәм яңадан ярларына кайта алар.

Очрамады түгел дустым, очрап торды,
Күңелдәген әйтергә дә булды вакыт.
Тик әйтмәдем: таныш хисле җилкенүне,
Өметемне югалтудан курыктым күк.



Рөстәм
Галиуллин

# БОССООЙКО

хикәя

Очкыч, аксыл болыт пәрдәсен ертып, калтырана-калтырана, өскә күтәрелде. Дәһшәтле «Боинг» озын канатларын әле бер, әле икенче якка янтайтып алганда, адәм баласын бу дөньяда тәкъдир йөрткәнен уйлап, һәр мизгелнең никадәр кадерле икәненә төшенәсең. Самолёттагы һәркем шулай уйлыйдыр кебек тоела. Әйе, күккә күтәрелү үзе бер могҗиза бит ул...

Ноябрь башы. Юеш кар Мәскәүнең урам ташларына орыну белән, мизгел эчендә карала. Кала читендәге тапталмаган кырлар гына бары аксыл булып күренә. Шуңадыр, куе томан эчендәге шәһәр өстән аклы-каралы кебек тоела. «Внуково» аэропорты исә биеклектән чиксезлек тамгасын хәтерләтә. Әллә елганы буып ясаудан хасил булган күлме шунда? Гүя, күл тирәли канатларын кагына-кагына су эчәргә җыелган казлар сибелешкән...

Ниһаять, очкыч тиешле биеклекне алды, калтырану, дерелдәүләр бетте, һәм ул ап-ак дулкыннары тын гына тибрәлгән диңгез өстеннән йөзгән корабка охшап калды. Маңгайдагы бөрчек-бөрчек тирне сөртеп алдым, саклану каешын ычкындырдым да драп пәлтәмнең төймәләрен чиштем. Бары хәзер генә юлдашыма игътибар иттем: җыйнак гәүдәле, калын кысалы күзлеге аша кысынкы күзе җемелдәп балкыган, киң йөзле сөйкемле агай икән.

– Кунакка барасыңмы? – дип сорады ул бәрхет тавыш белән.

– Әйе.

– Беренче тапкыр, ахры? – Ул минем җиңел пәлтәмә күз ташлады.– Безнең Сахада салкын көннәр тора.

– Тәүге баруым, әйе. Нәрсә кияргә дә белмәдем, бездә юеш кар бит, – дидем аклангандай. Аннары сүзне уен-көлкегә борырга теләдем: – Әй, исегез китмәсен сана, татарларны суык та, эссе дә алмый, чыдам халык без!

– Син татар егетемени?

Якут агайның күзенә җылы йөгерде. Аның сүзен раслап баш кагарга гына өлгердем, җилкәсен җилкәмә үк терәп, болай да ягымлы тавышын тагын да җанландырып, озын-озак әңгәмәгә әзерләнде. Хәер, сүзчән юлдашка үзем дә каршы түгел, җиде сәгатькә якын очасы бар, ул арада нишләп бетмәк кирәк?

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987) – *язучы, филология фәннәре кандидаты; «Гипнозчы малай», «Юлларда җил ак иде...», «Одиночество» китаплары авторы. ТРның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

– Сахада туганнарың бармы? Анда татарлар бик аз бит? Әллә эшкә урнашасыңмы?

Юлдашым сорау арты сорау яудырды.

– Дустым Хабырыыс – якут язучысы, күптән түгел Татарстанда кунак булып китте, хәзер менә үзе оештырган әдәбият бәйрәменә чакырды.

– Әллә син дә язучымы?

– Язмыйча тора алмаучы...

– Ә-ә, аңладым! – диде агай, тынычланып. – Төшендем! Син Боссоойко турында әсәр язарга барасыңдыр!

– Боссоойко?

– Әллә аны белмисеңме?!

– Беләм, беләм! – дидем кабаланып. – Миңа аның хакында Хабырыыс дустым сөйләгән иде! Саха халкының милли каһарманы ул! Татар егете Гыйззәтулла Рәхмәтуллин! Тиңдәшсез батыр, көчле, зур булганга сез аны Боссоойко дип йөртәсез икән!..

Якут агае канәгать көлемсерәде. Карашын дулкын-дулкын кабарып торган ак болытларга текәп, бермәлгә тын гына уйланды да, оныгын йоклатырга әзерләнгән бабайларныкы төсле тигез, йомшак тавыш белән Гыйззәтулла турында ишеткән-белгәннәрен сөйли дә башлады. Җиде катлы болыт өстендә, биектә – күктә милләттәшең турында әкияткә тартым хикәятләрне тыңлау шулкадәр мавыктыргыч, кызык иде...

Шомырттай кара күзле, түгәрәк йөзле чибәр стюардессаның җилкәмә кагылуыннан сискәнеп, айнып киткәндәй булдым.

– Самолёт җиргә төшәргә әзерләнә. Саклану каешын эләктерегез!

Их, бу вакытның кыскалыгы! Мин, имезлеген тартып алган баладай, нәүмиз генә юлдашыма бактым да дертләп куйдым: аның күзендә яшь иде!

– Мин белгәннәремнең барысын да түкми-чәчми сөйләдем, – диде агай, елмаеп. – Тагын да тулырагын, әнә, галимнәрдән, язучылардан белешерсең.

Очкыч Лена елгасының өстеннән очып узды да аклык патшалыгында утлары җемелдәп балкып торган Якутск каласының аэропортына төшеп утырды.

Якут агае белән каршы алучылар янына бергә чыктык. Саха халкының милли киемнән кымыз, ипи-тоз тотып каршы алуларын күреп, күңел тулды. Ул арада елмаеп торган ике кыз уртасыннан дустым Хабырыыс атылып чыкты да кочаклап алды.

– Юлың уңсын, Боссоойконың туганы! – Якут агай җилкәгә җиңелчә кагылып алды да саубуллашырга ашыкты.

– Рәхмәт, агай! Үзегезгә дә гел яхшы юлдашлар гына очрасын!

Хабырыыс исә драп пәлтәмне тотып карады да башын чайкады:

– Бу пәлтәң самолёт эчендә кияргә генә ярый, бездә инде утыз градуслы салкыннар хәзер,– диде ул, көлемсерәп. – Ярар, сиңа җылы тун табармын.

– Ничава, түзәрбез! Ишетмәдеңмени – абзый мине Боссоойконың туганы дип атады!

Хабырыысның күзендә кызыксыну утлары җемелдәде.

– Әллә вәгъдәңне үтәдеңме? Мин җибәргән архив кәгазьләре эшкә ярадымы?

– Ярады! Үзең дә язучы кеше, беләсең: күрмичә, тоймыйча, кичермичә әсәр язу мөмкин түгел! Шуның өчен дә Сахага килдем бит!

– Шуның өчен кунакка чакырдым да сине, дускай. – Хабырыыс сер бирмәскә тырышты. – Мәңгелек туңлык иленә, Боссоойконың ватанына рәхим ит!..

Якутиядә узган бер атна эчендә Гыйззәтулла Рәхмәтуллин турында юлымда очраган һәрбер саха кешесеннән сораштым дисәм дә һич ялган булмас.

– О-о, ул безнең милли каһарманыбыз! – диде күренекле галим-язучылары. – Сахаларның мөстәкыйльлеге, азатлыгы өчен көрәштә башын салган мөхтәрәм зат, батыр сугышчы. Беренче Бөтендөнья сугышында катнашып, каһарманлыгы өчен бүләкләнгән кеше...

– Совет елларында бу исемне кычкырып әйтмәскә тырыша идек, әлбәттә, – дип башлады сүзен карт тарихчы, як-ягына карангалап. – Хәзер инде аның инкыйлаб чорындагы роле турында иркенләбрәк тә сөйләргә буладыр, мөгаен. Саха иленең автономия алуында аның өлеше, һичшиксез, зур...

– Ул – башкисәр булган! Аның бандасыннан өркеп торганнар! – диде бер аучы. – Аның шикелле көчле кеше дөньяда юк! Әнә, Алдан елгасы ярында алтмыш потлы таш ята. Боссоойко күтәреп уйнаган таш ул!

– Ул көрәштә беркемгә бил бирмәгән! – Хабырыысның авылдаш агае, күзен серле кыса төшеп, Гыйззәтулла турында белгәннәрен сөйләргә әзерләнде. – Аның иң якын дусты Бараммат Байбал дигән саха батыры булган. Тик алар беркайчан да бер-берсе белән көрәшмәгән. Әле берсе, әле икенчесе чираттан батыр кала икән. Шуларның кайсы көчлерәк икәнен берәү дә әйтә алмаган. Бервакыт бер төркем халык киртәгә бәреп кергән нәсел үгезен ничек чыгарырга белми изалана икән. Әй, сез, дип көлгән алардан яннарыннан үтеп барган Боссоойко, мин бу үгезне күтәреп кенә алып чыгар идем, дигән. Халык кәмит ярата бит инде ул, үзең беләсең. Әгәр күтәреп чыга алсаң, үгез – синеке, дигәннәр. Боссоойко мөгезләре белән киртә җимереп йөргән үгезне җиңел генә күтәреп җилкәсенә салган да ике чакрым ераклыктагы алаһасына[1] кайтып киткән...

Тарих тәгәрмәче әйтерсең лә кирегә әйләнә башлады.

Чү! Әнә, еракта-еракта, Гыйззәтулланың тирмәсе күренә түгелме? Пөхтәләп төзәтелгән чем-кара сакаллы, куе кашлы, тундраның ачы җилләреннән кысыла төшкән яшькелт күзле, башына кара түбәтәй кигән киң җилкәле, мәһабәт нарат агачыдай төз, озын буйлы, хатын-кызларны бер караштан әсир итәрдәй кыяфәтле ир-ат Боссоойко бугай? Шул-шул, үзе! Әнә бит – алагаем ташны бик җиңел генә күтәреп алды да кулында уйнаткалап җиргә ташлады. Нәрсәдер тетрәде, җир кучәреннән кучте...

***

– Айхал!..[2]

– Айхал! Айхал!..

Гыйззәтулла үзен көрәш мәйданында сыман хис итте. Әнә, түгәрәк боҗра хасил иткән халык гөҗ килә. Үгез тиресенә капланган Гыйззәтулланы хөкемдар хәзер алан уртасына алып чыгачак та каплавычларыннан арындырачак. Шунда ул көндәшен күрәчәк һәм... аннан инде көчлене ачыклый торган гадел көрәш башланып китәчәк.

– Айхал!

– Айхал! Айхал!..

Гыйззәтулла тамырларын кыздырып кан йөгергәнен тойгандай булды. Гөжләү авазлары, колакны иркәләп, көчәйгәннән-көчәя, көрәшкә чакырган тавышлар якынайганнан-якыная бара иде.

Чү!

Бу боҗра ник кысылганнан-кысыла, һаман да тарая соң әле? Киресенчә, киңәергә, батырларга юл бирергә, иркенлек тудырырга тиеш түгелме соң?

[1] Алаһа – якутча: мең еллар элек боз эрүдән барлыкка килгән тирән сөзәк чокыр.
[2] Айхал – якутча: дан.

– Рәхмәтуллин, бирел!

– Боссоойко, син – капкында!

– Кулларыңны өскә күтәр дә алан уртасына чык!

Нәрсә бу?! Кем анда аңа – тирә-якта тиңдәшсез батырга – шулай эндәшергә җөрьәт итә?! Гыйззәтуллага күсәк белән тондырдылармыни – күз аллары караңгыланып киткәндәй тоелды. Кайсысы аңа – җиңелмәс пәһлеванга – шундый хурлыклы сүзләр әйтергә кыйды?! Гыйззәтулланың дилбегәне кыска тотуын, ачуы кабарса, кыя-ташлар җимерүен, таулар күчерүен алар белмиме әллә?

– Син җиңелдең, Боссоойко!

– Әшнәләрең безнең кулда!..

– Камалышта берүзең!..

– Башыңны иеп чык!..

Гыйззәтулла, ярсуын көчкә тыеп, иренен тешләде. Авызлыклана алмаган гайрәте, гәүдәсенә сыймыйча, аны калтыратырга тотынды.

– Беркайчан да... – дип пышылдады кан чәчрәгән иреннәре. – Беркайчан да, беркайчан да!

Ул землянка ярыгыннан тышка бакты: аның камалышта калуына инде өченче тәүлек китте. Ике ел тоташ аны эзәрлекләүчеләр, ниһаять, тайганың кеше аягы сирәк баса торган караңгы почмагында яшеренгән Гыйззәтулланы эзләп тапты. Кырык кешелек отряд инде өченче көн аның землянкасын утка тота. Мылтыклы солдатлар тирәсендә кызыл командир кайнаша.

Юк, тәнендә җаны бар чакта Гыйззәтулла беркемгә дә бирелмәячәк, җиңелмәячәк! Кем-кем, әмма аны җиңәрдәй, тезләндерердәй көч әле дөньяда юк. Шуңа да ул Боссоойко!

Кораллы солдатлардан берәү дә землянкага таба беренче адым ясарга, баш югалтып һөҗүмгә ташланырга кыймый. Гыйззәтулланың нинди батыр булуын, оста сугышчы икәнен ишетеп тә, инде күреп тә белә алар. Күбесенең хәтта аның көрәшкәнен якыннан күргәне һәм... сокланып, көч биреп торганы да бар.

Кызыл командир исә котыра, сүгенә, наган белән җилкәләргә төртә – әмма үзе солдатлар артында качып торудан ары китә алмый. Землянкага якынлаша торган түгел – Гыйззәтулла төз мәргән, өстәвенә, кулында гранатасы бар – беренче көнне үк ике солдат ахирәт дөньясына күчәргә өлгерде инде. Башкаларының исә алар артыннан китәргә һич исәбе дә, теләге дә юк. Аннан да бигрәк Саха иле батырына кул күтәрергә намуслары кушмый иде. Әмма... кызыл командир гына... төкерекләрен чәчә әнә:

– Ул безгә тереләй кирәк! Шәһәрнең үзәк мәйданына асабыз мөртәтне, искелек калдыгын! Революция дошманын! Халык корткычын!..

Гыйззәтулла бу көрәшнең чиксез түгеллеген бик яхшы белә. Дусларының коткаруына өмет бөтенләй юк – алар төрмәдә, инде байтагы фани дөнья мәшәкатьләреннән котылды да. Өч тәүлек буе керфек какмаудан, ачлыктан хәле кимегәннән-кими, күп дигәндә, ул бүген кичкә кадәр каршылык күрсәтә алыр.

Ә аннары...

Ул кулындагы гранатасын сикертеп алды. Аннары этисе өйрәткән догаларны укыр да... мәңгелек юлга кузгалыр...

– Ә-ти...

– Әт-кәй...

Чү?!

Улы Гарифулланың тавышы ишетелә түгелме соң? Әллә инде үлем саташуы башланды дамы?

– Ә-ти...

– Әт-кәй...

– Ал-дан-ма, чык-ма...

Ул, калкынып, землянка ярыгыннан күз ташлады: алан уртасында канга манчылган, авыр яралы унике яшьлек төпчек улы Гарифулла ыңгыраша иде.

Нәрсәдер өзелде. Йөрәге атылып чыгарга җитешеп тибеп алды да киселгәндәй тын калды...

... – Айхал!

– Айхал! Айхал!

Гыйззәтулла соклангыч карашлардан пәйда булган җанлы рәтләр арасыннан башын югары тотып, горур гына атлады. Кемдер аның кулын кысарга тырыша, кайсыдыр җилкәсеннән какмакчы. Ул арада мактаулы авазлар бер-берсенә ялганып, укмашып китә:

– Мондый батыр гасырга бер генә туа!..

– Бүтүн күүстээх киһи![3]

– Эһ тә итмәде, ә? Күрдеңме?

– Моның кулына эләксәң?!.

Божра ачылып аңа юл бирде – Гыйззәтулла бер читтәрәк басып торган хатыны Матыйфага таба атлады. Матыйфаның кулында ике яшьлек Гарифулла, әтисен еректан ук күреп алып, әнисенең кочагыннан тыпырчынып җиргә төште дә, аякларын чалыштырып атлап, әтисенә атылды.

– Әт-ти!

– Әт-тим! – дип бытылдады теле яңа ачылып килгән малай. Әле генә таш күтәргән Гыйззәтулланың кочагыннан кайнарлык бөркелеп тора иде – малай борынын әтисенең киң күкрәгенә төртте.

– Менә шушы улым, – Гыйззәтулла малаеның башыннан сыйпады, – минем кебек үк җиңелмәс батыр, иң көчле ир булачак! Әле мине дә уздырачак, күрерсез!

Гарифулла, аның сүзләренең мәгънәсенә төшенгәндәй, бер кагынып, аяклары белән тибенеп алды.

Ай-һай, каты да, нык та, зур да соң әтисенең кочагы!

Гыйззәтулланың кендек каны Сахада тамганлыктан, үзе дә якут кешесенә әйләнеп бетә язган иде. Даны-шавы еракларга таралганга, аның татар икәнен барысы да белә, мәрхүм әтисен дә хөрмәт белән Тулла татар дип йөртәләр иде. Әмма аны сахаларныкы, үз батырлары итеп саныйлар. Алып гәүдәле булганга, хәзер инде аны Боссоойко дип кенә йөртәләр. Менә бүген ул сахаларның җәй бәйрәме Ыһыахта иң көчле кеше булып танылды.

Белсеннәр, ишетсеннәр Саха иленең төп батыры кем икәнен, әй-һә-һәй, Өлүөнэ[4] елгасы, диңгезләргә, океаннарга җиткер бу хәбәрне! Әһ-һәй, туундара[5], мәңгелек туңлык иле, сызгырып искән җилләрең бөтенесенә дә таратсын шушы яңалыкны!

Җиһанда 1920 ел хөкем сөрә иде. Утыз җиде яшьлек Гыйззәтулла әнә шушы шатлыклы хисләргә уралып, төпчек малаен кулына күтәргән килеш һаман да тынмаган мактаулы авазлар хозурында атлады да атлады.

Аның әтисе бу якларга Казан ягыннан сөргенгә җибәрелгәнен генә белә

[3] Тулы көчкә ия. Сахаларда физик көч чирек көчле – 25 пот (400 кг) күтәрә алучы, ярым көчле – 50 пот (800 кг) күтәрүче, тулы көчле – 100 пот (1600 кг) күтәрүчегә бүленә.

[4] Лена елгасы.

[5] Тундра.

ул. Әмма ни өчен, сәбәбе нәрсәдә икәнлеген аңа беркем дә әйтмәде, үзе дә этисеннән бу хакта сорашмады.

– Сахалар мине шушы җиргә аяк басканнан бирле үз итте. Тамагымны туйдырырлык ризык бирделәр, сыеныр почмак таптылар, соңрак, киңәшләшеп, бөтенесе бергәләшеп бер алаһа бүлделәр. Син бу яхшылыкларны беркайчан да исеңнән чыгарма, улым. Сахалар – татарлар кебек үк, синең иң якын туганнарың. Һәрчак алар белән бергә бул, кайгыңны да, шатлыгыңны да уртаклаш, бүлеш, – этисе авырып аяктан калгач, аңа әнә шундый васыятен җиткерде.

Сахалар тормышын алып барса да, Тулла татар шактый ук диндар карт иде. Гыйззәтулланы да, өлкән уллары Аргылла белән Чыгылланы да ислам дине тәртипләренә өйрәтте ул. Үзе уртача буйлы, гадәти килеш-килбәтле ир-ат булса, өлкән улы Аргылла белән кече улы Гыйззәтулла нарат агачыдай мәһабәт, өрлектәй таза, нык булып үсте. Ике пәһлеван улы шаярып бил алышса, тирә-юнь халкы тамаша күрергә дип җыела иде. Көрәш башланыр алдыннан һәркайсы Аргылла җиңәр дип фаразлады. Ул Гыйззәтулладан биегрәк, киңрәк җилкәле, зур сакалы исә аны тагын да дәһшәтле күрсәтә. Әмма Гыйззәтулланы беркайчан да ега алмады.

Чыгылла исә этисенә охшап, уртачадан аз гына калкурак гәүдәле. Ул ике ир туганы белән чагыштырганда басынкырак, юашрак иде, шулай да буй җитүгә, Тулла татар вафат булуга, үз көнен үзе күрергә дип Дьокуускай[6] каласына юл алды. Кечкенәдән үзенчә тырышкан-тырмашкан иркен холыклы Гыйззәтулла исә, төпчек булуга карамастан, үзенә аерым тирмә төзеп, алаһаның югары өлешендә яши башлады. Аргылла төп тирмәдә тамыр җибәрде. Барысы да урынына утырды кебек, Гыйззәтулланың гаиләсе ишәйде, ул күпләп болан асрады, атлар тотты, шуларга җитәрлек иген чәчте, үтенеч белән килүчеләрнең атын дәвалады. Әмма тормыш ул Саханың кояш көлеп торган төнсез җәе, зәңгәр җиләк үскән тайгасы кебек гел матур гына булмый шул. Гыйззәтулла көн дә хатынының мышык-мышык елап, балавыз сыгып утыруына юлыкты.

– Ни булды? – дип соравына баштарак хатын дөресен җавап бирмәде:

– Әнием төшемә керде, – дип, яисә: – Туган тирмәмне сагындым, шуңа гына күз яшемне түгәм, – дип алдады.

Әмма посып, качып елаулар күпкә киткәч, Гыйззәтулла хатынын тезенә утыртты да коры гына:

– Хәзер дөресен әйт: сине абыйның аждаһасы рәнҗетәме?

– Юк, юк, – диде хатын, сулкылдап.

– Ни өчен аның белән күрешкән көнне генә шулай шыңшыйсың?

Матыйфа инде түзә алмады, болай да күпме вакытлар эченә җыеп килгәнне иренә ачты да салды.

Ул сыктаудан туктауга, Гыйззәтулла сикереп торып басты:

– Мин ул кашын песи ялаган җен хатынын тирмәсе белән алаһадан чыгарып атам!

– Тынычлан, Гыйззәтулла. Зинһар, минем аркада абыең белән ачуланышма. Китик без. Башка җиргә...

– Нәрсә? – Гыйззәтулланың күзен кан басты. – Бу – минем җирләр! Монда минем иң якын дусларым яши! Үзең күреп торасың, көннән-көн гади халыкны кысалар. Инде мин дә каядыр китеп барсам, аларны кем яклар?

[6] Якутск шәһәре.

Гыйззәтулла атылып урамга чыкты да шул кызулыгы белән абыйсының тирмәсенә атлады.

Кыш башы. Җәй буе хуҗаларча үзен иркен тоткан җил агай да тынып калган, аның иркә-назыннан мәхрүм агачлар да, калын ак юрганга бөркәнеп, моңсу гына йокыга талган. Гадәттәгечә, битләрне өшетә торган салкын көннәр тора. Пар бөркеп, кызу-кызу эре адымнар белән якынлашкан Гыйззәтулла киләкилешкә бозланып каткан тирмә ишеген суырып та алды!

Эчтә чырылдаган тавышлар ишетелде. Иң әүвәл Аргылланың хатыны күкрәген киереп чыгып баскан иде дә... Гыйззәтулланың янып торган күзен күреп, ире артында юк булды.

Ике ир туган бер-берсенә карап тын калды. Читтән күзәткәндә, бу күренеш коточкыч курку тудыра иде. Баганадай озын, аюдай киң ирләр менә хәзер бер-берсенә йодрык төйнәп ташланыр да, тирмә җир белән тигезләнер сыман.

Бер самавыр кайнарлык – чирек сәгатькә якын вакыт узгандыр, мөгаен. Ишексез калган тирмә эченә суык бабай хуҗа булып алды.

Тынлыкны Аргылла бозды, ул кинәт артына борылды да, хатынының күзенә туры карамыйча, коры гына фәрман бирде:

– Җыен!

– Аргылла...

– Җыен дидем!

Гыйззәтулла, кырт борылып, үз тирмәсенә таба атлады. Елаудан шешенеп беткән Матыйфа аны ярты юлда каршы алды.

– Бүре белән болан бергә су эчми, – диде Гыйззәтулла, аның сорау тулы карашын күреп.

Шулай диде диюен дә, әмма бу хәлдән соң бөтен күңелен төшенкелек биләп алды. Үз абыйсы каршында көчен күрсәтү бер дә батырлык түгел шул инде.

Әмма Гыйззәтулла гаделсезлекне кичерә алмый. Әтиләреннән мирас булып калган алаһаны бүлешергә теләмәгән абыйсы, аннан да битәр килендәшен зар елаткан хатыны хаклымы? Ни өчен аны Аргылла тыймаган? Югыйсә, Гыйззәтулла болай да аерым тирмә корып, алаһаның югары өлешенә күченде бит инде.

Гыйззәтулла беркайчан көчсезләрне рәнҗетмәде, кыерсытмады. Бүгенгедәй хәтерли: җан дусты – саха баһадиры Бараммат Байбал белән алар сүз бирешкәннәр иде:

– Гомернең соңгы мизгеленәчә гаделлек өчен көрәшәчәкбез! – диде Бараммат.

Гыйззәтулла һәрвакыт үзеннән яшькә олырак пәһлеванның һәр сүзен, һәр гамәлен үзенекедәй кабул итте.

– Шул юлда бергә башыбызны салырбыз да!

– Әллә! – Бараммат аны сахаларга нигез салучылардан булган Эллэй Боотурга охшатып әнә шулай атый иде. – Бу – безнең антыбыз. Изге ант!

– Изге ант! – дип кабатлады Гыйззәтулла.

Ул чакта берничә көн түзеп йөрде дә алаһаның түбән өлешенә, абыйсының тирмәсенә юл тотты. Ерактан ук ишеге юклыгын күреп алды да, йөрәге жу итте. Адымнарын тагын да кызулатып, тирмәгә йөгереп дигәндәй килеп керде.

Тирмә эче буш иде...

...Бүгенге шанлы җиңүдән соң, әнә шушы күңелсез вакыйга исенә төште аның. Иң якын кардәшең шатлыгыңны уртаклашканда янында юк икән, тормышның ни мәгънәсе бар? Шулчак иңендә авырлык тоеп, сискәнеп китте. Бакса – Бараммат Байбал икән.

– Котлыйм, – диде Бараммат ихластан.

– Сине дә! – Гыйззәтулла аңа кулын сузды.

– Нигәдер боек күренәсең?

– Абыйларны уйлап бара идем. Берсе дә янымда юк...

– Синең туганнарың бик күп, Боссоойко, – диде Бараммат. – Сахаларның һәммәсе өчен дә син иң якын кардәш...

Берсе таш күтәрүдә, икенчесе көрәштә батыр калган ирләр атларына таба атлады. Әле дә көрәш, ярыш рухыннан котылырга теләмәгән халык аларны озата барды.

– Киләсе елда Бараммат таш күтәрүдә батыр калыр инде...

– Боссоойко – көрәштә...

– Алар беркайчан да бер-берсе белән көрәшмәскә ант итешкән икән...

– Минемчә, Байбал көчлерәк. Күр, ике тапкыр киңрәк күренә. Тирмә ишегенә яны белән керә, болай сыя алмый ди...

– Юк ла, син нәрсә? Боссоойко ике башка озын! Аннан ул тимер белән бер...

Ике дус моңсу гына елмаешты.

– Көзгә Чеханда[7] якларына җыенам. Сыерлар сатарга исәп, – диде Гыйззәтулла. – Бергә бармыйбызмы?

– Юк, алып барырлык малларым юк шул. Елларның да, юлларның да, тормышларның да иминлеге китте әле...

– Үзем дә шуңа көеп йөрим. Әллә ниткән башкисәрләр дилбегәне үз кулларына алып маташа. Нәрсә булып бетәр?

Ике җиңүче, ике батыр, моңсу гына хушлашты.

Көз җитте. Ак башлы, чуар күлмәкле таулар яшел итәкләрен кызгылт сарыга алмаштырды. Каракучкыл төскә кергән болытлар күлләр өстенә күләгә ягып, шомлы гына куера төште. Болытлар арасыннан качышлы уйнаган кояш нурлары күл өстендәге сары төнбоекларны иркәләп узганда, тирә-юнь алтынга мангандай балкый башлый. Ул балкыш күл-сазлыклар читендәге камышларга күчә, болай да яктылык сөйгән озын карагачларның саргайган ылысларында көлтә-көлтә нурлар пәйда була. Әмма җылы нурларны тундраның көчле җиле бик тиз алыштыра. Тау сөзәклекләрендәге карлардан, мәңгелек туңлык иленең төньягыннан ук хәрәкәт алган җил агай суык бабайның хәбәрен сала: әзерләнегез, мин киләм, янәсе...

Әнә шундый гаҗәеп бер көндә Гыйззәтулла, ике сыерын сату максаты белән, Чехандага таба юл тотты. Үзе белән күрше алаһа егете, әле егермесен яңа тутырган Лаабысканы да ияртте ул. Төгәлрәге, Лаабыска үзе аның ияртүен үтенде.

Яшьләр белән юлның озынлыгы сизелми дә. Картлар белән генә ул ипле, тыныч, йокыга тарта торган озын-озак әңгәмәләр сәфәрне тагын да суза сыман. Лаабыскадан исә үсмерлек галәмәтләре әле чыгып бетмәгән. Төп сораулары, әлбәттә инде, көрәш, таш күтәрү турында.

– Боссоойко, сине хапсагайга кем өйрәтте?

– Нәселдән килә, – дип көлемсерәде Гыйззәтулла. – Әти ягыннан бабайлар татар көрәшендә батыр булганнар.

– Татар көрәше хапсагайга охшаганмы?

– Бөтен көрәшнең дә нигезендә якты көч ята!

– Нинди була соң ул?

– Намус, гаделлек, зирәклек, көндәшеңне ихтирам итү...

[7] Алтын табылган урын, анда сәүдә гөрләгән.

– Боссоойко, синең саха батыры Күүстээх Уйбаанны җиңүең хакмы?

– Анысын инде халык сөйләсен...

– Ул да синең кебек тулы көчле, йөз потлы ташны күтәргән, диләр. Дөресме?

– Уйбаан – чын батыр ул! Андыйлар гасырга бер генә туа...

...Сатып алучы тиз табылды. Шөкер, Чехандада тормыш сүнмәгән әле. Юлдашы Лаабыска үгезләре дә бик тиз яңа ияле булды. Рәт араларын бер урап узгач, егет аны тизрәк юлга кузгалырга өндәде:

– Юл кешесенең юлда булуы хәерле, Боссоойко!

– Көне әйбәт, син кузгал инде булмаса. Мин берәр көнгә калып торыйм әле, – диде Гыйззәтулла.

Лаабыска аның ни өчен калырга теләвен бик яхшы белә. Боссоойконың бу фани дөньяда һич төзәлә алмаслык бер кимчелеге бар – кәрт уенына битараф түгел ул. Үзен-үзе никадәр генә битәрләсә дә, уенга керешеп китүдән һич кенә дә тыела алмый.

– Боссоойко, еллар үзгәрде,– дип олыларча үгетләп карады аны юлдашы. – Сине яңа хакимиятләр өнәмәвен барысы да белә.

– Шуннан?

– Чакмасыннар диюем!

– Мин бит отсам да, ахырдан барысын да кире өләшәм!

Лаабыска, Боссойконың фикерен үзгәртү мөмкин түгеллеген аңлап, үз алаһасына кайтып китте. Гыйззәтулла Чехандада калды.

И-и, шушында инде дөньяның аҗаган кайнаган урыны!

Тормышның сере, бозыклыкның башы кайда яшеренгән, көлкенең туган җире кайда дисәгез, белегез – Чехандада булыр ул!

Монда көнчыгыш олысның бөтен халкы җыелгандыр, мөгаен. Кемдер сата, кайсыдыр ала, алданучылар белән алдаучылар тауларны дер селкетеп бер әйткәләшеп ала, яшеренеп кәрт сугалар, көмешкә, спирт саталар...

Боссоойко ике көнгә тоткарланды. Өченче көнне, үзен кулга алып, кайтырга кузгалды. Гадәтенчә, бөтен отканын уендашларына кире таратты. Юлы Амма бистәсе аша уза иде аның. Кинәт мылтык тоткан ике солдат юлын бүлде. Шулчак, каяндыр алар алдында наганын уйнаткалап, өскә таба кәкрәйгән нечкә мыегын сикерткәләп, күптәнге танышы Корякин пәйда булды. Патша заманында төрмә кошына әйләнгән иде бу бәндә. Хәзер исә Амма олысында халык дошманнарына каршы көрәш алып баруын ишеткән иде Гыйззәтулла. Заманында кулы кәкре бу адәмне көрәштә бик яхшылап җиргә аударган иде әле...

– Рәхмәтуллин, синең өстән шикаять бар! Кулга алынасың! – диде сөмсез Корякин. Аның артында ышыкланыбрак торган солдатлар мылтыкларын корып куйды.

– Ычкын каршымнан, юлымны бүлмә, имгәк, – диде Гыйззәтулла. Бу кешенең хәллерәк сахаларның өйләренә бәреп кереп, алтын-көмешләрен талавы, хатын-кызларның бизәнү әйберләрен тартып алуы, ярлыларны соңгы боланнарыннан, атларыннан мәхрүм итүе турында ишеткән иде ул. Шуңа да үгезне мөгезеннән алып, сүзне кыска тотарга теләде. Бер күзе мәшрикъта, икенче күзе мәгърибтә булган кешеләрне сөйми Гыйззәтулла. Кара син аны, кичә генә әллә никадәр гаепләре өчен рәшәткә артында утырган адәм синең юлыңны бүлеп, нәрсә өчендер кулга алмакчы булып маташсын әле!

Корякин ачы елмайды. Битенә төкерсәң, яңгыр тама дип торган оятсыз, намуссыз адәмнәрнең сыңары иде шул ул.

– Ха! Кем белән сөйләшкәнеңне онытма! Кәрт уенында откан алтыннарыңны чыгарып сал иң әүвәл. Аннан уйларбыз.

– Син!..

Гыйззәтулла йодрыкларын төйнәп, Корякинга ташланган гына иде, кинәт «дыңк!» иткән тавыш ишетелде.

Күзен ачканда ул аяк-куллары бәйләнгән килеш караңгы бүлмә идәнендә ята иде. Корякин үчле адәм булып чыкты – язга кадәр Гыйззәтулланы төрмәдән чыгармады. Анысы бер хәл, көн дә аннан алтын таләп итте. Кирәкләрен ала алмагач, өчәүләшеп, дүртәүләшеп Гыйззәтулланы бозлы киез итек белән типкәләделәр.

Алтын табылмады.

Яз иде. Елгалардан соңгы бозлар киткән чак иде. Боссоойко җәяүләп үз алаһасына кайтырга чыкты. Салкын кышны исән-имин чыккан болан көтүе тундрага әйләнеп кайткан, җәйнең якынлашуын хәбәр иткән умырзаялар баш төрткән – табигать йокыдан уянып килә иде.

– Мине – гаепсез кешене – бер дә юкка газапладылар! Гомеремнең ахырынача бу кансыз явызларга каршы көрәшәчәкмен! – дип сүз бирде Гыйззәтулла үз-үзенә. Тирмәсенә кайтып җиткәндә дә ачуы басылмаган иде әле аның. Бары Матыйфа белән балалары – дәррәү кочагына килеп сыенгач кына, бераз тынычлана төште.

Әмма тормыш бер кителгәч, тиз генә урынына утыра алмый шул. Бөртеге тулган башак иелгәндәй, Саха илендә явыз яңа хакимнәргә каршы ризасызлык дулкыны көчәйде-көчәйде дә, талауга, кыерсытуга түзә алмаган халык бердәм булып күтәрелде. Бары өч шәһәрдә һәм берничә авылда гына совет хакимияте калды.

Гыйззәтулла корал күтәреп сугышуның ни икәнен бик яхшы белә, алманнар белән сугыштан кайтканнан бирле аны төннәрен куркыныч төшләр бимазалый. Һич кенә дә тәртипне сугыш ярдәмендә урнаштыру яклы түгел ул. Тик тормышның үз кануннары – җыелып килгән саха ирләренә ул каршы килә алмады, кырыклап кешелек отрядның командирына әверелде. Көчләр бөтенләй тигез түгел иде – яхшы коралланган кызыллар үз хокукларын даулап күтәрелгән сахаларны бөтен яклап кысрыклый башлады. Ахыры ни белән бетәр иде бу качышлы уйнауның – билгесез, егерме икенче елның язында сахаларга автономия бирелде, менә сиңа шатлык – баш күтәрүчеләр җәзадан азат ителде. Инде үз көнен хәләл көче белән күрә торган гади халык урамына да бәйрәм килде сыман, Гыйззәтулла да, тынычланып, үз алаһасына кайтып китте.

Дөнья якты булсын дисәң, үз тирмәңдә ут кабыз икән. Гыйззәтулла үзәктә барган хәлләрдән читтәрәк торып, үз алаһасында кайнашты. Шөкер, гаиләсендә иминлек. Менә олы кызы Хәдичәне Чурапчы олысы егете Хәйретдин кияүгә алды.

– Шушы Саха җирендә үзебезнең мөселман егете белән ярәшү зур бәхет инде ул, карчык!

– Әле тагын ике кызны урнаштырасы, ике малайны кеше итәсе бар, – дип җавап бирде Матыйфа.

– Булыр! – диде Гыйззәтулла, кистереп. – Дөньялар гына имин торсын! Инде менә егерме өченче ел да килеп җитте, сугышлар, фетнәләр, хакимият бүлешүләр артта калды сыман. Кырыкны тутырдым бит, карчык, кырыкны!

– Кырыктан соң шырыкка ди идеме әле әткәй?

– Өметләнмә! Әле Гыйззәтулла абзаңның исеме бик озак теллэрдән төшмәс.

Менә, Гарифулла данымны тартып алганчы, – ул биш яшьлек тупырдап торган улын яратып күкрәгенә кысты да чөеп уйнап алды.

Гыйззәтулла алдан белгән диярсең, автономия урнашуга бер ел тулу уңаеннан Ысыаһ оештырырга ниятләгәннәр дә аны шунда чакырдылар. Урыны да кайда диген – Гыйззәтулланың алаһасыннан ерак түгел, күлләр уратып алган атаклы Басыттаһта!

Аланга Саха иленең бөтен халкы җыелган диярсең. Бик азга гына кунакка килгән җәйне бергә каршыларга теләүләре куандыра.

Гыйззәтулла бүген бәйрәмнең күрке иде: ул сахаларның атаклы идарәчесе Тыгын Дархан булып киенеп, спектакльдә уйнады. Эре гәүдәле, чибәр кыяфәтле патшаның һәр гамәлен, һәр сүзен, аның урыс казаклары белән көрәшен мәйдан халкы дәррәү алкышлады.

Гыйззәтулла, бик күңеле булып, үз алаһасына кузгалырга җыенып йөри иде, янына хәрби киемле әфәнденең килеп басканын күрми дә калды. Гыйззәтулла, сискәнеп, дертләп куйды. Аны шундук таныды: баш күтәрүчеләргә каршы көрәшкән гаскәрне җитәкләгән Петров Николай иде ул. Хәтерли, бик яхшы хәтерли! Әле бер ел элек кенә бармак янашып хушлаштылар. «Тагын бер дөнья болгатып йөрсәң, кара аны!» – дигән иде Петров.

Гыйззәтулла мизгел эчендә уйларыннан айнып, бер читтәрәк атлы гаскәрнең таптануын күреп алды.

– Алай, – дип уйлап куйды эченнән генә. – Безнең бәйрәмгә сөенмәүчеләр һаман да бар икән дөньяда...

– Рәхмәтуллин! – Петров шундук боерулы тавыш белән җикеренергә тотынды. – Нишләп йөрисең син монда? Ник син өеңдә генә ятмыйсың? Ни пычагыма кирәк булды сиңа бу Тыгын Дархан? Син бит татар кешесе! Сахаларга ник катнашасың? Булды бит инде, автономия алдыгыз, тагын ни кирәк? Ят үз алаһаңда гына!..

Гыйззәтулла атына сикереп атланды да чаптырып китеп барды. Ачуыннан атын тоташ камчылады ул.

– Юк, болар һич кенә дә халыкка якты көн күрсәтергә җыенмый. Димәк, чигенүләре дә вакытлыча гына, – дип, үзалдына сөйләнде.

Гыйззәтулла хаклы булып чыкты. Бик тиздән Саха илендә кабаттан ризасызлык дулкыннары купты: якутлар белән тунгуслар бергәләшеп үз мөстәкыйльлекләре, ата-бабаларыннан калган изге җирләр өчен яңа хакимнәр белән орышка чыкты. Боланнарын тартып алудан, үз җирләреннән, диңгез-елгалар буеннан куылуга ни сабыр халыкның түзәр әмәле калмады. Корал, утын, эт, агач кайрысы, тагын әллә нәрсәләр өчен салымнар салу – бу инде иң соңгы дәрәҗәдәге мәсхәрә иде.

– Кеше өендә кеше көн итмәс, кеше учагы ныклап җылытмас!

– Безгә килмешәк хуҗалар кирәкми!

– Җил чыкмаса, агач чайкалмый!

– Безнең тормышыбызга кысылмасыннар!..

Тыныч кына балык тотып, ауга йөргән, болан асраган ирләр тәмам ярсыган иде.

Гыйззәтулла тагын кулына корал алырга мәҗбүр булды. Үз отряды белән берничә канлы орышта катнашып, төньякта берничә каланы яңа хакимнәрдән азат иткәч, мөстәкыйль дәүләт төзү уена килсәләр дә, биш йөздән артык ирнең батырларча көрәше озак бара алмаячагын Гыйззәтулла да, саха белән тунгус ирләре дә яхшы чамалый. Аларның бәхетенәме, егерме бишенче елның маенда

яңа хакимнәр солых тәкъдим итте. Ике якның да төп җитәкчеләре – биш кеше – тынычлык килешүенә җыелды. Аның берсе, әлбәттә, Гыйззәтулла иде. Хакимнәр аларның теләкләрен истә тотарга, каршылык күрсәткән өчен җәза бирмәскә вәгъдә итте. Шушы җирләрнең төп хуҗаларының тормышына хәзер аяк чалучы булмаска тиеш иде.

Гыйззәтулла, тәмам тынычланып, үз алаһасына кайтып китте һәм ике ел тыныч кына үз тормышын алып барды. Бигрәк тә улы Гарифулланың көннән-көн ныгуы, көрәш серләренә төшенүе куандырды аны.

– Гомерем синең өчен янып-көеп үтте. Әллә малай тыныч кына башкалар кебек яшәсенме соң? – Матыйфа ата белән улның әле таш күтәреп ярышуын, әле көрәшүен, йә булмаса таяк тартышуларын күргән саен, җайлап кына Гыйззәтулланы үз ягына аударып карый.

– Батыр туса – халыкка файда, карчык! Хакимнәрдән якты көн күрмәгән кешеләр кемгә таянсын соң? Мин картайгач, сахалар киңәш сорап, яклау өмет итеп Гарифуллага киләчәкләр. Ул алар өчен калкан булачак!

Тыныч тормыш озакка бармады, бик тиздән тагын болыт чәйнәп, боз бөркәнә торган кара көннәр килде. Баш күтәрүчеләрне яңадан эзәрлекләүләр, җирләреннән кабаттан кысрыклаулар башлангач, җирсез, терлексез калган саха ирләре кабат коралга ябышты. Гыйззәтулла бу юлы да алар белән бергә булды. Авыл-калаларда канлы бәрелешләр канат җәйгәч, хакимнәр бу юлы да хәйләкәр адымга барды: баш күтәрүчеләргә тынычлык килешүе төзергә тәкъдим итте. Аларның үтенечләренә колак салыначак, җәза бирелмәячәк, дип ышандырды алар.

Табигать кочагында яшәгән кеше самими була. Саха ирләре дә, Гыйззәтулла да аларның ихласлыгына ышанды. Дьокуускай каласына шуңа да рухланып юлга чыктылар. Гыйззәтулла гаиләсен сагынган иде, бер-ике көнгә юл уңаендагы алаһасына кайтып килергә булды.

Борчылудан җыерчыклары тирәнәя төшкән Матыйфа аны кочаклап бик озак елады.

– Зинһар, барма шәһәргә. Күңелемне нидер тырный, ышанмыйм мин аларга! – дип бик озак ирен юмалады ул.

– Мин дусларны ярты юлда ташлап калдыручылардан түгел, карчык. Борчылма, җиңү әләме белән бик тиз әйләнеп кайтырмын!

Калада шомлы хәбәрләрдән торган җилләр генә исә иде. Килешүгә чакырылганнарның барысы да кулга алынган, кайберләрен инде асканнар, кемнәрнедер атканнар. Исәннәре төрмәдә үлем көтеп ята. Гыйззәтулла имәнеп китте.

– Беркайчан да... Беркайчан да бирешмәячәкмен! – дип кабатлады ул.

Башка юл юк иде – яңадан алаһасына элдерде.

Ике ел – утызынчы елга кадәр ул өненә поскан аю кебек куе урман эчендә яшәде. Рәхмәт яусын дусларына – аның гаиләсенә булдыра алганча ярдәм итеп торды, аны сатмады. Әмма һәрнәрсәнең ахыры була...

... – У-лым! Га-ри-фул-ла!..

– Әткәй...

Кинәт землянка урыныннан күчте, Гыйззәтулла батыр атылып чыкты да канга баткан улын кочакларга, үбәргә кереште:

– Улым! Улым, улым... – дип сөйләнде батыр. Артыгын әйтә алмый иде, теле көрмәкләнде, тамагына төер утырды.

– Әти... бар да бетте... – диде авырлык белән улы. – Әнине... абыйны...

# АНА ТЕЛЕ САГЫНДА

**Галимнәр әйтүенчә, дөньяда 6800 чамасы тел исәпләнә (диалектлар һәм сөйләшләр белән), һәм шуларның алтысы гына халыкара рәсми телләр, ягъни Берләшкән милләтләр оешмасының эш телләре буларак билгеләнгән: инглиз, рус, кытай, гарәп, француз һәм испан телләре. Димәк, Җир шарындагы халыкларның күпчелеге шушы телләрдә сөйләшә. ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, 2000нән артык телгә бүгенге көндә юкка чыгу куркынычы яный. Бер Россиядә генә дә шундый телләрнең саны 100дән артып киткән инде. Иң авыр хәлдәге телләр арасында вод, кет, селькуп, алеут, вепс телләрен атыйлар. Аларда сөйләшүчеләрнең саны көннән-көн кими бара... Тел үзендә кешелек тарихын саклый. Шуңа күрә дә һәр халык туган телен саклап калу, үстерү, укыту, дөньяда таныту һәм тарату турында кайгырта. Иң мөһиме – туган телне буыннан-буынга тапшыру, яшь буынга ана телендә белем бирү. Татар телен белергә теләүчеләр өчен бүгенге көндә мөмкинлекләр шактый күп. Телисең икән – китаплардан, үзөйрәткечләрдән файдалан, йә булмаса – курсларга языл, ә инде өйдән дә чыкмыйча, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында компьютер аша телне үзләштерергә хыялланасың икән – «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбенә теркәл: *http://anatele.ef.com.* «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе 2013 елның 1 гыйнварыннан эшләп килә. Әлеге проект ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов кушуы буенча Мәгариф һәм фән министрлыгы белән EF (Education First) компаниясе тарафыннан гамәлгә куелды. Анда берьюлы 10 000 кеше теркәлеп, бер ел дәвамында татар телен түләүсез өйрәнә ала. Шушы вакыт эчендә башлангыч дәрәҗәдән югары дәрәҗәгә барып җитеп була. Онлайн-мәктәпнең төп максаты – татар телен шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак өйрәтү, тел өйрәнүчеләрнең сөйләм осталыгын үстерү. Мәктәпкә теркәлгән һәр кеше көндәлек тормышта аңлашу-аралашу күнекмәләренә ия була, шулай ук татар дөньясы турында кызыклы мәгълүмат та ала. Ә инде Татарстаннан ерак яшәп тә, татарча сөйләшеп карыйсың килсә, җанлы аралашу дәресләренә рәхим ит! КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе үзәге эшләп килә (электрон адресы: *anatele@bk.ru*). Югары квалификацияле татар теле белгечләре көн саен кичләрен онлайн-режимда компьютер аша җанлы аралашу дәресләре алып бара. Төркемдә аралашып, тел өйрәнүчеләр бер-берсе белән әңгәмә корырга, тормыш вакыйгалары турында фикер алышырга күнегә. Татарстан һәм Россиянең төрле төбәкләрендә, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче төрле милләт вәкилләре, үзара аралашып, татар телен гамәли үзләштерә. Татарча сөйләшә алабыз, китаплар укыйбыз дип рәхмәтләрен белдерә алар укытучыларыбызга. Димәк, теләк булса, өйрәнеп була икән. Кайберләре, «АНА ТЕЛЕ» аша Казанга гашыйк булып, башкалабызга сәяхәт тә кыла. Әлеге Интернет ресурс, ана телебезне танытуга, төрле милләт кешеләрен үзара якынайтуга хезмәт итә. «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбенә рәхим итегез!»**

**Кадрия ФӘТХУЛЛОВА**

апаларны... оныгыңны... – барысын да җәзалап үтерделәр. Картларны... көмәнле хатыннарны да... кылычтан уздырдылар. Беркем дә... беркем дә... сине сатмады, эти... Беркем дә...

Җир шары күчәреннән кубып, кире якка әйләнә башлады сыман. Гыйззәтулла акылы киткән кешедәй аягына басты да әйләнергә-тулганырга тотынды. Күкрәгендәге ярасын кысып торткан Гарифулланың тешен шыгырдатып ыңгырашуы гына аны чынбарлыкка кайтарды.

– А-а-а! – Мәңгелек туңлык өстеннән йөгереп узып, урмандагы агачлардан көчәеп тауларга килеп бәрелде дә, кайтаваз тагын да катырак яңгырады. – А-а-а!..

Гыйззәтулла дерелди, үзен кулга алалмый калтырана иде.

– Һөҗүмгә! – дип кычкырды шулчак кызыл командир.

Әлеге күренештән тетрәнеп басып торган солдатларга бу фәрманның тәэсире булмады.

– Һөҗүмгә! – дип ярсып кычкырды ул тагын.

Солдатлар, бер-берсенең каралыгына аптыраган каргалар шикелле, үзара караштылар. Әмма тораташтай каткан аякларын җирдән аера алмадылар.

Шулчак җир селкенде, шартлау авазы бар җиһанны яңгыратты. Бөтенесе дә җиргә егылды. Иңрәү авазларын урман бик озак кабатлады. Бераздан дары тузаны таралды, солдатлар берәм-берәм җирдән күтәрелде.

Теткәләнеп беткән ике җансыз гәүдә алан читендә ята, Гыйззәтулланың йозактай бикләнгән ике кулы Гарифулланы кысып тоткан иде...

***

...Саха илендәге бер атна узып та киткән. Шәһәр үзәгендәге «Тыгын Дархан» кунакханәсе аклык кочагында күмелеп калды, саха дуслар озатуында аэропортка килдек. Хабырыыска җылы тунын салып бирдем дә үземнең пәлтәмне кидем.

– Икенче килгәнгә кадәр сакла, – дигән булдым, үземчә шаяртып.

Менә сиңа мә! – самолётның кечерәген билгеләгәннәр дә, кырыклап кеше сыймый калган икән. Очкыч һавага күтәрелергә ике сәгатькә якын вакыт бар югыйсә, әмма соңга калганмын булып чыкты. Юлга дәртләнгән күңелнең сүрелүеннән дә яманрак нәрсә бар дөньяда? Озата килүчеләр тыз-быз йөгереште, мин инде вакытында кайтмауны хәбәр итәргә әзерләнгәндә, Мәскәү рейсының тоткарлануы турында җиткерделәр. Ул арада авызы колагына кадәр җәелгән Хабырыыс күренде.

– Синең аркада самолётны туктаттык...

– Бу кадәр үк миннән туйгансыңдыр дип уйламаган идем...

– Әллә каласың киләме?

– Юк, кайтам. Монда сезнең бер татарыгыз бар инде.

– Боссоойконы әйтәсеңме?

– Гыйззәтулланы...

Очкыч һавага җиңел күтәрелде. Артык шомланмыйча гына аклык дөньясын, тундраны, чал чәчле тауларны, аяз күк йөзе аша бик биектән анда-монда күренгән кечкенә авылларны күзәтергә мөмкин иде. Бераздан ул киңлекләр күздән югалды, очкыч биеклеген алып, ак дулкыннар кочагында акрын гына тибрәлергә кереште. Күземне йомдым – ап-ак кар өстеннән эре-эре адымнар белән канәгать елмайган Гыйззәтулла-Боссоойко якынлаша иде...



Дания
Нәгыймуллина

# ОФЫКЛАРДА АЛ ТАҢ АТА...

## Уйлар

Төннәр көнне күрми һәм күралмый,
Үрмәкүчтәй үрә ятьмәсен...
Мин төннәргә томырылып карыйм,
Алдан аңлап ниләр әйтәсен...

Тизлек белән тизлек бәрелешә –
Гафу сорап тору юк күптән!
Сулышыма капкан Җилне этәм...
Ни була соң тимичә үтсәң?!

Хәтер уза башын аска иеп –
Чыжлап тора заман кылычы.
Бер минутка, Вакыт, җибәр мине,
Тынычлыкта азга калдырчы!

Вакыт мине кулдан сөйри һаман,
Җырлатырга тели үз җырын...
Ә минем бит көем башка, димен,
Бәйләнгәндер көйгә күз нурым...

Минем көйне алып, карашымны
Көйдерергә ахры исәбе...
Мәкер тулы Вакыт уйны кисә,
Әллә җилләр шулай исәме?

Минем җырым башка! Җилләр белән
Бер уңайга бара алмабыз...
Мин уемны учка төйнәп куйдым,
Бирмим ятка – шуны аңлагыз.

---

Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА – *шагыйрә; «Галәм агачының яфрагы мин» исемле китап авторы. Казанда яши.*

## Кем икән?

Җавап бирмә, дәшмә, йәме?
Күзләремә бак кына.
Кем ул хыял илең буйлап
Атлап килә вак кына?

Кем ул йокыңны урлаган?
Кем яралган ак таңнан?
Кем ул тормышыңа кереп
Хисләреңне актарган?

Кем ул назлы җилләр кебек
Битләреңә кагылган?
Кем ул ташкын җырлар булып
Йөрәгеңнән агылган?

Кем соң яфрак саны кадәр
Өмет бүләк итүче?
Кем мәхәббәт күпереннән
Бәхетеңә илтүче?

Кем ул очрашуга килгән
Хәтта сихри төшеңдә?
Кемне бер көн күрми торсаң,
Салкын җилләр өшетә?

Күзләреңнән җавап итеп
Үземне эзләп таптым...

## Якын дустыма

Хәтерлимсең, дөнья яшел чирәм
Җәеп салган иде юлларга.
Хәзер безне тормыш гаме күмде...
Вакыт юкмы сәлам юлларга?

Кайчан гына хыял сыймый иде
Кушып куйган ике пар учка.
Хәзер безнең сукмак аерым-аерым,
«Якын дустым» сүзе – йомычка...

Син торасың ярның бер ягында,
Мин кул изим сиңа каршыдан.
Ике якка таба йөгердек без,
Сулар күтәрелеп ташудан.

Серем, көзге пыяласын үбеп,
Кире кайта елап үземә.
Дуслык йомгаклары сүтелеп бетте,
Шуңа ахры үзәк өзелә.

Еллар белән без дә үзгәрәбез,
Уңа икән хыял төсләре.
Сиңа телим: чынга ашсын җете,
Якты, матур өмет төшләрең!

## Авыл кочагында

Бакчаларда гына түгел,
Җанда оча күбәләкләр...
Авыл мине кочып ала,
Серен сөйли каз-үрдәкләр.

Күңелдәге авыр ташны
Юып ала җылы яңгыр.
Юл газабы рәхәт кенә,
Булса булсын юллар такыр.

Ишетелә якты тавыш
Манарадан сихәт булып.
Чәчәк кумә күңел кырын...
Яшь тәгәри күңел тулып...

Капка төбе тулы чирәм
Келәм булып җәйрәп ята.
Шифа тулы нурлар сибеп,
Офыкларда ал таң ата...

Кайткан саен гашыйк булам
Өр-яңадан, Авыл, сиңа!
Озак кайтмый торсам әгәр,
Күңел әрни, күңел сына.

Бал кортлары безелдәве
Татлы балдай сихәт бирә...
Игенченең тырышлыгы
Җиргә тама кучеп тиргә.

Авыл! Авыл! Кире какма
Сине сагынып кайткан җанны!..
Сиңа кайткач аткан кебек
Гомеремнең тәүге таңы...

## Синле көннәр

Безнең алда җәйрәп ята юллар...
Булсын алар тигез һәм якты!
Карлар яуган урыннарын күрәм,
Анысына әнкәй шәл япты.

Безнең юллар озын булса иде!
Шатлык тулы җырлы булсачы!
Синле көннәр шикәр кебек татлы...
Сагыш безне урап узсачы.

Җылы карашларны саклый белик,
Язмыш безгә булсын шәфкатьле.
Кошлар сайраганын тыңлый-тыңлый,
Сәламлик без гүзәл шәфәкъне...

Йөрәк тибешләрен аңлый белик.
Йөрәкләргә тузан кунмасын...
Онытмачы: синең җаның туңса,
Минеке дә боегып туңасын.

Синең җырга минем җырым бәйле,
Минем күзләр – синең көзге ул.
Безнең яшьлек учагыбыз дөрли –
Әти-әни көткән көздер ул.

Һәр керфектә синең сөю нурың,
Алар миңа шундый кадерле!
Сиңа атап һәркөн җырлар язам,
Булсын җырлар гомер кадәрле!



Кадрия
Хәсәнова

# САНДЫК БИГЕ

ХИКӘЯ

Кәшифә карчык җайлап кына утырды да сандыгын актарырга тотынды. Шул сандык малын барлап алырга ярата ул. Эче пошса да, күңеле тулса да, бераз хәлсезләнеп торса да, шуңа барып ябыша. Бер сандык хатирә бит анда! Кулга тоткан һәр нәрсә белән бәйле вакыйгалар күз алдыннан йөгереп уза... Гамьсез балачак чыркылдап көлеп җибәрә, дәртле яшьлек еллары искә төшә, шул чактагы мәхәббәт ялкыннары йөрәкне телеп ала, ниндидер югалту ачылары җанны тырнап куя...

Әй, сандык, сандык! Сине йозак белән бикләп куйган кебек, йөрәктәге хисләрне дә башка чыкмаслык итеп, күңелгә, тирәнгә беркетеп бикләп куясы иде дә... Юк шул...

Кәшифәнең әтисе сугышта үлеп калган. Ул көрәш кырына китеп барганда, кызчыкка нибары ике ай гына була. «Әти» дип өздереп әйтүнең рәхәтлеген дә, андый кадерле кешенең никадәр якын булуын да тоеп калмады Кәшифә.

Тол калган әниләре бишкә ярылды – өч бөртек баласын үстерү, ач итмәү өчен тырышты. Балакайларына үзенең иске киемнәрен кисеп күлмәк-ыштаннар текте. Кай арада вакыт тапкан икән?! Төн йокыларын калдыргандыр инде.

***

Әнә, Кәшифәнең кулында сандыкның кадерле ядкяре – әнисе теккән кечкенә генә күлмәк! Бер уч кадәр генә! Аны бер яшендә кигән Кәшифә. Тузган инде – тукымасы шактый тузган. Катырак тотсаң, ертылып китәр сыман. Әнисе оста булган шул: кул белән нинди матур якалар уйган, бала итәкләргә кадәр тегеп куйган! Кәшифә гомере буе бик кадерләп саклады бу күлмәкне. Әнә шушы сандыкка рәхмәт инде, бүгенге көнгә кадәр, бәбкәләрен саклаган каз кебек, нәни күлмәкне үзенә «сыендырып» торды...

Кәшифәнең абыйсы белән апасы кул арасына керә башлау белән, әниләренең зур ярдәмчеләренә әйләнделәр. Кечкенә сеңелләренә әниләрен алыштырып, Кәшифәне карап-тәрбияләп үстерүчеләр дә алар иде. Әниләре кырдан кайтып кермәде, колхоз эшеннән бушамады шул.

***

Ә менә монысы – Кәшифәнең үзе тегеп кигән күлмәге. Кәҗәләрен сатканнан соң, әнисе аңа бик матур – акка зәңгәр һәм сары чәчәкләр төшерелгән тукыма алып бирде. Кәшифә ике атна йокламаса йокламады, тик шуннан үзенә бик матур күлмәк текте. Әнисеннән кызга да кул эшләренә осталык сәләте күчкән иде шул. Ул вакытта алмаш-тилмәш киеп йөрерлек кием бар димени?! Шушы яңа күлмәген сөйгән егете Рафил белән очрашканда гына киярмен дип хыялланган иде Кәшифә. Кая инде, башка күлмәге булмагач, эшкә дә шуны кими чарасы калмады. Тишкәләнеп, тузып беткән күлмәк. Итәгенең бер ягы

Кадрия ХӘСӘНОВА – *яшь язучы, журналист, Казан (Идел буе) федераль университеты аспиранты; «Иделем акчарлагы» яшь язучылар конкурсы лауреаты. Казанда яши.*

умырылган да. Хәер, аның умырылу тарихы бар бит. Шуларны уйлады да үзалдына көлеп куйды карчык.

Их, тиле яшьлек диген син. Шушы матур күлмәген киеп, кичен Рафил янына йөгереп чыкты. Җитәкләшеп кенә урам әйләнделәр. Гармунчы Гаптери агайлар турыннан узганда, кызның борынын баллы алма исе кытыклады. Мондый алма аларның бакчасында гына бар бит! Рафилгә шул җитә калды, бер генә селтәнеп алды да бакчага сикереп тә төште. Гаптери агайның бакчасын басарга керергә куркалар, тотса – эш харап, бик усал иде мәрхүм. Тик егет Кәшифәнең күңелен күрәсе итте. Кәшифәсе дә аптырап калмады, егет артыннан рәшәткәгә үрмәләде. Тик итәге эләгеп, эленеп калды. Хуҗаларның этләре өрә башлагач, Рафил Кәшифәне сөйрәп кенә алды да теге якка очыртты. Итәгенең ертылган кисәге бакчада калгач, кыз бүтән бу матур күлмәкне кимәде инде. Чәчәгеннән танып алырлар да, егерме яшенә җиткәндә бакча басып йөри, дип, кеше көлкесенә калдырырлар дип курыкты. Өстенә кабат ямаулы, иске күлмәге «кунаклады». Шуннан сандык төбенә «шуган» күлмәк инде бу – баллы алма истәлеге.

Рафил дигәннән, бик яратты Кәшифә Рафилне. Егет армиядән кайткан язда очрашып йөри башлаганнар иде. Хәер, кыз аңа кечкенәдән күз атты. Егет кенә, бер чәчәктән икенчесенә кунган күбәләк шикелле, әле бер кыз белән сөйләшә, әле икенчесе белән көлешә, әле чишмәдән кайтып килүчесе янына йөгереп барып, аның чиләкләрен күтәрешеп кайта. Ачуы килә иде лә соң Кәшифәнең. Ә Рафил ул шаянлык, шуклык белән генә шулай йөргән. Үзе дә Кәшифәне ошаткан булган. Күп егетләр кызыгып йөргәч, янына килеп сүз катарга кыймаган. Бары армиядән кайткач кына Кәшифәне озатырга тәвәккәлләгән. Шуннан соң бер-берсен яратып, кадерләп кенә йөрделәр алар.

Әле Рафилнең кызы булгач та, берничә егет Кәшифәгә кызыгып йөрүен яшермәде. Рафилгә читен булгандыр, билгеле. Күбесе белән каршылыкларга да кергән. Болар турында Кәшифә соңлап кына белде.

***

Вакыйгаларны бер-берсенә бәйләргә тырышкан күк, сандыкка куелган әйберләр дә тәртип белән тезелгән диярсең. Менә сәер соры таплы, үзе ак булса да, саргая башлаган шакмаклы сөлге... Анысын Кәшифә яшеребрәк куйган. Юка гына пакетка да салган үзен. Аерылып торган бу ядкярне кадерле дип әйтеп булмый шул... Кәшифәнең иң ачы, иң хәсрәтле хатирәсе белән бәйле сөлге бу. Пакетка салып куюы да аны кулына алмас өчен эшләнгән. Сөлгегә бер күз карашын төшереп кенә алса да, читен булып китә Кәшифәгә, йөрәге кыса башлый...

Авылның абруйлы егетләренең берсе Сәлим Кәшифәне бик яратып йөргән икән. Рафил белән берничә тапкыр тәпәләшкәннәр дә. Кеше белән сугышып йөргәне булмаса да, сөйгән кызын яклыйсы килеп, тыныч холыклы Рафил Сәлим белән бәйләнешмичә кала алмаган. Ә берсендә...

Сәлим ничектер Кәшифәнең яулыгын кулына төшергән. Шул яулык белән егетләр арасында мактанып йөргән. Менә, янәсе, кызның яулыгы кем кулында, кыз шуның кулыннан узган дигән сүз. Ә беркатлы Рафил сөйгәненең кем кочагында «булуын» белми дә калган.

Бу сүзләр җил тизлеге белән икенче көнне үк Рафилгә килеп ирешкән. Кичен Кәшифә янына килгәч тә, Рафил үзен сәер тотты, әллә нигә пошынды. Кыз бу сәерлекне сизми кала алмады. Берзаман, атка атланган Сәлим узып китте. Аның авылны чыгу ягына баруын күргәч, Рафил Кәшифә белән тиз генә саубуллашты да, тегенең артыннан китте.

Кереп урынына ятса да, йоклап китә алмады кыз. Рафилнең ни өчен үзен шулай тотуын аңламады, курыкты, шомланды. Эч пошуына түзә алмыйча, акрын гына урыныннан торды да урамга чыкты. Салкынча җил исә башлаган иде. Кыр ягына таба атлыйсы була дип, ишегалдында бауга элеп куйган керләр арасыннан шакмаклы сөлге алып иңнәренә япты, күз ачкысыз караңгы булса да, Рафиле киткән якка таба кузгалды.

Юкка гына пошынмаган икән, озакламый ниндидер ят тавышлар ишетте кыз. Адымнарын тизләтте, күзгә төртсәң дә берни күренмәс караңгыда йөгерә үк башлады. Рафил белән Сәлим сугыша! Янәшәләрендә, болай да куркыныч төнгә шом өстәп, Сәлимнең аты пошкырып куя... Икесе дә таза, нык егетләрнең берсе дә җиңелергә уйламый. Кәшифә аерырга маташып карады, әмма кая ул ажгырып торган егетләр арасына керү! Кайсыдыр төртеп кенә җибәрде үзен. Сәлимдер, мөгаен, ул бит: «Йөрмә монда, сөйрәлчек», – дип әйтте. Рафил бу сүздән тагын да ярсыды. Кай арада Кәшифәнең иңнәреннән сөлгесен тартып алды да Сәлимнең муенына салды соң?!.

Кыз боларны томан эчендәге кебек кенә хәтерләп калды. Кара төн уртасында ачы җилле ялан кырда Рафил Сәлимне әнә шул шакмаклы сөлге белән буды. Җан өзгеч куркыныч авазлар чыгарды Сәлим. Кәшифә берничек тә ярдәм итә алмады – биредә ул иң көчсез кеше иде. Елый да алмады, катты да калды...

Аннан соң булган хәлләр төштәге сыман гына исендә калган. Үз хәле хәл булса да, күзләре акаеп, ай яктысына караган Сәлимнең муеныннан сөлгене тартып алырга җөрьәт итте кыз. Аны, алып кайтып, үзе генә белгән урынга яшереп куйды.

Икенче көнне дә, аннан соң да тикшерүчеләр авыл буенча бик озак сорау алып йөрделәр. Фаҗигане күргән, ишеткән кешеләр табылмады. Авыл читендә булган хәлләрнең тавышын җил әллә кайларга алып китте шул... Хакыйкатьне Рафил белән Кәшифә генә белделәр. Һәм телсез ат... Хуҗасын ничек буып үтерүләрен күрсә дә, әйтеп бирә алмады шул хайван...

Рафилне кулга алдылар үзе. Яшьләр барысы да беравыздан, Рафил Сәлимгә ачулы иде, дип сөйләгәннәр. Турыдан-туры гаебен танымаса да, Рафил Сәлимгә үпкәсе булуын үзе дә әйткән. Тик җинаять коралын – буып үтергән җепне таба алмагач, Рафилнең гаебен тулысынча дәлилли алмадылар. Егетне эшләтү җәзасы белән Себергә озаттылар.

Бу вакытлар Кәшифәнең йөрәгенә бик авыр, кайгылы булып уелып калган. Кеше үтерүне үз күзләре белән күреп, җинаятьчене яшереп калды бит. Инде Рафилгә булган яратуының әсәре дә калмыйча, аны күралмас хәлгә җитсә дә, «сата» алмады шул аны. Яшьлек мәхәббәтен, тәүге хисләрен сата алмады! Сәлимнең дә гаебе юк түгел. Тик ялган гайбәт тараткан өчен генә кешенең гомерен өзү бернинди канунга да сыймый бит...

Сандык төбендә саргаеп яткан сөлгенең таплары – сугышкан егетләрнең берсенең каны инде менә...

Сөлгене башкача күрмәс өчен, Кәшифә аның өстенә кат-кат әйберләр тезде. Их, ул сөлгене каплап куеп кына үткәннәрне хәтердән җуеп булса икән! Сәлимнең ачыргаланып, газапланып кычкырган тавышы хәзер дә төшләренә керә бит, аның өметсезлек белән тулы, чиксезлеккә төбәлгән карашы һаман күз алдына килеп җәфалый...

***

Рафил Себердән Кәшифәгә хатлар язды. Бик авырлык белән генә җавап бирә иде кыз. Кыен иде аңа. Йөрәге, акылы бәргәләнде. Акылдан шашам бугай инде дип курка иде хәтта. Барысын да сөйләп күңелен бушатыр кешесе дә булмады. Мондый серне кемгә чишәсең ди?! Рафилнең язмышы Кәшифә кулында иде. Ә кеше язмышы белән уйнарга кем соң әле ул?! Кызганды егетне. Аны гомерлеккә төрмәгә утыртып куярлар дип курыкты. Ә болай, эшләү вакыты бетү белән, ирекле булачак бит. Вакытлыча тоткынлыктан тәне азат ителсә дә, гомеренең азагына кадәр күңелендәге хисләр тоткынлыгында яшисе була бит Рафилгә. Көнләшүдән, бәлки бик нык яратудан шушындый хәл китереп чыгарды – хисләрен йөгәнләп кала алмады...

Берсендә, Рафил: «Көтәсеңме?» – дип язган иде. Ни дип җавап бирергә дә белмичә, бер атна уйланып йөрде кыз. Юк, кеше җанын кыйган адәм белән гомер юлыннан бергә атлыйсы килмәде Кәшифәнең. Бер-берсенә караган саен, шул төнне искә алачаклар,

барысы да баштан кичәчәк, кабат шул ук курку йөрәкне меңгә теләчәк. Шул да булырмы тормыш?! Өздереп: «Көтмим», – дип язарга курыкты кыз. Уйлана торгач, җавап хатын язмады гына. Шуның белән шул, Рафил белән аралары бөтенләйгә – гомерлеккә өзелде. Яшьлекнең иң матур, иң ихлас, иң рәхәт вакытларына шуның белән калын итеп нокта куелды.

***

Кәшифә кулына чираттагы ядкяр – ап-ак мамык шәлне алды. Кәҗә мамыгыннан, бераз күпертеп җибәрсәң, әле хәзер дә ярарлык. Тик анысын да кулланмый карчык. Кәшифәнең кулын сорап килгәндә, Гомәр алып килгән шәл бу. Яратмыйм дип тормады кыз, кияүгә чыкты. Бер-бер артлы алты балалары туды. Гомәр әйбәт ир булып, Кәшифәне хөрмәтләп, балаларны яратып яшәде. Тормышлары барлы булды, ач тормадылар, кияргә кием юк дип тилмермәделәр. Дөрес, тормышта барысы да ал да гөл генә бармый. Олыгайгач кына Гомәр салгалый башлады. Хуҗалыктагы бөтен эш Кәшифә кулына калды. Ирен аракы коллыгыннан йолып ала алмады шул. Гомер буе рәхәт кенә күрсәтеп яшәгән иреннән олыгайган көнендә ишетмәгәнен ишетте, күрмәгәнен күрде хатын. Күп тапкырлар тотып кыйнаганы да булды Гомәрнең. Шәһәрдән ялга кайткан балаларына, егылдым, дип алдый иде хатын. Сизделәр инде алар да бичаракайлар, тик әтиләренә сүз әйтергә базмадылар.

***

Әнә шулай гомер узып киткән.

Сандык төбендә мәрхүм иренең куян бүреге дә саклана. Кибеткә бүрек кайткач, Гомәренә шунда ук сатып алды Кәшифә. Тик икенче көнне үк ире вафат булды. Эчә-эчә бавыры таралган, диде табиблар. Шул көнгәчә болай да чыдады әле ул бавыр...

Кәшифә бүрекне кире кибеткә илтмәде. Андый олылар бүреген уллары да кими инде. Үзенә атап алган идем, дип сандыкка салып куйган иде, тора әнә, көя дә тимәгән үзенә...

***

Шушы урында сандык актаруын туктатты карчык. Кара ничек кызык ә, берничә әйберне кулга алу белән, бөтен тормыш юлын урап узып була икән бит! Яшәлгән сигез дистәгә якын гомернең тоткасы булып берничә әйбер генә калган лабаса. Барысы да шуларга бәйле, барысы да шуларга барып тоташа... Әле бу сандыкта алардан башка да әйбер күп, билгеле. Барыннан да элек үлемтекләре шушында Кәшифәнең. Сандыкның кадерле ядкярләрен теге дөньяга үзе белән алып китә алмаячак ул, әнә шушы ап-ак бүзләре озатып барыр аны. Күптән дөнья куйган Рафилен дә, ире Гомәрне дә, хәтта Сәлимне дә күрәсе килә Кәшифәнең. Ходай очраштырсын гына үзләрен...

Бу дөньяда яшәвенең төп мәгънәсе алты баласы булды. Ә тегендә әле җавап тотасылары күп шул. Курка да карчык. Юк-юк, үлемнән түгел. Гомер буена йөрәгенә яшереп йөрткән дөреслек өчен җавап тотасы бар бит... Шушы ак бүзләре генә тәмуг утына пәрдә булып торсын иде лә...

Уйларына бирелеп, урамга ашыкты Кәшифә. Түбән очта үзләренә өй салып башка чыккан төпчек улларының хәлен белеп менәсе итте. Оныкларын да сагынды – бер генә көн күрмәсә дә, шул ташбашларны юксына башлый. Баланың баласы балдан гына да татлы түгел, бигрәкләр дә якын була икән.

Таягына таянып, акрынлап кына түбән очка төшеп җитте карчык. Үзләренең урамыннан кара төтен күтәрелүен дә сизмәде. Ә шул вакытта аның кечкенә генә агач өе дөрләп яна иде... Плитәгә чәен куюын бөтенләй оныткан Кәшифә... Сандыгын актарып алганнан соң, чәй эчәрмен дип уйлаган иде бит.

Йортының янып бетүен генә әйттеләр аңа. Торыр урынсыз калмады анысы, уллары болай да гел үзләренә чакырдылар. Тик менә сандыгы... Ут телләре йозакка бикләп куйган сандыкка да кергән... Хәтта шул бикле сандыкны да тар-мар иткән бит, әй! Кәшифә гомере буе шул сандыкның бигенә кызыгып, йөрәкне дә сандык кебек бикләп куясы иде, дип яшәде. Менә хәзер инде аңлады: җир йөзендә бикләп тотар, качырыр бер генә нәрсә дә юк икән. Кайчан да булса һәрнәрсәнең азагы килеп җитә. Гомернең дә...

# ГАЛИМ, ОСТАЗ, ШӘХЕС

## НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 80 ЯШЬ



Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамовның юбилей көннәрендә аның күпьеллык һәм бәрәкәтле гыйльми эшчәнлеге хакында җылы сүзләр, мөгаен, күп булыр. Чыннан да, аның хакында озак сөйләргә мөмкин, чөнки галим татар инсани фәне өчен гаять күп эшләде һәм актив фәнни эшчәнлеген әле дә дәвам итә.

Мин, Н.Ш.Хисамовның элекке аспиранты буларак, фәнни җитәкчем турында аның остазлык һәм кешелек сыйфатларына бәйле сүз алып барырмын.

Нурмөхәммәт абый белән (галим татарча шулай гади эндәшкәнне ярата) танышуым 1990 еллар башында булды. Ул чакта мин КДУның татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында студент идем. Без гарәп теле өйрәнә идек һәм, әлбәттә, тел өлкәсендәге белемнәребезне камилләштерү өчен, Шәрекъ илләренә бару турында хыялланып яшәдек. Нәкъ шул вакытта Нурмөхәммәт абый безнең, гарәп илләренә барып, белем күтәрүебез мәсьәләсе белән шөгыльләнеп йөрде. Юкса, бүтән фәнни оешмада эшләп, татфак студентларын укыту процессы белән бәйләнмәгән кешегә үз җилкәсенә шундый йөк алу нигә кирәк булыр иде икән! Моның мәгънәсенә мин соңрак төшендем. Галим фәннең киләчәге турында, әдәбиятчы, текстолог, археограф татар галимнәренең өлкән буынына алмашка кемнәр үсәчәк, дип борчылган икән. Ул елларда гуманитар фән көнчыгыш телләрен, барыннан да элек гарәп, фарсы, төрек телләрен үзләштергән белгечләргә кытлык кичерә иде. Революциягә кадәрге мәдрәсәләрдә белем алган өлкән буын инде дөньядан киткән, ә совет шартларында тәрбия алган урта буын шәрекъ телләрен белүдән мәхрүм заман.

Соңрак, Казан университетын тәмамлап, Ливанда тел стажировкасы узгач, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына аспирантурага керергә булдым. Нурмөхәммәт Шаһвәли улы фәнни җитәкчем итеп билгеләнде. Ул миңа гадәттән тыш кызыклы, ләкин бер үк вакытта шактый катлаулы тема бирде: урта гасыр татар әдәбиятының гарәп һәм фарсы телендәге борынгы чыганакларын өйрәнү бурычы куелды. Аерым алганда, сүз күренекле фарсы илаһиятчесе һәм тарихчысы Әбү Җәгъфәр ибне Җәрир (X йөз) хакында барды. Аның Коръән Тәфсире болгар-татар шагыйре Кол Гали өчен дә илһам чыганагы булганлыгына дәлилләр бар. Һәрхәлдә, Фирдәүси аңа таянган. Минем фәнни җитәкчемнең дә бу юнәлештә күзәтүләре бар иде. Әмма тулы мәгълүмат алу өчен, бар нәрсәне ташлап, бары шул тема белән генә шөгыльләнергә кирәк булды. Шулай итеп, тема мирас буенча миңа күчте. Чыганаклар белән дүрт ел эшләү Нурмөхәммәт Шаһвәли улының гөманнарын тулысынча раслады. Әмма хәзер сүз бу хакта түгел, ә Нурмөхәммәт абыйның үзе хакында һәм аның фәнни җитәкчелек ысулы турында бара.

Шуны күрсәтеп үтәргә кирәк ки: аның җитәкчелегендә фәнни тикшеренүләр башкарган барлык аспирантлар диярлек диссертация яклады һәм хәзер төрле академик институтларда, вузларда һәм мәктәпләрдә, һәртөрле бүтән оешмаларда актив фәнни һәм иҗтимагый эш белән шөгыльләнә, ә кайберләре фән докторлары булды һәм үзләре аспирантлар тәрбияли. Мондый уңышлы остазлыкның сере нәрсәдә соң? Сере гади. Нурмөхәммәт абый беркайчан да аспирантлары өстеннән вак күзәтчелек итми, ә аларга фәнни иҗат иреге бирә. Әмма шуның белән бергә ул эшнең нәтиҗәле булуын катгый таләп итә белә. Чөнки ул һәвәскәрлекне, компетенциягә сыймаган сүз боткасын һәм өйрәнә торган предметны өстән-өстән яктыртуны яратмый. Чын галим, аныңча, тикшеренү темасын җентекле белеп кенә калмыйча, фәлсәфәдән, әдәбияттан, сәнгатьтән яхшы хәбәрдар, ягъни һәрьяклап үскән шәхес булырга тиеш.

Нурмөхәммәт абый – бик илтифатлы һәм зыялы кеше. Мондый зыялылык һәм хәтта күпмедер дәрәҗәдә аристократлыкның тамырлары бик тирәндә – галимнең әти-әнисе һәм әби-бабалары үтә дә укымышлы кешеләр, заманының интеллектуаллары булган. Боларның һәммәсе әдәбият галименең холкында чагылыш тапкан. Әгәр Нурмөхәммәт абый фәнни нәтиҗәләрдән канәгать булмаса, беркайчан да вәгазь укымый һәм тавышын күтәрми, ә тыныч һәм дәлилле итеп үзенең дәгъваларын бәян итә. Аның ышанычын казану җиңел түгел, ә фәнни нәтиҗәләрдә уңай бәясенә ирешү тагын да читенрәк. Чөнки алар, Нурмөхәммәт Хисамов фикеренчә, иң югары таләпләргә җавап бирергә тиеш. Аның үзе өчен Россиянең һәм чит илләрнең иң яхшы тюркологлары өлге булып тора. Шунлыктан ул шәкертләренә таләп планкасын бик югары куя.

Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов дөреслекне бар нәрсәдән өстен күрүче галимнәр төркеменә керә. Галим гыйльми продукцияне тау-тау өеп бирүгә беркайчан да омтылмады, хәтта нык алга киткән социализм чорында да үз темасына тугры калды. Ул заманда партиянең генераль линиясе таләп иткәнчә, 1917 елга кадәр иҗат ителгән әсәрләр күбесе артта калган һәм яңа заманга яраксыз санала иде. Сер түгел, бик күп галимнәр шушы таләпләргә яраклашып яшәде яки фикерләрен туры ярып һәм ачык әйтергә курыкты. Курку өчен, чыннан да, сәбәпләр җитәрлек иде.

Н.Ш.Хисамов гомер буе «кайнар» темалар белән шөгыльләнде. Әле студент елларында ук ул советлар өнәмәгән шагыйрь Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүгә алынды. Соңрак исә XIII йөз татар әдәбияты ядкяре – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын тикшерүгә кереште. Болар «модадан» тыш эшләр генә түгел, бәлки, хәтәр темалар иде. Моның өчен җитди гражданлык батырлыгы кирәк булды.

Хисамовның фәнни эшчәнлеге белән яхшы танышмын. Шуңа күрә төгәл әйтә алам: ул үзенең бер генә мәкаләсендә дә, китапларының бер генә абзацында да тикшерә торган чыганакларны идеологик императивларга яки сугышчан атеизм таләпләренә туры китерергә тырышмады. Бу «Аллаһ» һәм «Коръән» сүзләренең юл хәрефтән языла торган заманы иде. Аның барлык хезмәтләре дә фәнни гаделлеккә тугры калып эшләнгән һәм идеологик тенденциозлыктан азат булулары белән аерылып тора. Мөгаен, шуңа күрәдер, галимнең китаплары зур популярлык казана һәм чыгуга ук сатылып бетә бара.

Тумыштан килгән зыялылыкка һәм барлык проблемаларны тыныч хәл итү тарафдары булуына карамастан, Нурмөхәммәт абый кайбер мәсьәләләрдә үтә принципиаль була ала. Ул буш гәп сатучыларны, тәкәббер, икейөзле кешеләрне, галимлек битлеге киеп, үзләренең ахмаклыгын һәм наданлыгын ялган исем, регалийлар астына яшергән затларны гафу итми. Андый кешеләргә мөнәсәбәтен Нурмөхәммәт абый яшермичә белдерә, күренешләрне үз исеме белән атый.

Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчесе булып киткәч, Нурмөхәммәт Шаһвәли улы бу фәнни оешманың продуктив эшен бик тиз җайга салды. ТӘһСИне «интектергән» күпсанлы ызгышлар һәм интригалар аның идарәсе чорында юкка

чыкты. Әдәбият белеме, текстология һәм тел гыйлеме өлкәсендә бик күп эшләр эшләнде. Ул елларда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты чыгарган дистәләрчә фәнни хезмәт Россия һәм чит ил галимнәренең китап киштәләрен бизәде. Институт аспирантлары монографияләрен, диссертация яклап, бер ел үткәнче үк диярлек бастыра алдылар. Болар аның эшчәнлегенең уңай нәтиҗәләре түгелмени?!

Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов актив фәнни һәм педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Галимнең потенциалы бик зур, ул әле үзенең интеллектуаль архивындагы барлык хәзинәләрен ачып бетермәгән. Без, аның шәкертләре, остазыбыздан яңа фәнни казанышлар һәм ачышлар көтәбез, ул әле күп еллар безне үзенең игелекле киңәшләре белән шатландырып торыр дип ышанабыз.

**Азат АХУНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты*

## Нурмөхәммәт Хисамовның төп басмалары


1. Хисамов Н. Яз миңа чәчәкләр китерә. Шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1967. – 24 б.

2. Хисамов Н.Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али (Анализ источников сюжета и авторского творчества): Автореф. дис. ... канд. филол. наук; ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова КФ АН СССР. – М., 1979. – 18 с.

3. Хисамов Н. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества. – М.: Наука, 1979. – 254 с.

4. Хисамов Н. Бөек язмышлы әсәр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1984. – 336 б.

5. Хисамов Н. Бәрәкәтле чишмәләр: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 150 б.

6. Хисамов Н.Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в средневековой тюрко-татарской поэзии XIII-XV вв. (Проблема версий): Дис. ... д-ра филол. наук в форме науч. докл. / Н.Ш.Хисамов; ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ. – М., 1996. – 96 с.

7. Хисамов Н.Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII-XV вв. (Проблемы версий). – Казань: ГУП ПИК «Идел-Пресс», 2001. – 216 с.

8. Хисамов Н.Ш. Тукайны төшенү юлында («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә материаллар) / Җаваплы мөхәррир – филология фәннәре докторы З.З.Рәмиев; Н.Ш.Хисамов. – Казан: ТаРИХ, 2003. – 80 б.

9. Хисамов Н.Ш. Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – 641 б.

10. Хисамов Н.Ш. Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 208 б.

11. Хисамов Н. Татар шагыйрьләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 287 б.

12. Хисамов Н. Язгы шәфәкъ (шигырьләр һәм драма). – Казан: «Дом печати» нәшр., 2007. – 283 б.


13. Хисамов Н. Остазлар. – Казан, 2012. – 102 б.

14. Hisamov N. Kul Alirec türkçe Yusufnâme. – Ankara, 2014. – 179 s.


15. Хисамов Н. Тукай: бөеклеге һәм фаҗигасе. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2017. – 125 б.



*Гомәр Гали (1900-1954) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы-прозаик. 1925-1927 елларда «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш мөхәррире. Шәхес культы корбаны. Рәсемдә сөргендә чакта үзе салып кергән йорты янында. Красноярск крае Подпорожье авылы. 1952 ел.*



*Әнәс Камал (1908-1978) – драматург һәм театр эшлеклесе. Классик драматург Галиәсгар Камалның улы.*



*Рахмай Хисмәтуллин (1934-2004) – шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе. 1989-1997 елларда Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе. Гаяз Исхакый премиясе лауреаты (1994).*



*Республиканың дәүләт эшлеклеләреннән Илгиз Хәйруллин (уртада) һәм Әгъзам Гобәйдуллин (уңда) Фоат Галимуллинны (ул вакытта Татарстан Язучылар берлеге рәисе) 60 яшьлек юбилее белән котлыйлар. Март, 2001 ел.*



*Ел йомгакларына багышланган җыелыштан соң. Мәдинә Маликова, Флүс Латыйфи (уртада), Әсгать Сәлах. 2006 ел.*

# ШАГЫЙРЬ ЭЗЛИМ

## 2016 ЕЛ ПОЭЗИЯСЕНӘ БЕР КАРАШ

### 1. Шигырь – серле могҗиза

Мәкаләнең гадилеге белән сәеррәк исеме кемсәнеңдер күзенә чагылуга, ул телен шартлатып, «вәт дивана, тәнкыйтьче атын күтәреп йөргән була, үзе шуны да белми, хәзер яше-карты, хәреф чыгара алганы шигырь сырлый, һич югы бәет чыгара, мөнәҗәт көйли, Язучылар берлеге чыгарган белешмәдән йөздән артык тезмәче таба алыр иде», дияр. Матбаганы күзәтеп барганы «Казан утлары», «Идел», «Безнең мирас», «Мәйдан», «Сөембикә» журналларында, «Мәдәни җомга» һәр атнада биреп барган шигырь битләрендә, башка басмаларда күпме кешенең уйлану-сагышлары, эзләнүләре, өмет-ниятләре белән танышырга мөмкин, дип тә өстәр кебек.

Бу мәсьәләгә шагыйрь Г.Мөхәммәтшин, мыек астыннан елмаеп, үз карашын белдерә. «Шигырь һәм заман» парчасында: *«Күптән инде шигырь язганым юк. – / Кемгә кирәк бүген шигырең? / Шигырь язучылар бүген инде / Миннән башка да бит шыгырым»*, дип күзгә төтен җибәрә дә, «Казан утлары»ның унынчы санында «Яшьлегемнән мәңге китмәс идем» дигән циклын тәкъдим итә. Яшьлегенә «ябышып» яткан затның каләменә богау салып булыр идеме икән?

Һәр шигырьдә ахыргача ачылып җитмәгән «сер» булырга тиеш дигән фикергә таянып, «Шагыйрь эзлим» гыйбарәсенең мәгънәсен мәкалә ахырында аңлатырга вәгъдә бирәм. Әдәбият тарихы мондый «серләрне» бик күп саклый. Мәсәлән, 1917 ел инкыйлабына чаклы Маяковский, Бурлюк, Крученых – яшь футуристлар – Одессада түләүле чыгышлары алдыннан пианиноны түшәмгә элеп куялар һәм тамашачыларның үрсәләнеп кызыксынуына «кичәнең ахырында аңлатырбыз» дип җаваплыйлар. Очрашу тәмамлангач, «сез вакытыннан алдан чыгып китмәсен һәм интрига өчен пианиноны күтәреп куюлары»н әйтеп шаккатырганнар. Көнләшеп искә алуым түгел бу вакыйганы. Үзебезнекеләр дә башкалардан ким-хур түгел икән. Әйтик, футуризм агымы белән саташып йөргән яшь шагыйрь Г.Кутуй айга шлем кидереп куя. Исе дә китми!

2016 елда дөнья күргән шигъри дәрьяны тулы иңләү мөмкин түгел. Милләт гамен, яшәү үзәнен чагылдырган, С.Хәким әйтмешли, «җиз иләк» аша үткәрелгән иң камил үрнәкләре әдәби барышның барометры, йөзек кашы «Казан утлары»нда басылып чыгуларын истә тотып, шул мәҗмуга битләренә күз салу мәслихәт, максатка ярашлы булыр дип «юлга чыктым». Әдәбиятның элгәр, җитез, элеккечәрәк әйтсәк, көн кадагына сугучы, кешенең рухи дөньясына, табигатькә иң якын жанр булуын истә тотып булса кирәк, журналыбыз шигърияткә урынны кызганмый. Озак еллар дәвамында саклана килгән ошбу традициянең, күрше-күләнгә әйтеп, урамда «шаулап йөрү» мәҗбүри булмаган янә бер сере бар. «Совет әдәбияты» – «Казан утлары» белән, мин хәтерләгән дәвердән, күренекле шагыйрьләр җитәкчелек итә: З.Нури, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, И.Ибраһимов. Кыска вакытка гына булса да, бу вазифаны Сибгат ага да үтәп алды. Журналда басыла килгән шигырьләрнең сыйфатын озак еллар дәвамында поэзия бүлеге белән җитәкчелек иткән зәвыклы, укымышлы Р.Гаташ тәэмин итүен дә онытырга ярамый. 2016 елның һәр унике санында кимендә өч-дүрт, Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт язучылары иҗатына багышланган айларда дистәләгән шагыйрь иҗатыннан үрнәкләр бирелә. Үтеп киткән ел татар шигърияте кайсы сыйфатлары белән үзенә җәлеп итә соң?

Совет чорында шигъриятнең, дөресе, бөтен әдәбиятның умыртка баганасын, җанын, шәхси башлангычны иҗат методы, уңай герой, алдынгы эшче, колхозчы алыштырырга

тиеш иде. Иншалла, хәзер андый шартлы киртәләр, кысулар, тәртәгә кертүләр юк. Үзең өчен язылган шигырьнең үзәгендә яткан кичереш, фикер-хис дулкыны укучыны да бөтереп алсын да күңел түренә үтсен, ягъни ул, «карале, шагыйрь минем хисләрне, уй-хыялларымны матур итеп әйтеп биргән ләбаса», дип әйтерлек булсын!

Шигъри тәлгәшләрнең күплеге, эчтәлекләрендәге тематик төрлелек, шәкли эзләнүләрдә кабатланмаска, яшәешебезнең төрле кыйтгаларын иңләргә, дөнья картинасын тулырак чагылдыруга омтылыш сокландыра. Шигырьләрнең муллыгы безнең милләтнең менталитетына, гореф-гадәтләренә бәйле дип уйлыйм: ул җырсыз, көйсез, матур сүзсез тормышын күз алдына да китерә алмый. Халык җырларына, бәет-мөнәҗәтләренә, дастан-риваятьләренә күз салыгыз! Аларда төрки-татарның тарихы, томан артында калган бөеклек һәм гасырлар дәвамында җиңүчеләр тарафыннан кимсетелү, мөстәкыйль халык буларак саклану өчен көрәш, милли изелү белән килешмәү тулышып ята. Шигърият ошбу юнәлеш-проблемаларның үзәгендә кайный.

Милли тормыш-яшәеш авырлыгы, югалып калу, киләчәккә ышанычның какшавы, 90нчы еллардагы үзгәрешләрнең кайтуына ышанмау шигърияткә, хәтта иң «титуллы» шагыйрьләр иҗатына да үтеп керә.

Төрле буын вә өслүб шагыйрьләрен берләштергән уртак юнәлешләр: халкыбыз, телебез язмышы, җәмгыятьнең бүгенге халәте, байлар белән ярлылар арасындагы чикнең ерагая баруы, вакыт, яшәү-үлем фәлсәфәсе... Шагыйрь Р.Вәлиев шул юнәлешләрдәге борчылуларны ике юлга сыйдыра алган:

*Бүлгәләнде кавем, илләр, җирләр,*
*Бүленми тик патша тәхете...*
(«Ут эчендә татар язмышы»)

Күпчелек шигырьләрнең мәхәббәт, сөю-сәгадәт мәүзугына багышланган булуын инкяр итмәстән, Тукай фатихасын алган ике агым бик күп шигырьләрне бер үзәккә туплый: татарның үткәнен искә төшерү аша аның киләчәге өчен борчылу.

## 2. Тукайны сөю – халкыңны хөрмәт итү

Үтеп киткән ел мәдәни-милли тарихыбызга бөек шагыйребез Тукайның тууына 130 ел тулу бәйрәме булып кереп калды. «Казан утлары»ның апрель саны тулысынча Тукайга, аның иҗатына багышланган. «Сөя халык үзенең Тукаен» дигән гомуми оя төрле буын шагыйрьләренең илһам җимешләрен тәкъдим итә. Инде бакыйлыкка күчкән Хәсән Туфан, Нажар Нәҗми шигырьләрен Фирүзә Җамалетдинова, Рифә Рахман, Рәмис Аймәт, Рөстәм Сүлти, Йолдыз Миңнуллина кебек яңа буынның эзләнү-уйланулары тулыландыра.

Татарстанның халык шагыйре Р.Гаташ белән Ф.Сафинның Тукай наменә багышланган шигъри гөләндәмнәре күңелне нурландырып, үзләренә җәлеп итеп тора. Р.Гаташ «Тукай хозурында» дип исемләнгән, өч мөстәкыйль бүлектән торган әсәренә «Гомер дастаныннан» дигән ачыкламыш биргән. Романтик Р.Гаташ Тукай бөеклеген татар тарихында тирән эз калдырган Туран, Һуннар, Дәшти Кыпчак кылганнарына бәйләп сурәтли. Аның җаны исә «йөз, мең гасырның» ярсуын, әрнүен тоя. Икенче бабта шагыйрь биниһая күп патшаларны, ханнарны күргән Идел, Казан язмышлары турында уйлана.

*Халкым җаны ирек даулый,*
*«Әй, байтагым, дип, байтагым –*
*Илем, сине алдырдыкмы тагын?*
*Дошман талар килгән соң,*
*Әл-аман бул миннән соң!»*

Үзе уйлап тапкан яисә башка төрки телләрдән алынган сүзләрдә, катнаш кафияләрдә (2-3, 4-5 юллар), халыкның аянычлы тарихы, милләтләре өчен җан атып яшәгән шагыйрьләрне кинәт искә төшерү дә Р.Гаташка килешә. Икенче бүлектә «Сөембикә

сынлы Фәүзияләр, Саҗидәгә сеңел шагыйрәләр» аталса, соңгы бүлектә «алтын энҗедәй сүзле Туфан, Хәким, Арсланнар», шулай ук фани дөньядан күчкән «Юзәй, Шәүкәт, Әхсәннәр» тезелеп китә. Үзе белән бер чордарак яшәгән, мәңгелеккә киткән һәр шагыйрьнең аңа гына хас сыйфаты табыла: «Нечкә җан Рәшит артыннан китте бунтарь Роберт дусты» – «Моң шагыйрьләре – Мөдәррис, Зөлфәт, Наис, Харраслар». Күзләрне камаштырырлык бу санаулар татар шигъриятенең үткәнгә таянган хәзерге торышын күз алдына китерә сыман. Р.Гаташ сөю, мәхәббәт, гыйшык шагыйре, аңардан мантыйкка корылган төгәл сюжет димим, хәтта кичерешнең эзлекле үсешен дә таләп итеп булмый (шуңа да ул прозага алынмый, тәнкыйть белән публицистикасында да үзенә турылыклы кала). Безне ташлап киткән шагыйрьләрне яд итүгә, төрки-татар кызы өчен» «мең җаны» булса, барысын фида кылырга әзер. Уйлап та тормыйча!

Иҗатында Р.Гаташ, әйтик, С.Рәмиев, С.Есенин, М.Әгъләм, Зөлфәтләр кебек сиземләвенә, дөньяны үз аңлавына таяна, эчке рефлекциягә буйсына. Аның хисси, хәтта мәгънәви күчеш-борылышлары да көтелмәгәнчәрәк булырга мөмкин. Әле генә үткәндә ясалган хаталар, бүгенге югалтулар өчен җаны әрнегән шагыйрь кинәт шатлыклы, яңгыравык аһәңнәргә өстенлек бирә башлый. Анысы да Р.Гаташка килешә.

*Исәннәргә юл – алга табан.*
*Идел ага... Яши Ил. Хыял – аман.*

Төрлечә уйласа-язса да, Р.Гаташ бер генә мизгелгә дә милли символ турында онытмый. Ул – Тукай бөеклеге, Тукай рухына тугрылык. Бу иманыннан аны җил-давыл котырынуы да, җир тетрәүләр дә чигендерә алмый.

Проза өлкәсендә җитди уңышларга ирешсә дә, нигездә шагыйрь булып калган Ф.Сафин 2016 елда укучыны «Без – Тукайлы халык» (киң әйләнешкә кереп киткән «Без – Тукайлы» гыйбарәсен безнең чорда, беренчеләрдән, шул исемдәге поэмасында шагыйрә Э.Шәрифуллина кулланды бугай) исемле сонетлар такыясы белән шатландырды. Көнбатышта туып, инглиз, итальян әдәбиятларында калыпка утыртылган, шәкли таләпләре ифрат катгый (ул ундүрт юлдан торырга, һәр мисрагы кафияле булырга тиеш һ.б.) жанр Ш.Маннур, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен иҗатларында мәгълүм уңышларга ирешсә дә, безнең чорда телебезнең силлабик «бишегендә» үзен иркен хис итә башлады. Үтеп киткән елда Р.Харис («Ай, үзгәрә дөнья» бәйләме), Ф.Сафин лөгатебезнең сыгылмалы мөмкинлекләре сонетта дан казанган телләрдән ким-хур булмавын раслыйлар. Иң мөһиме: өлешчә Шекспир иҗатында, тулысынча Петрарка сонетларында төп мәүзугъ мәхәббәт, сөю-сөелү сагышы булса, Ф.Сафин Тукай образын милләт вазгыятьләре яссылыгында тудырса, Р.Харис, сонетлар бәйләменең исеменнән үк күренгәнчә, дөньяның үзгәрүенә бәйле күп яклы үзгәреш- яңарышларны нигез итеп ала. Ике шагыйрь иҗатында да фәлсәфи хөкем үзәк агымны тәшкил итә.

Ф.Сафин Тукай образын, аның дәвамчылары рухын ачкан, милләт, тел язмышы турында уйландырган 15 сонеттан торган, махсус сөйләшүгә лаеклы цикл иҗат иткән. Һәр сонетына Тукай шигъриятеннән юллама-эпиграф алып, үзен «юлга» чакырган максатын тәгаен билгеле.

*Хәйлә, мәкер, йокы – безнең йортны сүтәр...*
*Биеклек бар – Тукай! Маяк итеп барыйк.*
*Бу юлны соң бездән башка кемнәр үтәр?!.*

Шагыйрь йөрәген «Тоташ сызлау, яну телсә дә», туган телебезне, милли гореф-гадәтләребезне саклау өчен лирик геройның ярсуы, чәпчүе, чебеннең тәрәзә пыяласын ватарга маташуыннан ары китә алмый. Чөнки татар җәмгыяте көндәлек мәшәкатьләр белән мәш килеп, иртәгесе көн турында уйламыйча, битарафлык бозлыгына кереп баткан.

Гаҗиз шагыйрьгә «Теләк белән, туган телдән качып барыш» дигән мәрасименнән соң, үзен: «Без бәхетсез халык түгел, без – Тукайлы халык», дип юатырга гына кала.

Ф.Сафинның тирән һәм шактый бай эчтәлекле сонетларына, шигырь техникасы

җәһәтеннән бәя биргәндә дә, аның кыю эзләнүләрен инкяр итеп булмый. Жанрның шәкли кысаларында да шагыйрь, эчке һәм юл азагындагы кафияләрдә тартык һәм сузык авазларны ярәштереп («Түбәм – нуры үтә», «беләм – җилләр өтә»), соңгы ике куплетны 4-2 урынына өчәр юлга чыгарып, фикерен өздереп әйтә, үзен эзләнүчән шагыйрь буларак раслый.

Татарстанның халык шагыйре, шигъри, драматик жанрларда уңышлы әсәрләр авторы Р.Харис «Аһ, үзгәрә дөнья!» (5нче сан) тупланмасында сонет жанрының мәгънәви эчтәлеген яңартып, дөньяви, фәлсәфи мотивларны әхлакый югарылыкка күтәреп сурәтли. Күңел халәтен, рухи эзләнүләрен укучыга җиткерү максаты белән, «Үлмәс зынҗыр», «Бәхет төшенчәсе», «Алманың хушлашуы» кебек сонетларында аллегорик, символик нисби төшенчәләрне яңача яңгыратып, чынбарлыкны тирәнрәк аңлау һәм сурәтләү юлларын эзли тынгысыз шагыйрь. Үзенең иң тирәндә яткан хыялын да калкытып кую җаен таба.

*Нарасый бала кебек гөнаһсыз,*
*фәрештә кебек аһсыз һәм ваһсыз*
*яшәп карыйсы килә кешечә...*

(«Бәхет төшенчәсе сонеты»)

Р.Харис каләменнән ак кәгазьгә төшкән сонетлар арасында «Эндәшмәү сонеты» иң кадерлесе дип сизенәм, чөнки биредә сүз Илаһи көчкә – Ходай Тәгаләгә якынлашу, табыну турында бара.

*Мин эндәшмим – мине Аллаһ тыңлый!..*
*Аның белән шулай аңлашам...*
.............................................................
*Мин Аллаһны аңлагандай булам...*
*Сөйли генә белмим халыкка...*

(«Эндәшмәү сонеты»)

Лирик затның хисен, уен («Мин эндәшмим») икенчесенә каршы куйгандай тоелса да («Аллаһ мине тыңлый», «Сөйли генә белмим халыкка»), антитеза, диалог-аңлашу тумаса да, бу алым кешенең Раббыбыз белән рухи сиземләүгә омтылган эчке халәтен ачып сала. Бетми торган «күңел ярасы», «бәхет төшенчәсе», күңел бөҗралары турында киеренке уйланулар белән беррәттән, көтмәгәндәрәк «Алманың хушлашу сонеты»нда шагыйрь алманың «эчке сөйләмендә» җирнең тарту көчен өзелеп төшкән алма ярдәмендә аңлаган бөек галим Архимед ачышына ишарә ясый.

*Мин иртәгә синнән китәмендер –*
*үзәгемне нидер кимерә...*
*Ләкин белмим – кая төшәрмендер,*
*Җиргә төшсәм, аны җимерәм.*

Алма бу сонетта ачкыч сүз, код булып кына калмый, ә әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Тулаем, бу жанрда үзен шагыйрь иркен, ирекле сизә. Шәхеснең гадәти эчке кичерешләре турында язганда да, үз-үзе алдында җаваплылыкны сизеп, яшәү хакында хөкем иткәндә дә, иң нечкә кылларга кагылмыйча үтә алмый.

*Барысы да үтә икән, сизәм...*
*Бетми икән ләкин берсе дә,*
*бигрәкләр дә – күңел ярасы...*

Р.Харис белән Ф.Сафин эзләнүләрендә «үзебезнеке» булып киткән «кылтык» сонет жанрында үзләрен иркен тотуларын, эчтәлекне, шәкли алымнарны баетудагы табышларын хупламый мөмкин түгел.

«Яшәп карыйсы килә кешечә» дигән хыялында Р.Харис ялгыз түгел, аныңча фикерләүчеләр тагын бар икән. Җөмләдән, шагыйрь, эпиграммалар, шаян күзәтүләр авторы Ләбиб Лерон яңа шигырьләр бәйләмен «Бер яшисе килә кешечә» (8нче сан) дип атый һәм аны тормышка ашыру әмәлләрен эзли.

Әдәби әсәрләрендә, яшәү рәвешләрендәге кебек, холык-фигыльләре чагылган, ягъни ясалмалыкны кабул итмәгән, үзләре булып калган шәхесләр була. Р.Гаташ шундый романтик зат дигән идек. Л.Леронның «Мәңгелек өн», «Яхшылык», «Чеховка кайту яки Ротшильд скрипкәсе», «Бер яшисе иде чын-чынлап» кебек шигырьләре белән танышканда, үзеннән-үзе аның мәһабәт гәүдәсе, сүзен ашыкмыйча, әмма өздереп әйтүе күз алдына килеп баса. Ничек күңеле тели, шулай яза, кемгәдер охшарга тырышып, көчәнеп маташмый. Аны укуы рәхәт. Шигыренең ахыргача камил эшләнешенә дә исе китми, сикереп төшми (мәсәлән, «Кара шәм»).

*Бүген мине йокы җиңәлмәде...*
*Бер ялгызым төнгә керәмен.*
*Куанычтан дөньям – мөлдерәмә:*
*Шигырь эчәм – кайнар перәме!*
(«Йокысызлык»)

«Керәмен-перәме» кафиясен «йотып» җибәрсәк тә, ни өчен (йоклый алмау сәбәплеме?) дөньясы мөлдерәмә икәнлекне кайнар шигырьдән дип кенә фаразларга кала. Л.Лерон, эпиграммаларындагы шикелле, лирикасында усалланып та куя белә.

*Азатлыкның әле исе дә юк.*
*Күренгәне дә юк ирекнең...*
(«Чеховка кайту...»)

Кешечә яшәүне ничек, ни рәвешле күзаллый соң шагыйрь. Аның таләпләре шактый һәм саллы:

*Бер яхшылык эшлим әле, дисәң,*
*Кылыйм әле, дисәң, игелек –*
*Тома ятимнәргә назлы сүз әйт,*
*Башларыннан сыйпа иелеп!*

Тукай 1910 елда язылган «Нәсыйхәт» шигырендә шул ук инсани хыялын калкытып куйган иде:

*Булса – бир, булмаса исә – җайлап сөйлә булмаслыгын, –*
*Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын.*
(«Нәсыйхәт»)

Яхшылык кылуның юллары төрле икәнне санап чыкканнан соң, Л.Лерон төп нәтиҗәсен ясый: «Иң әүвәле кеше булып яшә. Кеше булып кал син иң элек».

Һәрвакыт ачык йөзле (һәрхәлдә мин күргәндә), итагатьле Ләбибкә дә ялгызлык кебек замана чире йога ала икән. «Исән килеш дуслар... үлә бара» гыйбарәсе белән килешмәсәм дә (үтермәсәләр, бер җан иясе дә сау-сәламәт килеш үлми), аның «Бер дус исән әле: Ул да булса – Шигырь» дигән сүзләрен хупламый мөмкин түгел. Идеализм, әмма яхшы мәгънәсендәге күпертү... Чөнки биредә фәлсәфи вә иҗади фикер лирик геройның дөньяга карашы аша иңдерелә.

2016 ел шигъриятенең асылы кешегә игътибарлы булуга гына кайтып калмый, ә рухи-дини, әхлакый нигезләрне аңлап, саклап калуга омтылышта да ачык күренә. Җөмләдән, Ә.Рәшитнең соңгы пәйгамбәребезгә багышланган «Мөхәммәд» поэмасы, Н.Әхмәдиевнең «Пәйгамбәрләр турында кыйсса», «Фәрештәләр белән бәхәсләшмим» кебек дини-тарихи чыганакларга, аллегорик символларга таянып иҗат ителгән

әсәрләре пәйда булды. Үткән гасырның беренче чирегендә Һ.Такташ, М.Гафури, Ф.Бурнаш, М.Җәлил һ.б. иҗатында ислам мифологиясенә, Коръән поэтикасына тәкълид итеп язылган кыйссаларыннан соң, совет чорында бу мәүзугъка мөрәҗәгать итү тыелды. Берәүнең дә ут белән уйныйсы килмәде. 90нчы елларда, мәгълүм иҗат ирege бирелгәннән соң да, куркытылгын өлкән буын ошбу теманы әйләнеп үтүне исәнлеккә файдалырак дип саный килде.

Күренекле шагыйрь Казан ханлыгы чорының бөекләре турында мифоэтик әсәрләр («Сөембикә» (1987), «Колшәриф» (1990), «Мөхәммәдьяр» (1996)) иҗат иткән Ә.Рәшитнең пәйгамбәр образына алынуы табигый иде.

«Казан утлары»нда поеманың кыскартылган нөсхәсе бирелсә дә (3нче сан), ул шактый күләмле, бай эчтәлекле. Ә.Рәшит ислам динен тотучылар өчен изге зат Мөхәммәднең шигъри сынын тудырганда, тарихи, әдәби чыганакларга, халык дәһри елларда да Аллаһ илчесен бәетләрендә, мөнәҗәтләрендә зурлавын дәвам иткән әсәрләргә таянган. Шул ук вакытта ул бу тарихи-хыялый чыганакларны үзенчә «укырга» тырышкан.

*Кинәт кенә шунда әллә нәрсә булды,*
*Ишегалды якты нурлар белән тулды.*
.................................................................
*Һәм Мөхәммәд, һушы китеп, җиргә ауды,*
*Өстенә иштеләр гүя зур бер тауны.*

Шагыйрь Аллаһының Мөхәммәдкә Коръәнне иңдерүен, пәйгамбәрнең ислам динен тарату юлындагы сәләтен, ышандыру көчен, үзен-үзе кызганмыйча, кяферләр, дошмани кавемнәр белән көрәшүен икеләтелгән проекция алымын кулланып яисә ничәмә гасырлар элек булган хәлләрне үзе күргәндәй итеп сурәтли. Бу алым поеманың ышандыру көчен арттыра.

*Әллә нинди сәер уйлар туды җанда,*
*Ышанган һәм ышанмаган булды анда.*
.................................................................
*Туганнары, яшьтәшләре арасында*
*Тигез иде аның өчен син дә, мин дә.*

Тулы килеш укылмаган әсәргә дәгъва белдерү иртәрәк булса да, Ә.Рәшитнең иҗади мөмкинлекләрен белгән кеше буларак (аның иҗаты, бигрәк тә поэмалары турында язарга насыйп булды), кайбер теләкләремне әйтмичә кала алмыйм. Телгә алынган кыйссасында Н.Әхмәдиев дөрес яза:

*Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,*
*Үз дигәнчә һәркем көн иткән.*
*Пәйгамбәр дә судан яралмаган,*
*Кендекләре җиргә береккән.*

Димәк, Мөхәммәдне идеаллаштыру белән беррәттән, аның кешелек сыйфатларын, хатыны Хәдичә белән мөнәсәбәтләрен, мәхәббәтләрен, балаларын тәрбияләүләрен дә күрсәтү лаземдер? Инде үзебезнең төрки-татар дөньясы ничек, ни өчен ислам динен кабул иткән?

Поеманы тулыландырганда, әгәренки кирәк тапса, Ә.Рәшит әлеге мәсьәләләргә дә җавап, аңлату эзләп, Мөхәммәднең шәхесен тулыландырыр, бәлки, дәвамчыларының Исламны тарату юнәлешендәге эшчәнлегенә дә тукталыр дип ышанасы килә.

Әйтелгәнчә, 2016 елда пәйгамбәрләр тарихы вә язмышы кебек изге мәүзугъны яктыртуга алынган шагыйрь бер Ә.Рәшит кенә түгел. Прозаик, шагыйрь Нур Әхмәдиев «Офык артларында офык бар» (12нче сан) исемле бәйләменә кергән «Пәйгамбәрләр турында кыйсса», «Фәрештәләр белән бәхәсләшмим», «Кеше җаны» кебек, мифологик ышануларга, аллегорик образларга «иҗат ирege» биргән шигырьләрендә пәйгамбәрләр

язмышына кагылып, аларның Адәм балалары булуына басым ясап, «Аларга да ташлар атканнар, Хак илчесе дип тормаганнар», алар да безнең кебек тормышның ачысын-төчесен татыган дигән фикер уздыра.

*Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,*
*Күктә шулай кирәк тапканнар.*
*Хак илчесе диеп тормаганнар,*
*Аларга да ташлар атканнар.*

Нух, Гайсә, Ибраһим, Сөләйман пәйгамбәрләргә баш иеп, «Ахырзаман пәйгамбәре булып, Тик Мөхәммәд», дигәннән соң, кыйссасының төп өлешенә, шигърият нәбиләре – пәйгамбәрләрен сурәтләүгә күчә. Шигырьнең беренче өлеше дини укучыларны «җәтмәсенә» эләктерү өчен җим булып чыга, ягъни биредә дә икеләтелгән проекция алымы кулланыла. Шигъри «тасмада» Кол Гали, Тукай, Пушкин, Лермонтов кебек шигърият даһиләре турындагы сөйләмдә лирик каһарманның күңел тәрәзәләре ачылып киткәндәй була. Әмма алар шунда ук ябыла. Чөнки автор үз шәхесен сурәткә алып кереп, кемгәдер дәгъвасын белдерә, шаяртыбрак булса да, «мескенләнә».

*Мин дә шагыйрь, тел сагында торам,*
*Фикерем бар, баймын хискә дә.*
*Шигъриятта бер пәйгамбәр булу*
*Кереп карамый тик төшкә дә.*
(«Пәйгамбәрләр турында кыйсса»!)

«Кеше җаны» шигырендә ул кешене табигатьнең иң югары казанышы, горур зат дип саный һәм үлгәннән соң аның җаны башкага күчүгә ышана: «Белсәң иде: кайсы асыл затта Бәргәләнә Тукай йөрәге». Шагыйрь зәңгәр томан артында югалып калган олы тарихыбыз белән масаю юлына басмый, аны күбрәк кешелекне, татарны саклап калган «Газиз Аллаһ»ның мәрхәмәте, «Карурман»нарны тудырган нечкә күңелләр язмышы борчый. Ул саф татар телендә тигез 9-9, 10-9 иҗекле силлабик шигырьдә үзен иркен сизә. Иҗади активлыгын хупламый мөмкин түгел. 2015 елда да, 2016 санәдә дә ул укучысын яңа шигъри тәлгәшләре белән сөендерде.

## 3. Шигырьләрдә – милләт гаме

2016 елда Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Вәлиев, М.Мирза, И.Гыйләҗев, Р.Миңнуллиннарның яңа шигырьләре бер хакыйкатькә инандырды: иҗатчының һөнәре, яшәү рәвеше, иҗтимагый тормыштагы вазифалары аларның зиһененә, хиссият дөньясына юнәлеш коды сала һәм бу «бәйлелектән» алар, бик теләсәләр дә, кул селтәп кенә котыла алмыйлар. Гомеренең зур өлешен мәгариф, мәгърифәт, фән үсешенә, халык язмышын кайгыртуга багышлаган, Татарстанның халык шагыйре Р.Вәлиевне «Без – мәңгелек туган җир белән» (9нчы сан) тупланмасында да милләтебезнең бүгенгесе, киләчәге, Тукай теленең язмышы борчый. Бу җәһәттән аның «Җидегән» шигыре үзенчәлекле. Сүз Түбән Кама шәһәрендә озак еллар гөрләп яшәп, яшь буын иҗатчыларын әзерләүгә зур көч куйган «Җидегән чишмә» әдәби-мәдәни берләшмәсенең (ул аны оештыручыларның берсе һәм берәгәйлесе дип беләм) дәртле, җилле чоры турында бара. Шагыйрь гади күзәтүче, вакыйганы эзмә-эз сөйләп бирүче була алмый.

*«Милләт», диеп утка керде алар,*
*Ә кемнәрдер кабер казышты...*
*Ут эчендә бүген Тукай теле,*
*Ут эчендә татар язмышы.*
(«Җидегән»)

«Халыклар һәм илләр адашканда», күпләр өчен якты маяк булып балкып торган

«Җидегән чишмә» каһарманнарына багышланган шигырь киң гомумиләштерү, татарның илләр, җирләр буйлап югалткан бәхетен эзләтеп йөрткән холкы турында җитди уйлануларга алып чыга:

*Бәхет эзләп халкым җирләр гизгән,*
*Татар һәрчак төпкә җигелгән,*
*Җиңелгәнне алдап була икән*
*Орден-медаль, тәти җим белән.*
(«Җидегән»)

Әлбәттә, гомумән шигърияткә хас шартлылыкны «читкә куеп», орден-медальләрнең дә «затлыракларын» җиңүчеләр үзләренә тагалар, дип бәхәсләшеп тә булыр иде шагыйрь белән. Мәгәр авторның сүзен өздереп әйтеп, чаң сугып, халык мәнфәгатьләрен югары өслүб белән калкытып куюы теләктәшлек уята.

*Күптән инде, күптән, ирек даулап,*
*Чатырларга байрак элгән юк.*
*Тукай әйткән: татар йоклагандыр...*
*Уянырмы берчак? Белгән юк...*
(«Моңлы ядкарь»)

«Мин соң кемгә эндәшим?» шигырендә шаярып, көлеп, шагыйрьнең тормыштагы урыны, «биектә-күктә» булып, җиһанга эндәшсә дә, аның ялгызлыгы турында уйлана. Янында кешеләр күбрәк булган саен, эндәшер затлар сирәгәя икән.

Күренә ки, Р.Вәлиев эзләнүләрен төрле юнәлешләрдә алып барырга тырыша һәм, күп очракта, ул шигъри эшләнешкә, вәзен, кафия төгәллегенә зур әһәмият бирә, җеп очын, уңмаган хатын шикелле, салындырып калдырмый.

«Минем дошманым» башка шигырьләре арасында аерым урын тота. Гадәттә, синең һәр ялгышыңны алдан күреп, адымыңны санап торган дошманыңны күрә алмыйсың, аның белән бәхәсләшәсең, үзеңнекен исбатлыйсың. Р.Вәлиев каһарманы, күзенә туры карый алмаган бәндәнең үз-үзен тотышыннан, «әшәкелек эшләвеннән дә «файда» таба.

*...Дошманыма карап юлга салам,*
*Үзгәртәм мин тормыш агышын.*
*Ул булмаса, каян белер идем:*
*Кайсы дөрес, кайсы ялгышым.*
(«Минем дошманым»)

Күтелгән нәтиҗәнең киресен китереп чыгару – логик анализның сыналган классик алымы.

Татарстанның халык шагыйре Р.Фәйзуллин да укучысын «Яңа шигырьләр» тупланмасы (6нчы сан) белән сөендерде. Мәгълүм булганча, ул иҗат манерасы, сурәтле фикерләү рәвеше, бер бөегебезгә дә охшарга тырышмавы белән аерылып торды, шәрык белән гарәбтән иңгән робагый, газәл, сонет, ода, баллада һ.б. жанрлар белән мавыкмады, хәтта мәсәлгә дә (балалар өчен язылганнарны санамаганда) «баш бирмәде».

Соңгы елларда поэмадан да читләште. Шул ук вакытта яңача уйлаучы шагыйребез – милли җирлектә күтәрелгән, күпмедер дәрәҗәдә традицион әдип. Аның бер-ике-өч-дүрт юллыклары – ташка чүкеп язылган Орхон-Енисей ядкярләреннән, мәкаль-әйтемнәрдән, хикмәтле сүзләрдән үсеп чыккан шигырьләр.

Узып киткән Тукай елында дөнья күргән язмаларында нинди уйлар, хис-кичерешләр дулкыны били соң шагыйрьнең тынгысыз җанын?

*Җиңсәң – хөрмәтләрләр. Җиңмәсәң – юк!*
*Җиңсәң – санлашырлар. Җиңмәсәң – юк!*
*Җиңсәң – яратырлар! Ә җиңмәсәң –*
*суыныр синнән хәтта җиңгәчәң үк...*

***

*Мәңгелеккә килмәгәнбез.*
*Яхшылыкка – ашык!*
*Иреннәрең бер йомылыр.*
*Калыр... көмеш кашык.*
(«Дүртьюллыклар»)

Шагыйрь «Ахырзаман», «Тентү», «Киңәш», «Безнең икмәк», «Уйланыйк» кебек шигырьләрендә дә, әйтемгә тартым, кыска күләмле, тыгыз эчтәлекле һәм көтелмәгәнрәк нәтиҗәле хисси уйландыруында да сөйләм теле белән ирекле шигырьгә турылыклы кала.

Табигый сәләтен, акыл җегәрен, зиһен көчен халкының бүгенгесенә, киләчәгенә багышлаган, мәгънәле сүзе белән аның йөрәген җылыткан, тормышның, кеше рухының төрле кыйтгаларын сурәтләгән, кечкенә күренгән хәл-әхвәлләрдә хәрәкәтчән сюжет тапкан, һәркайсына яңарак чагыштыру, метафора эзләгән шигырьләрендә Р.Фәйзуллин үзе яулаган үрләрендә калырга тырышкан.

Төрле буын татар шагыйрьләре иҗатында бүгенге рухи-сәяси халәтебезне өмет, ышаныч белән тулыландыру рухы бер агым буларак яши. Язучыларыбызны да аңлап була: сүздә булса да ирекле яшәү, халкын дәүләтле мәмләкәтләр белән бер дәрәҗәдә күрәсе килү теләге табигый. Шагыйрь әкият «канатында» гадәти яшәешебездән өскәрәк «күтәрелеп», чынлыкта икенче өр-яңа дөнья тудыра. «Казан утлары»ның 8нче санында ифрат милли җанлы лирик, публицист, нечкә күзәтүләргә ия шагыйребез Р.Миңнуллин «Дәверләргә китеп барышы» (кемнең, ни өчен, нинди «йомыш» белән китеп барышы дигән сөаль туа) исемле бәйләменә кергән «Хөррият», «Кол Шәрифкә мәдхия» шигырьләрендә, хыялын «бәйдән ычкындырып», күңелендә йөрткән теләген чынбарлык итеп сурәтли, ягъни үзе тудырган миф «тозагына эләгә».

*Халкым сине гомер буе көтте –*
*Өметләрне акла, хөррият!*
*Без хөрлеккә әле өйрәнмәгән,*
*Хөр яшәргә безне дә өйрәт!*
*Сине безгә бүләк итмәделәр,*
*Яулап алдык сине, хөррият!*
(«Хөррият»)

*Нур чәчеп тор! Син үзең дә*
*Нурга күмел, Кол Шәриф!*
*Без кол түгел, без кол түгел,*
*Без кол түгел, Кол Шәриф!*
(«Кол Шәрифкә мәдхия»)

Роберт каләмдәшебез! Синең иң изге ниятләрең-сөенечләреңне хуплаган хәлдә дә, сорыйсы килә, кай тирәләрдә бездән «качып йөри» икән ул «яулап алынган хөррият», тоташтан ябыла килгән татар мәктәпләре, гуманитар йә педагогия институтлары, юкка чыгарылган милли факультетлар бусагасында яшь агызып ятамы, әллә вак милләтләрне надан, кол хәлендә калдыру өчен уйлап табылган бер телле ЕГЭ дигән зәхмәтнең кампитрындамы? Мин шагыйрьне аңларга тырышам. Ул бу әсәрләрен халкыбыз дәррәү күтәрелгән, «азатлык» дип шашып мәйданнарны тутырган, Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» кыйссасы белән бер чорда, 90нчы елларда ук иҗат иткәндер дә хәзер матбугатка тәкъдим итәргә булгандыр. Юкса, әлеге шигъри бәйләмдә хәзерге халәтебезгә ифрат дөрес «диагноз» куйган әсәрләр дә җитәрлек. «Пушкин бәйрәме» шигырендә лирик затның гаделсезлеккә мөнәсәбәте, иҗат кешесенең җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсен гаҗәп нечкә һәм үтемле итеп калкытып куя.

*Дөньядагы гаделсезлекләргә*
*Ничек түзсен шагыйрь йөрәге?!*

*Түзәр иде – җәмгыятькә әгәр*
*Шагыйрьләрнең булса кирәге.*
(«Пушкин бәйрәме»)

Мостай Кәримгә багышланган «Алып булып калыкты», «Казакъ акыннарына», «Нигә кирәк сиңа Казан?» кебек, үзәкләрендә кичереш үсеше яткан, җылы, күңелләрне иләсләндереп тә, үрсәләндереп тә җибәрердәй шигырьләре укучыны битараф калдыра алмагандыр дип ышанам.

Татар халкының сибелеп, бастырыксыз салам кибәне кебек, таралып яшәве, бер-берсенә авыр мизгелләрдә ярдәм итә алмавы – зыялыларның, аңлаган кешеләрнең бәгырен телгәләгән дөреслек. «Талдыкорганда да татарлар бар...» шигыре шул хакта. Лирик герой еракта көн күрүче татарларның хәлен белергә килгән.

*Күзләрендә – сары сагыш кына,*
*Телләрендә – истәлекләр генә!*
*Талдыкоргандагы татарларга*
*Телим бары исәнлекләр генә!..*

Язмышларына баш игән, тормыш күчәрен кирегә әйләндереп булмасын аңлаган тәкъдирдә дә, «Сагыналар алар Ватаннарын». Шагыйрь мулрак көнитештә яшәүче бәхетле бәхетсезләрне кызгана.

*Картайганнар инде, картайганнар*
*Талдыкоргандагы татарларым...*

## 4. Тарих аша – киләчәккә

Тарихи үткәнебезне, бүгенге рухи-сәяси халәтебезне өмет, ышаныч белән сурәтләү хәзерге татар шигъриятендә үзәк бер агым буларак үстерелә. Тарихилык рухы Ә.Рәшит, Җ.Сөләйман, М.Мирза, Н.Әхмәдиев, яшь шагыйрә Г.Батталова эзләнүләренә юнәлеш биреп тора. Кара морзалар нәселеннән чыккан, русның бөек галиме Н.Карамзин тарихилыктан өч юнәлешне аерып куя: тарихи чыганак, тарихи чынбарлык һәм тарихи белем. Татар-төрки тарихына мөрәҗәгать иткән, югалтуларыбызга күңелләре әрнегән шагыйрьләр интуиция-тоемлау белән Н.Карамзин билгеләгән юнәлешләргә, ягъни тарихилык принцибының берсенә килеп чыгалар. Җ.Сөләйман белән Г.Батталова өчен татар тарихы чынбарлык булса, Ә.Рәшит, М.Мирза, Н.Әхмәдиевләр үткәннән гыйбрәт (белем) ала.

Үткән белән хәзергенең, киләчәкнең бердәмлеге – Җ.Сөләйманның «Испания дәфтәре»ннән» дигән ачыкламыш белән бирелгән «Яңа халәт тоеп оча күңел» бәйләменең (11нче сан) үзәк мотивы.

Әүвәл шагыйрь, укучыны ымсындырып, җылы диңгез буенда, «җәннәт биләмәсендә», иректә илдә яшәүче халык тормышы белән сокланып, яхшы мәгънәсендә көнләшү (димәк, халкы шуңа лаек) уяткач, үз милләтебезнең шанлы үткәне һәм тарихи барыштагы югалтулары турында киеренке, сагышлы фикерләре белән реальлеккә кайтара.

*Безнең кебек, мәңгелек дип,*
*Корганнардыр йортларын да.*
*Кыпчаклар да, болгарлар да*
*Яши, дибез, безнең канда,*
*Әмма кайда ул халыклар,*
*Исеме кайда, йорты кайда?*
(«Киләчәккә карап уйлану»)

Бу юллар ирексездән 20 яшьлек Тукайның «Кичке азан» шигырендәге атаклы юлларны келт итеп искә төшерә.

*Беләмсез ни*
*Дияр азан:*
*Китте Касыйм,*
*Китте Казан,*
*Бетте татар,*
*Кырылды хан,*
*Бохар Хуканд*
*Һәм Әстерхан.*
(«Кичке азан»)

Гуманист, миһербанлы шагыйрь Җ.Сөләйман ерак бабаларыбызны «Халык булу, яшәп калу – Сирәкләргә тигән Өлеш», дип «аклау» әмәлен таба һәм татар халкын илаһи биеклеккә «алып менә».

*Татар телен канат итеп,*
*Нигез итеп Идел-йортны,*
*Үскән халык, горур халык,*
*Яңа татар – сәлкеш халкы!..*
(«Киләчәккә карап уйлану»)

Үз милләтен апофеозга күтәреп, югары бәя бирүендә хыял белән реаль чынбарлык арасындагы чикне «бутавын» аңлап, шагыйрь «кайтып» төшә: «Бу – бер хыял, сез күрәсез».

Югары мәдәни зәвыклы Сөләйман, реалистик һәм заманча фикерләү алымнарына турылыклы калып, эчке һәм тышкы кафияләр, авазлар яңгырашын төгәл саннардагыча саклап, үзенә дә кыю бәяләр биреп куя:

*Дөнья башка, мин дә – үзгәрәк,*
*Әйтерсең лә кичә курчак идем,*
*Бүген инде очам... күбәләк...*

Сөләйман – күкләр, галәм, җир берәмлеген, җан, тән, фикер-хисләр – нәфес арбаларын бербөтен итеп күзаллаучы шагыйрь.

*Тән дә исән! Җан – тән белән,*
*Аучы – ханнан аерылмас лачын кебек!*

Шигъри бәйләмнең соңгы юлларындагы лирик затның (шагыйрь үзе дип әйтәсе килми) төшенкелеккә бирелүен хупламадым:

*Фани дөнья арбасында мин – юк,*
*Юллар инде бакыйлыкка таба...*

Аның хаста хәлен белгән тәкъдирдә дә, бирәдә беркадәр иркәләнү, чытлыклану да бар кебек. Бу «юату» артык наив күренсә дә, Тукай сүзләре искә төшә.

*Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә.*
(«Шагыйрь»).

Олы иҗтимагый вазифаларны иңенә алып, Бөтендөнья татар яшьләрен хәрәкәткә китергән «Сәләт» оешмасына нигез салган, шигырьләрендә дә интеллектуал булып кала алган Сөләйманга исәнлек, озын гомер телик. Аның Ходай биргән һәрьяклы таланты безгә бик кирәк әле!

Өлкәннәрнең төрле юнәлешләрдәге эзләнүләренә яшьләр битараф калса,

шигъриятебез су күрмәгән гөл шикелле шиңәр иде. Иншалла, остазларның дәвамчылары бар икән.

Яшь шагыйрә Г.Батталова әлегәчә «ирләр темасы» саналган тарихи үткәнгә «пар атта» килеп керә. «Ихласлыкка сусаган җан» (5нче сан) бәйләменә кергән «Гафу итмәс тарих», «Безнең кавем», «Дога кылам», «Мең ел үткән...» шигырьләрендә югалтуларыбызны, «тарих төшкән кылыч кыннарыннан, язмышыбыз – күңел кылларыннан», дип йөрәге аша уздырып, экзистенциаль сагышка бирелеп уйлана шагыйрә.

*Мең ел үткән...*
*Далаларда – тояк тавышлары.*
*Гасырларның тоям агышларын.*
*Мең ел үткән...*
*Яулар килгән, яулар киткән.*
*Милләт көткән –*
*Мең ел үткән.*

(«Мең ел үткән»)

«Киләчәгем татарына Динем белән телем илтәм» юлларын һәм «Моң өзелмәс, рух җиңелмәс», дигән өмет чаткыларын хупламый мөмкин түгел.

«Татар кызы канын...» горурлык белән йөрткән Г.Батталова – 2016 ел шигъриятенең бер казанышы. Аңа иҗади уңышлар телик!

Тарихыбыз инде аркылыга-буйга өйрәнелгән, халкыбызның үткәнен барлаучылар күрми калган кыйтгалар юктыр, дип йөрсәм дә, «Казан утлары»ның 11нче санында М.Мирзаның «Хакны нахактан аерып...» шигырьләр тупланмасында урнаштырылган бер шәлкем шигырьләре бүген дөньяның кешелек яратылган изге туфрагында кан коеш сугышларга багышлана. Аның элгәрерәк язылган «Тарих тора патшаларның тәхет бүлешеннән, орышыннан» дигән юллары, «Әнкәй», «Кысыр Гариф» поэмалары һ.б. шигырьләрендә күтәрелгән мәңгелек тема – сугыш һәм тынычлык темасына тагы да әйләнеп кайта. Тупланмадан «Сарай шагыйре» исемле, Н.Карамзинның «тарихи белем» бүленешенә туры килгән, романтик әсәре янә фикерләремне уятты. Тарих – төпсез кое икән. Эчтәлеге вә йөгерек өслүбе илә баллада жанры кысаларында язылган («баллада – ялан тизлек» (Н.Тихонов); С.Хәкимнең «Ибраһим Йосфи» балладасын искә төшерегез) «Сарай шагыйре» төрки-татар ханнары яннарында чәчән-шагыйрьләр тотканнар дигән риваятьне үзәккә алган. Дәүләт эшләрендә мөһим урын биләмәсәләр дә, шагыйрьләр ханның гамәлләрен хуплап, урыны-вакыты белән үтемле вә файдалы киңәшләрен дә биргәннәр. Шунда бөек драматург Туфан Миңнуллинның еш кабатлый торган гыйбарәсе искә төште: «Язучылар һава торышын үзгәртә алмасалар да, аны бозарга мөмкиннәр».

М.Мирза сарай шагыйрьләре, хан янында асыл келәмдә утырып, «балда-майда йөзеп», рәхәттә яшәгәннәр дигән имеш-мимешкә ышануы өчен борынгы каләмдәшләреннән гафу үтенә һәм шунда ук, чигенеш ясап, түрәләргә ләббәйкә җырлап көн күрүчеләр, мул тормышта яшәүчеләр хәзер дә буа буарлык дигән фикерен калкытып куя.

*Чор-заман үзгә...*
*түгел дә кебек.*
*Хакимнәр шул ук,*
*шаһ ирләр дә бит,*
*тик якынында*
*тиле, юләрләр*
*өелгәннәр ник?*

(«Сарай шагыйре»)

Шагыйрь хакимият алдында «солых яки орыш» дигән котылгысызлыкта да һәрчак солых юлларын эзләргә чакыра.

*Булыйк без түзем –*
*Илче булырга,*
*Имче булырга*
*Әзермен үзем!*

«Сарай шагыйре» балладасы белән М.Мирза поэзиябезгә өр-яңа мәүзугъ алып керә һәм, иң мөһиме, каләм иясенең тормышта, җәмгыятьтә тоткан урыны, иҗтимагый функциясе турында фикерләре белән уртаклаша. Иҗатчыга тегеләй яз, болайрак уйла, дип киңәш бирүе җитди булмаса да, бер гөманым белән уртаклашасым килә: балладаны реаль шәхесләр белән тулыландырсаң, әсәр тагын да отар иде шикелле. Әйтик, шагыйрь Мөхәммәд Әмин үз кырында чәчәннәр тоткан, шигъри бәйгеләр уздырган, ди риваятьләр. Шул дәвернең күренекле шагыйре Мөхәммәдьяр үзе, хан төрбәсендә сакчы булып кына тордым, дисә дә, сарай тирәсенә якын булуына аның Казан илчелеге составында, тылмач булып, Мәскәүгә баруы, Муром тирәсендә үтерелүе, аның гади укчы гына булмавына дәлил. Менә шул легендаларны бераз «уйнатканда», баллада күп яктан отар иде кебек. Тулаем бәяләгәндә, М.Мирзаның «Сарай шагыйре» – 2016 ел шигъри елъязмасының бер табышы.

М.Мирза соңгы елларда иҗатының яңа бер чорына кереп бара кебек. Робагыйлар белән мавыгудан арына килеп, үзен поэма, баллада кебек гомумиләштерү, холык-мөнәзләрне ачу мөмкинлеге зуррак жанрларга алынуын хупламый үтү берьяклы булыр иде. Дөрес, ул кыска шигырьдә эзләнүләрен дәвам итеп, шактый җете фикерләрен күңелләргә иңдерә.

*Дүрт йөз алтмыш дүрт ел*
*Коллык хөкемендә...*
*Адәм баласының*
*Кулында лом-көрәк*
*Туар һәр көнендә...*

«Адәм баласы»н «татар баласы» белән алыштырып кую теләге туу табигый дип саныйм.

М.Мирзаның «Хакны нахактан аерып...» бәйләмендәге шигырьләр турында сүз купкан икән, аны тулаем кабул итеп, «Иблис ихтыяры» шигыренең «Ак күлмәктәге җетелек йога ап-ак болытка» метафорасы белән сокланган тәкъдирдә, җаннан да, таштан да кан чыгарырга яраткан шагыйрьләр (эпиграфларны кара) рухында лирик затның «җир шарын» урап алган салкын шәфәкътә югалып калуы сискәндерә.

*Җәллад төскәп аткан тәнгә –*
*Ядрә ярчыклый җанын...*
*Җан күзеннән чәчрәп чыгып*
*Күлмәген манчый каны.*

Ләззәт бирергә, күңелне иркәләргә тиешле мистик юллар җанны өшетә, каз тәне чыгара. Тәнгә атылган ядрә иң гади, мантыйк буенча, канны шуннан чыгарырга тиеш иде кебек, ә ул җанны ярчыклый. Аллегорик манзараның да реаль мәгънәсе булырга тиеш. Бәлки, ялгышамдыр, мин дә бит адәм баласы гына.

## 5. Кыскалыкта – осталык

Үткән елда кыска күләмле шигырьнең активлашып китүе күзәтелә. Кечкенә мәйданда төгәлләнгән фикер әйтүгә омтылыш үзәк эстетик юнәлеш, замананың динамик тормышына җайлашу буларак, гомумиләштерү, характерлар тудыру мөмкинлеге зуррак лиро-эпик жанрларны да «кысрыклап», алгы нәүбәткә чыгуы сер түгел. Поэма уңышлары белән артык мактана алмый. Ә.Рәшитнең «Мөхәммәд» әсәрен санамаганда, ел дәвамында тыйнак күләмле бер поэма – Р.Шәриповның тормышта да, сугышта да сынатмаган абыйсы Закирга багышланган «Җомга»

(2нче сан) әсәре пәйда булды. Шагыйрь каһарманының иманлы, нурлы йөзле психологик портретын бер үзара сөйләшүдә (диалогта) күз алдына китереп бастыруга ирешә.

*– Нинди бәйрәм бүген, Закир абый?..*
*– Җомга ич!.. – ди, миңа аптырап.*

Алдарак Закир сүз алып, эчке сөйләмендә дөньяга карашының, холкының төп юнәлешен ачып бирә:

*Чукрак булдым кирәкмәгән сүзгә*
*Телсез булдым кирәк вакытта.*

Темасы татар әдәбияты өчен яңа булмаса да, Р.Шәрипов, үз вәзенен табып, абыйсына шигъри һәйкәл куйган.

2016 елда кыска шигырьдә акыл һәм каләм көчен сынап карамаган шагыйрь юктыр. Бигрәк тә дүртьюллыкларның «өлгерлегән» әйтми үтү дөреслеккә хилафлык кылу булыр. Бу өлкәдә аеруча Р.Фәйзуллин, Р.Вәлиев, Р.Низами, И.Гыйләҗев, И.Иксанова, М.Мирза һ.б. эзләнүләре игътибарга лаек. Җөмләдән, Р.Вәлиев халык мәнфәгатьләре белән яшәп, мәдәният, мәгърифәт, мәгариф үсешенә зур өлеш керткән шәхесләргә багышланган дүртьюллыклардан торган тәлгәш иҗат иткән (9нчы сан). Анда Т.Миңнуллин, М.Госманов, Ә.Кәримуллин, Х.Бигичев кебек бакыйлыкка күчкән олы шәхесләр һәркайсы үз бәясен ала. Исәннәрдән бу исемлеккә И.Таһиров кына лаек була. Дөрес, парчаларда мәгълүм стандартлык, «изгеләштерү» сизелә һәм бөекләрнең артык гомуми билге-сыйфатлары гына атала. Күңелгә сеңеп калганнары – Хәйдәр Бигичев намена багышланганы һәм «үз бакчаларына» таш аткан, ironияле «Бераз Тукайчарак» (сәяси шигырь) исемлесе.

*Гасырлардан күкрәп аваз килә,*
*Җырлый күкрәп, җырлый тын гына...*
*Бәгырендә аның Тукай рухы,*
*Аның җаны тоташ моң гына.*
(«Хәйдәр Бигичевка»)

Шагыйрь, прозаик Р.Низами 10нчы санда 20дән артык дүртьюллык тәкъдим итә. Парчаларының мәүзугълары төрле, әле генә булып узган хәл-әхвәлләргә мөнәсәбәтен белдерү белән беррәттән, элегрәк булган вакыйгалар, әдәп-әхлак, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә дә игътибарлы шагыйрь. Күптән түгел татар зиратында йөзләгән кабер ташларын вату-җимерү җәмәгатьчелекне телсез калдырды. Шагыйрь билгесез җинаятьчеләрне вандалчылар дип атый.

*Каберташны вату, җимерү өчен*
*Кирәк түгел көч тә, акыл да.*
*Сәйдәш моңнарына кизәнгәнсез –*
*Сез бит ҖИНАЯТЬЧЕ асылда.*
(«Вандалчы...»)

Сәяси мәсьәләләрне калкытып куйган дүртьюллыкларына да күзәтүчәнлек, психологик нечкәлек һәм самими лиризм хас.

*Сандугач һәм тургай моңнарының*
*Гомер озынлыгын кара син:*
*Бер киртәсез узып китә алар*
*Кыйтга белән кыйтга арасын.*
(«Гажәпләнү»)

Милләтебезнең, туган телебезнең язмышы кыл өстендә торуы, җаваплы кешеләрнең ваемсызлыгы турында ачынып язганнан соң, шагыйрь, юмор хисенә ирек биреп, шаяртып, көлеп тә ала. Мәгәр ул башкаларны рәнҗетми, читкәрәк китеп, үзен «чеметә». Бу – комизмның югары күренеше санала.

*Тукай сыман җиктереп пар ат,*
*Киттем Парнаска таба карап.*
*Кучәр сынды, арба ватылды –*
*Аh, егетләр, тәмам эш харап!*
(«Үзтәнкыйть»)

Кыска юллыкларда (ошбу фикер башка шагыйрьләрнең шул төрдәге парчаларына да карый) дистәләгән лиро-эпик әсәрләр өчен зәмин-оеткы ята.

Татар язмышы, теленең киләчәге, җаваплы кешеләрнең битарафлыгы, бердәмлек җитмәү («Килер микән соң бу татарыма Кыйтгаларда кабат яңгырау?» («Вазгыять»)) кебек борчулар бик күп шагыйрьләр, аерым алганда, 2016 елда ошбу мәүзугъны әйләнеп узмаган Җ.Сөләйман, Р.Миңнуллин, М.Мирза, Н.Әхмәдиев һ.б. шигырьләрендә төп мотивларның берсен тәшкил итә.

Чаллы, Түбән төбәкләрендә, бигрәк тә Әлмәт тарафларында «Сарай шагыйрьләре» исемен күтәрерлек, тормыш барышын, һава торышын сизеп, тоеп яшәүче, оста куллы, бай телле шагыйрьләребез аз түгел. Әлмәтлеләрдән 2016 елда К.Булатова Тукай бүләген алуга иреште. И.Гыйләҗев, Н.Әхмәдиевләр түгәрәк тормыш бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр. И.Гыйләҗев үзен кыска күләмле, тыгыз эчтәлекле шигырьдә раслады. «Халкың гаме коткарыр» (1нче сан) исемле яңа шигырьләр бәйләме – шуның ачык мисалы. Шагыйрь тормышның төрле борылышларын үзәккә алган уйларын, хисләрен җыйнак гәүдәсен хәтерләтеп торган шигырьләренә сыйдырган. Кыска, афористик юлларда ул гаҗәеп төгәллеккә ирешә. «Бимазалап йөргән уй-хисләрем Шигырь булып тиеш ачылырга! ...Кабалану кирәк, кабалану» («Матур омтылыш»).

Халык тормышын яхшы белгән гамәли эш кешесе буларак, ул ялтыравык җимнәргә алданмый, күктән йолдыз чүпләми, башка милләтләр ареолында биләгән урыныбызны белеп яши һәм «Тыелган биеклек» шигырендә бу хакта фикерен төгәл вә образлы итеп әйтеп бирә.

*Җиде катлы манара дип*
*Күз алдына китерсәк,*
*Татарларның Рәсәйдәге*
*Урыны күренер, шәт.*
*Бик сирәкләр күтәрелә*
*Дүртенчедән югары,*
*Алтынчыга менеп җиткән*
*Татар күргән юк әле...*

Биредә гарьләнү, ачыну, үпкәләү белән ирония (үзе дә шулар арасында ич) – барысы бергә укмашкан. Кемдер безнең биюче Р.Нуриев, космос галиме Р.Сәгъдиев, вулканолог Һ.Таҗиев һ.б. бөекләребез бар бит, нигә мескенләнә шагыйрьләребез, дияр. Кызганычка каршы, алар татарлыкларыннан «качып», башка милләткә хезмәт итеп кенә бер-ике баскычка өскә күтәрелә алганнар шул.

И.Гыйләҗев – реалист һәм язмышыбызны аек акыл, ачык күз белән бәяли алучы шагыйрь: «Өметләнмим, күпме тырышсак та, Җиңелгәнне җиңгән аңламас» («Шуңардан башлыйк»).

Кешеләр, бигрәк тә иҗат әһелләре арасындагы мөнәсәбәтләргә бәясендә дә ул туры сүзле булып кала:

*Әле кайчан гына, монда килсәм,*
*Йөри идек дәррәү шатланып...*

....................................................
*Бу юлысы күргәч гаҗәпләндем:*
*Салкынайган сезнең аралар.*
(«Казан шагыйрьләренә»)

Шагыйрь, бер яктан, хаклы, дөнья белән акча, шоу-бизнес идарә иткән чорда чын, ихлас дуслыкның кадере китте.

«Акча булган җирдә дуслык бетә...» дигән фаразы гына дөрес түгел. Монда мәсьәләгә Тукайча килү сорала, минем кесә ягы такырайгач, «Казан шагыйрьләре» танымый ук башладылар, дию дөреслеккә турырак килер иде.

И.Гыйләҗевның шигъри өслүбе, бер караганда, бик гади, аралашу теленә якын кебек. Ул шаккатыргыч чагыштырулар, текә метафоралар эзләмәсә дә, таныш хисләрне ачу юлларын төрләндереп, көтелмәгән борылышлар ясап, фәлсәфи нәтиҗәләргә килә. «Җитлегү юлы» шигырендә Л.Толстойның язмышын, үләр алдыннан «мине мөселман дип санагыз», дигән язуын христиан руханиларының «Чиркәүдән кит... анафема!» дип тавыш күтәрүләрен искә төшереп, мондый йомгак ясый:

*Хак дин юлын эзләп табу*
*Булмыйдыр шул җиңелләрдән...*
(«Җитлегү юлы»)

И.Гыйләҗев шигъри юлларны куплетларга аерып тормыйча, мисрагъларны шырпы тартмасына шыплап тутыргандай, тыгыз итеп, урынны исраф итмичә урнаштыра. Ул – гомерлеккә үз юнәлешен, мәүзугын, кыйбласын тапкан шагыйрь.

Әмма аның тирән тамырлары белән туган җиргә, милләтнең бәгыренә барып тоташкан иҗаты озак еллар дәвамында тиешле бәясен алмый килде. Р.Мостафин, Ф.Миңнуллин кебек профессионал тәнкыйтьчеләребез арабыздан китеп, М.Вәлиев фамилиясенә Барҗылы кушаматын өстәгәч, тынычланып калды, аның каравы Ш.Бабичның дәвамчысы, шаян шигырь (эпиграмма) остасы Р.Мәннанның дүртьюллыгына лаек булды.

*Элек Мансур Вәли идең,*
*Өстәп куйдың «Барҗылы».*
*Ярый әле булмагансың,*
*Сөбханалла, марҗалы.*

Тәнкыйтьнең битарафлыгына исе китеп, сүзнең кадерен белүче, нәзакәт-эстет шагыйрь З.Мансуров уйланып йөрде дә 2016 ел башында олуг юбилеен уздырган И.Гыйләҗев иҗаты турында «Шигырь белән ясак түләп...» (3нче сан) исемле мәкаләсе белән чыкты. Үз юнәлеше булган, шигъри осталыкның иң тирән серләрен үзләштергән милли җанлы, тыйнак И.Гыйләҗев шигърияtенә мондый мәкалә күптән язылырга тиеш иде. З.Мансуровның бәясе дә төпле, нигезле: «...шагыйрь Илдус Гыйләҗев үзенең күңеленә сеңдерелгән илаһи хасияткә тугры калды, шуның нәтиҗәсендә асылына ятышлы язу рәвешен артык көчәнмичә камилләштерә барды».

## 6. Хиссият дулкынында

Тукай елында хатын-кыз шагыйрәләребез поэзия үсешенә җитди өлеш керттеләр. Кайберләренең исемнәрен атап чыгу гына да күп нәрсә турында мәгълүмат бирә: К.Булатова, Ф.Җамалетдинова, И.Иксанова, Р.Мөхияр, Г.Әхтәмова, Ф.Солтан, Э.Җәлилова, Л.Вәлиева, Таңчулпан, Л.Гыйбадуллина, С.Якупова кебек төрле буын вә өслүб шагыйрьләре чордашыбызның рухи дөньясын, табигать ямен, буыннар арасындагы якынлыкны саклау, ата-ана, бала назы, җәмгыятьнең, милләтнең киләчәге өчен җан ату, хатын-кыз бәхете, мәхәббәт күрке белән рухланып иҗат итәләр. Төрле традициядә, жанрда, үз тормыш тәҗрибәләре белән шигъри бәйгедә катнашкан

шагыйрәләрне якынлаштырган үзәк мотивлар – гаделсезлекне, явызлыкны, кешеләрне рәнҗетүне кабул итмәү, яхшылык эшләргә, игелек кылырга чакыру. Шундый бөек идеаллардан башка шагыйрьнең хаҗәте дә юк.

*Фикерләрем ирешмәсә әгәр,*
*Уй-хисләрем килешмәсә мәгәр*
*Кешеләргә?..*
*Языйм микән? Риза булыйм микән*
*Телне-тешне кысып яшәвемә?*
*Соң нишләргә?!*

(Р.Рахман. «Бир син миңа»)

«Хатын-кыз шигърияте» дип аталган саф, игелекле, вакыты белән тозлы сулы дәрьяны тулысынча иңләү мөмкин түгел. Шуңа күрә бу бүлектә төрле юнәлештә, мәүзугъта иҗат иткән берничә исемгә генә тукталам.

Әлмәт төбәгендә яшәп, үз юнәлешен, үзәнен тапкан, укытучылар, мәктәп, димәк ки, әдәп-әхлак, буыннар арасындагы мөнәсәбәтләрне үзәккә алган, тыштан тыныч, салмак, фәлсәфи һәм «тәртәгә» тибеп алудан да тайчынып тормаган Клара Булатова 2016 елда (3нче сан) укучыга «Шигъри көзләр әле дәвам итә» дип атаган шигырьләр гөләндәмен тәкъдим итә. «Җирнең өсте ак та...», «Ялгыз Каштан», «Җәйнең соңгы ае», «Шигъри көзләр әле дәвам итә...» шигырьләрен самими лиризм, эчкерсезлек, күңелен бушату, рухи омтылыш берләштерә.

*И, Ходаем! Раббем! Сынау гынамы бу?*
*Ил иманын җуйды. Шуңа гынамы бу?*
*Кемнәр ялгышлыклар җирдә кылган өчен*
*Ник афәткә тара бер гаепсез кешең?!*

(«Җирнең өсте ак та...»)

Юлларында күпләрне тәшвишкә салган, чәчләребезне агарткан сорауларны калкытып, усалланып та куя шагыйрь. Аның шигъри бәйләмендә, нигездә, тыныч, ышанучан уйлану, табигать белән бердәмлекне тою өстенлек итә.

*Шигъри көзләр әле дәвам итә,*
*Гомер дигән юллар бар әле.*
*Җанны назга, кышны язга бәйләп*
*Калдырасы җырлар бар әле.*

Менә шундый киләчәккә өмет белән язылгын ихлас шигырьләр янында «Исемдә калган чынбарлык», «Матәм» кебекләре сугыштан соңгы елларда күргән авырлыкларны, әтисен күмү мәшәкатьләрен бәян итүләр прозаны тезмәгә күчерү булып кына кабул ителә. Бу язмаларны автор оныклары өчен күңел дәфтәрендә генә калдырса, дөресрәк буласы икән. Бөтен ил күргән авырлыклар, елау-сыктаулар турында күп яздык, күп укыдык бит инде.

*Без чынлап та үтә фәкыйрь идек,*
*Хәттин ашкан иде ярлылык.*
*Әти-әни – «детдом балалары» –*
*Әз-мәз ярдәм итә алырлык*
*Туганнары да юк...*

(«Исемдә калган чынбарлык»)

Мәктәп директоры баласына болай ук мескенләнү кирәк идеме икән?

Дөресен әйткәндә, ул чорда укытучыларны, гомумән, авыл интеллигенциясен хөкүмәт онытмады, паёкка талон өләшеп торды. «Матәм»дә иҗек саннарын бүлгәләп,

сөйләм теленә – интонацион шигырьгә охшатырга тырышу да артык уңышлы чыкмаган. Үпкәләштән булмасын, Клара ханым, әлеге тәнкыйть сүзе генә тулаем иҗатыңа уңай, җылы карашымны киметми.

К.Булатова белән бер үк санда, әле күптән түгел генә Язучылар берлегенә әгъза итеп алынган З.Захарова «Күңелдән шигырь тама» исемле шактый саллы тезмәсендә йөрәк түрендә туган хисләрен, олы дөньяга, якыннарына мөнәсәбәтен, сөю-сәгадәт, мәүзугын ачып бирердәй шәкли алымнар эзли: «Безнең арада», «Кешегә», «Ниләр булган бу көнгә?», «Булырмы сагынып калучы...»

*«Юк», – диярга ашыкмале,*
*Өзмәле өметләрне,*
*Синең җылыңа сусаган*
*Җанымны өшетмәле.*

Нәкъ «авылча», тәмле итеп сөйләшүне чагылдырган юллар, «Кешене бәхетле итәдер Ихластан әйтелгән җылы сүз» («Кешегә») кебек нисби төшенчәләрне чагылдырган юллар янында «Керәшен зары» диссонанс булып кабул ителә. Автор керәшен «националистлары» әледән-әле болгата килгән теманы күтәрә һәм шактый буталчык, караңгы почмакка китереп терәгән, аныңча, «хәйләкәр» нәтиҗәгә килә.

*Телем – татар, денем – урыс,*
*Хөрмәт татар, урыска.*
*Мөселманның кулын кыссам,*
*Күзем кысам урыска.*
(«Керәшен зары»)

Үзәк тарафыннан хупланган, болай да таркалып яшәгән татар кавемнәрен бүлгәләү, чыннан да, яшәп килгән проблеманы куерту, гади халыкны котырту, мескенләнү, зарлану яхшыга илтми. Христиан динен кабул иткән якут, чуваш кебек төркиләр, угро-финнар динне милли күрсәткеч итеп санамыйлар (аларның бер өлеше һаман мәҗүси булып калган). Ә халыкны бербөтен иткән үзәк – тел, гореф-гадәтләр, мәдәният, диләр. Зинаида сеңелкәшкә дә гасырлар дәвамында чишелешен таба алмаган проблемага кереп, ике юл чатында адашып калганчы, шигырь белән чәчмәне, илаһи нечкәлек белән урам сөйләме арасындагы чикне сиземләргә өйрәнәсе иде.

Шәхеснең рухи дөньясына, яшәеш, үзенчәлекләренә, хатын-кыз бәхетенә, сөю-сәгадәт низагларына, сөенеченә, табигать матурлыгына тиң шигъри бизәкләр тапкан шигырьләр Ф.Җамалетдинова, И.Иксанова, Р.Мөхияр, Иделбикә h.б. хатын-кыз шагыйрәләр иҗатында аз түгел (Ф.Җамалетдинова. «Җир шарына әйләнүләр телә» (7нче сан), И.Иксанова. «Гомерем фасыллары» (2нче сан)). Һәркемгә хас хисләр-уйлар төрлелеген Р.Мөхияр «Күңелемнең төрле чагы була» дигән шигъри гөләндәменең исемендә үк калкытып куя.

*Күңел бүген гел күкләрдә оча,*
*Күңел бүген былбылларны коча.*
*Күңел бүген болыт-бишекләрдә,*
*Җир өстендә гүзәл илләр кичә.*
(«Бүген күңел»)

«Сулар ага – комнар кала» (11нче сан) тупланмасында Ф.Солтан табигать күренешләрен сурәтләү аша кешенең асылын, яшәү мәгънәсен аңларга омтыла. «Сыенамын, җирем, сиңа» шигырендә янәшәлек, ягъни психологик параллелизм алымы мәһабәт наратның өскә «үрмәләвендә» кешегә хас чалымнарны калкытып куярга мөмкинлек бирә.

*Наратлар үрмәли күккә,*
*Аяк астында ылыс.*

*Нарат ылыслары кебек*
*Яшәү чәнчүле, кырыс.*

Биредә сүз уйнату, чагыштырулар остасы Сирень Якупова, өйрәнчек чорын тиз узып, җитди иҗтимагый-сәяси мәүзугъларны күтәрү сәләтен ача килгән, классик силлабик системаны тоник шигырь алымнары белән баеткан Лилия Гыйбадуллина шигырьләре дә игътибарга лаек: «Әни! Бүген белдем – Бер күз ачып йому гына Икән гомер...» (С.Якупова. «Кызганам яшь гомеремне»)[1].

Үтеп киткән елның шигъри мәҗлесендә Ф.Гыйззәтуллина, Л.Шагыйрьҗан, Э.Мөэминова, С.Гәрәева һ.б. өлкәннәребез катнашмаса да, 2016 ел шигъриятенә дәгъва белдереп булмый, бер яктан, «Казан утлары»нда һәр санәдә басылу мөмкин түгел, икенче тарафтан, «илһам уты» гел кабынып, Пегас һәр елны «сыртын» бирмәскә дә мөмкин.

## 7. Күңел догалары

Хәзерге татар шигърияте күпкырлы, киң колачлы. Сүзен өздереп, чаң сугып, халык мәнфәгатьләрен югары өслүб белән калкытып куйган, тарихилык рухы өстенлек иткән шигырь янәшәсендә тыныч, салмак, самими хисле әсәрләрнең йөрәге тибә, ягъни олы дөнья мәшәкатьләрен, зурдан купкан хыялларны бер мизгелгә булса да оныттырып торган, эчке уйлануга, үз-үзеңә хисап бирүгә, психологик күзәтүгә корылгын медитатив лирикада яши һәм үсә. Күңелнең нечкә кылларына кагылган шигырьләр, дога кебек, җанга май булып ята. Медитатив, ягъни тыныч, моңлы, эчке серләреңне «үзеңә-үзең» ачкан, күзәтүчән лирика үрнәкләрен күренекле рус, татар шагыйрьләре иҗатында күпләп таба алабыз: А.Ахматова, Б.Пастернак, О.Мандельштам, Н.Заболоцкий, Б.Ахмадуллина, үзебездә Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, М.Әгъләм, Л.Шагыйрьҗан, Ш.Җиһангирова, И.Иксанова, Р.Аймәт һ.б. 2016 елда ошбу юнәлеш үрнәкләрен барлык шагыйрьләр иҗатында диярлек табып була.

Сүз осталары үзләрен аңлауга табигать фасылларын, йөрәк серләрен, уйлануларын ачуга еш кына эчке сөйләм-монолог аша киләләр. Кайбер галимнәр ошбу юнәлешне «элитар» поэзия дип тә атыйлар. Р.Җамал «Үзем белән сөйләшәмен әле» (10нчы сан) шигъри көлтәсенә кергән «Арада юп-юка пыяла», «Безнең киләчәкләр – куе томан» һәм бер төркем кыска (4-12 юллыклар) шигырьләрендә тыныч, үз эчке дөньясын, рухи халәтен, тирәлекне аңларга, бәя бирергә омтылып яшәгән, иҗатчының үзенә, күңеленә якын (совет чорында аны авторның «рупоры» диярләр иде) лирик затны алгы нәүбәткә чыгара. Ул беркая да ашыкмый, кабаланмый, язмышына үпкәләми, ә бары тик уйларына, хисләренә бирелеп, үзен аңлау нияте белән яши. Күңелнең нечкә кылларын уяткан хисси-моңлы сүзгә халык бик мохтаҗ! Юк, ул тышкы мохит өчен ябык түгел, мәгәр дөнья мәшәкатьләренә йөрәк серләрен, җан ярсуын ачу аша килә. Бу – медитатив лириканың дәреслекләрдә тәкъдим итәрлек үрнәге.

*Үзем белән сөйләшәмен әле,*
*Шыпырт кына, тып-тын, килешеп.*
*Кайвакытта нидер пышылдый күк*
*Талгын гына җылы җил исеп.*
(«Үзем белән сөйләшәмен әле»)

«Уйлар, уйлар... Кайчак алар – тып-тын Җәйрәп аккан елга агымы», дип, шагыйрь иң тирән серләре белән уртаклаша: Әнисенә сабыйларча мөнәсәбәте, җитлеккән, дөнья күргән ирләрчә, хатын-кыз матурлыгына мөкиббән китүе хакында ачыктан-ачык бәян итә.

Р.Җамал бик әһәмиятсез күренгән вакыйгада да олы мәгънә орлыгы таба. «Мәҗнүн» сөеклесенең бүлмәсендә ут кабынганны көтә, ә кыз караңгыда «өзелеп егетне күзәтә».

[1] «Казан утлары»нда (1нче сан) Д.Заһидуллина «Чаллы шагыйрьләренең иҗат үзенчәлекләре» мәкаләсендә С.Якупова, Л.Гыйбадуллина, Р.Мөхияр турында шактый тулы мәгълүмат бирә.

Гашыйкларны кавыштырмаган «гаепле» дә табыла: «Көтәләр йөрәкләр бер-берсен – Арада юп-юка пыяла». Икенче шигырьдә арадашчы «локаль» образ буларак томан алына һәм кичереш шуңа бәйле рәвештә «туарыла». «Безнең киләчәкләр – куе томан... Ул томанда бәхет бар сыман». Бөтен кеше зарланганда, кемне дә булса гаепләп сүккәндә, Р.Җамалның каһарманы дәшми, тик елмая, чөнки аның уңышсызлыгы – бары аның гаебе. Күрәсез, Р.Җамалның бар кешегә дә яхшылык, күңел тынычлыгы теләгән, шуның өчен җанын бирергә әзер каһарманы матурлыкны үз җанында, уй-хисләрендә таба һәм яшәеш фәлсәфәсенең мәнәзен шунда күрә.

*Шушы җирдә биргән тормыш өчен*
*Рәхмәтлемен насыйп язмышка!*
(«Тирә-якта бар да зарланыша...»)

Г.Мөхәммәтшин «Унсигездә», «Юлчыга», «Шушма» (10нчы сан) кебек лиризм тирән агым булып саркыган шигырьләрендә «Ак сакалым – ак намусым үзем белән һаман да», дип, туган җирендә, табигать кочагында, яраткан кешесе янында узган гомерен олылый һәм бар кешегә бәхет теләп, талгын тынычлык дулкынында «йөзә». Каударланмыйча гына үз-үзе алдында, намусы каршында хисап тота.

*Һәр чибәргә гашыйк булам,*
*Сабый күрсәм елмаям,*
*Гел игелек, гел могҗиза*
*Көтеп яшим дөньядан.*
(«Унсигездә»)

Яшәештә гашыйклык чоры да уза, тормыш ваклыкларына кереп, югалып калган чаклар да була.

*Иртән торам да кушылам*
*Тормыш чынбарлыгына,*
*Шикләнсәм дә вакыт-вакыт*
*Ерып чыгарлыгыма.*
(«Иртән торам да кушылам...»)

Медидатив лириканың үзенчәлекле чагылышын Р.Харисның «Тәрәз каршындагы юкәләр» бәйләмендә (5нче сан) таптым. Ихлас әсәр язу өчен фәләненче еллардагы кебек завод-фабрикаларга, кырларга чыгып йөрисе дә юк икән. Тирә-юньне аңлау, күзәтү һәм, чакмадан ут үрләткән шикелле, маңгай һәм күңел күзең күргәнне хисси дөньяң аша уздырып, Ходай биргән сәләтеңне уята алсаң һәм шигырь серләрен белсәң, «юллар» үз үлчәмнәрен, сурәтләү байлыкларын «сайлап» алалар. Табигатьнең һәр күзәнәгендә, чәчәкнең «күз ачып йомуында» югары шигърият саклана имди.

«Тәрәз каршында юкәләр» гөләндәме язылуының нигез сәбәбен дә чамалыйм. Шагыйрь чиратын уздырып, кыска вакытка гына чирләп алды. Күрәсең, җегәре ташып торган Р.Харис урамга яисә мәдәният эшләре белән читкә чыгып йөри алмаганда, тәрәзәдән йортта үсеп утырган юкәләрне игътибар үзәгендә тоткан, шул «аралашу» уяткан хисләр дулкынында мәхәббәт маҗараларын янәдән кичереп утыргандыр, дип фаразлыйм. «Баллы яңгыр»шигырендә бу хакта үзе дә «тәмләп» искә ала:

*Искә төште юкә аллеясы:*
*аягыбыз балга ябышты;*
*балга басып, баллы һава сулап,*
*балдай татлы итеп кавыштык...*
(«Баллы яңгыр»)

Әледән-әле кабатлана килгән «баллы яңгыр» гыйбарәсе, мәхәббәт күрке, шәхес

язмышы, яшәеш фәлсәфәсе символы дәрәҗәсенә күтәрелеп, лирик каһарманның хис-кичереш дөньясын ачуга буйсына.

«Юкә балы» образы «Яшел яфрак аша» шигырендә, сары төскә кереп, гомер агышын, талгын сагышны сурәтләүгә буйсына.

*Тәрәз каршындагы юкәләрдән*
*әле генә сары бал тамды...*
*Бүген – сары яфрак!..*
*Гомер оча!..*
*Тизлегенә аның таң калдым...*
(«Яшел яфрак аша»)

Сизәсезме, бик күп мактаулы дәрәҗәләр алган шагыйрьдә гомернең кыска булуына, тиз үтүенә исе китеп, шигырь дилбегәсен дә беразга кулдан «ычкындырып», юлларны бүлгәли, сүзләр үзләре, мисрагътан «очып чыгып», мөстәкыйльлек таләп итәләр. Шагыйрь, хисләр дулкынына бирелеп, йомшарып китүеннән оялып, чираттагы шигырен: «Мин курыкмыйм... Башны учка салып, кыш турында уйлап утырам», ди. Ә уе «Искә төшә иртә киткән дуслар, җимеш булмый калган өметләр...» хакында икән («Көзге яшел яфрак»). «Табигатьнең Морзе әлифбасы», «Карт бер ала карга», «Әллә нишләде дөньялар», «Ятьмә кебек ботаклар» шигырьләре табигать белән кешенең бердәмлеге турында.

Табигатьнең һәр фасылы, күренеше, детале кеше кылган гамәлләрне кабатлый, һәрхәлдә шуңа омтыла дигән тәэсир туа «Ятьмә кебек ботаклар» шигырен укыганда.

*Кара җептән үргән ятьмә кебек*
*ботакларын җәеп, юкәләр,*
*тәрәзәмә карап, нәрсәнедер*
*эләктермәк булып көтәләр...*

Иң соңыннан лирик герой яз кошларын безнең якка чакырып хат җибәрүен хәбәр итә. Гади күзәтүне катлаулы метафора, четерекле күчешләр эзләп тормыйча, каушамыйча, ашыкмыйча гына, кәгазьгә төшерә. Олы проблема да, каударлану да юк. Ә җан ял итә, табигать (шәһәрнеке булса да) кочагында иркәләнә.

Шагыйрь дә адәм баласы, ул гомер бакый бер дукында, дошман көткән керпе кебек, энәләрен тырпайтып кына яши алмый.

Р.Вәлиевнең «Моңлы ядкарь», «Тик минеке», «Көз», «Авылга кайту» кебек шигырьләрендә талгын, кешелекле моң, үткәндәге үрләрне сагыну һәм үз эчке дөньясын тирәнрәк аңларга омтылыш өстенлек итә.

*Күңелемә кайгы-сагыш төшсә,*
*Ак чәчәкләр җирдә эзләдем.*
*Офыкларга карап көтә торгач,*
*Сагышларга мандым күзләрем.*
(«Тик минеке»)

«Көз» шигырендә рухи халәтне табигать күренешләре, янәшәлек психологизмы ярдәмендә ачу, самими, ихлас беркатлылык укучыны битараф калдыра алмас дип уйлыйм.

*Кабат кайтмас яфракларын сагынып,*
*Бар агачлар ятып елады.*
*Агачларга кушылып мин еладым,*
*Сагындым да үткән елларны.*

*Урамнарда йөрдем дәрвиш кебек...*
*Ай урамда йөзә, ай арган.*

*Боз астында катып калыр кебек...*
*Айны кудым пычрак сулардан.*
(«Күз»)

Минемчә, ай образын җанлы итеп сурәтләгән, аны кызганып, пычрак судан арындырган символик мәгънәле шигырь юк иде кебек.

Эчтәлекләре, сурәтле фикерләү үзенчәлекләре буенча әлегә иң җитлеккән ихлас шигырьләр бәйләмен («Гомерем фасыллары» (2нче сан)) И.Иксанова Тукай елына саклап тоткан дигән тәэсир туды күңелемдә. Ул – тыныч, талгын, салмак лирика тарафдары. Медитатив юнәлеш шул ук вакытта аның эзләнүләрендә үзенчәлекле чагылышын таба. И.Иксанова шәхси кичерешләре, рухи дөньясы турында язса да, әйләнә-тирә, олы мохит мәшәкатьләре, якын шәхесләре («Әни», «Тукайга») турында да оныта алмый.

*Юккамыни синең әрнүләрең*
*Бәгыремдә минем сулкылдый.*
(«Тукайга»)

Татар халкы кичергән, әле дә дәвам иткән XXI гасыр фаҗигасен ул, табигать сурәтенә (ялган фасылына) таянып, берничә юлга сыйдыра.

*Гыйнвар.*
*Агачлар бөредә.*
*Ымсынып саташу бу бары.*
*...Хәтердә яңарды милләтнең*
*«Яз!» диеп алданган еллары.*
(«Алдану»)

«Җәйге этюдлар» тупланмасында И.Иксанова кешегә хас кичерешләрне, хәтта үзара аралашуларны да табигать тормышында күрә.

*Башаклар серкә очыра, –*
*Кыр өсте – яшькелт рәшә.*
*Тын гына,*
*Тибрәлеп кенә*
*Җир белән күк сөйләшә...*

«Җир белән күк сөйләшкән» мизгелдә 2016 ел – Тукай елы – сиздермичә генә «шигъри таякчыкны» 2017 елга тапшыра. Уңышлар телик аңа! Синең белән дә исән-сау күрешергә язсын!

***

Исемгә чыгарылган «Шигырь эзлим» гыйбарәсенә аңлатма бирергә вакыт җитте кебек. Мине «котыртучы» шәхес мөхтәрәм Гаяз Исхакый булды. Үз мөхәррирлегендә чыккан «Таң йолдызы» гәҗитәсенә килгән тезмә әсәрләрне өйрәнеп чыкканнан соң, ул мондый нәтиҗәгә килә: «Шигырьләр күп, ә шагыйрь юк». Шул чорда аның янәшәсендә Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиев, Сүнчәләй йолдызлыклары балкый, ә әдип һаман канәгать түгел. Аның күбрәк башлап язучыларны, үзешчәннәрне күздә тотуын аңлаган тәкъдирдә дә, остаз белән килешүе кыен. Мин исә 2016 ел шигъриятен аркылыга-буйга укып, мием аша уздырып чыккач, милләт гаме, аның кайгы-хәсрәте, шатлыгы, үткәне, хәзергесе, киләчәге белән яшәгән бер илаһи зат таптым. Аның исеме – 2016 ел татар ШИГЪРИЯТЕ.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# ШАГЫЙРЬЛӘР СОЛТАНЫ

Татар мәдәнияте үсешендә сизелерлек эз калдыручы һәм киңкатлау милләттәшләребезгә яхшы билгеле шәхесләр арасында шагыйрь һәм тел галиме Мостафа Ногман да бар. Әллә җырларын көн дә тыңлап һәм җырлап үскәнгә, аны хәтта якыннан, күреп беләмдер кебек. Җитмәсә, әле үсмер чагымда – Арча педучилищесында укыганда, улы Айдар Мостафович каршыма килсә, шагыйрьнең үзен күргәндәй исәнгерәп китә идем, чөнки ул да әтисе кебек зыялы, гаять чибәр һәм зәвык белән киенгән булыр, янына җиткәч, башын ия төшеп, гүзәл бер елмаю белән балкып, шул рәвешчә бик зур итагатьлек күрсәтеп исәнләшер яисә сәламеңне алыр. Моннан тыш талантлы музыка белгече, таләпчән мөгаллим буларак та истә калган. Галимнәр, балаларда талант йоклый дисә дә, ялгыша шул.

Яшьлегендә күңеле көйгә-моңга тарткан Мостафа Ногман хакында да йә көйче, йә опера җырчысы булыр дип хөкем йөрткәннәр. Ул әнә фән һәм шигърият юлыннан киткән. Әлбәттә, аңа музыкаль тоемы шул юлда югары күтәрелергә, өйрәнгән проблемаларын чишәргә бик нык ярдәм иткән. Хәзер менә күңелдә яшьлектән сакланып калган җырларны искә төшереп утырам да, аларны, нигездә, М.Ногман белән Р.Яхин язган икәнлегенә таң калам. Ник берсенең көе һәм сүзе онытылсын! «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Бөдрә таллар», «Киек казлар китә»... кебек җыр һәм романслар булган ул. Отряд яисә дружина белән машина арбасына утырыпмы, җәяүләпме, нинди генә ерак һәм якын араларга чыгып китсәк тә, алар иҗат иткән иҗтимагый-сәяси, гражданлык җырларын җырлаганбыз икән. Бергәләп ял иткәндә, һәркемгә туган ягын күз алдына китерткән яисә сөю турында уйга салганнарны көйләгәнбез.

Мостафа Ногман улы Ногманов бүген күз алдыма шактый катлаулы гасырны ничектер исән-имин кичә алган, хәтта совет илендә уңышларга да ирешкән бәхетле кеше буларак килә. 1912 елның 22 декабрендә Татарстанның Арча районы Кызыл Яр авылында сәүдә белән дә шөгыльләнүче хәлле крестьян гаиләсендә туган ул. Димәк, чорына күрә дөньяны аңларлыгы, танып күрерлеге, җитәрлек белем алырлыгы булган. Ә элек иң белемле кеше, әлбәттә, укытучылык һөнәрен сайлаган, үзе белгәнне башкаларга да өйрәтергә тиеш дип санаган. М.Ногман да шулай уйлагандыр. Ул 1931 елда Казан педагогия техникумын тәмамлый.

Әлбәттә, совет илендә укытучылык эше сәясәттән аерыла алмаган, мәктәпләргә ил идеологиясенә хезмәт итүче генә кирәк булган. М.Ногман да берничә ел Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә укыткач, 1935-1937 елларда Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда секретарь булып эшли. Минем уйлавымча, елларын исәпкә алсаң, эш-хәлләрне теркәп утырганда гына да, кешене рухи сындыра торган коточкыч хезмәт! Моннан соң җыр язу түгел, яшисең дә килмәс. Ул әнә шуңа күрә дә кире педагоглык эшчәнлегенә күчәргә тырышадыр – 1937-1941 елларда Дүшәмбе дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Шул арада, кызганыч ки, ил тарихында яңа бер фаҗигале этап башлана.

М.Ногман сугыштан соң гыйльми эшчәнлекне журналистлык һәм укытучылыктан алгырак планга куя. Бигрәк тә 1947-1951 елларда Мәскәү Көнчыгышны өйрәнү институтын һәм соңрак Казанда аспирантура тәмамлагач, фәнгә тирән кереп китә. Узган гасырларда төзелгән сүзлекләрне өйрәнәме, Н.Лобачевский исемендәге китапханәдә Көнчыгыш кульязмаларын барлау-тикшерү, тасвирламаларын төзү белән шөгыльләнәме, студентларга фарсы һәм борынгы татар телен укытамы – зур тарихлы поэзиябез аның төп тикшерү чыганагы булып кала. Шул өйрәнүләр нәтиҗәсендә, традицион татар поэзиясенең нинди камил икәнлеген аңлый, ул ирешкән уңышлардан этәрелеп иҗат итә.

М.Ногманның беренче әсәрләре үк, Тукайныкы кебек, чор хроникасын тудыру рухында була («Давыллы еллар лирикасы», 1944). М.Ногман поэзиясендә башта сәяси лирика калкурак булса да, соңыннан ул җыр жанрына күчә һәм гади халыкта аеруча шушы өлкәдә таныла. Әлбәттә, шагыйрь бу вакытта да заман модаларын, чор ихтыяҗын нык исәпкә ала. Аның Татарстан районнары, авыллары турындагы

«Актаныш таңнары», «Балкый Шәйморза утлары», «Арча кичләре» кебек җырлары, көйләрен күбесенчә С.Садыйкова иҗат иткәч, чит төбәк кешеләре өчен дә якын була.

М.Ногман иҗатында аерым шәхесләрне ачкан, дус илләргә багышланган җырлар да шактый урын тота. Гомере буена ил сәясәтен данлаган әсәрләр язучы кеше, Тукай кебек, халык проблемаларын күтәргән, аның тормышын тасвирлаган, идарәче катламнарга каршы як позициядә торучыны кабул итмәскә, иҗатын данламаска да тиеш кебек. М.Ногман исә яшьлегендә үк Тукай поэзиясендә халык сәнгате уңышларын да, шәхси табышларны да тотып алган, боларның ни дәрәҗәдә кыйммәтле икәнлеген дә бәяләгән.

М.Ногман мирасханәсендә Тукайга багышланган әсәрләр берничә. Шуларның иң билгелесе, бүгенге көндә мәктәпләрдә күп чараларда кулланылганы – «Апрель таңы». Аңа Р.Яхин көй язмаса да, башка бер композитор күреп алган булыр иде, чөнки шигырь сыйфатында да бик ритмик һәм көйле яңгырый. Ул «Апрель таңы» дип язылган башка күпсанлы шигырьләр арасында теләсә кемнең күңелен кузгатып җибәрә алырлык отышлы яңгырашлысы гына түгел, барча кешегә бердәй аңлаешлысыдыр да. Мин үзем, «Апрель таңы» җырын тыңлаганда, инде Ленин туган көнне түгел, Тукайны дөньяга биргән айны күзаллый башладым.

*«Бик ерактан сызылып аткан / Бер гүзәл апрель таңы / Бирде сине бу җиһанга / Әй, шагыйрьләр солтаны!»* – дип башланган әлеге әсәр Г.Тукайны шагыйрьлек баскычының иң югары биеклегенә күтәрә. Ул аның иҗатыннан *«Азмы какканны вә сукканны / Күтәрдең, син – ятим / Җырладың шуңа халкыңның / Моң тулы хиссиятен»* һәм башка киң билгеле кайбер цитаталарны трансформацияләү юлы белән иҗат ителгән.

М.Ногман текстыннан Тукай әсәрләренең мелодиясе, ритмы, шигъри үлчәме, иң мөһиме – лексик катламы һәркемгә ачык тоемлана. Автор, Тукай белән диалог коргандай, риторик рәвештә куйган сорауларына җавап биргәндәй яза. Әгәр Тукай «Өзелгән өмид»тә үкенечле рәвештә: *«И мөкаддәс моңлы сазым! / Уйнадың син ник бик аз?»* – дисә, М.Ногман аңа каршы зур горурлык белән һәм бер үк вакытта каләмдәшен юаткандай, күңелен үсендергәндәй: *«Тынмый сазың, моңлы сазың, / Кем тыя алсын аны?! / Син яшәрсең, мең яшәрсең, / Син – шагыйрьләр солтаны!»* – дип белдерә. Ә бит бу сүз авторның үзенә карата да әйтелә ала икән.

М.Ногманның Тукайга мөнәсәбәтле икенче атаклы ядкаре – «Иделләр буйлап» циклына кергән «Тукай пароходында» шигыре («Таң йолдызы»). Анда борынгыда булган хәл – Тукайның Уфага баруы һәм яр буена аны каршыларга М.Гафуриның килүе җанландырыла. М.Ногманның әлеге әсәрне иҗат итүенә, шул вакыйгадан соң озак еллар узгач, лирик геройның нәкъ менә «Тукай» пароходында Агыйделгә йөзеп керергә, Тукай узган юлны үз күзе белән күрергә теләве, ә юлчыларны портта «Гафури» пароходының каршы алуы сәбәп булып тора.

Циклның чираттагы шигыре «Күптән-күптән...»дә исә Г.Тукайның Кырлайдагы кечкенә вакыты, шигырьләрендә чагылыш тапкан кайбер мизгелләр, шул исәптән балаларның яңгыр явып узганнан соңгы уеннары тасвирлана. Габдулла иптәш малайлары белән чабыша, гөрләвектә көймә агыза. Автор кечкенә Апуш агызган көймәчек детален аның исемен йөрткән зәңгәр пароход образына китереп тоташтыра. Әлеге әсәр «Акчарлаклар оча Иделдә» китабына «Зәңгәр пароход» исеме белән кергән дә.

М.Ногман хәрәкәттәге армиядә вакытта язган «Илһам чишмәсе»нә эпиграф сыйфатында Г.Тукайның «Мәхәббәт» әсәренең тәүге юлларын куя, әмма аның илһам чыганагы хакындагы фикерен заман шартларына, сугыш вакыйгаларына бәйле үзгәртә – чын шагыйрь өчен солдат булу, дошманны җиңү, юк итүнең дә иҗатка теләк тудыра алуын күрсәтә. Бу текстта Тукай һәм Такташ иҗатына хас стиль, алар иҗатында яңгыраган кайбер фикерләр бергә үрелгәндәй.

Г.Тукай исемен халык күңелендә мәңгеләштерү проблемасы М.Ногманның «Һәйкәл янында» әсәрендә дә чишелә. Алай да язмамны яңадан «Апрель таңы»на әйләнеп кайтып тәмамлыйсым килә. Әлеге әсәр җыр сыйфатында «Тынмый моңлы сазың» дип теркәлгән. Шуның соңгы юллары күңелне гел айкатып тора сыман: *«Тынмый сазың, моңлы сазың, / Кем тыя алсын аны! / Син яшәрсең, мең яшәрсең, / Син – шагыйрьләр солтаны»*.

**Рифә РАХМАН**

# ПАР ГЫНА КҮКЕЛӘР ЧАКЫРГАНДА...

Халык санын соңгы исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, Татарстаныбыздан, Башкортстан Республикасы һәм Төмән өлкәләреннән кала, Чиләбе өлкәсе – татарлар күпләп яши торган төбәкләр исемлегендә. Биредә гомер итүче халыкның 5,4%ы үзен татар милләтеннән дип саный, бу сан аларның монда күпчелекне тәшкил иткән милләтләр арасында икенче урында булуларын күрсәтә. Әле нагайбәк дип язылган туганайларның рәсми төстә татарлар исәбенә кермәгәнен истә тотсак, биредәге милләттәшләребезнең саны тагын да арта. Шуңа да Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы фәнни экспедицияләрнең берсе нәкъ менә Чиләбе өлкәсенә булу бер дә очраклы хәл түгел. Институтыбыз – татарларны һәрьяклап фәнни өйрәнә торган академик оешма, Чиләбе өлкәсе татарлары белән кызыксыну тел, халык иҗаты, тарих, археография, сәнгать белгечләрен бергә туплады.

Экспедициянең җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты Илмир Ямалтдинов, белгечләрдән телче, филология фәннәре докторы Флёра Баязитова, фольклорчы, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова, сәнгать белгече Людмила Шкляева, археограф Айгөл Әхмәтова – комплекслы экспедиция әлеге составта эшләде, татар авыллары буйлап безне институтыбыз автобусында Наил абый Шәрәфетдинов йөртте.

Биредә табигать искиткеч! Ул җиләк, җәнлек, кош-корт тулы калын урманнар, төп-төз купшы наратлар, күкрәп үсеп утырган очлы башлы мәгърур чыршылар, бөдрә каеннар, кыя-ташлар, Җаек елгасы үзе, җәелеп аккан Өфе, Нәзе, Ураим, Гөмбәй һ.б. эреле-ваклы матур елгалар, Кондыравы, Чибәркүл кебек зур-зур күлләр – болар бар да борынгы әби-бабаларыбызның Көньяк Уралны үз итүләре нигезендә зур хикмәт ятуы хакында сөйли. Кайчандыр көчле булган шул төрки бабаларыбыз, шуңа да яшәү өчен иң гүзәл, иң уңайлы урыннарны сайлый белгәннәр.

Бу тирәләрдә татарлар турында тарихта иң беренче мәгълүматлар XI гасырга ук барып тоташа. Шул чордагы фарсы галиме Әл-Гардизи Көньяк Урал территориясенең, шул исәптән бүгенге Чиләбе өлкәсенә карый торган җирләрнең урта гасыр төрки дәүләтләренең берсе – Кимак каганлыгына керүе хакында язып калдырган. Кимак каганлыгы составына җиде үзара якын кардәш кабилә кергән, шулар арсында Татар һәм Кыпчак кабиләләре дигән исем белән билгелеләре дә булган. Татарлар каганатта идарә итүче йорт исәбендә торганнар[1], каганлыкның көнбатышын, ягъни хәзерге Чиләбе өлкәсе урнашкан территорияне биләгәннәр. XIV йөз тарихчысы Ибн-Халдун шулай ук кыпчаклар арасында татарларның аерым этногенетик тармак тәшкил итүләре турында яза.

Татар этносы ныгып формалашу чорында Чиләбе өлкәсе җирләре данлы һәм шанлы татар дәүләте – Алтын Урда территориясе булган, биредә батырлар дан алган, нигезләр корылган, төрки нәсел дәвам иткән... Алтын Урда чорында хәзер Чиләбе өлкәсенә керә торган җирләрнең көньяк өлешеннән кәрван сәүдә юллары үткән, бу исә җирле татарларның әле урта гасырларда ук сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрендә актив катнашуы турында сөйли. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсендә Алтын Урда чоры кайтавазы булып татар шәһәрлекләре, «Тамерлан манарасы» исеме белән билгеле һ.б. борынгы төрбәләрнең табылып торуы, әлеге төрбәләрнең төзелеш архитектурасы, төзүдә кулланылган материаллары, бигрәк тә квадрат формалы «татар кирпече» һ.б. – болар бар да татар культурасы эзләре, элгәрләребез тормышының урта гасырлар катламына карый торган ядкарьләре.

Алтын Урда таркалгач, бу җирләрнең төньяк өлеше – Себер ханлыгына, көньяк

[1] Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI – первой четверти XV века. – Казань: Иман, 2000. – 136 с.

өлеше Нугай Урдасына керә[2]. Чиләбе туфрагының, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, ханлыктан көнчыгышка таба качып китәргә мәҗбүр булган кан-кардәшләребезне сыендырган урын икәнлеге дә мәгълүм. Себер ханлыгы алынганнан соң, XVII йөздә бу территорияләр татар административ идарәсенә әверелә, рус дәүләте колонизацияләгән җир буларак, йомышлы татарлар урнашып эшли торган биләмәне тәшкил итә. Мәсәлән, Алексей Иванович Тәвкилев исеме белән патша хезмәтендә полковник дәрәҗәсендә йөргән Котлымөхәммәд исемле татарның биредә Миасс, Чиләбе, Чибәркүл һ.б. ныгытмалар салдыруда зур роль уйнавы билгеле. Бу ныгытмаларда исә татар казаклы отрядлары хезмәт иткән. Соңгырак чорда – XIX-XX йөзләрдә – Чиләбе җирләренә Оренбург, Уфа губерналарыннан татар мигрантлары агыла, алар да, биредә төпләнеп гомер итәргә дип, Урал итәгенә утырып кала.

Димәк, биредә татарларның тупланып яшәүләре әле мең еллык тарихка ук барып тоташа икән. Ун гасырны эченә алган төрки тарихлы җирләр булуында шик юк Чиләбе өлкәсенең. Без биредә һич кенә дә килмешәк түгелбез, без биредә – җирле халык. Сакланып калган матди һәм матди булмаган мәдәният үрнәкләре арасында монда яшәүче татарларның бик борынгы төрки тамырларын раслый торган кыйммәтләр, чыннан да, күп.

Чал гасырлардан бирле биредә күпме сулар аккан...

Казаннан ала шактый ерак юл аша безне бирегә китергән максатыбызны тормышка ашыру Нязепетровск районыннан башланып китте. Биредә Нәзенең үзендә (Нәзе елгасы буендагы Нязепетровскны татарлар шул исем белән атый), татар авылларында – Арыслан, Әптерәк, Йосып, Постниково, Чулпанда булдык, андагы милләттәшләребез белән аралаштык. Халык ачык күңелле, ипи-тоз, чәкчәк, җыр-моң белән каршы ала, безнең белән бик теләп сөйләшә, Казан турында сораша, күңел хәзинәләре белән бик җиңелдән уртаклаша.

Алдан ук уйланылган маршрут буенча юл тотабыз, җыясы ризыгыбыз безне Чибәркүл районына алып килде. Биредә Варламово авыл җирлегенә карый торган Попово авылында нугайбәкләр яши. Эчкерсез, гади, җыр-моңга, төрле йолаларга бай да соң керәшеннәребез! Попово, Бишкил авылларында эшләдек биредә. Уй районына керә торган Әмин авылына тукталып, андагы халык белән дә аралаштык. Шулай экспедициядә йөри торгач, хәтта Парижга чаклы барып җиттек. Нугайбәк районында шундый исемдәге авыл бар. Эйфель манарасыз нинди Париж булсын, диптер инде, шуңа охшаш биек каланча да корып куйганнар авыл уртасына. Бу районда Париждан тыш Кассиль (татарчасы – Кили), Остроленко (Сарашлы) авылларында да булдык. Өчесе дә зур-зур авыллар, боларда нугайбәк керәшеннәре яши.

Барыбызга да билгеле: бүген – фән-техника заманы, шулай ук халкыбызның кабат исламга, китапка, уку-гыйлем эстәүгә кайтып барган бер чоры. Бу галәмәтләр никадәр генә алгарыш булып саналса да, нәкъ менә шушы алгарышның күңел сандыкларына яшерелгән тел-авыз иҗаты истәлекләренә урынны шактый тарайта төшкән булуы гаҗәп түгел. Моңа әле гади халыкның яшәү шартлары бер генә дә ал да гөл булып тормау да өстәлә... Шушындый табигый шартларда Чиләбе өлкәсендә көн күреп ятучы милләттәшләребездә фольклорның торышы ничек соң? Мәгърур тарихыбызны барлый-барлый, бүгенгегә таба килеп, шушы сорауга җавап эзләдем мин, Чиләбе өлкәсе татар авылларында экспедициядә йөргәндә. Милләттәшләрем язмышын, биредә телебезнең, традицияләребезнең яшәү-торышын күзәтүләрем, бер яктан, куанычлы уйлар тудырса, икенче яктан, бик нык борчыды да. Булган рухи хәзинәләребезне туплап калырга әле өлгерәбез, җор телле халкыбыз, татарча сөйләшә торган әби-апаларыбыз, абыйларыбыз исән-сау әлегә. Монысы өчен шөкер диярга була. Тагын биш, ун, егерме елдан болары да табылмас кебек. Яшь буын, мәктәп балалары белән әңгәмә корып карыйм, яшерен-батырын түгел – он суы да, тоз суы да юк.

– Тукайны беләсеңме?

– ...

– «Су анасы»н да укыганың юкмыни?

– ...

Күрәм: татарча биргән сорауларымны аңлый бала, әмма ни татарча, ни русча җавап

[2] Долгих Б.О. Родовой и племенной состав народов Сибири в XVII веке. – М., 1960. – С.62.

бирергә фикере юк. Бер дә булмагач, «Су анасы»н үзем сөйләп киттем. Тарак, басма кебек сүзләрне русча аңлатып барам, юкса ни турында сүз барганын аңламый.

– Бу әкиятне ишеткәнең бармы? – дип аптыратам баланы, «Су анасы»н сөйли-сөйли. Малайга унбер яшь. Шулай азаплый торгач, ачылып китте бу:

– А! Это тот, кто расчёску украл, а тот его прищемил!

«Прищемил»ы бөтенләй башка әсәрдән булмаса, җавапны ничек тә кабул иткән булыр идем. Булмады.

– Син татармы?

– Татар.

– Татар шагыйрьләреннән кемне беләсең соң?

– ...

– «Су анасы»н, «Шүрәле»не кем язган?

Бу соравыма каршы, бераз уйлап торганнан соң, малай кычкырып әйтеп салды:

– А-а! Этот – Пушкин!!!

Яшь буын вәкилләре белән әлеге әңгәмәнең урыс катыш авылда түгел, ә саф татар авылында – Әптерәктә булуы кәефне кырды. Яхшырак нәтиҗә көткән идем, ник дигәндә, боларның ата-ана, әби-бабалары шуның кадәр матур итеп үз телебездә сөйли торган буын бит әле, аларыннан дөнья кадәр фольклор материалы язып алуга ирештем. Ә балалары – менә шундый. Тел белмәүләре турында әйтмим дә инде, милли мәдәнияткә игътибарлары һәм, гомумән, ихтыяҗлары күренми яшь буынның... Монысы бик аяныч. Бер-ике дистә елдан: «Бу җирләрдә элек үз телендә сөйли белгән татарлар яшәгән, кыз алып, кыз биргәннәр, татар-башкорт катнашып, никах туйлары уздырганнар, мулла чакырып, балаларына татар исемнәре кушканнар, бакыйлыкка күчкәндә, мәетне ислам кушканча җирли торган булганнар», – дип, үткән заманда сөйләргә калырмыни? Турысын әйткәндә, бик ихтимал.

Бу җәһәттән караганда, башларына «Сез – татар түгел, ә нугайбәкләр – төрки телле аерым бер халык, телегез дә нугайбәк теле» дигән фикер нygытып сеңдерелгән, Россия законы белән рәсми төстә аз санлы халыклар исәбенә кергән, «Нагайбакща – русща, русща – нагайбакща» сүзлекләренә кадәр төзеп бастырылган, чынлыкта гомумтатар халкының керәшен этник төркеменә карый торган туганайларның да хәлләре әллә ни шәптән дип әйтеп булмый. Нугайбәкләр рәсми рәвештә татар дип саналмыйлар, шуңа да аларның балаларына мәктәпләрдә татар теле укытылмый, аңа карап нугайбәк теле дә өйрәтелми, нәтиҗәдә яшь буын ана телләрен өйрәнүдән бөтенләй үк мәхрүм. Татарның электән үткәрелеп килгән Сабан туе да уздырылмый икән хәзер нугайбәкләрдә. Ник дигәндә, татарлар яшәмәгән авылда милли бәйрәм уздырып яту бөтенләй дә шарт түгел ләбаса! Нугайбәкләрнең нугайбәк булуыннан, татарларның татар булып азрак күренүеннән кем ота да кем оттыра? Уйласаң, уй бар монда. Ә менә Республикабызның Мамадыш районы Җөри авылында ел саен уздырыла торган атаклы Питрауны Чиләбе өлкәсе керәшеннәре белә һәм бик ярата. Мамадышның якты данын Уралга барып ишетү минем өчен бик күңелле булды.

Тупланган фольклор материаллары арасында иң зур күпчелекне авылның килеп чыгышына багышланган тарихи, урман-таулар исемен аңлатуга корылган топонимик риваятьләр, бу төбәккә генә хас үзенчәлекләре булган календарь һәм көнкүреш йолалары, милли уеннар, уен-бию җырлары, йөрәккә үтеп керә торган моңлы да, шаян да керәшен җырулары, җен-зәхмәтләр турында мифологик хикәятләр тәшкил итә, моңа кадәр ишетелмәгән табышмаклар, берән-сәрән генә булса да әкият сөйләүче дә очрап куя хәтта. 12 көн буе дәвам иткән экспедициядә җыелган тел-авыз байлыгы хәзинәсендә ни бар – шулардан кайберләрен игътибарыгызга тәкъдим итәм. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсендә гомер сөрүче милләттәшләребез яшәү рәвешләре, холык үзенчәлекләре, сөйләшләре, иҗатлары белән татар милләтен үзләренә генә хас милли этник төсмерләргә бизи – ничек кенә булмасын, монысын инкарь итеп булмый әлегә...

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре докторы*

## Чеңләү йоласы

Кияүгә киткәндә кызны елаталар. Ата-анасын онытмасын, бәхетле яшәсен, дип. Кыз өстенә чаршау коралар. Чаршауны кызның җиңгәләре, туган тиешле кешеләре тотып тора. Шуннан чеңләтәләр. Чеңләүчеләр – шул ябынгычны тотып торучылар инде, бу йоланы белгән апалар, кыз ягы туганнары. Хәзер чеңләтүче җыручыларны махсус та чакыргалыйлар.

*Бисмиллахи-ррахмани-ррәхим. Әүвәле иман баш, имеш,*
*Әтекәйдән аерылу – әҗәлләрдән авыр эш, имеш.*
*Әтекәемнең өендә йомшак нигезләргә бастым мин,*
*Әтекәемнән аерылгач, тимер шыртларга бастым мин.*
*Әнкәй, аш пешерсәң, аз пешермә, күп пешер,*
*Балаларың янына килсә, мине дә исеңә төшер.*
*Әнкәй, мине ник таптың, ник таптың да ник саттың?*
*Мине сатып, ниләр алдың? Газиз баласыз калдың.*
*Әткәй, бирдең якынга, якын гына түгел, ялкынга,*
*Янар да сүнәр ут түгел, йән генәем тынар йир түгел.*
*Әткәй, балам, дидеңме, кулларыңа алып сөйдеңме,*
*Ачуларың килгән чакта: «Бәхетсезкәй булсын», – дидеңме?*
*Кил, әтекәем, каршыма, таяныйм яурың башына,*
*Яуры башың талды инде, бәхил генә булып кал инде.*
*Әтиемнең ак тастымалы элеп куелган чөенә,*
*Әтекәем, ник елыйсың, сөяр балаларың кулыңда.*
*Әтекәемнең өендә утырганым бары бер такта,*
*Бер такталарың кызганып, сатып бирдең, әти, чит-ятка.*
*Чылтыр-чылтыр чын чынаяк, чылтыратмый ничек юаем,*
*Усал кайнәләргә бирдең, ничек кенә итеп түзәем?*

**Рәхмәтуллина Гөлнур Хәмидулла кызыннан,**
*1953 елгы, Арыслан авылы*

## Кашкаш урманы

Топонимик риваять

Бу урман тау өстендә утыра. Шул урман тавына килеп чыкканнар да урман күрмәгән халыклар, шаккатып, кулларын әле бер, әле икенче кашлары өстенә куеп, тирә-якка карап торганнар, ди. «Нинди матур урманнары!» – дигәннәр. Матур бит бу яклар. Монда яшәүчеләр дә, шул урман тавына менеп, кулларын маңгайга куеп, тирә-якны, килүчеләрне күзәтә торган булганнар. Шуннан урманның исеме Кашкаш урманы булып калган.

**Дәүләтшина Рәмзия Наил кызыннан,**
*1958 елгы, Әптерәк авылы*

## Алтын колын

Әкият

Борын-борын заманда булган бер тутыккан йозак, кем ача, шуңа – әкият.

Булган әби белән бабай. Малайлары булган боларның. Ашарларына юк икән. Ярлы яшәгәннәр. Малай әйткән: «Әтәй, – дигән, – заработкага китәм», – дигән. Күрше авылга киткән. Кергән бер йортка, байга. «Эш эзлим», – дигән.

– Сине эшкә алам. Көтү көтәрсең. Ел да бер атым колынын югалта. Колынны югалтмасаң, мин сиңа түләрмен, – дигән хозяин.

Бер көн, ике, өч көн көтә бу көтүне. Ул-бу юк. Шуннан йокысы килә башлый моның. Шулвакыт ат кача. Колынлар вакыты җиткән. Колынын качырырга кача. Йокысы килсә дә, малай артыннан күреп кала моны. Ат артыннан чаба.

Ат чабып бара-бара да күл эченә кереп китә, шунда колынлый. Алтын колын таба. Малай күреп тора моның барысын, артыннан чапты бит инде. Хозяинга алтын колынны алып кайтып бирә. Теге шатлана, ярты байлыгын моңа бирә, благодарить итә инде моны. Ярлы малае өенә баеп кайта.

**Мостафина Фагыйлә Хәбиб кызыннан,**
*1938 елгы, Нәзе шәһәре*

## Сандык сату йоласы

Килен алырга киләләр. Кыз ягыннан берәү сандык өстенә менеп утыра. Сандыкта – бирнә. Кияү кеше бүләк бирергә тиеш. Бүләкләрен бирми торып, сандык өстеннән төшмиләр. Кияү кыз ягы сораган әйберләрне бирә, акча сибә. «Байлыкка, бәхеткә!» – дип әйтә. Килен төшерер алдыннан шулай сандык саталар.

**Бикбаева Нәсимә Мәгасүм кызыннан,**
*1957 елгы, Әптерәк авылы*

## Табышмак

Дөбер-дөбер дүртәү, Александр – икәү, Фёдор мескен берүзе.
Җавабы: сыер (дүрт имчәк, ике мөгез, бер койрык).

**Галиулина Фәния Гыйльметдин кызыннан,**
*1932 елгы, Чулпан авылы*

## Кияүләп йөргән чаклар...

Кыз ягында никах укыйлар. Кияү үзенең иптәш егетләре белән кияүләп кала шунда никахтан соң. Ике-өч кич кунып кайта кияү кыз йортында. Дүртәр көн кияүләп йөргән чаклар була торган ые. Шуннан кызны алып кайтабыз гармун уйнап. Килен төшерү була бу. Бал эчү була торган ые инде анда. Эчәбез дә җырлыйбыз. Кияү егете булып йөрисең инде шулай. Кияүләп йөрү, диләр.

*Каян кая барабыз?*
*Ерак түгел арабыз.*
*Алтын кебек кызыгызны*
*Алып китеп барабыз.*

Шулай дип җырлый торганыек кызны алып, капкадан чыгып киткәндә.

**Мостаев Фәһим Камилән улыннан,**
*1927 елгы, Постниково авылы*

## Чук итү йоласы

Иртә белән ике-өч катын продукты җыярга чыга. Кем күкәй, кем он, сөт бирә. Бу катыннар алып китәләр җыелган продуктыны чук иткән җиргә. Ул махсус урын шундый. Анда су ага, елга. Яңгыр булмаган елны үтә Чук. Яраслау (Ярославка. – *Л.М.*) елгасы буенда пешерә башлыйлар. Казан куялар, боламык пешерәләр. Ботка инде. Аерым казанда сөт салып күкәй пешерәләр, омлет шикелле итеп. Чәй кайнатыла. Катын елгадан су ала итәге белән һәм үзенә сибә. Анысы соңыннан. Башта «Символ веры», «Отче наш»ны укыйлар. Аннары Яраслауга төшәләр иконаны күтәреп, чукынып, яңгыр сорыйлар. Менә аннары катыннар итәк белән су алып, өсләренә сибә башлыйлар. Балалар сибенә.

Шуннан боламыкны ашарга баралар. Боламык – он боткасы. Тоз, май салып, сөттә пешерәләр, он сибеп, куерталар, пешкәнче болгатып торалар. Тәлинкәгә боламык салалар, кырыена омлет куялар, бөтен кешегә өләшәләр.

И яңгыр ява башлый шуннан соң! Туктамый да туктамый. И правда ведь.

**Селевёрстова Марина Павловнадан,**
*1959 елгы, Попово авылы*

## Әлләрәйләзәйлирәйлә

Җыру

*Тал бөгелә, тал бөгелә, нигә бөгелә икән?*
*Шулкадәрле үзәкләрем нигә өзелә икән?*
*Әлләрәйләзәйлирәйлә, нигә өзелә икән?*

*Тал бөгелсен, тал бөгелсен, тал бөгелсен, җиргә тисен,*
*Онытмамын туганайны, онытырлык түгелсең.*
*Әлләрәйләзәйлирәйлә, онытырлык түгелсең.*

*Тал бөгелә, тал бөгелә, каен бөгелми бит ул,*
*Ир ташласа да табыла, яшьлек табылмый бит ул.*
*Әлләрәйләзәйлирәйлә, яшьлек табылмый бит ул.*

*Алмагачтан алма тама алма пешкән айларда,*
*Кычкырып җырлап җибәрәм искә төшкән чакларда.*
*Әлләрәйләзәйлирәйлә, искә төшкән чакларда.*

**Бегашева Галина Григорьевнадан,**
*1948 елгы, Попово авылы*

## Җәй көннәре

Җыру

*Җәй көннәре бигрәк җәмле,*
*Җиләк чәчкә атканда,*
*Төнлә төшләремдә күрәм,*
*Җуям таңнар атканда.*

*Кимә ката, ки чабата,*
*Ката аякны кабарта,*
*Китмә читкә, кит шушында,*
*Читтә ямансулата.*

*Кунаклар да килгән безгә,*
*Иптәшләр дә килгән безгә,*
*Кунаклар безгә килгәч,*
*Тагын ни кирәк безгә?*

*Һавада ай бер генә,*
*Йолдыз виксән мең генә,*
*Бу авылда син бер генә,*
*Сине сөйгән – мин генә.*

*Һавалардагы йолдызларны*
*Нигә бер санамадым,*
*Күзләреңә күз тидереп,*
*Туйганчы карамадым.*

*Кызыл җаулыклар киштәдә,*
*Алып салдым иңсәгә,*
*Сезнең белән күрешүләр*
*Кермәде бит төшкә дә.*

**Уряшова Надежда Николаевнадан,**
*1958 елгы, Попово авылы*

## Ай-гай, керәшеннәр

Җыру

*Кайгыга калды керәшен халкы: патшаның сүзләре бик каты,*
*Бүген без сезне казакъ итәбез, иртәгә сез моннан китәсез.*
*Ай-гай керәшеннәр – Гөмбәй (елга исеме. – Л.М.) буйларында яшиләр.*

*Саубуллашып җыелып киттеләр, арбага атларын җиктеләр,*
*Туган илләрен ташлап киттеләр, Гөмбәй буйларына җиттеләр.*
*Ай-гай керәшеннәр – Гөмбәй буйларында яшиләр.*

*Араларында олы кешеләр тукталырга урын сайлыйлар,*
*«Шушында тормыш башлагыз», – диеп, сандугачлар килеп сайрыйлар.*
*Ай-гай, керәшеннәр – Гөмбәй буйларында яшиләр.*

*Казакълар озак яланда яттылар, дошманнарга юлны яптылар,*
*Сабаннар сөреп, ашлыклар үстереп, яңа җирдә тормыш башлыйлар.*
*Ай-гай керәшеннәр – Гөмбәй буйларында яшиләр.*

**«Сарашлы» фольклор коллективы башкаруында,**
*Сарашлы (Остроленко) авылы*

## Җака чылбыры

*Карагай гына агач – каты агач, кайрамыйча балта ник үтсен.*
*Җугалды ла җака чылбырым,*
*Алларым, алдамам, сылуым, сары былбылым.*
*Каерасаң балта ниен куйсын, үз туганнарыннан кем туйсын.*

*Өстегезгә кигән киемегез алып карасам да ал түгел.*
*Җугалды ла җака чылбырым,*
*Алларым, алдамам, сылуым, сары былбылым.*
*Сезләрнең кеүек яхшыларга*
*Җаным җарып бирсәм, җәл түгел.*

**«Ностальгия» фольклор коллективы башкаруында,**
*Кили (Кассель) авылы*

## Париж

*Урманнардан чыгар түше чуар – кара урманнарның бөркете,*
*Атларга ла менсә, ат уйната Парижларның асыл җегете.*

*Пар гына күкеләр чакырганда шаулый безнең урман буйлары,*
*Җанган җөрәкләрне баса безнең Париж чишмә сулары.*

*Җирле җиркәйләрен бик мактыйлар, Париж авылына ни җитә,*
*Бу гомерләр бездән үтә китә, татулыккайларга ни җитә?*

*Шелкәй буйларында йөргән чакта, аякларым батты тирәнгә,*
*Тирәннәр дә булмый, сайлар кайда? Парижлардан асыл җир кайда?*

**Иванова Раиса Осиповнадан,**
*1934 елгы, Париж авылы*

## Биюле уен

Бу уенда бөтенесе бергә бииләр. Парлап басалар. Берәү алда күрсәтеп тора ничек биергә, нинди хәрәкәтләр ясарга. Башкалар шуны кабатлап биеп бара тыпырдап. Гармунчы уйнап утыра. Парлап басып биисең. Егет-кызлар шунда таныша торган ые. Биегәндә җырлыйсың:

*Ач тәрәзәң, җиләк бирәм,*
*Җиләктән кайтып киләм,*
*Сезнең нурлы йөзегезне*
*Мин кайчан кайтып күрәм?*

**Галиулина Фәния Гыйльметдин кызыннан,**
*1952 елгы, Чулпан авылы*

## Җенияләшкән

Берәүнең атасы сугышта үлде. Анасы гел ирен көтте. Кызларына җенияләште. Кояш баткан турга матур киенеп куя бу көн саен. «Әти килә, – ди дә өенә кереп китә. Кич белән атасы булып җен килә икән. Ул кызны өшкерделәр. Җен бит ул төрле сурәткә керә ала. Аның нинди булуын сөйләргә ярамый.

**Сакаева Тутыя Әгъзам кызыннан,**
*1934 елгы, Чулпан авылы*

## Нардуган көннәрендә йөзек салыш җырлары

*Эдек-дудык барабан,*
*Чәчен майлап тараган,*
*Тараса да үрмәгән,*
*Матур егет күрмәгән.*

*Чылтыр-чылтыр су ага,*
*Матур кызлар су ала,*
*Матур кызлар арасында*
*Шадра кызны кем ала?*

*Сары, сары, сап-сары*
*Сары чәчәк саплары,*
*Уналтыда-унҗидедә*
*Кызның матур чаклары.*

*Әйдәгез, барыек,*
*Чия пешкән, алыек,*
*Яшь гомерләр үтеп китәр,*
*Уйнап-көлеп калыек.*

*Арыякның капкалары*
*Ачыла да ябыла,*
*Төнлә җөргән җегетләргә*
*Матур кызлар табыла.*

**Шитулова Эмма Григорьевнадан,**
*1948 елгы, Попово авылы*

*Татарстан референдумына 25 ел*

# ИРЕК ДИГӘН ТАТЛЫ СҮЗ...

*Ялган белән яла бер тамырдан,*
*Бер камырдан бугай тарих та.*
*Җирдә җәбер-золым яшәгәндә,*
*Гел үзгәреп торыр харита.*



«Референдум» дигән латин кәлимәсе безнең телгә «ирештерелергә тиешле хәбәр» диебрәк тәрҗемә ителә икән. Ә менә «хәбәр»нең исламияттә «вәхи» дип тә аталуын истә тотсак, әлеге сүзнең илаһи, галәми мәгънәсе дә ачык шәйләнә кебек. Күрәсең, ул урысча «Глас народа – глас Божий», безнеңчә «Халык әйтсә – Хак әйтә» дигән әйтемнәргә мотлак туры килгән төшенчә-категория була торгандыр инде.

Гәрчә 1936 елда кабул ителгән СССР Конституциясендә референдум үткәрү мөмкинлеге турында әйтелсә дә, тоталитар режим шартларында аны гамәлдә куллануны хәтта күз алдына китерүе дә кыен иде, әлбәттә. Кыскасы, 1990 елга кадәр безнең телдә бу сүзнең ис-косы да юк иде. Шул елны Литва парламенты, совет империясендә беренче буларак, бөтенхалык референдумы турында канун кабул итте. Декабрь аенда СССР халык депутатлары корылтае да шундый ук закон чыгарып куйды. Шул закон нигезендә, 1991 елның 17 мартында СССРда беренче һәм соңгы мәртәбә яңартылган мөстәкыйль республикалар федерациясен саклап калу турында бөтенхалык референдумы үткәрелде. Халыкның зур күпчелеге бу сорауга уңай җавап бирде. 20 августта исә яңа Союз килешүе имзаланырга тиеш булып, анда Татарстан да тигез хокуклы җөмһүрият сыйфатында кул куярга әзерләнгән иде. Әмма, ни хәл итәсең, Союзны элекке хәлендә саклап калу сылтавы белән фетнә оештырып, илгәсәрләр бу юлы да бар дөнья алдында рисвайга калды. Бөтенхалык референдумы карары да танк башмаклары астында сытылып чәлпәрәмә килде, зур империя үзе дә, терәүдә торган черек йорт кебек, күз алдында ишелеп төште[1]. Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итүгә ирешкән Татарстан да, димәк, моннан соң да империя хәрабәләре тузанын сулап яшәргә тиеш була иде...

Бер акыллысы әйтмешли, бездә кыяматкә илтә торган юллар да изге ниятләр белән түшәлгән шул.

Хәер, илгәсәрләр никадәр генә чәбәләнсә дә, «җен шешәдән чыгып» өлгергән иде инде. 1985 елда исә башлаган үзгәреш җилләре тәмам сөрсегән «халыклар төрмәсе»н әкренләп җилгәрергә керешкән иде. Хакимият тарафыннан гомер-гомергә куркытып тотылган халыкның да теле бераз ачыла төшкәндәй булды. Матбугатта, радио-телевидениедә ил җитәкчеләрен уңлы-суллы тәнкыйтьләү дә гадәти бер күренешкә әйләнеп китте. Һәм иң кызыгы: моның өчен төрмәгә дә, җүләрләр йортына да илтеп япмый башладылар.

[1] ГКЧП фетнәсе күздә тотыла. *Ред.*

Ә 1987 елның 28 маенда (Чик сакчылары көнендә!) моңарчы дөньяда күрелмәгән бер сәер тамаша булып алды: Матеас Руст атлы алман егете самолёты-ние белән исән-имин генә Кызыл мәйданга төшеп утырды. Чыннан да, башка сыймаслык хәл бит: Көнбатыш империалистларының кошлары да очып керә алмастай ил чигеннән очкыч кадәр очкыч белән үтеп кара әле син! Әллә күрмичә калганнар, әллә күреп тә күрмәмешкә салышканнар. Белмәссең... Өстәвенә, хулиганлыкта гаепләп берничә ай ябылуда тоткач, ул егетне туган иленә дә кайтарып җибәрделәр. Бәласеннән башаяк дигәннәрдер инде. «Тегe» чорларда, билгеле, мондый «хулиган» белән артык юанып тормаслар, ким дигәндә йә «сары» йортка, йә Себергә үк олактырырлар иде. Хәзер уйлап куям: әллә соң ул Руст дигәннәре безгә чынлап та «давыл хәбәрчесе» булып очып килгән идеме икән?..

Әлеге «гасыр очышы»ннан соң тагын берничә ел узар да без, ниһаять, Казанның үзендә үк тагын бер «давыл хәбәрчесе» Борис Ельцин авызыннан: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз!» – дигән канатлы гыйбарәне ишетербез. Илнең карагруһчыл көчләре аны чыраен сытып, әледән-әле көтелмәгән гамәлләр майтарып куярга яратучы Ельцинның чираттагы бер шаяртуы дип кенә кабул итсә, Татарстанда исә ул алга таба тәвәккәлрәк адымнар ясар өчен хәер-фатиха кебегрәк аңлашылыр.

Һәм бу нәкъ шулай килеп чыкты да. Республикабыз җитәкчеләренә дә, халкыбызга да әлеге сүзләр бик тә җитди әйтелгән кебек тоелды. Ельцин үз Мәскәвенә кайтып китеп, өч атна үтүгә, Югары Советыбыз, килештерү комиссияләре төзеп, бөекдержавачыл «демократ» депутатларны игә китерә-китерә, төн уртасы җитеп килгәндә, ниһаять, бертавыштан Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне кабул итүгә ирешә. Әлеге тарихи документны халыкка укып ирештергән депутат Фәндәс ага Сафиуллинның хәрбиләрчә кырыс та, ораторларча ышандыргыч, үзәкне өзәрдәй җылы-ягымлы да бәрхет тавышы әле хәзер дә күңелдә шул даулы көннәрнең шаулы кайтавазы булып яңгырап тора кебек...

Татарстанның субъектлылыгын күрсәтмичә генә, иң алдынгы халыкара стандартларга туры китереп эшләнгән Декларация, шулай итеп, халкыбызның гасырлар дәвамында кан тибеп торган җәрәхәтле күңеленә сихәт өстәгәндәй, канат куйгандай булды. Инде аны халкыбызның үзенә лаек эчтәлек белән баетасы гына калды.

Ләкин гомер бакый крепостное право шартларында көн иткән, халыкларны сортларга бүлеп, аларны бәйдә тотып яшәргә күнеккән бу илдә хәтта «тигез хокуклылык», «мөстәкыйльлек», «үзбилгеләнү» кебек мөкатдәс төшенчәләр дә тискәре мәгънә белдерергә, башбаштаклык булып аңлашылырга мөмкин шул. Декларациябез өстендә, көне-сәгате белән дигәндәй, кара болытлар куера башлавы нәкъ шуны күрсәтә дә. Мәскәү үз таләбен катгыян кистереп әйтә: референдумнан башка без сезнең суверенитетны таный алмыйбыз, ди. Юкса Татарстан Югары Советын куып таратып, Декларацияне гамәлдән чыгарырга да күп сорап тормаслар иде ул вакытта.

Ни гаҗәп, җөмһүриятебездә референдумга әзерләнү һәм аны үткәрү мәрәкәсе турында әлегәчә бер генә рәсми исәп-хисапның да басылып чыкканы юк икән. Хәтер яңартыр өчен бердәнбер диярлек ышанычлы чыганак – ул да булса, Рәфикъ Юнысның «Татарстан референдумы» дигән китабы *(Татарстан китап нәшрияты, 2000)*[2]. «Тарихи-сәяси детектив кебек укылган, әмма бер генә юлы да авторның хыял җимеше булмаган» (Фәндәс Сафиуллин сүзе), тәфсилле елъязмага бәрабәр саллы хезмәт язган Рәфикъ абыебыз. Кыскасы, референдумның үзе кебек, тарихи кыйммәтен беркайчан җуймаслык, халыкның һәрдаим хәтер сагында торырлык документаль әсәр иҗат ителгән! Бу җәһәттән, Фәндәс Сафиуллинның аерым язмалары да (әйтик, «Яшәсен референдум!» дигәне[3]) иш янына куш булып тора.

Әмма референдумга чаклы Татарстан тагын бер хәлиткеч сынау-имтихан

[2] «Идел» журналында 1997-1998 елларда татар һәм рус телләрендә дөнья күрде бу тарихи-публицистик әсәр. *Ред.*

[3] Фандас Сафиуллин. За свободу и равноправие. – Казан: «Җыен» фонды, 2016.

тапшырды әле. 1991 елның 12 июнендә Россиянең беренче Президенты сайланырга тиеш иде, баштарак ул кампания республикабызда да тавыш-тынсыз гына узып китәр төсле тоелды. Барып чыкмады. Ирек мәйданы янә каршы килде, чөнки Декларациядә субъектлылыгы күрсәтелмәгән Татарстан туфрагында Россия сайлаулары үткәрүнең юридик нигезе юк иде. Өстәгеләр, бәлки, моңа күз йомарга да уйлагандыр, ләкин Декларацияне яклап мәйдан тоткан, утка-суга керергә дә әзер торган халкыбызның күңел күзе тәмам ачылып өлгергән иде шул инде. Бу юлы эшләр тагын да зургарак китеп, хәтта ки сәяси ачлык тотуга кадәр барып җитте. Татарстанның халык депутаты, милли әйдәрләребезнең берсе булган Фәүзия Бәйрәмова Ирек мәйданында башлады бу авыр сәяси акцияне. Аннары аңа егермеләп кеше кушылды яки кушылып алды. Фәүзия ханым барысыннан да озаграк, 14 көн буена ач торды. Татарстанда Россия Президентын сайлауны үткәрмәү таләбе белән Татарстан Югары Советында да чыгыш ясады әле ул. Шактый дәрәҗәдә шушы сәяси ачлыклар тәэсирендә Югары Советыбыз, шөкер, Россия Президентын сайлау Татарстанда рәсми төстә үткәрелми дигән карар кабул итте. Юкса ул чакта мөстәкыйльлеге референдум нигезендә дә расланмаган, Россия белән Шартнамә аша да ныгытылмаган Татарстан янә гап-гади бер субъект булып каласы иде бит. Сайлауда катнашу тыелмады үзе. Ләкин анда катнашучылар саны нибары 35,5 процент тәшкил итте.

Дөресен әйтим, мин үзем табигатем белән шактый ук кыюсыз һәм беркатлы адәм. Тик менә Фәүзия Бәйрәмова, Зәки Зәйнуллин, Рәшит Әхмәтҗан, Илдус Әхмәтҗан кебек гаярьләр арасына ничекләр тәвәккәлләп барып кергәнмендер – хәзергәчә аңлап җиткерә алганым юк. Өстәвенә, бу ачлыкның күпмегә сузылачагы да, ничек тәмамланачагы да безгә мәгълүм түгел иде бит. Әгәр Татарстан Югары Советы, халык ихтыярына каршы килеп, федералларга гына ярашлы карар чыгарып куйса, ул, гомумән, тәмамланыр иде микән әле? Монда инде, телисеңме-юкмы, 1981 елда ун ирланд егетенең ирек хакына сәяси ачлык тотып шәһит китүен кабат исеңә төшерергә туры килә. Ә шул егетләрнең берсе, 66 көн ачлыктан соң, Тукай яшендә дөньядан киткән Роберт Сэндс, үзенең төрмә көндәлегенә түбәндәге юлларны теркәп калдырган: «Алар мине сындыра алмас, чөнки хөрлеккә, ирланд халкының хөрлегенә омтылыш – минем йөрәгемдә...» Ул чакта бу каһарманнарны яклап һәм, әлбәттә, неоколонизаторларны кискен гаепләп, Мәскәү матбугаты да бер шаулап алган иде. 80нче еллар башында, әлеге егетләр истәлегенә багышлап, мин үзем дә «Лонг-Кеш» дигән бер әсәр язып бастырган идем әле.

Утлы таба сыман чыжлап торган Ирек мәйданында, ирексездән, менә шуларны да уйлап утыргаларга туры килде безнең башкайларга. Уйламаслык та түгел иде шул: әгәр Мәскәү, дуамал бер фикергә килеп, гөрзиле опричникларына боерык иңдерә калса?.. Ә андый хәл кабатланмас дип йә кем кистереп әйтә ала? Ил әле Тбилиси, Баку, Вильнюс, Ригадагы канлы вакыйгалардан да айнырга өлгермәгән. Ә Россия куенындагы ниндидер татар тагын буза куптарып йөри!..

*Хөр булырга хакы бардыр җирдә*
*Һәрбер кызның, һәрбер угылның...*
*Ачлык тотып ачыклады халкым*
*Кояш астындагы урынын*[4].

Фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килгәндерме, бу юлы язмыш безгә мәрхәмәтлерәк булып чыкты. Ачлык вахтасы хәвеф-хәтәрсез тәмамланды. Безнең саулыкны хәтта табиблар да карап-күзәтеп торды. Бәлки, үзләренчә ачлык тотучыларның «тәртибен» тикшерүләре дә булгандыр инде...

27 май көнне Ирек мәйданына агылган халык вәкилләре бердәм рәвештә

[4] Г. Моратның «Казан утлары»нда басылган (1992, №8) «Ачлык» дигән поэмасыннан бу. Журналда (2001, №4) Рәшит Әхмәтҗанның шул 1991 елда язылган «Ачлык мәйданы» циклыннан шигырьләр дә чыкты әле. *Ред.*

парламентыбыз кабул иткән тарихи карарны алкышлады. Ихтимал, соңгы гасырларда бу кадәр үк татарның бер уй, бер теләк белән бергә җыелганы күрелмәгән хәлдер әле. Әлеге сәяси акция кайбер хәлиткеч мәлләрдә халкыбызның бердәм була алуын да күрсәтте. Бердәмлек дигәннән, Ирек мәйданы безләргә тагын бер сабак бирде: әгәр җитәкчеләр үз халкы белән аңлашып эш йөртсә, халык хадимнәре, үз сайлаучылары ихтыярына каршы килеп, ордым-бәрдем кануннар вә карарлар кабул итеп утырмаса, ил-иләт тә, җитәкчелек үзе дә зур эшләр майтарырга сәләтле икән. 90нчы еллар дәвамында җөмһүриятебездә халык файдасына кылынган байтак игелекле гамәлләр әнә шул хакта сөйли. Дөрес, ул заманда кануннарны тәңгәлләштерү шаукымы да, БДИ мәрәкәсе дә юк иде, салымнар да азрак салына иде. Ә иң мөһиме – Ирек мәйданы безне һәрвакыт ирек тәмен тоеп яшәргә өндәп торды...

Шулай итеп, Татарстан Россия Президентын сайлауда катнашмады. Хәзер инде бөтен эш Татарстан референдумына барып терәлде. Һәм җитәкчеләр, һәм депутатлар, һәм милләтпәрвәрләр алдына аны үткәрергәме, юкмы, дигән үтә дә катлаулы сорау килеп басты. Баштарак алар бүки кебек тоелган бу сорауга кистереп җавап бирергә җөрьәт тә итмәде әле. Дөресрәге, бизмән тәлинкәсе референдум уздырмау ягына тәмам авышкан иде. Ни дисәң дә, ул чакта тавыш бирү нәтиҗәләренең республика халкын милли билгеләр буенча кырт икегә аеру ихтималы да бик зурдан иде шул. Асылда җирле «демократлар» да, Мәскәү үзе дә референдумны үткәрүне нәкъ шуңа исәп тотып таләп итте дә бугай инде. Тик менә 1992 елның 21 февралендә Татарстан Югары Советы референдум үткәрү турында карар кабул итүгә, Россия Югары Советы шундук әлеге карарны гамәлдән чыгарырга катгый боерык биреп куйды. Конституция суды да шуны ук тәкрарлады. Бу очракта да Фёдор Тютчев мең кәррә хаклы булып кала: дөрестән дә, акыл-зиһен белән аңларлык илдә яшәмибез икән шул без. Димәк, һаман да ышанырга гына туры килә инде. Тик кемгә ышанырга соң?..

Әйдәгез, сүзне озакка сузып тормастан, референдум мәрәкәсенең эчендә кайнаган шәхесләрнең сүзләрен тыңлап карыйк әле. Алар булышлыгы белән моннан чирек гасыр элек булган шомлы да, шанлы да хәл-вакыйгаларны искә төшереп, янә бер кат хәтер яңартып алыйк. (Биредә Р.Юныс китабыннан, аның сорауларына бирелгән җаваплардан өзекләр китерелә.)

**Минтимер ШӘЙМИЕВ:**

*– Башта без үзебез дә референдум кирәкми дип уйлый идек. Югары Советтагы «Народовластие» дигән төркем исә гел «референдум кирәк» дип тукып торды. Мәскәү дә, Татарстан җитәкчеләре сепаратизм белән шөгыльләнә, Россияне тарката, суверенитет аларның үзләреннән башка берәүгә дә хаҗәт түгел, дип гаеп ата башлады. Халык белән киңәшеп эшләмисез, референдум үткәрмисез, дип, үзебезгә дә әйткәннәре булды. Тегеләре дә, болары да без Татарстанда референдум уздырырга җөрьәт итмәбез дип уйлаган иде. Ә без тоттык та уздырдык менә. Һәм бик дөрес эшләдек. Чыннан да, әйбәт юл, мәдәни юл. Әгәр дә без шул референдумны уздырмасак, шуның нигезендә Конституциябезне кабул итмәсәк, Мәскәү белән бер өстәл янына утырып мәсьәләләрне хәл итүләр дә, Шартнамә төзүләр дә мөмкин булмас иде. Конституция судында да хөкем иттеләр безне, башкача да басым ясап карадылар. Ләкин референдумга каршы көрәш халыкка каршы көрәшү инде ул...*

*...Референдум көне якынайган саен, басым да көчәя барды. Конституция суды гына түгел, хәтта Россия Югары Советы алдында җавап тоту да булды әле. Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин барды анда. Кызганыч ки (тарих монысын да белергә тиеш!), республиканы шулай гаепләгәндә, Россия Югары Советына Татарстаннан сайланган депутатларның берсе дә ачыктан-ачык яклап чыкмады... Әйе, якламадылар – шул залда утырып, шуны күреп-ишетеп торсалар да! Алай гына да түгел, федералист карашлы депутатларыбыз республикага пычрак та аттылар әле...*

*Әйе, менә шундый чакта сынала кешеләр... Аз гына йомшаклык та күрсәтергә ярамый иде. Чөнки халыкта шик тууы бар. Сессияләрне бит тоташ телевидениедән*

*күрсәтеп тордылар. Ә инде үз халкыңда шик туа икән, ул чагында без 50 процент тавыш та җыя алмас идек...*

*...Референдум алды төнендә мин күбрәк шул турыда уйладым: егетләр каушап калмас микән, сайлау участоклары ачылыр микән? Аның бит берничәсе генә ачылмаса да, Мәскәүгә шул җиткән. Радиодан, телевидениедән шундук шау-шу куптарачаклар иде. Фәлән-фәлән участоклар референдум үткәрүдән баш тарталар, Югары Советның һәм Президентның карарына каршы чыгалар, дип...*

*...Егетләр берсе дә каушап калмады! Берсе генә дә! Шунда бер генә администрация башлыгы җебеп төшсә дә, шом, дулкын булып, шундук участокларга таралыр иде... Иң мөһиме: халык куркып калмады, бердәм рәвештә референдумда катнашып, үз сүзен кистереп әйтте.*

**Фәрит МӨХӘММӘТШИН:**

*– Мәскәүгә мин үзем генә бармадым. Югары Советның закончылык һәм закон чыгару комиссиясе рәисе Рөстәм Хафизов белән бергә киттек. Рөстәм барырга бик атлыгып тормады, нәрсәдәндер курка иде кебек. Ләкин мин аның һичшиксез барырга, миңа чыгышымны да, йомгаклау сүзен дә әзерләргә булышырга тиешлеген әйттем... Мине Хасбулатов һәм аның беренче урынбасары Филатов янына чакырдылар. Бу вакытта Рөстәм алгы бүлмәдә утырып торды. Мине референдум үткәрүдән баш тартырга күндерергә тырыштылар, мин ризалашмадым. Чыккач, Рөстәм миңа болай диде: «Зинһар, мине өйгә кайтарып җибәрегез әле. Монда эш юньлелек белән бетмәскә тора, минем әтине дә 38нче елны кулга алганнар...»*

*...Коточкыч авыр утырыш булды бу. Бөтенесе дә референдумга каршы чыктылар. Бу – Россияне таркату, дип тукыдылар, Казанда урыслар белән татарлар арасында күп кан коелачак, дип сөйләделәр...*

*...Югары Совет утырышы бетте, ә алар миңа әйтәләр: «Бар, кайт, без референдумны үткәртмәскә, Татарстан Югары Советына референдум уздыру турындагы карарын гамәлдән чыгарырга тәкъдим итәргә дигән карар чыгарачакбыз», – диләр. Ягъни мин кайтып, үзебезнең Югары Советны җыеп, тавышка куеп, референдум үткәрмәскә дигән карар кабул иттерергә тиеш икәнмен. Ну, минем дә ачу килде инде. «Ярый, ә минем кулда сезнең ул документыгыз юк та әле», – дидем. Иртәгә сессияне үткәрә алмасак, берсекөнгә, шимбә көн, инде референдум – шуңа өмет. Тик болар, шушы карарны эшләп бетергәннәр дә, Казанга машина белән китерттергәннәр. Шофёрлар бер-берсен алыштырып, машинаны төне буе куып! Ә мин поездда кайтам шакы-шокы...*

**Рафаэль ХӘКИМОВ:**

*– Минем «референдум кирәк түгел» дип мәкалә дә язганым булды. Чөнки бүленү китте, бик яман ыгы-зыгы кубуы мөмкин иде. Татарстанда гына түгел. Бөтен татар күтәрелү куркынычы бар иде. Ул чакта милли хәрәкәт бик көчле иде бит. Кайбер шәһәрләрдә инде карарлар да кабул ителгән иде. Референдум үткәрик һәм Татарстанга кушылыйк, дип. Бүген Башкортстанның төньяк-көнбатыш өлешен тәшкил иткән районнарның кайсы республикага карарга тиешлеген хәл итү өчен 1922 елда референдум үткәрелергә тиеш була, ул үткәрелми кала. Андагы татарларның күтәрелүе бар дип тә шикләнә идек. Бу инде татарга да, башкортка да файда китермәс иде. Татарстанда да вазгыять үзгәрде. Урыслар «безне монда кысарлар» дип шикләнә иде бит, шул шикләнү кимеде. Татарстан Молдова да, Балтыйк буе да түгеллекне аңладылар. Үзебез дә аңлата алдык – сәясәт һәм икътисад аша...*

*... Референдум алдыннан Мәскәүдә Куркынычсызлык советы утырышы үткәрелә. Анда Шахрай белән Станкевич Татарстанга гаскәр кертергә тәкъдим итә. Скоков (ул чакта шул советның секретаре. – ред.) каршы була. Без Татарстанда үз тикшеренүләребезне үткәрдек, Шәймиевнең сәясәтен анда татары да, урысы да хуплый, ди ул. Бу хакта миңа Скоков үзе сөйләде.*

*Референдумга чит илләрдән күзәтүчеләр килү бик шәп булды. Арада бит АКШ конгрессменнары да бар иде. Аннары Швеция, Бөекбритания илчелекләреннән дипломатлар килде – сәяси яктан бик мөһим нәрсә бу... Дөресен генә әйткәндә, Рәсәйдә татар да күп инде. Алар да күтәрелергә мөмкин бит. Күпме кеше әнә телеграмма җибәрде, Татарстанга тимәгез, дип. Татар бик таралган-чәчелгән. Конфликт-фәлән чыкса, локальләштерү читен булачак иде.*

**Фәндәс САФИУЛЛИН:**

*– Референдум кирәклеккә безне Мәскәү ышандырды. Үзенең туктаусыз йодрык изәп торулары белән... Казанга килгән Россия прокурорлары җитәкчесе Ильюшенконың кесәсе тулы ордер булган, диләр. Һич шикләнмим, әгәр дә халык референдумда тискәре җавап бирсә, суверенитет яклы кешеләрне кырып-себереп алып китәчәкләр иде. Иң беренче – Президентыбызны, башка җитәкчеләребезне... Безгә бит ул чакны гаскәрләрне якын китерделәр...*

Әйе, ул көннәрдә Мәскәүнең кыланмышлары бөтенләй дә кырга сыешлы түгел иде шул. Татарстанның урыслар чагыштырмача күбрәк яшәгән шәһәр-район үзәкләре берсеннән-берсе хәтәррәк эчтәлекле листовкалар белән тулды, урамнарга түшәлде (соңыннан аларның конфискацияләнгән өлеше генә дә 34 тонна икәнлеге ачыклана), үзәк радио-телевидение, матбугат чаралары берөзлексез коткы таратып, куркытып, янап, «юк» дип тавыш бирергә өндәп-тукып торды, җирле «демократик» басмалар да, аларга кушылып, шуны ук «сайрады».

Инде килеп, референдум алдыннан тагын да бер хәтәр, хәлиткеч алыш прокурорлар арасында була. Ни дисәң дә, соңгы сүзне алар әйтә ич. Генераль прокуратурадан референдумны өзәргә дип килгән прокурорлар төркеме дә шулай уйлагандыр, күрәсең. Ләкин безнекеләр дә, кем әйтмешли, елан аягын кискән гаярь егетләр булып чыга шул! Татарстан прокуроры Антонов аумакайлана башлагач, аның беренче урынбасары Марсель Мусин һәм Казан прокуроры (соңыннан Татарстан прокуроры) Сәйфихан Нәфиев (мәрхүм инде, авыр туфрагы җиңел булсын) референдум язмышын хәл итүне үз өстенә ала. Шушы урында, әйдәгез, Марсель аганың үзен тыңлап карыйк.

*– ...Беркөнне иртәнге якта мине һәм урынбасарлар М.Әхмәтшин белән М.Шәрәповны Антонов бүлмәсенә чакырып керттеләр дә безгә районнарны бүлеп бирделәр һәм кулга бер документ тоттырдылар. Ну, без инде буйсына торган кешеләр. Берничә районга берьюлы заказ бирдем дә, беренчесенә, Мөслим районы прокурорына телефон буенча тапшыра да башладым текстны. Укып барам шулай, кинәт чәчләр үрә тора башлады. Анда референдумны үткәрүнең законга сыймавы, сайлау участокларын кичекмәстән ябарга кирәклеге язылган иде. Әгәр дә япмасагыз, Җинаять кодексы буенча җаваплылыкка тартылачаксыз, диелгән.*

*Законга таянып язылган булса да, бу кәгазь законнарның берсенә дә туры килми иде. Юридик яктан надан документ. Мин ике урынбасарга да шалтыраттым, без моны тапшырмаска тиеш, дидем. Шулай килештек. Мин яңадан Антонов бүлмәсенә кереп киттем, тегеләргә үз фикеремне әйттем. Документ юридик яктан дөрес түгел, референдум үткәрү турындагы карарны беркем дә гамәлдән чыгара алмый, дидем...*

*Шуннан соң районнардан шалтырата башладылар. Нәрсә эшлик тә, нәрсә эшлик, диләр. Мин әйттем, бернәрсәкәйгә дә кысылмагыз, сезнең эш түгел бу, дидем. Әгәр дә инде куркасыз-нитәсез икән, әнә дачага китегез, кунакка китегез яки «чирләгез». Күбесе шулай юкка чыкты да...*

*...Мине эштән алырга теләгәннәр анысы. Белүемчә, Президентыбыз яклап калган...*

Менә шулай, өстән иңдерелгән теләсә нинди әмерне карусыз үтәп яшәргә күнеккән прокурорларны да егетлектә сынаган ул референдум дигәннәре. Бу инде һич тә законнарны тәңгәлләштерүне таләп итеп, протест белдереп утыру гына түгел сиңа. Хәлиткеч мәлләрдә прокурор үз халкының адвокаты вазифасын башкара белергә дә бурычлыдыр ул.

Ниһаять, референдум тарафдарларының уртак тырышлыгы белән, Татарстан тагын бер хәтәр сынауны уңышлы үтте: *«Сез, Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коруына ризамы?»* дигән сорауга референдумда катнашучыларның 61,4 проценты хуплап җавап бирде. Әгәр ул, әйтик, Квебек, Шотландия, Уэльс, Каталониядәге кебек цивиль шартларда да уза калса, әлеге күрсәткеч күпкә югарырак та булыр иде, бәлки. Ләкин бездә андый «мәрхәмәт»кә исәп тоту шактый кыен шул. Хәзер инде мөмкин дә түгел бугай. Чөнки закон кушмый, диләр...

XX гасырда иң бәрәкәтле референдум, мөгаен, Норвегиядә үткәрелгәндер (1905 ел). Шуның нигезендә ил, Швеция йогынтысыннан арынып, бәйсез дәүләт статусын ала. Гомер-гомергә балык тотып көн иткән, өстәвенә эчкечелектән дә шактый җик күреп яшәгән норвей халкы, тиз арада тернәкләнеп китеп, Норвегия үзе тора-бара дөньяның иң алдынгы илләреннән берсенә әйләнә. Халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча ул бүген, гомумән дә, беренче урынны били шикелле. Заманында әлеге могҗизави илне минем үземә дә барып күрергә туры килгән иде. Дөньяның аулак бер читендә, шактый ук кырыс табигать шартларында гомер кичереп ятучы бу викинглар токымы ни арада шундый зур ыргылыш ясаган да мул, имин тормыш коруга ирешкән соң әле? Әлеге дә баягы нефть, газ сату аркасындадыр дияр идең, алары тормыш дәрәҗәсе ягыннан иң артта сөйрәлүче бериш илләрнең дә төп яшәү чыганагы лабаса. Күрәсең, хикмәт башкада, – норвейларның милли керемне үз ватандашларына гадел итеп бүлеп бирә белүендәдер! Әйтүләренә караганда, бу илдә хәтта череп баеган олигархлар да юк икән. Юкса алар, гадәттә, нәкъ менә нефть, газ торбаларыннан сураеп килеп чыга ич инде.

Ерак бабалары үрнәгендә, норвейларда бүген дә тишек акча әйләнештә йөри. Викингларның ышануынча, шул тишектән Кояшка баксаң, ил-көнеңә бәрәкәт, бәхет иңә икән, имеш. Әлеге ырымга норвейлар бүген дә ышана, димәк.

*Ышаныч шул кирәк...*
*Үз эргәңдә*
*Ятим икәнеңне белсәң дә.*
*Идел-йортка кот, бәрәкәт иңсен –*
*Тишек акча йөртәм кесәдә...*

Татарстан референдумында хәтсез генә халыкара күзәтүчеләр дә катнашты. Шуларның берсе, АКШ Конгрессының Аурупада иминлек һәм хезмәттәшлек комиссиясе әгъзасы Майкл Оукс референдумнан соң үткәрелгән матбугат очрашуында: «Татарстандагы референдумның җиңүе – Берләшкән Милләтләр Оешмасының Уставы җиңүе ул», – дип белдергән иде. Үз «демократ»ларыбыздан аермалы буларак, күңелдә ышаныч уятырдай сүзләр әйткән иде безгә ерак Америка кунагы. Рәхмәт аңа! Вакытлар узар, бәлки, якты киләчәктә бездә дә халык ихтыярын санга сугарга, хөрмәт итә белергә өйрәнерләр әле.

Шуңа ышаныйк.

**Газинур МОРАТ**

# ТАТАР КУШАМАТЛАРЫ

Татар антропонимик системасында кушаматлар этномәдәни тирәлекнең мөһим берәмлеге буларак исем йөртүче белән исем бирүче арасындагы уңай яки тискәре мөнәсәбәтне чагылдырып, кешегә хас характер үзенчәлекләренең күләмен яктыртып, исем бирүченең прагматик максатларын тормышка ашырып, шәхси һәм тирә-юнь дөнья картинасын ачуда исем бирү сәнгатенең мөмкинлекләрен тулысы белән реальләштергән гаять мөһим антропонимик берәмлекләрне тәшкил итәләр. Әдәби әсәр тукымасында кушаматлар номинатив, шәхесне идентификацияләү, аеру вазифасыннан тыш әдәби стилистик функция дә үтиләр. Вербаль-семантик яктан караганда, кушаматларда исем бирү сәнгатенең төрле мөмкинлекләре ачыла. Когнитив яктан кушаматлар милли үзбилгеләнү һәм милләтнең характер үзенчәлекләрен чагылдыру мөмкинлегенә ия. Прагматик яктан караганда, кушаматлар билгеле бер социаль катламның төрле коммуникатив шартларын яктырталар.

Кушамат («кушама» (кушма) + «ат» (исем) сүзләре кушылу юлы белән ясалган) кешенең рәсми, төп исеменә кушма, өстәмә ат бирә. Исем, ата исеме, фамилия образлы эмоциональ-экспрессив төсмерләрдән азат килсәләр, кушамат коннотив, эмоциональ-экспрессив төсмерләргә ия мәгънә бирә. Кушамат – кешегә аның үзенчәлекле сыйфатларын яки җәмгыятьтәге урынын ачу максатында җәмгыять яки кешеләр тарафыннан бирелгән официаль булмаган исем. Кайвакыт кушаматлар рәсми төс алып, исем, фамилия, ата исеме белән бергә дә килергә мөмкин: Пётр Беренче, Бөек Патшабикә һ.б. Кушаматларның шәхси яки группага хас төрләрен аерып карыйлар *[ЭССЛТП, 2008: с.146]*. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә кушаматка конспирация өчен яки кешеләрдән көлеп, мәзәк өчен бирелгән исем дип аңлатма бирелә *[ТТАС, 2005: с.299]*. Кушамат – антропонимның бер төре, үзенчәлекле характерга ия, аерым бер тормыш шартларына бәйле барлыкка килгән, кешегә бирелгән өстәмә исем *[Подольская, 1978: с.115]*. Н.В.Подольская кушаматларның түбәндәге төрләрен аерып күрсәтә: мелиротив кушамат – кешенең аерым бер яхшы сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү өчен хезмәт иткән исем; коллектив кушамат – аерым бер кешеләр төркеменә, гаиләгә, нәселгә, этник төркемгә бирелгән исем; шаярту кушаматы – кешене кимсетү, көлү максатында кулланылган исем; түбәнсетү кушаматы – кешене түбәнсетү максатында, сүз белән түбәнсетү өчен бирелгән исем; мәктәп кушаматы – мәктәптә укыган чорда бирелгән кушамат *[Подольская, с.116]*. А.М.Селищев кешенең физик кимчелекләрен ачу һәм кешегә хас тискәре сыйфатларны күрсәтү кушамат белән исемне аеруда төп критерий дип билгели *[Селищев, с.407]*. Аның фикеренчә, борынгы чорда кушамат сүзнең мәгънәсенә тәңгәл килмәгән, ә сүз знагы функциясен генә үтәгән *[Селищев, с.408]*. Локаль группа кушаматларын фольклорга мөнәсәбәтле өйрәнүче Н.В.Дранникова кушаматны тел һәм фольклор арасында торган антропонимик категория буларак билгели. Кушамат фольклоры йола контекстында интертекстуаль мөнәсәбәттә төрле жанрларның барлыкка килүенә китерә. Димәк, кушаматлар аерым бер лексемаларга, мәкаль һәм әйтемнәргә, поэтик текстка, нарративка бәйле килергә мөмкин *[Дранникова, с.21]*. Т.В.Шпар индивидның тышкы кыяфәтен һәм физик үзенчәлекләрен, холкын-характерын, һөнәри эшчәнлеген яки җәмгыятьтә

тоткан урынын билгеләү семантик яктан мотивлашкан кушаматларны ачыклауда төп критерий дип саный. Кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган кушаматлар, күпчелекне тәшкил итеп, кешегә характеристика бирә, аның буен, фигурасын, чәч төсен, физиологик кимчелекләрен күрсәтә *[Шпар, с.14]*.

Рус теле белемендә кушамат категориясе С.И.Зинин, Н.В.Подольская, А.М.Селищев, А.В.Суперанская, Н.Н.Ушаков, З.П.Никулина тарафыннан өйрәнелә. Е.Ф.Данилина, И.Ю.Карташева, Т.Т.Денисова, Ю.Б.Воронцова, Ж.Д.Маюрова, Е.С.Шостка, А.Н.Лангнер, Н.В.Дранникова, Т.В.Шпар һ.б. диссертацияләрендә кушаматларның лексик-семантик үзенчәлекләре теоретик яктан нигезле итеп тикшерелә. Татар антропонимикасында кушамат категориясе Г.Ф.Саттаров, С.И.Гасыймова хезмәтләрендә җентекле итеп өйрәнелә. Төрки тел белемендә кушамат мәсьәләсе башкортларда – Г.А.Амиргалина, кумыкларда – Р.А.Мусаева, каракалпакларда – Ю.Н.Хоҗалепесова, азәрбайҗаннарда – А.Корбанов, М.Н.Чобанов, үзбәкләрдә – Э.Бегматов, кыргызларда – Ш.Жапаров, казакъларада – Т.Җ.Жанузаков, төрек тел белемендә Ю.Кенан Караҗан, Мехмет Семих тарафыннан яктыртыла.

Кушамат терминының икенче өлешендә борынгы төрки телдән килгән «ат» сүзе булуы аның тамырлары тирәндә икәнлекне һәм төп исемгә өстәмә рәвештә элек-электән кулланылуны раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарган, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырган. Орхон-Енисей язмаларында, М.Кашгарыйның «Диване лөгатет төрк» хезмәтендә исем белән бергә кушамат та аерым функция үти. М.Кашгарыйның әлеге сүзлегендә «at» сүзенең беренче мәгънәсе «исем» дип күрсәтелсә, икенче мәгънәсе – «кушамат» *[Махмут ал-Кашгари, с.112]*. Борынгы төрки язмаларда кушамат кешене төрле яктан сыйфатлап килә. Мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында кешенең физик һәм психологик үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар, төп исемгә ялганып килеп, кешене төрле яктан характерлый. Орхон-Енисей ташъязмаларында еш очрый торган Bilgä кушаматы – «акыллы» *[ТЕЭ, с.318; OY, с.129; ДТС, с.99]*; Alp – 1) «укчы»; 2) «герой, батыр»; 3) «курыкмас, кыю» *[ТЕЭ, с.315; OY, с.120; ДТС, с.36]*; Küčlüg «кыю, көчле» *[OY, с.156; ДТС, с.323]* дигәнне аңлата. Шул рәвешле, борынгы төрки чорның акыллы, көчле, кыю кеше образын реконструкцияли. Исемнәрдән күренгәнчә, Bilgä – «акыллы» компоненты бинар исемнәрдә кулланыла. Эпитафик язмаларда чагылыш тапкан Билге Каган акыллы, сакчыл, йомшак күңелле кеше булган, шуңа күрә әлеге компонент, исем составында килеп, акыллылык мотивын чагылдыра *[Айдаров, с.102]*. Борынгы төрки язмаларда көч мотивы Küč *[OY, с.156; ДТС, с.322]* кушаматы нигезендә чагылыш таба: Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan. Борынгы төркиләр көчнең Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар һәм әлеге кешеләрнең дә Тәңре тарафыннан яратылуына инанганнар. Борынгы төрки антропонимик системасында беренчел һәм икенчел антропонимик берәмлекләр арасында аерма юк, әлеге категорияләр бер вазифа башкарган. 922 елда ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүе антропонимик системага да сизелерлек йогынты ясый. Мөселман культурасы тәэсирендә антропонимик системада кушамат һәм исем антропонимик категорияләре арасына чик куела. Шулай да күп гасырлар дәвамында мөселман антропонимик системасы белән янәшә төрки антропонимик системасы да кулланылышта була. Кешенең социаль тормышын күзалларга мөмкинлек биргән титуллар, кушаматлар озак вакытлар исем белән бергә кулланылышта йөри. Мәсәлән, Алтын Урда чоры чыганакларында да традицион борынгы төрки исемнәрнең кулланылышын күзәтергә мөмкин: Биш Куртук, Буга Тимер, Бәк Тимер, Илбуга, Илтотмыш, Карабулат, Карабаһадир һ.б. Алтын Урда чоры чыганакларында борынгы төркиләрнең исемнәрендә тотем хайваннарның кушамат ролендә килүе күзәтелә: Буга Тимер, Биш Буга, Арык Буга һ.б. Хайван тотемнары белән бирелгән кушаматлар шәхеснең нәсел-нәсәбе, ыруг башлыгының исеме турында да мәгълүмат бирә. XVI-XVII гасыр писцовая кенәгәләрендә исем белән кушамат аерылып бетмәгән антропонимик компонентлар очрый: Күчүк («кечкенә»), Кәтүк («кечкенә»), Тулбай («тулы +бай»). Күкеш, Сытыш кушаматларының сәламәт булмаган балага бирелүе турында искәртелә. XVIII гасырга караган ревизия кенәгәләрендә исемнәр белән бергә

кушаматлар кулланылышы күзәтелә: Карабаш Гали, Сабай Ишкенә һ.б. Күренә ки, Карабаш, Сабай кебек компонентлар кушамат ролен үтәп, рәсми кенәгәләрдә теркәлгән.

Матур әдәбият стилендә кушаматлар әсәр тукымасына, эмоциональ-экспрессив төсмерләрне куертып, образны тагы да калкурак күрсәтү максатында, татар авылы колоритының тулы бер палитрасын чагылдыруда язучылар тарафыннан отышлы кулланыла. Әгәр язучы кушаматны милли антропонимиканың үзенчәлекләренә туры китереп кулланса, образның семантик-стилистик яктан мәгънә күләме арта яисә әсәр турында тулаем фикер тирәнәя. Кушамат шәхеснең яшен, җәмгыятьтәге урынын, физик һәм психологик кимчелекләрен, шәхескә карата булган тискәре яки уңай мөнәсәбәтен дә чагылдырырга мөмкин. Нигездә, шәхес турындагы мәгълүматлар әсәр контексты эчендә ачыла. Ә.Сәлах «Аккан сулар...» әсәрендә авыл җирлегендә кушамат тагу турында болай дип яза: «Безнең авыл халкы бер-берсенә кушамат куярга хирыс. Ялгыш авызың кыйшайса да, сиңа кушамат чәпәп куялар. Капка Минач абзыйның кушаматы бер генә түгел, берничә иде. Сугыштан яраланып, аксак аяк белән кайтканда, бу абзый: «Мин бик зур елга – Кунай елгасын кичкәндә ранный булдым», – дип сөйләп йөргән өчен безнең мишәрләргә шул җиткән. Ләкин алдан бирелеп, дистәләрчә еллар буе аклап килгән «Камка» кушаматы үз позициясен тиз генә югалтмаган: Минач абзый элеккечә «Камка» булып калган, ә үсеп килгән улы Салихка «Кунай» кушаматы тагылган». Хәзерге татар әдәбиятында Батулла, Н.Гыйматдинова, Ф.Бәйрәмова, Т.Галиуллин, Ахир, Р.Газизов, Ә.Сәлах кебек күренекле язучылар иҗатларында кушаматларны әдәби алым буларак оста файдалана.

Борынгы чорларда кушамат нәсел тамгасы, нәсел-ыруг атамасы яки шәхеснең рәсми исеменә өстәмә исем булып йөргән, дидек. Тотемистик карашлар нигезендә барлыкка килгән кушаматлар хәзерге татар антропонимик системасында да традиция нигезендә сакланган. Шәхси кушаматлар исә, теге яки бу кешенең төрле сыйфатларына нигезләнгән метафорик мәгънәви эчтәлек биреп, чыгышлары белән реаль чынбарлыкка тыгыз бәйле була. Алар кешенең гомуми, хосусый, физик һәм рухи сыйфатларына, һөнәренә, яшәү урынына һ.б. мотивларга нигезләнеп кушыла. Балага исемне тугач та әти-әнисе бирсә, кушаматны тормышының төрле этабында коллектив, җәмгыять куша.

Шәхси кушаматларның күбесе кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясала. Кешенең рухи яки физик сыйфатларын теге яки бу предметка, күренешкә, кош-корт яки хайванга охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар байтак. Мәсәлән, Күсе – төрле әйбер җыярга һәвәс адәмгә, Борча – кечкенә буйлы, бик хәрәкәтчән яки тиктормас кешегә тагылган кушамат. Шәхси кушаматлар кешенең һөнәренә, эшләү яки яшәү урынына, милләтенә, титулына, социаль чыгышына, берәр сүзне еш кабатлау яки үзенчә әйтүенә, рәсми исемен бозып әйтүгә мөнәсәбәтле рәвештә дә барлыкка килә. Топонимнарга яки микротопонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар, башлыча, шәхеснең нинди торак пункттан булуына яки кая да булса барып кайтуына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килеп, этнокультур тирәлеген билгели: Өчиле Зөлкамал (М.Мәһдиев, «Торналар төшкән җирдә»), Көҗмә Микулай (К.Булатова, «Яшел яфрак – яшәү төсе»), Чишмә башы Газиз (А.Хәлим, «Кыйбла»), «Норма Сәми» (Р.Газизов, «Кичер кичерә алсаң...»), «Бәкер Вафич» (Р.Газизов, «Гаян абый хат укый»), «Норма Ягъфәр» (Р.Газизов, «Түттүт Гарифы»).

Этнонимнарга нисбәтле кушаматлар кешенең теге яки бу милләт вәкиле булуына яисә әлеге милләт вәкиленә физик яктан охшашлыгына ишарәле: Чирмеш (М.Мәһдиев, «Торналар төшкән җирдә»), Үзбәк бабай (Ф.Абдуллин, «Чүл бүресе»), Кыргыз Әхмәдулла (Ә.Сәлах, «Аккан сулар...»). Матур әдәбиятта әлеге кушаматлар шәхеснең милли чыгышына яки аның башка этник группа вәкиленә берәр ягы белән охшашлыгына, яисә бәйләнешенә нисбәтле кулланыла.

Татар антропонимик системасында антропонимнарга мөнәсәбәтле кушаматлар билгеләнә. Әлеге төркемгә караган кушаматлар шәхеснең ерак бабасына бәйләнешле яки аны икенче берәүгә охшату җирлегендә барлыкка килә: 1) шәхеснең нәселенә нигез салган ерак бабасының исеменә нисбәтле кушаматлар: Гайфи Исхагы (Ф.Шәфигуллин, «Сафура, Бәкер һәм трактор»), Шаһи Саниясе (Р.Шәфигуллин, «Утлы дулкын»), «Куян Сәхие» (Р.Газизов, «Дөл-Дөл»), «Куян Зарифы» (Р.Газизов, «Түттүт Гарифы»), «Куян

Кәримулласы», «Куян Вакыйфы» (Р.Газизов, «Җылылык»), Галәви Шакиры (С.Зыялы, «Агулы теш»); 2) шәхеснең үз исемен бозып әйтү нигезендә ясалган кушаматлар: Нурла – Нурулла исеменнән (Н.Гыйматдинова «Нурулла»), Сөләй Әмәт – Әхмәтне бозып әйтү юлы белән барлыкка килгән кушамат (Ф.Абдуллин, «Чүл бүресе»), Дәлтүн – «дальтон» сүзен дөрес әйтә белмәгәнгә (З.Зәйнуллин, «Курск дугасы батыры»), Прох – Прохов Вадим (Ф.Имамов, «Күләгә») һ.б.

Хәзерге татар әдәбиятында шәхеснең кәсебе-һөнәренә яки эшләү урынына мөнәсәбәтле кушаматлар да еш очрый. Мондый кушаматларның күбесе хәзерге һөнәр атамаларына нигезләнеп ясалган. Шулай ук онытылып бара торган һөнәр-кәсепләргә нисбәтле кушаматларның да очравы күзәтелә: Атҗабар Минниса (М.Мәһдиев, «Бәхилләшү»), Итекче Җиһанша, Тимерче Нотфый (М.Мәһдиев, «Торналар төшкән җирдә»), Сунарчы Сәбәк (А.Хәлим, «Кыйбла»), Прит Әлфинур, Силсәвит Мәдинә (Ахир, «Таш калада баш кала»), Умартачы Равил (З.Хөснияр, «Гарасат»), Көтүче Хөснетдин (С.Зыялы, «Агулы теш») һ.б. Хәзерге татар әдәбиятында шәхеснең яки аның ата-бабаларының титулына, социаль чыгышына мөнәсәбәтле кушаматлар да очрый: Алпавыт Шәйхи (М.Мәһдиев, «Бәхилләшү»), Зимагур Булат (Ф.Бәйрәмова, «Кырык сырт»), Зимагур (Ахир, «Таш калада баш кала») һ.б.

Кешенең характерында аерата калку тискәре яки уңай сыйфатлары еш кына аңа кушамат итеп тагыла: Кире Урай (М.Мәһдиев, «Кире Урай»), Җүләр Әйдүш (Батулла, «Ике җүләр»), Канәгать Мыштым, Псих Сәлимгәрәевич (А.Хәлим, «Кыйбла»), Пытыр Хәлимәсе (Ахир, «Кәбисә елы»), «Түттүт Гарифы» (Р.Газизов, «Гаян абый әкият сөйли»), «Сәдака Миңнехан» (Р.Газизов, «Әманәт»), «Шәвәли Шәвәлиеч» (Р.Газизов, «Үчтеки Миңлехан»), Дуамал Касыйм (А.Әхмәтгалиева, «Капка») һ.б.

Шәхеснең тышкы физик билгеләрен характерлый торган кушаматлар хәзерге татар әдәбиятында зур күпчелекне тәшкил итә: Сары Сәвия (М.Мәһдиев, «Егет язмышы»), Бәләкәй Камилә (А.Хәлим, «Кыйбла»), Зур колак Иван, Киңкүкрәк Иван (А.Хәлим, «Ала-коладагы дүрт Иван»), Ташмаңгай, Тимертән (А.Хәлим, «Исемсез малай»), Таз (З.Хөснияр, «Гарасат»), Шадра, Таз, Бөкре (Ә.Сәлах, «Аккан сулар...»), Бүдәнә Салих (Р.Газизов, «Кичер кичерә алсаң...»), Агулы теш Миңлегали (С.Зыялы, «Агулы теш») һ.б. Шәхеснең авыруына нисбәтле кушаматлар: Кылый Нигъмәтҗан (Г.Ахунов, «Яшьлек яме»), Бөкре Гафият «(Г.Ахунов, «Идел кызы»), Чулак Газиз, Чатан Газиз (А.Хәлим, «Кыйбла»), Кылый, Аксак (Ә.Сәлах, «Аккан сулар...»).

Хәзерге татар әдәбиятында нәсел тамгасын белдерә торган хайван атамалары яки билгеле бер хайван, кош-кортка охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар да очрый: Бүре Гыйбадулласы (Г.Ахунов, «Идел кызы»), Бүре Бадул (Г.Ахунов, «Идел кызы»), Бүре Әскый (М.Мәһдиев, «Торналар төшкән җирдә»), Күгәрчен Мөхетдин (З.Хәким, «Сәер никрут»), Кабантеш Сәгъдәт (А.Хәлим, «Ала-коладагы дүрт Иван»), Чикерткә Рәхимәсе (Ахир, «Таш калада баш кала»), Аю Гаяны (Р.Газизов, «Дөл-дөл»), Шимпанзе (С.Зыялы, «Агулы теш») һ.б.

Табигать күренешләре нигезендә ясалган кушаматлар: Чишмәбай (Г.Ахунов, «Идел кызы») һ.б.; шәхеснең исәп-хисабы, төрле үлчәм берәмлекләренә бәйле кушаматлар: Җиде авыз Мостафа (А.Хәлим, «Кыйбла») һ.б.; мифологик һәм дини терминнарга нисбәтле кушаматлар: Шайтан Шакир (Ф.Бәйрәмова, «Кырык сырт»), Әүлия (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»), Шүрәле Халидәсе (С.Якупова, «Туй алдыннан») һ.б. да очрый.

Шәхес белән бәйләнешле берәр кызыклы вакыйга яисә аңа карата әйтелгән нинди дә булса көлкеле сүзгә нисбәтле кушаматлар да аерым урын тота. Әдәби әсәрдә әлеге төр кушаматлар көлке тудыру алымы буларак кулланыла һәм әсәр тукымасына реальлек төсмере өсти. Мәсәлән, Р.Газизов «Кичер кичерә алсаң...» әсәрендә геройга кушамат тагылуын болай дип аңлата: «Безнең авылда Вәгыйз абыйның гына ике кушаматы бар. Берсе – Герман, чөнки бу – аның яраткан сүгенү сүзе. Икенчесе соңгы елларда гына тагылды. Анысы – Күкеле сәгать. Әйе шул. Нәкъ тәрәзәсе шалт итеп ачылып, аннан ялт итеп Вәгыйз абый башы атылып чыккач, авылдашлары таккан кушамат. Авыл тарихында булмаган байлык, бер кешегә ике кушамат». З.Хәкимнең «Сәер никрут» бәянында Күгәрчен Мөхетдин исемле персонажның кушаматы яраланган күгәрчен

вакыйгасына бәйләнешле аңлатыла. Әсәрдә Мөхетдин бодай өеменнән кошларны куганда, агач көрәк белән сугып, бер күгәрченне каты җәрәхәтли. Шул яраланган кошны ике учына алып, ул ярты көн елап утыра. Күгәрченне өенә алып кайта. Медпунктка фельдшер янына алып төшә. Шуннан соң гына күгәрчен исән кала. Әлеге вакыйгадан соң аны Күгәрчен Мөхетдин дип атый башлыйлар.

Кушаматлар эмоциональ-экспрессив тирәлектә барлыкка килә һәм кулланылыш ала. Матур әдәбият тукымасында кушаматлар язучылар тарафыннан отышлы файдаланылып, әдәби алым буларак кулланыла. Хәзерге татар әдәбиятында әлеге әдәби алымның бик уңышлы мисаллары күзәтелә. Әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрелгән кушаматлар, телнең этнокультур тирәлегенең моделен гәүдәләндереп, әсәрнең төп мәсьәләләрен һәм тирән фикерләрен, әдәби-эстетик концепциясен чагылдыру алымы ролен үти. Кушаматларның антропонимик трансформацияләре сюжет линияләрен куерту, эмоциональ-экспрессив яки юмористик төсмерләр бирүдән тыш, геройның характер үсеш-үзгәрешен дә ачарга ярдәм итә.

**Әдәбият**

Айдаров Г. Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII в. – Алма-Ата: Наука, 1971. – 376 с.

Дранникова Н.В. Локально-групповые прозвища в традиционной культуре: функциональность, жанровая система, этнопоэтика. – Автореф. дис. ... докт.филол.н., 2005.

ДТС – Древнетюркский словарь. – Ленинград: Наука, 1969. – 675 с.

Махмуд ал-Кашгари. Диван лугат ат-турк (Свод тюркских слов): в 3 т. / пер. с араб. А.Р.Рустамова, под ред. И.В.Кормушина, прим. И.В.Кормушина, Е.А.Поцелуевского, А.Р.Рустамова; Институт востоковедения РАН: Институт языкознания РАН. – М.: Вост. лит., Т.1. – 2010. – 461 с.

OY – Tekin T. Orhon Yazıtları. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2008. – 200 s.

Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. – М.: Наука, 1978. – 135 с.

Селищев А.М. Труды по русскому языку. Т.1. Язык и общество / Сост. Б.А.Успенский, О.В.Никитин. – М.: Языки славянской культуры, 2003. – 632 с.

ТЕЭ – Кормушин И.В. Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстология. – М.: Наука, 2008. – 342 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2005. – 848 б.

Шпар Т.В. Прозвищные антропонимические номинации в социолингвистическом аспекте. – Автореф.дис. ... канд. филол. н. – Уфа, 2012.

ЭССЛТП – Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х томах / А.Н.Тихонов, Р.И.Хашимов, Г.С.Журавлёва и др. / под общ.ред. А.Н.Тихонова, Р.И.Хашимова. Т.1. – М.: Флинта: Наука, 2008. – 820 с.

ЭССЛТП – Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х томах / А.Н.Тихонов, Р.И.Хашимов, Г.С.Журавлёва и др. / под общ.ред. А.Н.Тихонова, Р.И.Хашимова. Т.2. – М.: Флинта: Наука, 2008. – 816 с.

**Гүзәлия ХАҖИЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕ



*1954 ел*

Безнең әткәй, Миргалим карт, балта остасы иде. Ел тәүлегенә бер көн дә калдырмый, балтасын кыстыра да төзелеш бригадасына юнәлә. Шунда арба-чана ясыйлар, ватык-җимерекне төзәтәләр. Әмма җәйге челләдә плотникларны, бу эштән алып, кыр станына, ашлык суккан җиргә күчерәләр. Әткәй безне – Рафаил абый белән мине дә шунда ияртте. Яслегә, балалар бакчасына йөрү мөмкинлеге булмады. Әнкәй уракта иде.

Ындыр табагының, ашлык сугу күренешенең үз хозурлыгы, күңелгә дәрт өсти торган сихрияте бар. Хистойгыларда ниндидер бер рәхәтлек, күтәренкелек пәйда була. Өстәвенә ындыр табагы әле үзенең сыен да әзерләп куйган икән. Молотилка туктап торган арада уңган, җитез хатын-кызлар подаука төбендә бодай куырып алалар. Кыздыргач борчак кына түгел, бодай да тәмле була икән.

Бер кичне әткәйгә авылга кайтырга кирәк булды. Ара шактый ерак. Иртүк килеп җитәсе дә бар. Шунда әткәй эскерт төбен йолкып иркен генә куыш ясады.

– Кайтып йөрсәгез арырсыз. Йокыгыз да туймас. Йоклагыз шушында гына. Мин иртүк килеп җитәрмен, – диде әткәй.

Куыш эчендә бик рәхәт. Ястык йомшак, молотилкадан яңа гына чыккан салам җылы, хуш исле. Кәеф күтәренке. Инде йокыга китәбез дип оеп барганда гына, өлкәнрәк бер малай, куыш янына килеп:

– Әнә бүре килә, – дип, безне өркетмәкче булды. Ләкин, хәтерлим, без артык шүрләп калмадык. Килсә соң! Ул бит иң әүвәл безне түгел, әлеге малайның үзен күрер иде. Шулай итеп, теге «бүре» дигәнебез тыныч кына юкка чыкты.

Безгә ындыр табагындагы мәгыйшәт бик җанлы, күңелле тоелды.

Без дөньяга килгәндә, әткәй-энкәй колхоз члennары булганнар инде. Әткәй гомере буена атын сагынып, юксынып яшәде, шул ук вакытта аның белән горурлана иде.

– Юлда ат артыннан баруны бер дә яратмады. Берәрсен куып җиттеме, билдән көрт ерып, йөзеп булса да алдагы атны узып китә иде, – дип еш искә ала иде. Күрәсең, карап торган бахбайны яхшы тәрбияләгән. Бәлки, бердән артык ат тотуның хәвефсез түгеллеген күңеле белән тойгандыр. Шуңа күрә бер булсын, берәгәйле булсын дип аны ике атка торырлык итеп ашаткан, эчерткәндер.

Атка җылы мөнәсәбәт тумыштан киләдер дип уйлыйм. Бераз өлеше әткәйдән дә күчкән булуы ихтимал. Атлар тирәсендә чуала идем. Болар инде – колхоз атлары.

Бераз калкына төшкәч, миңа ярарлык атлы эш тә табылды. Ындыр табагында чүмәлә тарттыра башладым. Миңа «Очкын» исемле тай беркетелде. Гәүдәгә зур булмаса да, бик көчле, җитез, карусыз ат иде ул. Молотилка эшли башлагач, атың белән машинадан агылган салам, кибәк астына кереп китәсең дә чүмәләнең уң ягына килеп чыгасың. Шунда эшләүче хатын арканны камыт бавына шудырма итеп кенә бәйләп куя, кузгалып киткәндә, чүмәләне тырма сабы белән бераз саклап бара. Эскерт янына җиткәч, иелеп, арканның очын тартып җибәрәсең. Ул бик җиңел чишелә. Очкын белән кабат молотилка янына җилдерәсең. Хәтердә әлеге гамәлнең әнә шул яклары калган. Тәнгә кибәк, кылчык тула дип борчылуны мин хәтерләмим.

Ә менә горурлык, канәгатьлек хисе истә калган.

Сугыш чыккан елны миңа – унбер, эткәйгә алтмыш ике яшь иде. Әнкәй дә пенсия яшендә.

Ул елны иген бик нык уңды. Җыеп алырга гына эшче көчләр кинәт азаеп калды. Шул чакта әнкәйгә шактый зур участокны бүлеп бирделәр. Аны берүзенә ерып чыгарлык, урып бетерерлек түгел иде. Без өчәүләп: әнкәй, мин, Рафаил абый, уракларны яхшылап тешәтеп, урырга керештек. Әгәр көлтәне бастырып куйсаң, ул кеше буе була иде. Бераз җилләгәч, көлтәләрне чүмәләгә салабыз.



*Фәритнең әткәсе Миргалим, әнкәсе Гатифә*

Бер елны колхоз абзар-кура төзү өчен саман кирпечләр сугарга кереште. Ул болай эшләнә. Җирне кара туфрактан әрчиләр дә кызыл балчыкны көрәкләр белән казып йомшарталар, аннары ныклык өчен аңа салам турап тараталар, су сибәләр. Мин шуны ат белән таптатам, балчык әлеге салам – «арматура» белән аралашканчы, үзле хәлгә җиткәнче шунда атны йөртәм. Бу – әллә ни кыен шөгыль түгел. Тайга атланып йөрүе – үзе бер хозурлык. Тик менә яланнан шул тайларның берәрсен тоту шактый мәшәкатьле. Башка бригаданыкы булгач, аларны танып, холкын-фигылен белеп бетереп тә булмый. Аның каравы эштән соң атны тирән сулы буага кертеп йөздерү күңелдә әйтеп бетергесез канәгатьлек, куаныч тудыра, кәефне күтәрә. Җан рәхәте. Юыну-чистарыну тайның үзенә дә ошамады микән дип уйлыйм.

Мин еш кына әткәй эшләгән җиргә барып чыгарга, йомычкалар арасында, алачык тирәсендә уралырга ярата идем. Ял итеп алган арада картлар дөнья хәлләре турында әңгәмә коралар, уйлап җиткерелмәгән гамәлләр турында карашларын белдерәләр. Аларның сүзе, фикер сөреше мәгънәле, мавыктыргыч була торган иде. Әткәй – Миргалим карт – төзү бригадасы башкарган эшләрне язып бара, аннары миңа әйтеп яздыра. Мин озак вакыт әткәйне язу танымый дип йөри идем. Баксаң-күрсәң, ул гарәп имлясын белә икән. Тик әле бу хакта артык шауламый иде. Аны куллануны бәгъзе берәүләрнең килештермәве бар дип уйлавы булды микән? Мин шулар нигезендә ведомость кебек нәрсә төзеп идарәгә тапшырам.

Әткәй балтасын үткенләгәндә, миңа чар әйләндерергә туры килә иде. Ул чар гел суга тиеп тора. Моның хикмәтен соңрак аңладым. Чыланмаса, тимер кыза, йомшый, үткенлеген җуя икән.

Төзү бригадасына ике ат беркетелгән: туры алаша «Канаш» һәм күк бия. Монысы да җитез, ләкин усалрак кебек күренә. Мин Канашны үз итәм һәм күп вакыт үзем карыйм. Аны кайбер сәер гадәтләргә дә өйрәттем. Әйтик, чабып барган җирдән тыр-р дип тезгенне тартсаң, шып туктый иде. Бервакыт Рәсхәт дигән дус малай:

– Атланып чабып килим әле, – дип сорады. Урамны урады бу, килеп җиткәч, туктарга дигән ымны аңлау белән ат кинәт туктады, дүрт саны белән бераз шуып та барды әле. Рәсхәт атның башы аркылы очып төште. Ул моны көтмәгән иде. Канашның ошбу гадәте турында дус малайга искәртергә башка килмәгән. Җайдакның хәбәрдар булмавын бахбай да белми иде.

Атлар тирәсендә мин иркен эш итә идем. Атка үземчә атлана идем. Атның ялын сул кул белән урап тотасың да, бераз чигенеп, гәүдәңне ат сыртына ыргытасың. Кайчак бу алым уңышлы гына чыга. Әмма бәгъзе тайларның ат өстендә синең ныклап урнашканыңны көтеп торырга сабырлыклары җитми, эре адымнар белән юыртып китәләр, син койрыкка таба шуып төшеп каласың. Ярый әле тезген кулдан ычкынмаган.

Печән өстендә плотникларны болын эшенә җибәрәләр. Безнең бригада болыны Чәчер аръягында Өшәр күле буенда урнашкан. Күлнең теге ягында Әнәк печәнлеге. Миңа Өшәрнең тирән суының сафлыгы ошый иде. Иркенләп йөзәсең, төбенә



*Уңнан сулга: Фәрит, Рафаил*

төшеп җитү буенча малайлар белән ярыш оештырырга да кулай. Зур куыш та Өшәр тирәсендәрәк корыла. Гүзәл җир. Анда озак вакыт күңелдә саклана торган үзенә бер төрле сихри матурлык бар.

Болынның икенче башы нарат урманына терәлеп тора. Бу урман хәзер юк инде. Түбән Кама төзелеше уңае белән кисеп бетерделәр.

Печәнгә әткәй – Миргалим карт, Нуретдин абзый, Шәйхелгали абзый, Нургали абзый һәм башкалар төштеләр. Алар һәммәсе дә өлкән яшьтә. Ләкин әле эшкә ныклылар. Шулар арасында мин аеруча Нургали абзый хезмәтенә сокланып, кызыгып карап торам. Гәүдәгә җыйнак булса да, эшкә бик сәләтле, куәтле, күп сөйләшми торган, тыйнак зат. Менә ул, киң алдырып, үләннәрне төбеннән үк кыркып, алдан бара. Эре, кызыл җиләкләр күренеп кала. Ул үткән пакус үткен пәке белән чәч алганны хәтерләтә. Хәер, чалгының үткенлеге чәч пәкесенекеннән ким түгелдер. Телевизорда печән чабу күренеше үләннәргә таяк белән сугып баруны хәтерләтә. Режиссёрлар Нургали абзый кебекләрнең ничек чапканын күрсеннәр иде дип әйтәсе килә. Сәнгатьтә барлык элементлар да югары кимәлдә булырга тиешләр бит.

Печәнне киптереп кибән койганда – мин кабат чүмәлә тарттыруда.

Кышкы каникул җитүгә, без Рафаил абый белән кабат чәчер тарафына, әнкәйнең апасы Фәхрикамал әбиләргә юл тотабыз. Заманында бу гаилә җитешле, таза тормышлы булган. Колхоз оештыру елларында аңа кулак мөһере сугылган. Гаилә башлыгы Салах җизни Себергә сөрелгән җирдән кайта алмаган. Без белгәндә Фәхрикамал әби янындагы өч баласы белән кеше өендә өйдәш булып яши иде. Барлык уллары сугышта үлде. Җиңел түгел иде аңа. Шулай да безне якты чырай белән каршылый иде. Бик туган җанлы, ягымлы карчык иде ул.

Безнең монда килүнең төп максаты табигать хезмәтеннән файдалану, күл бозында тимераякта шуып, шуның рәхәтен, хозурлыгын тою иде. Моның өчен әбинең улы Мирхәт абый белән бергә, конькиларны кыстырып, урман ышыгында җилгә каршы барабыз. Күлнең аргы башына җиткәч, конькиларны тагабыз, ышыктан чыгып, бозга төшәбез, бишмәтне җәеп җибәрәбез, җилкәнне җил иркенә тапшырабыз, ул безне «ә» дигәнче шудырып күлнең икенче башына китереп җиткерә. Ошбу гамәл берничә тапкыр кабатлана. Арып, хәлдән тайгач кына визитның планы үтәлгән санала. Бер баруда көчле буран чыкты. Безне әткәй ат белән килеп алды. Песи балалары кебек башны да чыгармыйча толыпка төренеп кайттык.

Инде китап турында бер-ике кәлимә. Безнең урамда, якында гына шактый бай китапханә эшли иде. Хезмәткәрләре дә ачык йөзле. Мин аннан алып байтак роман-повесть укыдым. Алар шундый кызыклы. Тәэсирләрне үзеңдә генә калдырасы килми, малайлар белән дә уртаклашасы килә. Бервакыт Марк Твенның «Том Сойер маҗаралары» әсәрен күршедәге дусларга – Фоат белән Рәфкатькә сөйли башладым. Бирелеп тыңлыйлар. Дәвамын алга таба укыгач сөйләрмен, дим. Сабыр гына көтеп торалар.

1942 елда «Совет әдәбияты» журналында Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повесте басылып чыкты. Гаҗәп матур әсәр иде ул. Мин аны бөтен класска укырга иде дип ана



*Фәритнең әнкәсе, әткәсе туганнары арасында. Пучыда Сабантуй көннәре. 1930 ел*

теле укытучысы белән киңәштем. Ул моңа уңай карады. Тик шулай да моның өчен вакыт бик күп кирәк, диде.

– Без болай итик. Син аны үзең кабат укып чык та класста сөйләрсең, – диде. Мин риза булдым. Шактый тулы итеп, детальләре белән, стилен дә саклап сөйләргә тырыштым. Кызыксынып тыңладылар. Журнал кулдан-кулга күчеп йөрде. Газета-журналны безгә Казанда яшәүче Хәнифә апа яздыра иде.

СССР Верховный Советына сайлауларга әзерлек барышында мине сайлаучылар исемлеген төзергә, Пучы халкының исем-фамилияләрен язарга чакырдылар. Без башка тагын берничә «писарь» белән авыл советында төнге сәгать берләргә кадәр язып утыра идек.

Яз көне кырчылык бригадасының хисапчысы итеп билгеләделәр. Кайчак кешеләрне эшкә дә дәшәм. Кайбер колхозчылар моңа бик үк куанмыйлар. Миңа кыен булып китә. Дәресләр беткәч, басуга җыенам. Ул вакытта балта осталары нишләптер тратайка – бер күчәрле арба ясаганнар иде. Мин, ат җигеп, җыелма сажинны алам да кырга юнәләм. Көн бик матур, баш түбәсендә тургайлар сайрый. Хыял еракларга китә. Колхозчылар Бүләк белән Урдалы арасындагы басуда булырга тиешләр. Бүләк – каен урманы, Урдалы – имән урманы. Күңелгә бик якын урын. Анда хатын-кызлар һәм Кәшби мулла абзый язгы культураларны чәчәләр.

Кәшби мулла абзый – аеруча игътибарга лаеклы шәхес. Аның белән күрешү, хәл-әхвәл белешү – үзе бер күңелле күренеш. Ул – тирән белемле, кешелекле, мөлаем карт.

Бераз гәпләшеп алгач, мин чәчелгән җирне үлчим. Дәрестә алган белем ярап куя. Аннары ведомость төзеп бригадир Фәтхи абзыйга тапшырам.

Игеннәр өлгергән мәлдә ындыр табагында весовщик-үлчәүче итеп билгеләделәр. Башта мин моны бик җиңел итеп, молотилкадан чыккан ашлыкны теркәп тору рәвешендә генә күз алдына китерә идем. Чынлыкта ул башкачарак икән. Үлчәү өч аяклы таганга беркетелгән. Көянтәнең бер башында – герләр, икенче башында – тимер мичкә. Шул тулгач, әйләндереп бушатасың да язып куясың. Бушатылган ашлыкны даими көрәп торырга кирәк. Көрәмәсәң, алга таба бушатырга урын да калмый. Гер янында зур көшел хасил булгач, берничә кеше бергәләп таганны буш урынга күчерәбез. Малай-шалай сугылган ашлыкны капчыкларга тутырып, амбарга ташый. Әмма капчыкны арбага күтәреп салырга көч җитеп бетми. Ул өмет белән миңа карый. Өлкәннәргә мөрәҗәгать итәргә, бәлки, уңайсызлана да торгандыр. Нишлисең, күтәрешәсең инде.

Беркөнне кичке якта Мирзагали аты белән безнең капка төбенә килеп туктады. Төнге сменага чыгарга кирәк икән. Ялт итеп торган айлы төн. Шул чакта ашлык төяп



*Фәрит Хатипов туруны (оныгының кызы) Әмирә белән. 2012 ел*

соңгы арбага утырып амбарга кайту җылы истәлек булып хәтердә калган.

Тазартылган икмәкне малайлар белән бергә Дербёшка элеваторына илткәләдек. Хәзер, ул хакта язганда, Чыңгыз Айтматовның «Җәмилә» повесте күз алдына килә.

Без бәләкәй чакларда чорына хас шөгыль – маһирлык та барлыкка килә иде. Мин үземә тунлык тире иләргә өйрәндем. Әмма бу эшне осталардан карап торырга, отып алырга туры килмәде. Авылда иләүчеләр булмады микән? Белгән кешеләрнең сөйләүләренә карап кына эшкә тотындым. Ул чакта тирене бик күп көч сарыф итеп илиләр иде. Башта ике тире ертылды. Шуннан соң процесс үз эзенә төште. Иләү үз җае белән китте, тиреләр кулъяулык кебек йомшарды. Ахырдан мин аларны тал кайрысы белән сары төскә буядым. Тун әйбәт кенә килеп чыкты. Йоны озын, җылы.

Ләкин уңайсызлык килеп чыкты. Или башлаганчы тирене юарга кирәк булган икән. Бу хакта миңа нишләптер әйтүче булмады. Ул заманда  порошогы да юк иде. Сарык өстендә юмыйча да яраса да, тун өчен алай бик әйбәт түгел икән. Шулай итеп, дублёнканың абруе әллә ни югары булмады.

Бер җәйне озын арба белән Мөшеге урманыннан бүрәнә ташыдык. Озын арбаның идәне булмый. Кучер утыра торган урынга бау чорныйлар да шуңа иске сырма җәеп куялар. Урманга беренче башлап кемнәр белән барганмындыр, хәтердә калмаган. Соңгы рейста ялгыз барырга туры килде.

– Юлны белгәч, үзең генә дә бараласың инде, – диделәр. Белеп әйтәләрдер инде. Арбаны кайту ягына каратып, бүрәнәләргә терәп диярлек куйдым. Әүвәл агачның бер башын арбага салдым, аннары икенче башын менгереп куйдым. Кирәк кадәр, гадәттәгечә төягәч, йөкне тыгызлап бәйләдем. Таралып, тәгәрәп китмәсеннәр. Җай гына, бахбайны атлатып кына кайттым, сөян бүрәнәләрне ишләре янына кертеп бушаттым.

Җәй көне авылда эш бетеп тормый. Менә иген өлгереп килә. Без ерак басуда Фоат белән бер тирәдә борчак чабабыз. Шулчак безнең янга тарантаска үзе яраткан кара айгырны җиккән колхоз рәисе Шәрип абзый Шәймиев килеп туктады. Төшеп безнең белән исәнләште. Тирә-юньгә күз салды. Җылы гына сөйләште. Эшебез аңа ошады. Фоат белән миңа рәхмәт әйтте.

Малайлар өлешенә әле тагын пар җирен сөрү дә калган икән. Күрше егет Сабир белән, тирәннән тирәнлеген көйләп, әнә шул пар җирен сөрдек.

***

Аны-моны эшләп йөрү, күрәсең, хакимиятнең күзенә чалынгандыр. Унсигез яшькә чыккач, 1948 елның 20 февралендә хөкүмәт миңа «1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. Инде моңа да алтмыш тугыз ел үткән икән. Ошбу бүләк үз артыннан башка медальләрне ияртте.

**Фәрит ХАТИПОВ**

# ЖУРНАЛНЫҢ БЕР НӨСХӘСЕ

Бөек Ватан сугышы елларында без, фронттагы язучылар, «Совет әдәбияты» журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән саен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә иде дисәм дә, арттыру булмас.

Кызганычка каршы, журналны тәртипле рәвештә ала алмый идек. Хәрәкәттәге армиягә подписка юк иде. Бары бандероль белән генә килә иде ул безгә.

...1943 елны журналны алдыруда шактый зур өзеклек булды. Тылга, каләмдәш иптәшләребезгә хатлар язып, ялынып-ялварып та алдыра алмаган чакларыбыз булгалады. Андый вакытларда журналның яңа санын гына түгел, хәтта күптәнге саннарын күрү өчен дә әллә ни бирергә әзер идек без.

Журналның чираттагы саннарын күрергә сусап йөргән шундый айларның берендә, каты сугышлар барган көннәрдә, алгы сызыкта бер лейтенант миңа, сүз ара сүз чыгып:

– Безгә моннан бер ай чамасы элек «Совет әдәбияты» журналы килде, – диде.

– Ул журнал кайда соң? Миңа биреп тора алмыйсыңмы?

Кызганычка каршы, биреп тора алмый икән. Оборонада торганда, журнал батальондагы татар сугышчылары арасында кулдан-кулга күчеп йөргән, аны аерым-аерым да, җыйнаулашып та укыганнар. Ә хәзер ул күрше батальондагы татар сугышчыларында икән. ...Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти-әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар.

...Шулай да мин әлеге журналны табу бәхетенә ирештем. 1943 елда чыккан 5нче санның бер нөсхәсе иде ул.

Гадәттәге нөсхә. Сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык. Хәреф хаталары да җитәрлек. Шулай да аның тышкы күренеше, торышы һәм язмышы кызык иде.

Тышлыгын ертып алганнар. Әлеге лейтенантның әйтүенә караганда, аның эчке ягы буш булган, ягъни аңа бернәрсә дә басылмаган. Кәгазь юклыктан йөдәгән сугышчылар моңа бик шатланганнар, шунда ук аны ертып алып, тылга, әти-әниләренә, туганнарына хат язганнар. Ике хатка җиткән, ике кешене бәхетле иткән.

Журналның текстлы өлеше беренче битеннән алып соңгы битенә кадәр тулысынча сакланган. Әмма ул, укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри, шулкадәр тузган, таушалган, күпереп, калынаеп киткән, аерым юллары хәтта танымаслык хәлгә җиткән иде – кыскасы, иң бәхетле, иң укылган китап язмышын башыннан кичергән иде ул.

...Бу кызыклы вакыйгадан соң инде бик күп еллар үтте, бик күп сулар акты. Шулай да журналыбызның әлеге укыла-укыла тузып, керләнеп, каралып беткән нөсхәсе, аның язмышы әле һаман күңелемдә, күз алдымда.

**Афзал ШАМОВ**
*1972, №5*

# КҮҢЕЛЕМӘ ХУШ КИЛГӘН ӘСӘР

«Казан утлары» журналының 2017 елгы 1нче санын алу белән, «Илбашы» дип аталган әсәргә күзем төште. Рабит Батулланың бу әсәрен комарланып укырга керештем. Узган саннарда басылган «Чукрак» (Данил Салихов), «Тимә, яшәсен!» (Марсель Галиев) әсәрләренә дә мөнәсәбәтем бик җылы иде. Аларны кайта-кайта укырлык әсәрләр рәтенә кертеп, журналны көтеп алган идем. Данилның үзенә дә: «Мөхәммәт Мәһдиев стиленә тартым итеп язгансың», ә Марсельгә: «Аязым кебегрәк стильдә итеп кабул иттем», – дигән идем. Шундый, узган гасырчарак язылган әсәрләр сагындырган ахры. Сагынычны канәгатьләндергән сөенеч бик татлы булса да, аларны читкәрәк куеп, «Илбашы»на карашымны төбәдем. Ул әсәр документаль хикәяләр җыелмасыннан тора.

Әдәбиятсыз, әдипләрсез, театр-моң, сәнгатьсез милләт була алмый. Милләтне бөтендөнья аренасына чыгару эше әдәби басмалар аша башкарыла. Яшьлегемдә мин Рәсүл Гамзатовның «Мой Дагестан» әсәрен укып, ул халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын тотып яши белүенә сокланганлыгымның тәэсире әле хәзер дә күңелемдә саклана. Алга таба Чыңгыз Айтматов кыргыз халкын дөньякүләм мәйданга чыгарып, укучыларында ул халыкка җылы мөнәсәбәт тәрбияләде. Хәзер дә яратып укыла торган әсәрләр рәтендә кала бирәләр. Әйтәсе килгән сүзбашым – әдәби әсәр аша милләтләр дә, шәхесләр дә мәңгелеккә теркәлеп калдырылалар дип уйлыйм мин. Әсәр чын мәгълүматлы, милли булырга тиеш.

Татар тарихында без яшәгән чорда пәйда булган БӨЕГЕБЕЗ – Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең эшчәнлеген күреп, тоеп яшәгән без – яшьтәшләре аның турында мәгълүматлы әсәр язып чыгара алган Рабит Батуллага зур рәхмәтлебез, дисәм, ялгышмыймдыр!

«Илбашы» әсәре Минтимер Шәрип улы яшәгән мохитне нәкъ булганча тасвирлавы белән кадерле. Анда әсәр героеның яшәеше, нәселенең эш-гамәлләре ниндирәк булганлыгы автор тарафыннан нык өйрәнелеп теркәлгән. Шуннан чыгып, мин бу әсәрне киләчәктә язылачак әсәрләргә чишмә башы – киләчәк буын әдипләребезгә «таяну ноктасы» булыр дип өметләнәм. Ни өчен шулай дип фаразлыйм соң? Башка язучыларга әсәргә кергән хикәяләрнең кайберләрен сайлап алып, үзенә киң күләмле әсәр тудырырга мөмкинлек ачкан ич автор. Шулай итеп, мин бу әсәрне мәңгелеккә юл башы буларак кабул иттем.

Без үзебез яшәгән чордагы вакыйгаларны, фактларда теркәп калдырмыйча, бары тик матур сүзләр белән генә чуарлап, кылынган гамәлләргә карата мөнәсәбәтебезне белдермичә, «куык очыртып» кына яшәсәк, киләчәк буыннар безнең хакта ни уйлар? Ай-һай, гомер кыска – без яшәгән гомер тарих өчен ялт-йолт итеп алган яшен кебек бер мизгел бит ул. Әдипләрдән киләчәккә калырлык әдәби әсәрләр таләп итү мәслихәттер дә.

Шигъри җанлы, әдәбиятны яратучы, театр сәнгатенә мөкиббән киткән, сәясәт өлкәсендә утлы хәнҗәр уйнаткан, милләте өчен җанын фида кылырга әзер торган, янәшәбездәге башка милләтләр белән дус-тату яшәүне хуп күргән, диннең, татар дөньясына рухи азык чыганагы буларак, татар халкын саклап калудагы ролен аңлап эш иткән Илбашыбыз – һәрбарча зурлауларга лаек зат! Без шундый «каты куллы» хуҗабыз булуы белән горурлана да беләбез. Шушы урында үземнең күңелемә хуш килгән бер фактны теркәп китәсем килә. Минтимер Шәрипович театрга премьераларга йөрергә ярата. Театрга аның яратып йөрүенә сәнгать дөньясыннан хәбәрдар булган тамашачылар нык күнегеп бетте инде. Ә менә мине гаҗәпләндергәне шул (үзем дә бу гадәтне мең мәртәбә хуплаган хәлдә): халыкның, Минтимер Шәрипович тамаша залына килеп керүгә, дәррәү басып кул чаба башлавы! Режиссёрлар халыкны җыеп репетиция ясамаган ич.

Форсаттан файдаланып, Минтимер Шәриповичка шәхси мөнәсәбәтемне дә белдереп үтим әле. Ул Аязымның иҗатына беркайчан да битараф булмады. Аязны һәрвакыт төрле тантаналарга үз янәшәсенә дәшеп ала торган иде. Анда алар иҗади хәрәкәтләр барышы турында да фикер алышырга җәй таптылар. Мин, Аязның хатыны буларак, аңа мең-мең рәхмәтлемен.

**Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА**

# МИЗАН БУРАНЫ

ХИКӘЯ

Көн кичкә таба авышса да, Сәйдә карчык белән Зарифа карчык әллә ни ашыкмадылар. Ара ерак түгел, ат юлны белә, ә төн аяз булырга охшаган иде. Әле мәҗлес беткәч тә алар, йокы бүлмәсенә чыгып, Балтай (Бал түтәй) белән әллә ни кадәр сөйләшеп утырдылар. Ике ел элек, Бәләкәттәйнең (Бәләкәй түтәй) җеназа мәҗлесендә очрашканнан бирле күрешкәннәре юк иде әле. Утыра торгач вакыт та җитәрлек узган. Инде өйдәгеләр кунарга калу турында да сүз кузгата башладылар. Балтай ныклап ук кысташа башлады:

– Ярар, әллә нигә бер килеп, кунып китсәгез дә гөнаһ булмас. Иртәгә таң башыннан кузгалырсыз. Әнә, телефон бар, шалтыратып кына әйтәбез дә хәзер. Гөлчәчәк, бәбкәм, бар әле телефонны кара, эшлиме?

Шул арада, сап-сары чәчле матур кызчык, әбисенең итәгеннән шуып кына төште дә, түр бүлмәгә таба йөгерде.

– Юк, юк, юк, Балтайкаем, мәшәкатьләнмәгез дә, нитмәгез дә. Кайтабыз. Мөхәммәтгазиземнең иртә таңнан ат җигеп эшкә менәсе бар. Юк, юк. Кайтабыз, – дип тәкрарлый-тәкрарлый, Сәйдә карчык кайтырга җыена ук башлады. – Әйдә, кем, ни, Зарифа, киен син дә. Кузгалыйк, Аллага тапшырып.

– Ыкы, ыкы, – ди-ди, Зарифа карчык та караватка өеп куйган киемнәр арасыннан үзенең тунын тарткаларга кереште.

– И-и-и, юкка сүз кузгаттым ахрысы. Утырыр идегез әле бераз. Аннары, әнә, Шәрифҗан озата барган булыр иде, – дип, Балтай ашыга-ашыга түр бүлмәгә чыгып, аш өстәленнән күчтәнәчкә дип, аннан-моннан камыр ризыклар чүпли башлады. Сәйдә карчык, матур беләзекле кулларын Балтай ягына болгый-болгый, чыгуга таба ашыкты.

– Берни кирәк түгел, Балтайкаем. Сыйландык, булды. Мәшәкатьләнмә дә, нитмә дә, салма бер әйбер дә. Менә исән-сау гына кайтып җитсәк, шуңа бик шөкер.

...Алар күрше авылның капкасын чыкканда, караңгы төшеп, буран уң яклап, басудан себереп китергән карны юл кырыйларына сылап маташа иде инде. Әлегә әллә ни куркыныч күренмәсә дә, көчәергә исәпли ахры, дип, Сәйдә карчыкның эче сызып куйды.

– Кай арада кузгалган бу буран?

Сәйдәнең пошынуын сизенгәндәй, Зарифа да, әллә ниләр күрер кешедәй, элпәле күзләрен буран аша караңгы басуга текәде.

Зарифадан аермалы буларак, Сәйдә карчыкның ат чанасына утырып гомерендә беренче тапкыр төнгә каршы юлга чыгуы түгел иде, әлбәттә. Буранда да калгалаганы булды. Бүген дә хәл гадәттәгечә кебек иде. Тик ат кына, нидәндер шикләнгәндәй, колакларын торгызып ашыга. Курыкканга юш килә, дигәндәй, кинәт урман ягыннан җилгә ияреп бүре улаган тавышлар да ишетелгәләп куйды.

– Сөбханаллаһ! – Зарифа карчык, җылы толыбы эченнән мамык шәлгә төргән башын чыгарып, тавыш килгән якка колагын куйды.

– Буран күргәнең юк мәллә, шаккаттың, – дип дустын ачуланган булды Сәйдә карчык. – Курыкма, җил урман ягыннан исә. Тапмыйлар алар безне.

– Тапмас, ди. Бүре бит ул! – Зарифа карчык юлдашына көлемсәр караш ташлады.

Бераз икесе дә тын гына бардылар. Зарифа карчык, зур толыбын сөйрәп, чананың түренә үк шуышып килде дә, аркасын чана кырыена терәп, дилбегәне җай гына тарткалап баручы Сәйдә карчыкка таба борылып утырды.

– Яшь чаклар түгел шул, Сәйдәкәй. Бирешеп киттек бераз.

– Юк сүз сөйләмә, Зарифа. Нинди бирешү ди? Карт кеше, әнә, урын өстендә ята. Ә без әле-е-е! Аллага шөкер, ат җигеп, буранда сызгырып аштан кайтып киләбез!

Зарифа карчык эндәшми генә тагын елмаеп куйды.

– Картлык безгә якын килергә куркып тора ул, Зарифа. Без тиз генә картаер өчен шушы тормышны кордыкмыни? Син картлык дип телеңә дә алма башка. Исемен әйтүгә, шалт итеп килер дә басар яныңа.

Сәйдә карчык шәпләнеп, кулындагы камчысын өскә алып селкеп, «һай-һай»лап атны куган булды.

– Әле үткән көз Сәкинә карчык урманнан төшеп килә иде, – дип дәвам итте Сәйдә. – Мин бозаулар алып төшеп киләм. Нишләп йөрисең болай бик иртә, дим? Әй, ди бу, иртән торсам – картлык өскә атланган, чир бугазга ябышкан, ди. Мин әле сезне шушылай өскә атландырып ятыйммы, дидем дә, сикереп торып урманга менеп киттем. Менә, бераз язылып төшеп киләм әле, ди.

– Сәкинә карчыкмы? Илаһым, ул гомергә шул булды. Туксан тулгач, яңа тешләр чыга башлый икән, дип, шатланып йөри, ди.

– Ник, чыксын! Яңалары чыксын.

Карчыклар кеткелдәп көлешеп куйдылар. Икесенә дә бераз хәл-куәт кереп киткәндәй булды. Буран да тынып киткән сыман тоелды. Алар, кәефләнеп, иреннәрен генә кыймылдатып пышылдап, нидер укый-укый, төймәләнгән изүләрен ачып, куркудан кысылган күкрәкләренә иркен сулыш алдылар.

Ике авыл арасы ерак түгел, нибары дүрт чакрым. Төн аяз булса, утлары әллә кайдан балкып, үзенә чакырып торыр иде. Утлар бүген алдан да, инде арттан да күренмәде.

– Сәйдә, – диде Зарифа карчык. – Безнең синең белән болай чанага утырып чыкмаганга да хәйран еллар бит инде.

– Менә, чыктык бит. Буран кузгалды хәтта.

Авыл фермасын узуга, юл тармакланып, бер чаты кыйгачлап басуга алып чыга. Шул басу юлыннан ялгыш менеп китмәсәк кенә ярар иде, дип пошаланды Сәйдә. Шуңа күрә, як-ягына каранып, һаман юлны чамаларга тырышты. Юлдашын борчуга салмас өчен, ул бу шиген кычкырып әйтмәде. Аннары, толыбы эченә сыенып, күзләрен йомып, баядан бирле дога укып баручы дустын бүлдерәсе дә килмәде. Дога кирәк иде бүген аларга!

Бу вакыт эчендә, авыл зиратын инде күптән узган булырга тиеш булсалар да, аңа җитәрәк менәсе текә тауга да килеп җитмәгәннәр иде әле. Сәйдә зур түземсезлек белән атының шул тауга күтәрелә башлавын көтте.

Кинәт, якында гына бүре улаган тавышка, барган җиреннән ат сискәнеп туктап калды. Сәйдә карчык, көр тавыш белән «на-на-на»лап, дилбегәне күпме генә селтәсә дә, ат бер адым да атламады. Хәтта аның алда барлыгы да күренмәде. Чөнки күз ачкысыз кара буран, шушы чанада утыручы икәүне генә яшәештән аерып аласы килгәндәй, аларны тоташ стена булып уратып алган иде.

– Килеп җиттек, Зарифа. Ач капкаңны киереп, – диде Сәйдә, дилбегә тотып өшегән кулларын тыны белән җылытып.

– Аллаһның кодрәте шушы микәнни, Сәйдә? Аллага тапшырган!

Карчыклар тын калып, бу киеренкелекнең ни белән бетәсен көттеләр. Вакыт аз иде. Уйларлык та вакыт юк иде. Әйтерсең, яшәеш аларны бураны белән кысрыклап кара стенага китереп терәде дә, сакка бүреләрен утыртты.

Кызганыч! Сиксән ел гомернең шушылай бетәчәге кызганыч иде! Алар бит икесе дә ап-ак түшәкләргә ятып, балаларына акыллы сүзләр әйтеп, яхшылап бәхилләшеп, матур үлем турында хыялланганнар иде.

– Сәйдә, селкенми генә утыр. Артыңа борылма. Ахры, артыңда бүре тора. Эндәшмә, – диде Зарифа карчык, пышылдап.

Сәйдә эчтән генә калтырап куйды. Гөжләп башына кан йөгерде. Кинәт тирә-як чайкалып тора башлады. Ул, бүренең алдына ук тәгәрәп төшүдән куркып, аякларын җай гына шудырып, тезләрен Зарифаның җылы тәненә терәде.

– Килеп басканмы, Зарифа? Артта ук торамы?

– Буран тынып торган арада башы күренеп киткән сыман. Толыбыңа каплан да әкрен генә чанага ят.

Сәйдә карчык шулай эшләде дә. Хәзер инде икесенең дә колагына бүре улавы да, буран сызгыруы да түгел, доң-доң йөрәк тибеше ишетелде. Доң-доң, доң-доң! Соңгы тибешеме? Яшәргә иде, диешеме?

– Безнең ат исән микән ул?

– Белмим? Исәндер, – дип җавап бирде Сәйдә.

«Килдеңме тагын, әй син, зур башлы соры бүре? – дип күңеленнән генә эндәште Сәйдә. – Ничә тапкыр юлыма чыгып та тотынмаган идең? Әле бураннар булыр, очрарсың, дигән идеңме? Теге вакытта, чанага салып төрмәгә алып киткәндә дә чыккан идең. Аша, өзгәләп ат, дип ялвардым. Тимәдең! Рәнҗедем сиңа! Менә тагын килеп артыма бастың. Бу юлы рәнҗеп калмасын, дисеңме?»

– Сәйдәкәй, – дип, уйларыннан бүлдерде аны Зарифа карчык. – Әйдә, мондарак шуыш. Икебез бер тирәдәрәк булыйк. Эзләүчеләр булса, дим.

– Ни сөйлисең син, Зарифа? Үзебез кайтып җитмәбез, дисеңмени?!

Сәйдә карчык акрын гына алга табан шуышты да Зарифа карчыкның итәгенә башын салды.

– Кайтабыз, Сәйдә, кайтырбыз. Менә таң сызыла башлагач та, буран басылыр. Кайтырбыз, иншаллаһ, – дип пышылдады Зарифа.

– Бүре һаман шундамы, Зарифа? Күренәме?

Сәйдә карчык, толыбыннан башын чыгарып, тын гына бүре булырга тиешле якка карап торды, тик эндәшмәде.

– Зарифакай, син миңа рәнҗеп китмә инде, яме.

– Нәрсә өчен?

Зарифа, кайчандыр Сәйдәнең авызыннан шушы сүз чыгар, дип көткән иде. Көтә-көтә, ни өчен икәнен дә, көткәнен дә оныта башлаган иде инде.

– Теге еллар... 43не әйтәм инде.

Зарифа карчык авыр сулап куйды.

– Buласы булды инде, Сәйдә. Рәнҗешләр дә күңелдә йөри-йөри искерделәр. Тузанга әйләнеп сибелеп кала баралар. Рәнҗемим, Сәйдәкәй, рәнҗемим. Син дә миңа рәнҗемә.

Карчыклар тагын тынып калдылар. Аларны инде, котырынган буран да, хәтта бүре дә куркытмый иде кебек. Алар, шушы аяусыз төндә пышылдашып

кына булса да, гомер буе күңелләрен сызлаткан төенне чишәргә, ниһаять, андагы рәнҗеш-үкенечләрне шушы буранга чәчеп, бушанып калырга телиләр иде кебек. Шуңа буран да күмеп китәргә ашыкмады, һәм бүре дә, өсләренә ташланудан тыелып, бу икәүнең сүзләре беткәнен сабыр гына көтте сыман.

– Авыз тулы кара кан булса да, кешегә сиздермәдек, дус яшәдек. Рәхмәт сиңа шуңа, – диде Сәйдә, Зарифага сыена төшеп.

Зарифа карчык үрелеп, толыбының итәген тартып, Сәйдәнең ачылып киткән иңнәрен каплады.

– Сәетгалиемнең бәхете булмады. Дөньяда урынын таба алмый бәргәләнде-бәргәләнде дә китеп барды. Уллары да гомерле булмады. Нәселе корысын, дип рәнҗегән булгансыңдыр.

– Ә минекеләр, Зарифа?

Сәйдә, башын күтәреп, күзләре белән Зарифаның йөзен, карашларын эзләде.

– Аллаһы Тәгалә күптән бизмәненә салган инде, барын да. Оҗмаһы да, тәмугы да шушында булган, Зарифакай.

Зарифа карланып туңган бияләйләре белән битләрен, күзләрен сыпырып куйды.

– Синең ул көнне минем йортка тентү җибәргәнеңне ишеткәч, җир убылгандай булды. Балалар өчен курыктым. Өйдә булган бар ризыкны җыеп, төенчеккә төйнәп, бакчага, кар астына алып чыгып күмдек. Ходаем, өлкәнем Сәетгалиемне генә алып китмәсәләр ярар иде, дип Аллаһтан ялвардым. Ул безне ач үлемнән коткаручы иде. Инде котылдык, дигәндә, Шәрифулла килеп керде. Ломы белән бар җирне тишкәләп бетерде. Сине коткарасы килгәндер. Аны да син җибәргән, диделәр.

Сәйдә карчык, бер-берсеннән йөзләрен яшергән шушы мәрхәмәтле буранда, дустының хөкемен кабул итәргә әзер иде.

– Җибәрдем, Зарифакай. Минем дә бит, синеке кебек, итәк тулы бала иде. Шул кемдер урлаган өч йөз илле грамм икмәк өчен төрмәгә барасым килмәде.

Зарифа эндәшмәде. Ул, чана кырыена башын куеп, тын гына сулкылдады.

– Бүре, имеш, – диде Сәйдә. – Бүре дә булдымы безгә дошман, Зарифа? Безнең теткәләнеп беткән җаннар кирәк микән аңа? Безнең агулы итне ашамый ул.

Игелекле иде буран! Ул, бу икәүнең әле яшьләрен, әле елаудан калтыранган иңнәрен, әле бозлана башлаган итәкләрен себереп, туктаусыз чана тирәли әйләнде. Карчыкларның авызыннан чыккан һәр сүзнең сер икәнен белеп, башка беркем ишетмәслек итеп, кайсын-кая куды, таратты, йотты, гаип итте.

– Сәетгалиеңнең гаебе зур икәнен белдең, Зарифа. Тик, ләм-мим, беркемгә дә белдермәдең.

Сәйдә калтыранып, әллә сулыш алырга, әллә тамагына утырган төерне йотарга дип тукталып калды. Аннары, кытыршы куллары белән Зарифаның өшегән аякларын, кулларын сыпырды.

– Мин хәзер рәнҗемим. Онытым инде мин аларны, Зарифа. Бәлки, мин дә шулай эшләгән булыр идем... Балалар бит. Ачлык, ялангачлык... Кеше кешене ашарга әзер чаклар иде шул.

Зарифа эндәшмәде. Ләкин толып аша Сәйдә аның авыр сулавын да, сулкылдавын да тойды.

– Елама, Зарифа, мин аны шул вакытта ук аңлаган идем инде. Исламгалинең үчен аласың килде синең.

– Юкны сөйләмә. Үч аласым килсә, сине төрмәгә алып киткәч, өч балаңны

үземнең дүрт ач тамак янына сыйдырыр идемме? Аннан әйләнеп кайтканыңнан соң, йорттан-йортка тилмереп йөрмәсен дип, үзеңне дә керттем. Миндә яшәдең. Үч, имеш. 41дә үк үлгән иде бит инде Исламгали. Болай да тилмереп җан биргән кешенең үчен алып буламы?

Зарифа, дустының салкыннан кызарып шешенгән кулын өстеннән алып, читкә этмәкче булды. Ләкин, базнат итми, аны ипләп кенә, әле аз гына җылысы калган толыбы астына яшерде.

– Яхшы күңелле кеше син, Зарифа. Шуңа Исламгали сине яратты.

Зарифа карчык, урыныннан калкып, Сәйдәнең йөзен күрәсеме, әллә иңнәреннән аласымы итте. Тик хәле җитми, кире чүкте.

– Сәйдә, кузгатмыйк Исламгали рухын. Хәзер нигә кирәк? Ул бит безне ташламады. Үпкә чире белән комиссовать итеп кайтаргач, ут күршебез Хәтмулла, дезертир дип, ялган данын таратты. Син аны яклап сүз әйтә ала идең. Син дә үчләштеңме?

– Ничек итеп? Ул минем сөяркәм, дип яклап барырга идеме? Заманасы нинди иде соң?

Зарифа карчык эндәшмәде.

– Утырып кайтканнан соң, кеше миннән йөз чөергәндә, мине дустың иттең, – диде Сәйдә, елаудан шешенгән йөзен өшегән куллары белән каплап. – Син кылган изгелекләрне кайтарып бетереп булмас, Аллаһ шаһит.

– Барында да Сәетгали хакы. Мин дә бит синең алда бурычлы идем, – диде Зарифа, ниндидер хәлсез тавыш белән. – Минем дә бит, бер килеп, Аллаһ каршына басасы булыр...

Сүзләр өзелде.

– Менә бәхилләштек тә.

Сәйдә әллә нидән сискәнеп, дусты ягына күз ташлады. Зарифаның йөзе тыныч, күзләре йомык иде. Дога укый, дип уйлады Сәйдә. Аннары, үрелеп кенә Зарифаның агарынып киткән йөзен толыбының киң якасы белән каплап куйды да, аны гәүдәсе белән ышыклап, бүреле якка борылып утырды.

– Ашаса мине ашасын, Зарифа. Мин әзер! Син качып кал! Сиңа тими ул. Ул минем арттан килгән. Мине күптән сагалап йөри инде ул, ач соры бүре. Күрдеңме, кылган гөнаһларым бүре булып минем артыма баскан. Йә, Хода...

Сәйдә карчык, тезләренә басып, өшегән кулларын күккә, бураннан да югарырак күтәреп, анда өстә кемнеңдер җылы кулын тоясы килепме, бер талпынды да хәлсезләнеп чанага ауды.

...Таң сызылганда, буран да тынды. Кайдадыр якында гына мотор тавышы ишетелде.

...Эзләүчеләр, чана янына килеп җиткәч, сәер күренештән аптырап калдылар. Бу урында бервакытта да кот салмый. Ике авыл арасындагы юл, төн буе буран себергәнгә көзге кебек ялтырап тора. Сәйдәнең аты, туры юлдан бер адым да тайпылмый, зират янындагы тау итәгенә килеп туктаган. Карчыклар, әйтерсең, бераз хәл алыр өчен генә туктаганнар да, елмаешып, мамык шәлгә төргән башларын җылы толыпларыннан салкынга чыгарып, чана түренә сөялгәннәр иде. Ә әйләнә-тирәдә төн буена бүре туе булган кебек, чана тирәсе эре-эре эзләр белән тапталып беткән иде.

**Лира ИБРАҺИМОВА.**
*Алабуга*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Гәрәй РӘХИМ**

## ИЛЛЕ БЕР

Марсель Галинең «Уены-чыны бергә» рубрикасын алып барганын белеп:

– Мин күп итеп кыска-кыска юмор яздым, шуларны «Казан утлары»нда бастырасым килә, – дидем.

Марсель тавышын бөереннән чыгарып, эре генә җавап бирде:

– Ким дигәндә иллене китер, шуннан өч-дүртен сайлап алырмын, – ди.

Икенче көнне үк нәкъ илле юмор алып килдем.

Ниһаять, Марсельдән телефон хәбәре килде.

– Гәрәй, – ди бу, – укып чыктым, журналда күренерлек булсын өчен синнән бер юмор кирәк.

Минем инде ачуым чыкты.

– Иллесеннән берне дә таба алмадыңмыни? – дим кырыс кына.

– Гәрәй, син мине аңламадың, илле итеп бастырсак, укучы бу төгәллеккә шикләнебрәк карар, булган-булган илле бер булсын инде...

## Зурладылар

Түрәләр йөри торган махсус чәчтарашка бардым. Миннән алда гына хакимият башлыгы чәчен кыркытып чыкты. Аннан 5 мең сум алдылар. Мин дә чәчемне нәкъ глава фасонында алдырдым. Миннән 10 мең сум сорадылар.

– Нигә алай иттегез? Тегеңәрдән 5 мең, ә миннән 10 мең сорыйсыз, – дим.

– Безнең өчен шагыйрь башы главаныкыннан кыйммәтрәк, – диделәр.

## Заманча төзәтү

Заманында Лев Толстой, яшүсмерләр 18 яшенә кадәр шигырь язып карамаса, аларны психиатрга күрсәтергә кирәк дип, киңәш биргән. Мин бу тәкъдимнең безнең заманга яраштырылган дәвамын тәкъдим итәм: «Әгәр яшүсмер 20 яшьтән соң да һаман шигырь язуын дәвам итсә, аны икенче мәртәбә психиатрга күрсәтеп карарга кирәк.

## Бер рецензиядән

Марсель Галиев догасыз еллар турында «Догалы еллар» дигән әсәр язган.

## Ике мактану

Разил Вәлиевне йөртүче шофёр Рәфкать мактана икән:

– Мин Разил Вәлиевнең үзен йөртәм... Мин аның шофёры...

Дуслары янында Разил Вәлиев мактана икән:

– Мин – Гәрәй Рәхимнең начальнигы...

## Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә Гәрәй Рәхимнән гариза

Дөньяның күренекле акыл ияләре некрологны реклама дип саныйлар. Шуны искә алып, миңа багышланган некрологны газеталарда исән чагымда ук бастырып чыгаруыгызны сорыйм.

## Юмор почмагы

Күренекле татар язучысы Мирсәй Әмир язучыларның бер идарә утырышында тәкъдим кертте: «Чаян» журналында юмор почмагы ачарга кирәк», – диде.

## Түгел

Һәр хатын-кыз – шигырь!..
Тик һәр хатын-кыз шагыйрә түгел.

## Әйтәсен әйтте

Хатыны аңа әйтте: «Синдәй акчасыз акыллы кеше белән яшәгәнче, акчалы аңгыра белән яшәвең артыграк».

## Бәһа

Төн уртасында яңа шигырь яздым да тизрәк хатынга укыдым. Хатыным:«Шигырең әйбәт, үзең начар...» – диде.

## Быелның иң авыр көннәре

Әлеге дә баягы шул экстрасенслар, агымдагы һәр айның авыр көннәрен исәпләп, матбугатта игълан итеп баралар. Мин дә аларга ияреп, икътисади һәм финанс өлкәләрен өйрәнеп, быелгы елның иң авыр көннәре 1 гыйнвардан алып 31 декабрьгә кадәр булыр дип фараз кылам.

## Ертык тишектән көлә

«Нигә ул язучылар, исемнәрен төрлечә язып, укучының башын катыралар икән?..» – дип зарлана ди Гәрәй Рәхим, Родионов Григорий Васильевич, Гөргеригә.

## Бер кулъязма авторына

Сиңа – кулъязма, миңа – аякъязма.

## Берничә мәртәбә

Тәмле телле, көләч, бөтен гәүдәсе килешле ханым белән сөйләшкәндә әйтәм: «Һәй, гомер бушка үтте, мин сиңа берничә мәртәбә өйләнгән булыр идем...»

## Куркып

Татар, эреләнден, дигәннәреннән куркып, тәмам вакланып бетте.



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ӘЗҺӘР

Мин егерме йортлы Яңа Ташлыяр дигән кечкенә бер авылда үстем. Челтерәп аккан чишмәләр, таллар, зирек агачлары, әкрен генә аккан инешне күз алдына китерегез. Тау битләрендә кызарып пешкән җиләкләр, исле гөлләр, мәтрүшкәләр – кыскасы, санап бетергесез төрле-төрле чәчәкләр. Өйдән ишегалдына чыккач та синең җаныңны шушы матурлык биләп ала. Бер сүз белән әйткәндә, үзенә күрә бер оҗмах инде. Урманында, күп булмаса да, җаның ни тели, шул бар: чикләвек, миләш, шомырт, карлыган, кура җиләге дисеңме… Иң сөендергәне шул: ул җирләрне машина-трактор таптамаган, анда зур көтүлекләр кермәгән, табигать ничек бар, шулай сакланып калган. Су буйларында «Йомры күл», «Тирән күл» дигән чокырлар бар, тирәнлеге ике-өч метр, киңлеге өч-дүрт метр. Шул суларда хәтта кушбаш балыклары да йөзеп йөри, нинди зурлыкта икәнен, бөтен матурлыгын күреп була. Шуларга сокланып, кызыгып, ничек кенә тотарга икән дип уйлап көннең үткәнен сизми дә каласың. Мин авылым турында бу сүзләрне бүгенге күзлектән карап язам. Бала чагыңда исә аларга әлләни игътибар да итмисең, чөнки алар синең белән бергә туган, күз алдыңда, җаныңа, күңелеңә шулкадәр сеңеп кереп калганнар ки, алар турында уйлап торырга вакытың да юк. Менә хәзер инде авылны башкача күз алдына да китерә алмыйм. Бүген инде ул авыл юк, зираты гына калды…

### Җиңү килгәч

Балачагым, мәктәптә укыган елларым, нәкъ әйткәнемчә, кайбер әйберләр ниндидер томан эчендә искә төшә. 1945 елгы Җиңү көне, миңа әле биш яшь кенә тулган икән. Без урамның уртасында җыен бала-чага, укучылар, апалар, әбиләр. Кем аягында йөри ала, барсы да «сугыш бетте!» дип кычкыралар. Мин әле сугышның нәрсә икәнен хәзерге мәгънәдә аңламыйм, шулай да хәтергә кереп калган инде. Матур җиз таска агач кисәге белән бәреп Гайшә әбинең: «Война бетте, война бетте, биш малай кайта!» – дип бии-бии кычкырганы әле дә истә. Нишләптер башкаларның алай бик нык шатланганнарын хәтерләмим. Күрәсең, күбесенең йә ире, йә баласы һәлак булгандыр. Ә менә итле аш ашаганымны хәтерлим. Мин яшь чакта сакау идем, кайбер хәрефләрне әйтә алмыйм, бигрәк тә «р» хәрефен. Шуңа күрә миңа: «Яле, «тыр-тыр» дип атны туктат», – диләр. Мин бик каты итеп «тыг-тыг» дип кычкырам. Шуннан барысы да рәхәтләнеп көләләр. Менә бер заман немецчә сөйләшә башладым, сугыштан кайткан кешеләрдән немец сүзләре ишетеп, шуларны сөйләп йөрим. Күрше-тирәләр мине немецчә сөйләтеп рәхәтләнеп көләләр. Күрәсең, немец теле мин сакауга килешеп торган, анда бит «р» хәрефе сакаурак яңгырый. Үзем дә шуннан ниндидер рәхәтлек табам. Беркөнне күрше Мөҗәһит абыйларга кердем, аларның минем яшьтәге кызлары, малайлары бар. Боларга немецчә сөйләп күрсәтергә телим, бик каты кычкырып: «Агбайтен, агбайтен! Угыс шваен…»[1] — дип сөйли башлаган идем, берәү күткә китереп типте, очып киткәндәй

[1] Арбайтен — эшләргә, шваен — дуңгыз.

булдым .Күтәрелеп карасам, Мөҗәһит абый икән. Куркудан аска җибәргәнмен, ике балактан агып чыкты. Балалары рәхәтләнеп көләләр: «Астына нитте, астына нитте, нимес!» Мин елый-елый су буена төшеп киттем. Тегеләр минем арттан үрти-үрти киләләр. Ыштанны салып, тегеләрне куарга тотындым. «Әтигә әйтәбез, әтигә әйтәбез, ул синең җаныңны ала!» – дигәч кенә туктап калдым. Мөҗәһит абый «Буралы»да авыл советында эшли иде. Кайчагында, салып кайтса, хатыны Нурлыхадә түтигә кул күтәрә. Андый вакытта минем әни Нурлыхадә түтине безнең базда яшереп тота. Икенче көнне, тегесе айныгач чыгарып җибәрә. Мөҗәһит абыйның сугышта нервылары беткән, салып алса, бик тиз кыза, нәрсә эшләгәнен дә белми. Ул эчкән көнне барыбыз да бик куркып тора идек. Хәтта безнең этне – Актүшне атып үтерде. Аны жәлләп елаганым һич истән чыкмый.

## Сәхнәгә чыктым!

Мәктәп урам аркылы, каршыбызда гына иде. Шуңа күрә мин алты яшемдә беренче класска укырга кердем. Ничек кердемме? Бер партага килдем дә утырдым. Укытучы Сәхипҗан абый куып чыгармады тагын, ул яңа гына сугыштан кайткан, малае Рим белән бергә утыртты. Мәктәптә өч класс бергә укый, хәзер инде хәтерләмим, ничә бала булганбыздыр, унмы, уникеме. Өйдә бәләкәй генә кара такта бар, шунда язарга өйрәндем акбур белән. Кайвакыт ак таш та була. Язарга исә дәфтәр юк иде, өйрәнгәч кенә бирделәр.

Беренче тапкыр сәхнәгә чыктым. Шул беренче класста укыган чакта октябрь бәйрәменә (7 ноябрь көнне) сәхнәгә чыкканымны хәтерлим. Сәхнә шул мәктәпнең идән такталарын бераз югары күтәреп эшләнгән бер почмак, аны концерт беткәч кире сүтеп урынына куялар. Безне карарга бөтен авыл җыелгандыр, мәктәп тулы иде. Нәрсә сөйләгәнемне хәтерләмим. Хәзер уйлап куйдым: кияргә юньле кием юк, буй кечкенә, үзем сакау, җитмәсә яман кычкырып, «р» хәрефен әйтергә теләвем булгандыр, болай да сүзем аңлашылмый, бәләкәй көчек кебек ырылдаганмындыр гына. Шуңа күрә авыл халкы рәхәтләнеп көлгәндер. Халык көлгән саен минем көлдертәсем килә. Рәхәт бит, көләләр, кул чабалар. Алар бит мин сөйләгән әйбердән көлмәгәннәр, минем үземнән көлгәннәр. Авыл кешесе кызык эзләргә, күңел ачарга ярата ул... Ни генә булмасын, бәлки, шул вакытта җанымда сәхнә дигән «җен»не ярату уянгандыр.

## Җәннәткә кердем!

Тагын бер вакыйга исемә төште. Миңа биш-алты яшьләр чамасы булгандыр. Зәйтелҗиһан апа белән Сарман янындагы Әлмәт авылына Җәннәт апага кунакка барыш. Җәннәт апа Әлмәт авылы кешесенә кияүгә чыккан иде. Күз алдына китерегез: безнең авылдан Әлмәткә егерме чакрымнар булыр. Әйткәнемчә, миңа — биш, Зәйтелҗиһан апага унбер яшьләр тирәсе. Шулай барабыз-барабыз, барып кына җитә алмыйбыз бит. «Апа, мин арыдым, — дип елый башладым. – Аяклар шеште, атлап булмый!» Апа: «Җылак тәре, әни сиңа: «Барма, балакаем, ул бик ерак», – дип күпме ялынды. Үзең бит, үкерә-үкерә: «Барам, барам!» – дип яшьләреңне агыздың, хәзер түз инде! Җылама, җылак, әгәр тагын бер тапкыр еласаң, үзеңне генә калдырам да китәм!» – дип котымны алып бара. Шулай талаша-талаша, елый-елый бара торгач, иртән-иртүк чыккан кешеләр Әлмәт авылына кич белән генә килеп җиттек. Килеп җиттек тә авыл уртасында басып торабыз: кая барырга, кемгә керергә белмибез. Бездән: «Сез кемгә килдегез соң?» – дип сорыйлар. Без: «Апа белән җизнигә», – дибез. Халык аптырап, безгә карап көлеп тора. «Апа белән җизни күп була ул, кемгә килдегез, исемнәре ничек?» – дип сораштыралар. Җизнинең исемен белмибез дә белмибез инде, каушаудан апаның исеме дә онытылган. Кинәт искә төште. Сөенечебездән: «Җәннәт апа, Җәннәт апа!» – дип кычкырабыз. Аны беләләр икән,

түбәсе калай белән ябылган бик матур бер йортны күрсәттеләр, безнең авылда андый матур йорт юк! Бу йортка керү миңа ул чакта җәннәткә эләгү белән бер булды! Җизнинең исемен барыбер тиз генә искә төшерә алмадык. Соңыннан искә төште, Хаҗи Әхмәт бит инде, бик кунакчыл, киң күңелле кеше иде, мәрхүм. Авылда кешегә исем-фамилия белән эндәшмиләр ич. Апа, җизни, абый, җиңги, әти, әни. Кире авылга кайтканда, бер апа мине бәләкәй арбага утыртып, Карамалыга хәтле тартып алып кайтты. Ул Минзәләбаш авылыннан булган икән. Мин хәзер күз алдына китерә алмыйм, биш яшьлек баланы әни шундый ерак юлга ничек чыгарып җибәргәндер? Күрәсең, бик нык теңкәсенә тигәнмендер инде. Бүген биш-алты яшьлек балалар шундый ерак юлга җәяү йөрерләр иде микән, ышанып бетмим. Шулай да Җәннәт апага кунакка бару күңелемә онытылмаслык хатирә булып кереп калды.

## Зелпеләндек!

Мин инде алты-җиде яшьтә үк урман буена җиләк җыярга бара идем. Урман безгә ерак түгел, булса бер-ике чакрымдыр. Шуңа күрә һәрвакыт үзем генә җиләк җыярга яратам, бер кешене дә ияртмим. Иптәшләрем миңа үпкәлиләр, нишләп бездән качасың, диләр. Гадәтем шундый, кеше белән җиләк җыя алмыйм, хәзер дә шулай. Урманга барган саен матур, эре, кызарып пешкән җиләкләрне сабагы белән җыеп әнигә алып кайтам. Ул авыру булганга урманга җиләккә баралмагач, күрсен әле, нинди матур җиләкләр була, сабагыннан өзеп ашасын дип үземчә сөендермәкче идем. Әни шунда: «Рәхмәт, балакаем, җиләкләреңне әтиеңә бир, аның күңеле булыр», – дигәне әле дә хәтердә.




Беркөнне шулай әти белән зелпе тамыры җыярга барабыз. Ул зелпе тамырына нәрсәдер биргәннәр, күрәсең, акчамы, бүтән әйберме, анысын хәтерләмим. Күп кешеләр зелпе агачын белми, чөнки аның ашый торган җимеше юк. Бераз балан агачына охшаган, бик зур булып үсми. Чәчәк атар алдыннан тамырын кисеп алабыз, балта белән суккалагач, тамыры тиз кубып төшә, шуның каерысыннан каучук ясыйлар, янәсе. Ул сирәк-сирәк кенә үсә, аны эзләргә кирәк. Мин эзләп табам да әтигә кычкырам: «Әти, монда кил, мин таптым!» Әти килә дә эшен башлый, мин тагын эзләргә тотынам. Тагын берсе очрый, тагын кычкырам. Шулай көне буе эзли торгач, шактый күп җыелды зелпе тамыры. Мин инде кайтырбыз дип уйлап тора идем. Әти әйтә: «Килгән-килгән, тагын бераз җыйык әле, улым», – ди. Мин эзләп чокыр кырыеннан барам, монда юк, тукта әле, бераз өскәрәк менеп карыйм дип өскә күтәрелгәч, озак кына эзләгәч, зелпе очрады. «Әти, монда кил, мин таптым!» Әтине көтә-көтә хәл җыям, бераз вакыт үткәч, тагын кычкырам: «Әти, монда кил, мин таптым!» Бик матур зелпе бу. Нишләптер әти генә күренми. «Әти, мин монда, нишләп килмисең?!» – дип кычкырам. Бер тавыш та ишетелми. Нәрсә булды икән дип әти янына киттем. «Әти, син кайда? Нишләп дәшмисең?» Әтине эзләп теге калдырган зелпе янына барып җиттем, әти юк. «Әти! Әти! Син кайда?!» – дип бар көчемә кычкырам. Бер тавыш та ишетелми. Югыйсә шушында гына калган иде бит. Куркудан тәнем калтырана башлады.

Нишләп мине ташлап китте икән? Бу урманнан хәзер ничек чыгарга? Күз алдына китерегез, ул чагында миңа сигез яшь чамасы. Шуңа менеп, үземнең кай төштә икәнемне күрергә дип бер зур усак агачы янына килдем. Карасам, усак агачы төбендә әти ята, янында балтасы, киндер капчыгы, үзе яланбаш. Әти үлгән! «Әти, әти, нәрсә булды, нишләп үлдең», — дип җылый-җылый әтине акрын гына селкетә башладым. Әти кымшанмый да! Янында күпме утырганмындыр, анысын хәтерләмим, бары тик күздән бертуктаусыз яшь ага, инде нишләргә белмичә: «Ярдәм итегез! Ярдәм итегез, әти үлгән!» – дип җан ачысы белән кычкырганым гына хәтеремдә. Бервакыт акрын

гына әтинең күзе ачыла башлады, ул: «Улым, су китер», – диде. Мин чокырга, тау астына төшеп киттем. Башымдагы фуражканың төбенә әрекмән яфраклары салып, әтигә су алып мендем. Әти эчте дә калган су белән битен юып төшерде. Минем аптырап җылап торганны күргәч: «Улым, мин бит үлемнән калдым, — диде. — Әнә, күрәсеңме, усак агачында шөпшә оясы булган, мин аны умарта күче дип торам. Балта белән бер-ике мәртәбә суккан идем, шунда бик зур кара шөпшә муенымны чакты. Башыма агач белән китереп суктылармыни. Аңымны югалтып аудым. Мин үтергән шөпшә шунда булырга тиеш». Чыннан да, әтинең эшләпәсе янында үлгән шөпшә ята. Андый шөпшәне үз гомеремдә күргәнем булмады, бармак озынлыгы, сары-кара төстә, карарга куркыныч. Ишеткәнегез булдымы икән, җиде еллык шөпшә чакса, кеше һәлак була диләр бит. Әти акыртын гына торды, кулына балтасын алды, миңа зелпе тамырларын күтәрергә кушты. Без аны киндер капчыкка җыя идек. Берзаман әтинең бөтен бите шеште, күз күрмәс булды. Көч-хәл белән өйгә кайтып егылды. Болай да бер үпкәсе булмаган кеше бит — шактый азапланып ятты. Шөкер, әни төрле авырулардан дәвалый иде, монда да әти исән-сау калды.

## Чия чияләнгәндә



Мин җәй буе урманда ни очраса, шуны җыям. Шулай бер көнне Мөдәррис әйтә, Буралы урманында, Тырыш янында чия бар диләр, әйдә шунда барыйк, ди. Безнең авылга алты-җиде чакрым булыр. Әйтүе булды, киттек Мөдәррис белән чия җыярга. Чыннан да, урыны-урыны белән зур-зур чиялекләр очрый, биек түгел, булса шул билдән булыр. Бервакытны карыйм, каршымда кып-кызыл эре-эре чияләр үсеп утыра, Мөдәррис килеп җиткәнче дип тиз-тиз җыя башладым. Берзаман аяк ниндидер йомшак әйбергә тиеп китте. Карасам, еланнар чия төбендә уралып яталар, куркуымнан әллә кая сикердем. Нишләргә, шундый эре, кызыл чияләрне җыймасаң, әрәм була бит, бер таяк сындырып алдым да еланнарны куам. Ысылдыйлар, ләкин качалар тагын. Күрәсең, еланнардан куркып башкалар ул чиялеккә кермәгәннәрдер. Мөдәррис килгәнче ярты чиләккә якын чия җыйдым. Шулай итеп, кичкә хәтле бер чиләк чия җыйдык, авылга көтү кайтканда гына кайтып җиттек. Иртәгә тагын барырга сүз куештык. Шулай итеп, көн саен чиягә китәм. Шактый җыелды бит. Әни аны кар базына төшереп куя. Вареньесын эшләр идек, шикәр юк. Беркөнне Мөдәррис: «Әйдә, Әлмәткә чия сатарга барабыз, анда аның стаканы бер тәңкә», — диде. Миңа шул җитә калды: «Әни, мин Әлмәткә чия сатарга барам», — дидем. «Юк, улым, утыз чакрым җиргә чияңне ничек күтәреп барырсың?» – диде әни. «Бер чиләген биштәргә салып аркага асам, бер чиләкне кулда тотам, юлда машина очрар әле. Әлмәттә абый янында кунам, мин бит үзем генә түгел, Мөдәррис белән». Бик ялына торгач, әни түзмәде, риза булды. Иртән-иртүк, көтү куганда чыгып киттек. Минзәләбаш авылы безгә биш-алты чакрымнар, килеп җиттек, ул хәтле арымадык та. Күрәсең, әйбер ташып тән күнеккән булгандыр. Минзәләбаштан Кәшер авылына хәтле самосвал машинасында утырып бардык. Аннан соң бурильщиклар автобусына утырдык, шулай итеп исән-сау Әлмәткә килеп җиттек. Әлмәтнең Горький клубы янында мин чия сатарга утырдым. Мөдәррис исә туганнарына китте. Килеп утыруым булды, бала-чага сырып алды, тәмле микән, кабып карыйк дип чиямне акрын гына ашый да башладылар. Күреп торам, болар минем чиямне ашап бетерәчәк! Шулвакыт

таза гына бер апа тегеләрне минем яннан куып җибәрде. Чиямне сатып бетергәнче янымда торды. «Рәхмәт, апа!» дип, чия биргән идем, алмады. Күрәсең, мине ятим бала дип уйлагандыр инде. Чөнки яланаяк, яланбаш, өстә бары күлмәк-ыштан гына. Йөз дә алтмыш тугыз сумлык чия саттым. Абыем Нурулла Әлмәттә шофёр булып эшли иде. Аның янына кунарга киттем. Абый кешеләрдә фатирда тора, көчкә эзләп таптым үзен. «Йә ничек, чияңне сатып бетердеңме?» Абыйга бер стакан чия дә калмаган, сатып бетергәнмен. «Менә йөз алтмыш тугыз сумлык чия саттым, кара, күпме акча эшләдем. Иртәгә шикәр, чәй, күмәч алам», – дип акчаны бүлгәләп ята идем, абый әйтә: «Акчаң күп, әйдә, бер шешә вино алыйм, соңыннан бирермен», – ди. Бер дә бирәсе килмәсә дә, әйдә, миннән көчтәнәч булсын дип бирдем инде. Йокларга ятуым булды, стенадан минем өскә әллә нәрсә коела башлады. Утны яндырып карасак, бөтен җиремне кандала сырып алган. Тышка чыгып утырдым инде. Уянып китсәм, кояш чыккан. Абый белән саубуллашып, кибеткә чыгып киттем. Ике чиләккә дә ап-ак ипи, чәй, шикәр тутырып, Мөдәррис белән кайтырга чыктык. Бәхеткә каршы самосвал очрады. Минзәләбашка кайта икән. Әлмәтне чыгуыбыз булды, коеп яңгыр ява башлады, бөтен өс-баш манма су булды. Машина көчкә-көчкә кайта, юлдан чыкса, беттең. Минзәләбаш күперен чыкканда, машина сөрлегеп китте, Мөдәррис белән Минзәлә суына сикердек. Күтәрелеп карасак, машинаның бер тәгәрмәче генә эләгеп тора. Куркуыбыздан суны ерып ярның икенче ягына чыктык. Ничек исән калганыбызны хәзер дә аңлый алмыйм, күлмәк, чалбар ертылган, тән сыдырылган, кан тамып тора. Шулай да биштәрдәге чиләк тә, кулымдагы чиләк тә исән, ычкындырмаганмын. Әмма ап-ак ипи дә, чәй белән шикәр дә су белән буталып бетте. Мөдәррис мине тынычландырырга тырыша: «Борчылма, хәзер кибә ул, су чиста бит», — ди. Чыннан да, кояш чыккач, киемнәребез кибә башлады, ак ипи белән шикәр дә бераз җилләгән сыман булды. Көчкә авылга кайтып җиттек. Өйгә кайткач, әни минем хәлне күреп: «Юк, балакаем, моннан соң беркая да әйбер сатарга йөрмисең, ризалыгым юк!» – диде.

### Сталин үлгән!

Беркөнне иртән-иртүк, укырга барганчы, безгә Раиф килеп керде. «Әйдә минем белән, мин сиңа бер әйбер әйтәм», – ди бу. «Нәрсә әйтәсең, әйт». Үзе нәрсә икәнен әйтми, йөзе ап-ак, бик нык курыккан. Авылда Раифларның шырпы кабы хәтле генә радиоалгычлары бар. «Мә, тыңла, үзең аңларсың». Колакка радионы куеп тыңлый башладым, бик ямансу музыка уйный. Берзаман русча: «Говорит Москва. Сегодня 5 марта 1953 года скончался товарищ Сталин», – диделәр. Авылдан Буралы мәктәбенә чыгып чаптык. Аз гына буранлап тора. Буралы авылы безгә өч-дүрт чакрым. Мәктәпкә бик тиз килеп җиттек. Мәктәп ишегалдында балалар кар атышып, куышып, берсен-берсе карга батырып уйныйлар. Мин ишегалдына килеп керүгә үк: «Малайлар, ишеттегезме, Сталин үлгән!» —дип кычкырдым. Берсе дә миңа борылып карамый, уеннарын дәвам итәләр. Түзмәдем, мәктәп баскычына менеп: «Сталин үлгән, Сталин үлгән!» – дип бар көчемә кычкыра башладым. Бөтенесе тып-тын калды. Шулвакыт укытучы Сәлихов абый, ул директор да иде, мине карга алып атты, борыным белән бозлы карга кадалдым. Борыннан кан ага, үзем җылый-җылый: «Сталин үлгән, Сталин үлгән, радиодан ишеттем. Нишләп миңа ышанмыйсыз, ышанмасагыз, Раифтан сорагыз!» — дидем. Сәлихов абый мәктәпкә кереп китте. Малайлар мине сырып алды: «Йә, сөйлә, кайчан ишеттең?» «Әле яңа гына радиодан сөйләделәр». – «Нәрсә диләр? Ничек үлгән, кем үтергән? Бәлкем, ялгыш ишеткәнсеңдер?» «Юк ла инде, Сталин үлгән!» Берсе дә миңа ышанмый. Ничек инде Сталин үлсен, ул үлсә без нишләрбез, ничек яшәрбез дип уйлыйлар инде. Берсе: «Беләсеңме, сине моның өчен нишләтәләр, мәктәптән куалар, ялган хәбәр таратканың өчен җаныңны алачаклар», — дип тә әйтте әле хәтта. Борыннан кан ага, үзем калтырыйм: «Нишләп миңа ышанмыйсыз, үлгән инде, үлгән». Шунда мәктәптән укытучым Нәзирә апа килеп чыкты: «Балалар,

классларыгызга керегез». Минем кыяфәтне күреп: «Әзһәр, син дә класска кер», – диде. Бераздан линейкага тезделәр. Шунда Сәлихов абый Сталинның үлгәнен әйтте. Барсы да елый, бигрәк тә укытучылар, бер мин герой кебек басып торам. Күрдегезме, янәсе, миңа ышанмаган идегез, хәзер елагыз инде барыгыз да. Еламый кара, Сталин үлгәндә дә еламады дип утыртып куюлары да бар. Шул кадәре бөтен күңелем, җаным белән рәнҗедем, ник шунда елап үлмиләр. Күрәсең, бу хисләрем бөтен кыяфәтемә чыккан булгандыр. Укытучым Нәзирә апа минем янга килде дә: «Сине директор Сәлихов абыең үз янына чакыра», – диде. Минем әле директор кабинетына кергәнем юк иде, чөнки гел «5»кә генә укыйм. Сәлихов абый яныма утырды да, болай диде: «Әзһәр, энем, Сталинның үлгәнен кычкырып йөрмиләр. Бу бит шатлык түгел, бик зур кайгы. Син Сталинның үлгәненә сөенәсең дип уйлаулары бар. Бу безнең ил өчен иң зур кайгы. Үзеңә сабак алгансыңдыр дип ышанам, хәзер сиңа тагы да яхшырак укырга кирәк. Бар, безнең ни турыда сөйләшкәнне беркемгә дә әйтмә». Мин, җиденче класста укый торган малай, директор Сәлихов абый әйткән мәгънәне каян белим. Ничек инде мин Сталин үлгәненә сөеним ди. Минем бары тик үземне генә күрсәтәсе килде, сез берни дә белмисез, ә мин беләм, шул гына. Сәлихов абыйның сүзен тоттым, бу турыда беркемгә дә сөйләгәнем булмады.

## Җеннәр чолганышында

Инде минем тормышымда бик аянычлы фаҗига белән бетәчәк бер вакыйганы да искә төшерәсем килә. Миңа тугыз яшьләр чамасы булгандыр, без көне буе су керәбез. «Син бүген ничә мәртәбә кердең? Унике мәртәбә. Ә син? Унҗиде мәртәбә». Үзебез дер-дер киләбез, йөз ап-ак, күзләр генә утырып калган. Шунда Фазыл: «Әйдәгез минем белән, мин сезгә мәк орлыгыннан тәмлерәк бер әйбер ашатам», – ди. Ул яр буеннан бармак башы хәтле генә кипкән әйберләр җыеп алды да, учына салып уды да: «Менә, карагыз, бу чыннан да мәктән тәмлерәк», – дип ашый да башлады. Мин дә кабып карадым, орлыгы мәккә охшаган, үзе чыннан да  тәмле. Яр буенда бернәрсә дә калдырмадык, ашап бетердек. «Әйдәгез, яңадан су керәбез!» Киттек су буена җыйнаулашып. Берзаман Фазыл бөтен тәнен кара ләмгә буяп, кешеләргә кызык күрсәтәм дип урамга менә башлады. Безгә җитә калды, Фазылдан калышасы килми, тәннәребезне кара ләмгә буядык та, кычкыра-кычкыра, урам буйлап кайтабыз. Кешеләр безгә шаккатып карап торалар. Безнең турыга килеп җиткәч, әни мине өйгә алып кереп китте. Аннан соң нәрсә булганын хәтерләмим.

Төнлә уянып киттем, кешегә охшаган, зур башлы, кызыл күзле, аяклары бәләкәй бер җен самавыр артыннан чыкты да миңа таба килә башлады. Куркуымнан кычкырып җибәрдем. Әни: «Нәрсә булды, балакаем?» – дип, башымнан тотты. «Әни, әни, кара әле, самавыр артында нинди кеше басып тора?» Шулай дип әйтүем булды, ишектән икенчесе  килеп керде. «Әни, әни, мине үтерәләр!» – дип кычкыра башладым. «Балакаем, монда бит беркем дә юк, күзеңә генә күренә торгандыр. Кызым, Зәйтелҗиһан, бар, әтиеңне алып кайт». (Ул төнге каравылда икмәк саклый иде). Әти кайтканчы тегеләр өйгә кереп тулдылар, минсиңайтим, мендәрләр белән тегеләргә ташланам, әнинең күлмәкләрен ертып бетердем. Әти нәрсә булды дип килеп кергәч, әни елый-елый минем хәлне аңлата. Җеннәр әтидән куркып, акрын-акрын гына чыга башладылар. «Әти, әти, әнә тегендә, ишек янында берсе качып калды, ул мине үтерәчәк, коткарыгыз, коткарыгыз!» – дип кычкырам. Әти: «Улым, анда беркем дә юк, күзеңә генә күренә торгандыр. Яле, минем яныма кил, кара, монда беркем дә юк». Әти башымнан, әни кулларымнан тотып утыра. Әни нәрсәдер эчертте, сөтме, әйрәнме, хәтеремдә калмаган. Менә таң атты, ә мин косам да косам. «Үләм, үләм, ярдәм итегез», — дим. Тәмам хәлсезләнеп сәкегә аудым, шуннан нәрсә булганын хәтерләмим. Аңыма килгәндә, бу ниндидер саташу, төш сыман тоелды.

Хәзер генә аңладым, без бит тилебәрән орлыгы ашаганбыз. Шул безне харап иткән. Безне дип шуңа әйтүем, иптәшләрем дә нәкъ минем шикелле авырганнар.

Ничек исән калганбыздыр акылдан язмыйча. Мин болай да төсле төшләр күрә идем, шуннан соң инде кайвакыт йокларга да куркып яткаладым. Бу вакыйганы нигә искә төшердең дип сорасагыз, шуны гына әйтә алам. Бүгенге күзлектән караганда, без нindидер наркотикка охшаган әйбер ашаганбыз, күрәсең. Юкса мондый коточкыч саташу булмас иде. Көне-төне эчкән кешеләрнең генә күз алдына җеннәр күренә дип сөйләгәннәре хәтеремдә калган.

Менә гомерем дә узып китте, яшьлек елларының бер өлеше шушы мизгелләрдә генә калды. Гомер узган саен, күп әйберләр онытыла, әле ярый бераз хәтердә бар икән. Минем туган авылым күптән юк инде, зираты гына калды. Язмышым белән кызыксынган кеше булса, китаплардан укып белерсез, бәлки, иң кызыгы шунда язылгандыр.

**Әзһәр ШАКИРОВ,**
*Татарстанның һәм Россиянең халык артисты,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

## «ТАНЫМЫШ ДӘРЕСЕ»

Бу кызыклы дәрес дәвам итә. Шаржлардан безгә кемнәр карап тора – язып җибәрегез. Биш дөрес җавап өчен – «бишле», дүрт дөрес җавап өчен «дүртле» куячакбыз. Мондый имтиханда хәтта «икеле» алу да җиңел түгелдер. Шигъри эпиграммаларыгызны өстәп җибәрсәгез, журнал редакциясе чыгарган «Печән базары» дигән китап белән дә бүләкләрбез.

1




2



3



4



5



*Шаржларның авторы* – **Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.**

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

Шушы исемдәге быелгы бәйгене дә башлап җибәрәбез менә. Аның шартлары һәм башламнар 1нче санда бирелде.

«Башлам» дигәннән, хикәяләрнең бисмилласы кебек булган ошбу кыска текстларга аларны язучылар арасында да ярыш ачтык бит әле. Иң күп хикәяләрне кайсы башлам һәм кайсы автор яздырыр икән? Һәр башлам артына авторның инициалларын куеп барачакбыз, ел бәйгесе төгәлләнгәч, җиңгән өч авторның тулы исемнәре дә күрсәтелер.

Бу хикмәтле берничә җөмләне киләсе ел бәйгесе өчен инде хәзер үк әзерли башласагыз була – бу ярышка һәркайсыбыз кушыла ала.

## Бала каргышы

**– Безнең әткәйне син урладың! Син!**

**Ләйлә, бу сүзләрне ишеткәч, өстенә кайнар су коелгандай, бөрешеп, кечерәеп калды. Яшүсмер кызның йөрәге читлектәге нәни кошчыктай бәргәләнергә тотынды.** *(А.Ә.)* Аягында басып торырлык хәле бетә баруын тоеп, ул яңа гына явып үткән карлы җиргә тезләнде.

– Үсеп кенә җитим, мин аны барыбер үтерәм. Син дә әтисез калачаксың! – диде малай, күзләреннән очкыннар чәчеп. Ләйлә маңгаен карга батырды. Аның күзенә каршысында басып торучы малай күренми дә инде. Никадәр каты кычкырып сөйләсә дә, сүзләре дә бөтенләй ишетелми. Ә малай сөйләвен белә!

– Әтиең булмагач, син дә ямаулы чалбар киеп йөрерсең, кешеләр йокыдан уянганчы, әниеңә ияреп кар көрәргә чыга башларсың. Әтисез үсүнең ничек читен булуын үз башыңнан үткәргәч, аңларсың.

Ләйләнең бер сүз дәшми торуы да малайны сөйләвеннән туктата алмады!

– Беләсең килсә, минем әнием синең әниеңнән матуррак! Ул иреннәрен генә буяп йөрми, көн саен чәчтарашка барып причёска ясатырга аның вакыты гына юк! Үсеп җитеп, акча эшли генә башлыйм әле! Мин аны җир йөзендәге иң матур әни итәчәкмен! Беркайчан да безне ташлап китми торган икенче әтием дә булачак! Ул миңа компьютер да алып бирәчәк, аны интернет челтәренә дә тоташтырачак!

Өзми-тукталмый гына шушы сүзләрне әйтеп бетерде дә, малай бер мәлгә тынып калды. Шунда гына ул Ләйләнең башы белән карга кадалып, тынсыз торуына игътибар итте:

– Ләйлә! Күзеңне ач! Миңа синең әтиең кирәкми! Безгә әтисез дә яшәү әйбәт. Тиздән мин әниемә подъездлар җыештырырга да булыша башлыйм. Әни миңа үзе компьютер алачак!..

Ләйләнең һаман да бер сүз дә дәшмичә хәрәкәтсез тезләнеп торуын күреп, малай куркып калды. Үз-үзен белештермичә, ул атыла-чаба күршедәге тугыз катлы йортның соңгы подъездына йөгереп керде. Лифтның килеп җитүен көтеп торырга түземлеге җитмәде, өченче катка баскычлар буенча очып диярлек менде дә Ләйлә яшәгән фатирның кыңгырау төймәсенә басты. Ишектән халатының аскы төймәләрен эләктерә-эләктерә Ләйләнең әнисе килеп чыкты. Ананың күзенә күтәрелеп карарга кыймыйча, малай бер-берсенә бәйләнешсез берничә сүз генә әйтә алды:

– Сәвия апа! Мин –Илдар! Анда Ләйлә. Тизрәк! Мин аңа тимәдем… Ул үзе…

Урамда салкын кыш булуга да карамастан, Сәвия ялан аякларына өйдә кия торган башмакларын гына элеп, Илдар артыннан йөгерде. Аның: «Балам! Үлмә! Сабыр ит! Аллам! Сакла газиземне!» дигән үзәк өзгеч ялварулы сүзләре малайның баш миен бораулыйлар иде кебек.

Ананың борчылу сәбәбе дә җитди шул: Ләйләсенең йөрәгенә ясалган операция

җөйләре йомыла гына башлаган иде әле. Илдар белән Сәвия чабышып килеп җиткәндә, Ләйлә инде аякларына торып баскан, учындагы кары белән чигәләрен, бит алмаларын ышкып тора иде. Сәвия, кызының исән-саулыгына сөенеп, Ләйләне дә, Илдарны да кысып кочаклады.

## Кыш бабайга хат

**Бер-бер артлы унбиш квартирны үткәч, уналтынчысында Кыш бабай – Әүхәтне урта яшьләрдәге хатын һәм тынлык каршы алды. Өстәлгә табын ризыклары һәм шампан шәрабе куелган иде. Аның аптыраулы карашыннан хатын кызарды һәм: «Зинһар, ялгыш уйлый күрмәгез! – диде.** *(Р.Ю.)* – Ә Кар кызыгызны кайсы квартирда онытып калдырдыгыз? Үзегез дә югалудан курыкмыйсызмы?»

– Дүрт яшьлек улының температурасы күтәрелеп киткән, шунлыктан соңгы өч квартир үземә генә калды инде. Бу минем соңгы ноктам – Рәхимова Рәхилә яшәгән квартир түгелмени? Аңа дүрт яшь булырга тиеш иде бит.

– Әйе, бу – Рәхимова Рәхилә квартиры. Нуль санын сызып ташладым да үземә-үзем Кыш бабай чакырырга булдым әле. Берничә сәгатьтән минем туган көнем җитә – кырык тула. Кырык яшьне билгеләп үтәргә ярамый диләр, шуңа күрә котларга беркем дә килмәячәк. Кыш бабай, гафу ит! Яңа елны ялгыз каршылыйсым килмәгәнгә генә, бу ике бокал белән шампан шәрабе куелды.

Әүхәт туган ягына Өркет каласыннан өч ел элек кенә, хатыны – Наташаның вафатыннан соң күчеп кайткан иде. Әби-бабалары – Балтач районы кешеләре, мулла нәселеннән. Чиләбе якларына сөргенгә сөрелгәннәр. Ә ул Өркет каласының үзендә туган. Хатыны Наташаны никах укытырга күндерә алмады Әүхәт, бәлки, шуңа күрәдер Аллаһы Тәгалә аларны бала сөю бәхетеннән мәхрүм иткәндер?! Өч ел инде Чаллыда яши, әле кочак җәеп каршы алырдай татар хатын-кызын очратканы юк.

Рәхилә исә балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Ә үз баласы юк! Бер чегән хатыны аңа быел кияүгә чыгасын әйткән иде. Тик менә елның соңгы сәгате дә узып бара бит инде!

Берара кара-каршы басып торганнан соң, сәер тынлыкны Кыш бабай бозды.

– Рәхимова Рәхилә! Кыш бабайга нинди һөнәреңне күрсәтергә җыенасың? Шигырь сөйлисеңме, җыр җырлыйсыңмы?

– Кыш бабай! Җырлыйм да, шигырь дә сөйлим, биим дә. Туган көнемне ялгыз каршылыйсым гына килми. Ә капчыгың төбендә миңа дигән бүләгең калганмы соң?

Кыш бабайның капчыгы төбеннән соңгы бүләк килеп чыкты. Шунда ук ул:

– Әйдә җырла, кызым. Бүләкне җырлагач кына бирәм! – диде. Рәхиләнең моңлы җыры Кыш бабайны кара урман уртасына алып кереп киткәндәй булды.

Яңа ел башланырга санаулы минутлар гына калып бара иде. Шунда Кыш бабай Рәхимова Рәхилә кулына бер бит ак кәгазь белән ручка тоттырды һәм болай диде:

– Рәхилә кызым! Хәзер инде, яңа елда ниләр булуын телисең, бөтен теләкләреңне дә шушы кәгазьгә язып бир! Ә без аны бөкләп, шушы банкага салып куярбыз. Бөтен теләкләрең дә кабул булыр!

Рәхиләнең бит алмалары кызарып чыкты, ике дә уйлап тормыйча: «Бу Кыш бабайның үземнеке генә булуын телим!» дип язды, кәгазьне үзе әйбәтләп бөкләп, Кыш бабайның кулындагы банкага салып куйды.

Кремль сәгате сукты. Кыш бабайга тунын һәм бүреген салып, Рәхимова Рәхилә дигән кыз белән бергә чәкешеп, шампан шәрабе эчәргә туры килде. Икенче бокал Рәхимова Рәхиләнең туган көне хөрмәтенә күтәрелде һәм аңа Кыш бабай тарафыннан матур теләкләр теләнде.

Тунын һәм бүреген киеп, теләкләр язылган банкалы капчыгын күтәреп, Кыш бабай чыгып киткәндә инде кояш чыгып килә һәм яңа елның ап-ак кары ява иде. Рәхимова Рәхилә аны озатып калды. Кыш бабай аның теләк хатын укырга онытмаса гына ярар иде инде.

## Кәнфит бирәм!

**Өстәл янында тәмләп чәй эчкән Шәмсенур әбине ачыргаланып кычкырган бала-чага тавышы сискәндереп җибәрде. Ул урыныннан торырга теләде, ләкин** *(Р.Р.)* аяклары гына аңа буйсынырга теләми иде. Соңгы вакытларда аякларының тыңламый башлавы берничә мәртәбә булды инде. Алар тик торганда гына, тез турыннан катып калалар, тик тезләрне җайлап кына ике кул белән ышкый торгач, Шәмсенур әби тагын берни булмагандай атлап китә. Соңгы елларда авыл урамында бала-чага тавышы кимеде. Кул астындагы берәр нәрсә белән тәрәзә пыялаларын чәлпәрәмә китереп, бөтен көчеңә кычкырсаң да, тавышыңны ишетүче табылмаячак. Килене Фәнүзә фермада, ә улы Мансурның кич җитмичә өйгә кайткан көне бөтенләй юк. Телефон трубкасы белән ара да югыйсә дүрт кенә метр, аннан да файдаланып булмый – буе җитми!

Йокы бүлмәсе ишегеннән чыккан төтен исе Шәмсенур әбинең борынына килеп керде. Яшисен-яшәгән, ашыйсын-ашаган булса да, терелән утта янып үләсе килми. Оныкчыклар бигрәк кечкенә шул әле, ут-күз белән уйнауның нинди хәвефкә китерүен аңламыйлар. Кычкырсаң, аларны куркытуың бар, ашыгудан бернинди файда да юк. Шәмсенур әби бисмилласын әйтеп ике кулы белән тезләрен угалый башлады: «Әй, Аллам! Ут-күзләр зыяныннан, хәвеф-хәтәрләрдән үзең саклый күр!» – дип туктаусыз догаларын укыды. Башка чакларда «Аятел-көрси»не укыгач, буыннар язылган кебек була иде бит! Бүген аның да файдасы сизелми.

Шәмсенур әби җайлап кына урындыгыннан идәнгә шуып төште, терсәкләренә таянып йокы бүлмәсенә таба шуышты, җайлап кына ишекне ачты:

– Гөлнурым – күз нурым! Монда кил әле, күрше Фәүзия апаңны гына чакырып кер, кәнфит бирер идем үзеңә!

– Әбием, нинди кәнфит бирәсең? – дип, Гөлнур, өлкәнрәк оныкчык, йокы бүлмәсеннән килеп тә чыкты.

– Суыткычтагы иң тәмле кәнфитне үзең сайлап алырсың. Тик башта Фәүзия апаңны чакыр! Әбинең аяклары авырта, дип әйт! Илнурны да үзең белән иярт! Яланаяк көенчә генә йөгерсәгез дә ярый, тизрәк кенә булыгыз!

Балалар бүлмәдән чыгып йөгерү белән Шәмсенур әбигә җиңелрәк булып калды. Ичмасам оныклар исән калыр! Әле ярый, күршедәге Фәүзия эштән кайтып җиткән! Атыла-бәрелә, тыны бетеп, ул өйгә килеп керде, караватта җыелмый калган калын юрган белән ялкынны төреп сүндерде. Балалар агач идән такталары өстендә кәгазь кисәкләренә ут төртеп, учак якканнар икән. Әле ярый идән паласлары бер читкә җыеп куелган, идәнгә ут кабарга өлгермәгән иде.

«Учак»ны сүндергәч, Фәүзия Шәмсенур әбигә аягына басарга ярдәм итте. Аяклар, берни булмагандай, тагын атлап киттеләр…

**Флёра МӘРДАНОВА.**
*Тукай районы Күзкәй авылы*

## Ландышлар

**Палатада һава бөркү иде. Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары аның битен сыйпады.** *(Р.Р.)* Күргән төшеннән аерыласы килмичә, Ландыш җылы ятагында яткан килеш, тәнен язып, йомшак кына киерелде, күзен йомып, әле генә төшендә ландышлар җыеп йөргән урман аланына кире кайтмакчы, шул чәчәкләрнең исерткеч дәртле исенә өнендә дә исермәкче булды. Авыру хатынның төшенә бүген тагын шул май төне кергән иде.

Ел фасылларының барысын да ярата Ландыш, әмма ямьле яз аен, аеруча майны – өзелеп-өзелеп ярата, көтеп ала. Май башында – беренче оныгының, уртасында – яраткан сеңлесенең, иң ахыргы көнендә бердәнбер улының туган көннәре булганга гына түгел, юк, бу яратуның сәбәбе ландышлардан килә.

Ландышлар! Чәчәкләр бәйләмендә аларның урынын беренче планга куюы – үзенең дә исеме Ландыш булганга гына да түгел, һич юк. Энҗе бөртекләредәй керсез, ак, хуш исле мәрҗәннәргә аның мәхәббәте кыз чагында ук, дөресрәге, студент елларының беренче язында бөреләнде.

… Сессия көннәре иде. Алар баш күтәрми зачётлар, экзаменнарга әзерләнәләр. Бүлмәләреннән чыкмыйча, китап, дәфтәрдәге лекция конспектларын «кимерәләр».

Ниһаять, иртәгә соңгы имтихан! Һәм – ымсындыргыч тәкъдим: иптәш кызының егете аларны культпоходка чакыра икән!

Кызлар ризалаштылар, азык-төлек алуда, ашау-эчү әзерләүдә, хуҗалык эшләрендә ярдәм итәчәкләрен белдерделәр. Әмма егетләр бар эшне дә үз өсләренә алгач, сүз әйтмәделәр.

Идел ярларының табигатен, бар гүзәллеген күреп үскән Әнвәр белән Илсур беренче минуттан ук дилбегәне үз кулларына алдылар. Кирәкле җирдә «Метеор»дан төшеп калып, бер матур алан сайлап, палатка кордылар.

Бергәләшеп учак тергезделәр, алып килгән күчтәнәчләре белән берсен-берсе сыйлап, тәмләп тамак ялгап, чәй эчтеләр.

Казан урамнарында күренмәгән ямь-яшел үлән, алар исемнәрен дә белмәгән дистәләрчә чәчәкләр исеннән, кошлар, чикерткәләр җырыннан, Идел суының тыныч, дустанә дулкыннары шавыннан, яннарындагы егетләрнең итагатьле игътибарыннан – барыннан, барыннан да канәгать иделәр кызлар, бәхетле иделәр…

Менә җир өстенә төпсез коедай тирән тоелган зәңгәр күгә, Зөһрә кызлы ае, кемгәдер күз кысышкан йолдызлары, сихрилеге белән яшь йөрәкләрне ешрак тибәргә мәҗбүр иткән җылы май төне иңде. Яшьләр, учак җылысын тоеп, парларының тән җылысына оеп, озак гәпләштеләр, дөресрәге, төне буе серләшеп утырдылар. Учак сүнгәч, таң алдыннан гына палаткага кереп, татлы йокыга талдылар.

Иделнең җәннәткә тиң яры буеннан китәр сәгатьләр якынлашкач, егетләр кызларга сюрприз ясадылар. «Сюрприз» дигәннәре — ландышлы зур гына алан иде. Кызларына алар шул аланнан ландыш җыеп бүләк иттеләр…

Аһ, ул көннәр, җылы хатирәләр! Ландыш исеннән баш әйләнгән мизгелләр! Кайларда калдыгыз сез, яшь гомерләр? Гомергә дә аерылмас кебек тоелган сердәшләрем, шул парлары белән гаилә корган иптәш кызларым, сагынды, бик сагынды сезне Ландыш, сизәсезме шуны?

Ландышлар бүләк иткән егетне май аенда гына түгел, бик еш искә ала Ландыш. Искә ала һәм китап шүрлегендә гел бер урында торган, беркайчан да шиңми торган фарфор ландышларга күз сирпеп тынып кала, чын ландыш исе килеп бөркелгәндәй тоела…

– Кара инде, тагы йоклап киткәнмен, – дип, Ландыш караватыннан җиңел генә торды, өстенә ак чәчәкле яшел җылы халатын киде. Тәне, башы, башындагы бар уйлары, ни гаҗәп, сихәтләнгән, тәртипләнгән иде. Яшьлегендә бер генә тапкыр, әйе, әйе, бер генә тапкыр, аның белән бергә күргән, йөргән ландышлы аланның, сихри май төненең гүзәллеге, тылсымлы сихеренең гомере буе үзен җылытыр, җанын дәвалар дип башына да китермәгән иде ул вакытта Ландыш. Хастаханәнең бөркү һавалы бүлмәсендә ул шушы хакыйкатьне, ландыш чәчәкләренең җанына- рухына тәңгәл килгән серен аңлады менә.

**Надия ВӘЛИЕВА.**
*Казан*

## Җимерек баскыч

**Баскыч белән бергә Ришат та түбәнгә очты. Җир белән күк бергә тибрәлгән мизгелдә малайның башыннан: «Беттем!» дигән уй сызылып үтәргә өлгерде.** *(А.Ә.)*
Аның авыр гәүдәсе биек итеп өелгән печән эскертеннән ыргылып көчле итеп җиргә

килеп бәрелде. Җитмәсә, таушалган, сынган баскыч гөрселдәп Ришатка каты итеп тондырды да әле, һәм ул аңын җуйды бугай.

Хуш исле җәйге урман печәне эченә күмелгән Хәмдүнә төнге аяныч хәлне тиз арада аңлап алды һәм түбәдән ярымпышылдап:

–И Ходаем, менә нәрсә күрәселәрем бар икән! Ришат! Ришат, бәгърем, ни булды үзеңә! Әйт инде, җавап бир инде татлы җимешем, — дип түбәнгә таба эндәште. Тик Ришат дәшмәде.

Бу мәлдә Хәмдүнә гаепне үзеннән дә, Ришаттан да, хыянәттән дә, җимерек баскычтан да таба алмый каушап калды.

— Инде нишләргә хәзер, печән эскертеннән түбәнгә сикереп Ришат янына төшсәм, үзем имгәнәм, төн уртасында ярдәм сорап кычкырсам, Ришатның хатыны Фәридә ишетеп башымны туздырачак, башкалар ярдәмгә килсәләр, адәм көлкесенә калам бит, – дип, Хәмдүнә күктәге тулган айга ялварып үз-үзен өзгәләде.

Ә айга барыбер, ул төне буе йолдызлы күктә рәхәтләнеп йөзде дә йөзде һәм, бу кызганыч, хыянәтле төннең ничек тәмамланганы белән кызыксынмыйча, таң алдында юк булды.

Ике көннән соң, җимерек баскычтан егылып хушын җуйган, аяк-кулын имгәткән Ришат район больницасында аңына килде.

Икәү бергә печән өйгәндә хатыны аңа: «Егылып имгәнүең бар, яңа баскыч ясa», – дип әйткән иде бит, ник тыңламадым икән. Их, хатынны тыңлаган булсам, бу хәл килеп чыкмый иде бит! –дип, исенә төшереп үкенеп тә куйды мескен ир.

Шундый уйлар белән чуалып ятканда, баш врач аңа:

– Сезнең хәлегезне белергә килгәннәр, – дип кычкырды.

— Кем килгән? Хатыны Фәридәме? Сөяркәсе Хәмдүнәме?

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
*Сембер өлкәсе Иске Кулаткы районы*

## Алтын тәңкә чыңы

**Җырлый-җырлый бәрәңге чүпләгәндә, Нәфисәнең күзе ниндидер кечкенә тимер кисәгенә төште. Аны ул саклык белән генә кулына алды. Бу – әнисенең югалган тәңкәсе иде...** *(Р.Р.)*

«Күземә күренәме әллә?» – дип, башта ышанмыйчарак торса да, кулындагы тәңкә беркая да эреп югалырга теләмәде, киресенчә, Нәфисәнең учына батып, пешереп алгандай булды. Ул, кеше-фәлән күренмиме дигәндәй, тирә-якка каранып алды. «Шөкер, беркем дә юк бугай», – дип, алтын тәңкәне җәһәт кенә кесәсенә таба шудыртты. Күршеләре, атна-ун көн тирәсе элек үк, яңгырлар башланганчы дип, бәрәңгеләрен казып, эшләрен бетереп куйган иде.

Ялгызы көн иткән Нәфисәнең генә ярты ындыр бакчасы ята. Дөрес, моңа кадәр күршеләре гел ярдәмләшеп килде. Әнисенең: «Күршеләр аяк басасы булмасын йорт-ихатага!» – дип әйткәнен истә тотып, быел аларга эндәшергә кыймады. «И гомер, бигрәк тиз үтәсең, әле язын бәрәңге утыртканда гына әнисе исән иде... «Җиңәсезме, бетәсезме әле?» – дип кереп-чыгып йөргәннәре әле дә күз алдында тора.

Быелгы җәйге чиллә көннәрнең берсендә китте дә барды шул әнисе.

Нәфисә, бик кыен булса да, әнисенең васыятен аяк астына салып таптамады – күршеләр белән аралар өзелде. Югыйсә тату яшәделәр күршеләре белән. Аш-судан бер-берсен калдырмадылар, бәйрәм-туйларны да, тормыш мәшәкатьләрен дә уртага сала иделәр. Бигрәк тә Нәфисә ун ел яшәгән иреннән аерылып кайткач, иң зур терәкләре, әлеге дә баягы, шул ике як күршесе булды. Онык сөю бәхетеннән мәхрүм Санияттәй күрше балалары белән юанды.

Быел бәрәңге утырткан көнгә кадәр шулай булды. Ә икенче көнне...

Ул кичне Нәфисә мунча яккан иде. Өмәдән соң башта әнисе белән үзе юынып чыкты, аннары күршеләрен дәште. Икенче көнне иртән Санияттәй чәчен тарап үрә башлагач, бер тәңкәсен таба алмый азап чикте. Халат, камзул кесәләрен кабат-кабат актарды, аннан Нәфисәне мунчага йөгертте. Эзләп-эзләп тә таба алмагач, Нәфисә әнисенең кушуы буенча күршеләргә дә кереп чыкты. Тик ул бер тәңкә суга төшкән кебек юк булды да куйды. «Инәкәйнең кыз чагындагы тәңкәләрен ничә еллар саклап тагып килдем, кайсы рәхмәтлесе алды икән?» – дип, атна буе сөйләнеп йөргәннән соң, Санияттәй урын өстеннән бөтенләй тормас булып китте. Нәфисә аны никадәр генә тынычландырырга тырышса да, Санияттәй дөньядан ваз кичкән кыяфәттә ята бирде. Алай гына да түгел, беркөн килеп: «Күршеләрнең берсенең генә эше, тәңкәм мунчада төшкән, шуннан табып алган кайсысыдыр», — дигән карарын да чыгарып куйды. Нәфисәнең аңа каршы: «Әнкәй, язган булса, табылыр тәңкәң, бар да Ходай кулында, син бит үзең әйтә идең, иң аламасы – кеше рәнҗеше, юкка шикләнмик әле», – диюен ошатмады. «Син, балакай, яшь шул әле, белмисең, инәкәй төсенең ни икәнен. Үлемтеккә җыеп куйган акчам югалса да борчылмас идем, җирдә калдырмаслар, күмәрләр дияр идем. Инәкәй төсе бит кабатланмый... кабатланмый...»

Нәфисәдән бәрәңге казу кайгысы китте. Ул, кош тоткан кешедәй куанып, күршеләренә таба юл алды.

Бүген таң алдыннан Нәфисәнең төшенә әнисе керде. Икегә үреп салган чәчендәге алтын тәңкәләрен чыңлатып, исән чагындагыча, күршеләрен кунакка дәшеп йөри иде ул.

**Люция ӘБЛИЕВА.**
*Казан*

## Сихерче

**Мөрсәлимә абыстай «Ясин»ны бертөрле көйгә салып укый. Беренчесен генә чыкмый инде ул бүген. Иртәдән үк чакырттылар аны. Ятим калганнан соң, тәрбияләп үстергән абыстасын ахирәткә әзерләргә җыенуы. Тик әҗәл дигәнең карчыкны һаман җиңә алмый. Сәбәбе куәтле: ул онытгын көтә, аңа гына әйтәсе васыяте мөһимрәк шул!** *(Р.Х.)*

Белә-күрә торып әҗәл көтеп ятудан да мәгънәсез нәрсә юктыр. Оркыя ялгыз яши, ялгызлыктан да авыр нәрсә юклыгын, тик ятканның үләксә икәнен, берәүгә дә кирәкмәгән кеше булуын белә. Мөрсәлимә абыстай да аның хәлен белмәс иде, Алладан курыкканга килеп йөридер.

Уналтысы тулгач, күңел күзе чибәр егеткә төште. Үзенең исә кеше күзенә чалынырлык кыяфәте булмагач, аның игътибарсыз калдырачагы көн кебек ачык иде, тик җуясы килмәде шул. Авыл очындагы җиргә сеңеп беткән салам түбәле өйдә җәйге ачы эсседә башында тискәре ягы әйләндереп киелгән колаклы ирләр бүреге, өстендә билен бау белән кысып бәйләп йөри торган сәер хатынкай яши. Таң атса, бәләкәй кул арбасына капчык салып, тау башыннан тизәк җыярга чыгып китә, көн кыздыра башлаганчы кайтмый. Кергән-чыккан кешесе дә юк. Оркыя аның читтән төшкән килен, иренең ул килеп, авырга узганчы ук, халык дошманы дип Себергә сөрелүен, кияргә алмаш күлмәге дә юклыгын, сыер тизәген кыш ягып, өй җылытырга җыйганын белми, сихерче дип уйлый иде. Күрәзәчегә барма, башыңа кайгы алма дигәнне ишеткәне бар юкса. Шулай да көлдә пешергән арыш икмәгенең яртысын кисеп алып, әлеге карчыкка илтте. Башта читләтеп, гашыйк булу хәлләрен сөйләде, соңыннан егетне карату өчен ни дә булса эшләп бирүен үтенде. Карчык, битендәге бармак башы кадәре миңен бармагы белән сыпырып куйгач, сиреньнән ботаклар өзеп, зур гына гөлләмә ясады да:

– Мә, кешегә сөйләнеп йөрмә, — диде. — Җиде таҗлысын эзләп табып, «син минеке булырсың» дип нык кына теләп, җиде кат кабатлап, өчесен аша. Калганнары

арасыннан сайлап шундый ничә җиделене калдырганыңны сана, аннары егетеңә илт. Ул да санасын, икегезнеке тап килсә, бүгеннән аныкы булырсың.

– Тап килмәсә?

Карчык кызны шулкадәр юкка ышанадыр дип уйламаган иде. Аның кинәт кәефе күтәрелде, җыерчыклы йөзенә елмаю йөгерде:

– Ул чагында ничәне тапсагыз, шулкадәр көннән кавышырсыз.

Алланың рәхмәте киң. Юраган юш килеп, күрәзәче әйткәнчә килеп чыкты. Алар матур яшәделәр, уллары һәм кызлары туды. Ире үлеп яратса да, Оркыя икеләнде. Сихерләтмәгән булсам, мине күрмәгән булыр иде, ашыктым шул, ихластан яратмыйдыр дип уйлады. Һәм... Печән чабарга киткән ярының җансыз гәүдәсен ат арбасына салып алып кайттылар. Чәчкәләр арасында очып йөргән бал корты чаккан! Моны очраклы хәл буларак кабул итмичә, яшь бичә үзен гаепләде.

Иренең елын үткәргән көнне авылны зәһәр атлар җигеп килгән чегән өере басты. Әллә аш исен сизеп, әллә ире юклыгын белеп, Оркыяның өен сырып алып хуҗалардай кыландылар. Әрсез кыланып, бала-чагалары тәм-томны ялт иттерде, кайсы тавыгын суя, кайсы чистартып, аш өстенә аш пешерә, хатын-кызлары кәрт суга. Юрамнарыннан «скоро уедишь» «замуш пайдуш», дигәннән башкасын аңламады. Кап-кара көдрә чәчле, колагына кыршау шикелле алка таккан бер иркәй кибиткасын абзар буена тугарып, күзен майландырып, кулларын болгап, янына йокларга чакырды. Төнне бергә үткәрделәр. Иркәләшергә тел белүнең кирәге юк икән. Иртән ул ат җиккәләгәнче хатын, барлы-юклы нәрсәсен төенчегенә төйнәп, ике баласын җитәкләп арбага менеп утырды. Яңа тормыш – чегән тормышы башланды, көтүгә ияргән эт сымак ияреп тик йөрде. Бер ел чамасы таборга ияреп йөргәч, аяк тибеп каршы торса да, елтыр дегет күзле чегәне, икенче узганда кереп алырга антлар итеп, татар авылындагы буш ташландык өйдә калдырып китте. Көтеп, ышанып озатты ул аны. Йорт унике яшьлек үксез, ятимә Мөрсәлимәнең мәрхүм әти-әнисенеке икән. Бу хәлләрдән соң җиңгәчәй тиешле кеше кызны сәгате, минуты белән Оркыя кулына китереп тоттырды. Аның кулында ике үз баласы бар бит әле, бер атна да үтмәде, тагын малай тапты — суйган да каплаган чегән инде. Үзе белән бергә биш ятимгә әйләнделәр. Гөнаһка бату турында уйлап, ач утырып булмый, бар белемен эшкә җикте, сихер-михеренең яңа төрләрен уйлап чыгарды, өшкерде, әфсен-төфсен итте, авыл кешеләренә башлап сәлам бирмәде, биргәнне алмады. Исемен берәүгә дә әйтмәде. Шуңа аны йомышы төшкәннәр — «абыстай», читләр исә «сихерче» дип йөртте. Балалары янында кул арасына керә башлаган Мөрсәлимәне калдырып, якын-тирәдәге район үзәкләренә, шәһәрләрдәге базарга чапты: кәрт салды, киләчәк юрады, ышанучыларны сауды. Хәзер инде ул булдыра алганына ышанып эшләде. Күзе, хатыны үлеп тол калган, нәни генә улы булган урыс егетенә төште. Үзеннән күпкә яшьрәк тә, чибәррәк тә иде чукынган. Нәфесне нигә өйрәтсәң, шуны куа. Эт тизәге белән көчле сихер ясап, үзенә каратты, чиркәүгә барып ярәштеләр, баланы онығы итеп кабул итте. (Әле җан бирә алмыйча, чит илдә яшәгән шул бердәнбер үги онығын көтеп ята.) Яңа ире эчмәде, тартмады, акча таба белде, кулыннан эш килде, тик көтмәгәндә чиргә сабышты. Кинәттән ябыгып кипте, күзгә күренеп, чәче коелып, таз башка әйләнде, теле көрмәкләнеп, сүзен әйтәлмичә, эт кебек шыңшыды; карашы пыялаланып катты. Әрә белмәгән эт өенә бүре китерә. Оркыя сихерне кире кайтармакчы иде дә, килеп чыкмады. Корган тормышы чәлпәрәмә килде.

Ул, үзендә колын салган кола биядәй хәлсезлек сизгәч, белгәннәрен Мөрсәлимәгә өйрәтмәкче булды, әмма тегесе якын да килмәде. Кыз, кичләрен күршедәге әбигә кереп, догалар өйрәнде; җомга көннәрендә, аның белән мәчеткә йөреп, вәгазьләр тыңлады. Уналты яше тулгач, бу ипле кызыкайны күптән түгел Төркиядә укып кайткан яшь мулла никахлап үзенә кәләшлеккә алды. Шул көннән башлап Мөрсәлимә абыстай туган йортына эзен суытты.

Оркыяга алма кебек өч баласының берсенең дә игелеген күрергә язмады. Тизрәк онығы кайтсын иде. Бәхиллек алып каласы, баланың әтисе алдындагы гаебен

танийсы иде. Хезмәтенә күрә җәзасы, Аллага каршы барып булмаганны соңлап булса да аңлады, гафу сорап дога укыйсы иде. Тик бер генә дога да белми шул…

…Мөрсәлимә абыстай никадәр ашыкса да, барып җитешә алмады. Ул килгәндә, абыстасы яшәгән йорт янып бетеп, янгын сүндергеч машиналар су сипкәнлектән, кап-кара кисәүләр генә пыскып ята иде. Шулай итеп, Оркыя абыстасының чыга алмаган җанын ялкын алды…

**Сания ШӘРИПОВА.**
*Башкортстан, Бүздәк*

## ХАЛЫК ӘЙТСӘ, ХАК ӘЙТӘ

- Уналты яше тулган кыз энә өстендә бии.
- Кызлы йорт – нурлы йорт.
- Кыз бала – йорт зиннәте.
- Кызларның күз яше иртәнге чык кебек, кояш төшү белән кибеп оча.
- Кызлар киенгәнче кысыр сыер бозаулар.
- Тырнак үстергән кыздан саклан.
- Кыз – алмагач, егет – сандугач.
- Ягымлының шадрасы күренми, сөйкемленең сипкеле беленми.
- Эзләмә матурны, эзлә күңеле яктыны.
- Тышы хур кызы, эче җен кызы.
- Кыз байлыгы – күркәм холык.
- Матурлыктан кырык көндә туялар, матур холыктан кырык елда да туймыйлар.
- Матурлык морат түгел, ямьсезлек оят түгел.
- Матурлык туйда кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк.
- Тауның күрке – таш, кызның күрке – чәч.
- Кат-кат бизәнү – матурлыкка кизәнү.
- Кыз чагым – солтан чагым.
- Кыз тыйнак булса, егет җыйнак була.
- Дөньяда кем гүзәл? Кемне сөйсәң, шул гүзәл.
- Егет җиле белән йөрер.
- Дәрт коймадан сикертә.
- Тиле дәрт оят белмәс.

## Матуркай балык тота

Ямьле җәйләргә дә алыштырмаслык һәйбәт көннәре була алтын көзләрнең. Әбиләр чуагы диләр аны.

...Кояш әллә ни кыздырмый, аркадан кыяр-кыймас, яратып кына сыйпагандай итә. Кышын ызбадагы талгын мич җылысы сыман гына. Ефәк тоҗымнарның сиздерминитми биткә сарылуы да кәефне кырмый. Көн яктысында көмешсу нурлар булып ялтыравы бәйрәм төсмерен бирә. Яңа ел чыршысындагы аллы-гөлле бизәкләреңбер читтә торсын.

Ә һавасы нинди, төсе? Тоташ бәллүр! Шылт иткән өнгә дә чатнап китәргә тора. Һәй, ямансу да һәм күңелле дә соң бу чакларда! Йөзендәге һәрбер җыерчыгы белән елмаеп балкыган әби-сәбиләр мөлаемлыгы, тәмле төшләр күреп ятучы сабый бишеген тирбәтә торган илаһи бер тынлык мәле, яшәү яме, тормыш матурлыгы бар аларда. Адәми затларның җаннарын йомшарта, сафландыра, күңелләренә иман иңдерә торган мохит шундый буладыр инде ул...

Шундый аяз, тымызык, җилсез көннәрдә бәрәңге алулары үзе бер хозур, дөнья рәхәте. Көрәк белән ипле генә селтәнгән саен чем-кара туфрак өстенә ак, кызыл, ал, сары төстәге йомрылары да таралып ятса... Без дә ызандашыбыз Җәмил абый һәм аның чапак телле хатыны белән җай гына сөйләшә-сөйләшә бәрәңге казыйбыз. Дөресрәге, күбрәк Әлфия апаның «тегермәне тарта». Абзый үзе әллә нигә бер генә сүз ката. Кылый күзләренең берсе безнең буразнага төбәлгән кебек: гүя күршеләр уңышын чамалап, көнләшеп карый.

Шулай ипле генә буразна арты буразна аударганда, чәчәкле чиләгенә нидер чүпләгән атлы булып аяк астында чуалган биш яшьлек Динаралары кинәт корт чаккандай чырылдап куймасынмы:

– Әни, карале, Матуркай балык тоткан!

Мондый әче тавышка кызу эшне ташлап, баш күтәрми хәлең юк. Чыннан да, ак маңгайлы кара мәченең янәшәдәге су буеннан менеп килеше иде. Авызында орчык шае теп-тере балык, уйнаклап, бәргәләнә. Мыраухан уттай янган күзләре белән сагаеп карый-карый, карак-угры сыман җиргә елышып ук яныбыздан узып китте дә җәһәт кенә агач келәт астына сызды. Балык тоту һәвәслегеннән уяулыгын җуйган берәр ачыгавызныкын чәлдергән инде бу, дип көлештек тә, кызык бетте шуның белән. Әмма бераздан күрше кызы янә сөрән салды. Мут песинең тагы тыпырдап торган балык әләктереп кайтышы икән. Инде дә тәмам хәйран калдык бу әкәмәткә. Бу юлы чираттагы сәфәренә юнәлгән балыкчы мәче койрыгына сиздерми генә үзебез дә «тагылдык».

Бик шәп көйләгән кәсебен хәйләкәр мияубикә. Шамбы дигән ертлач, комсыз балык бар ич әле. Шундый җылы, кояшлы көзләрдә яман чослана, әрсезләнә, котыра, диләр аны. Яр читенә үк килеп, сай җирдә чебен-черки, маймыч ауларга хирыс ул. Әнә, Матуркайның йөнтәс койрыгын җиргә бәргәли-бәргәли шуны күзәтүе. Сабыр гына көтә бу. Шамбының бөтенләй ышкылып диярлек сөзәк яр кырыена якынлашуы булды – мәченең тәпие белән тегенең башына кундыруы булды. Һәм күз иярмәслек тизлек белән корбанын чирәм өстенә селтәп тә җибәрде.

Мондаен зирәклеге, җитезлеге, осталыгы белән ушыбызны алды Мыраухан.Үз тамагын гына кайгыртып сунарга чыгуы түгел икән ич дүрт аяклы балыкчының. Үзебез күрдек: алачык астында качып яткан ике бөртек нәни баласына ташый ул хәләл тотымын.

## Гыйбрәт

«Егылганны түбәләмиләр» кебек бик мәгънәле мәкале бар халкыбызның. Әмма «син хайван да син фәлән-төгән» итенгәләп, өерләре белән аста калган бичараны канга батырып типкәләү һич бетәргә охшамаган бездә. Кем хайвандыр, дуңгыздыр бит әле монда... Кече «туганнарыбыз» шәфкатьлерәк...

Бер хуҗалык фермасы белән танышып йөргәндә, шундыйрак күренешкә тап булдым... Сыерлар мышный-мышный күшәп торганда, аран эченә чит төркемнән адашып бер сөтлебикә килеп керде шулай. Килеп тә керде, әрсезләнеп, апара салынган утлыкка ябышты. Әлбәттә, хуҗалар моның бу кыланышын өнәмиләр. Берсе авыр мөгезле зур башы белән селкеп торып җибәрә тегене читкә! Икенчесе очлы мөгезе белән янтавына төртә, өченчесе «җитмәгәнен» өстәргә ашыга. Кыскасы, барысы да урап алды хәчтерүшне. Бетте, үтерәләр бу мүкләкне дип уйлыйсың инде.

Менә ул, аптырагач, аяк астына сузылып ятты. Һәм, ни хикмәт, шуннан соң бүтән тимиләр, рәнҗетмиләр бит ишләре! Аяк астында аунаган «дошманны» түгәрәкләп алалар да, «йә, ни кирәк булды инде сиңа монда!» дигән кебек кызыксынгандай күзәтеп торалар, юеш танауларын төртеп иснәштергәлиләр. Егылганны тәпәләргә маташуның әсәре дә сизелми! «Әсирлеккә эләккән» сыер кымшанмыйча да яткач, бераздан берәм-берәм таралыштылар. Һәрберсе үз шөгыленә керешә: кайсы сагыз чәйни, кайсы утлыкка үрелә, әлеге мәхлукны бөтенләй оныттылар. Ул да, форсаттан файдаланып, җәһәт кенә бинадан чыгып тайды. Менә шундый гап-гади генә бер вакыйга. Уйлаганга – гыйбрәт, уйламаганга ник кирәк дигәндәй, моны шәрехләп торасы юк.

## Бөркет килгән авылга

Чулпан авылыннан:

– Бөркет килгән әле монда! Әмирләргә ияләшкән, – дигән шаккатмалы хәбәр ирештерделәр. Карчыгалар семьялыгыннан булган бөркет, Кавказ кебек биек тауларда гына яши торган ерткыч кош. Безнең якларда ни калган аңа; козгын яисә тилгән түгел ич ул тавык чебие, бүтән кош-корт аулап йөрергә дип уйланып калдым инде.

...Терлекчелектә эшләүчеләр фермалар тирәсендә бер канаты салынган килеш очратканнар теге кунакны. Ни дип фаразларга да белмиләр. «Цирк арбасыннан төшеп калды микәнни?» – ди берсе гаҗизлектән. «Ул сиңа агач чәкүшкә түгел, төшеп калырга. Таулардан адашып очып килгән ул. Белдеңме?!» – дип кырт кисә икенчесе. Ә бөркет халыктан ятсынып, очарга итенә, тик каты яраланганга күрә, уң як канаты җилпенеп китәргә ирек бирми... Нурлаттагы ветеринария дәваханәсе белгечләренә күрсәткәч, шактый вакыт элек сынган уң канаты дөрес ялганмаганын ачыклыйлар. Аны янә сындырып, гипска катырудан башка чара юк, диләр. Шулай да берара вакыт узу белән үзеннән-үзе рәтләнү, язылу ихтималы да юк түгел икән. Аны ач үлемнән, кышкы суыктан йолып калган мәрхәмәтле хуҗа үзе дә:

– Бигрәк жәл бит... Көннәр җылытканчы миндә торып карасын әле шул килеш, аннан күз күрер, – ди ич әнә. Аннары, озын мыек чылгыйларын сыйпаштыргалап, шаяртып өсти:

– Бездә дә күңелсез түгел. Дуслашыр, аралышыр өчен әнә йорт куяннары, маэмай, кош-корт бар...

Чыннан да, тавык кетәклегенә менеп кунаклаган куе көрән төстәге бөркет үзен искиткеч тыныч тота, бик тере күренә; баш – текә, очлы томшыгын да аска салындырмаган. Бөркетләрнең кечерәк төреннән булса да, һич махы бирә торганга охшамаган. Янәшәдә генә кызыл кәпәчле әтәч кукрайган. Астарак исә үз ояларында эреле-ваклы йорт куяннары кайнаша. Шуларның ник берсенә тисен. Кыскасы, тулы идиллия хөкем сөрә тавыклар аранында. Әнә нәрсә ди бит хуҗа:

– «Тимоша» исемле куянны алдына ук куйдым, рәхәтләнеп авыз ит, дип. Юк, ашамый. Күгәрченгә дә исе дә китми. Әллә, мәйтәм, бәладән коткарып, үзенә сыендырган шәфкатьле кешеләрдән үрнәк алуымы?! Башка төрле итне умыра гына бит үзе... Балыктан да баш тартмый.

Иркенлекне, кояш нурларын яраткан бөркетне ачык һавага чыгаргалыйлар. Үзе генә түгел, куян Тимоша белән. Утыра болар янәшә җылы кояшта рәхәтләнеп. Шул чакта фотога да төшереп алдым.

Кайтырга җыенганда, авылдашларның берсе «күрше авыл тирәсендә шундый ук бөркет очып йөри иде. Моның пары түгелме икән?» дип ычкындырды... Парлап оя кора, икәүләп балалар үстерә торган кош ич ул. Чыннан да, көннәрдән бер көнне бөркет юкка чыккан. Әллә дөрестән дә ярын очратып кавышулары булды микән?!.

## Балта белән чуртан тоту

Быел кыш балыкчы дустым Рөстәм белән Чирмешән елгасына кушылган уннарча урман күлләрен айкап чыгарга насыйп булды... Язларын елга ташыгач, аларга төрле балык кереп тулып, токарланып кала, үрчи, тереклек кыла, бүтән киек-кошларны җәлеп итеп, тирә-юньгә ямь өсти. Менә Зәңгәр күл! Ерактан ук көмешләнеп, бозы үзенә тартып тора. Кемдер су асты патшалыгына «тәрәзләр» уярга – бәкеләр ачып китәргә өлгергән. Корбан, сазан, чуртан ише балыклар калын боз астында саф һава җитмичә тончыкмасын өчен шулай эшли игелекле балыкчылар. Кичләрен фонарь-ут яктысына килгән эре-эре балыкларны зур чәнечке кебек корал белән чәнчеп алучылар да булыр. Әлбәттә, чамасын белеп кенә, комсызланмыйча гына. Шуның шикелле сулыш алу бәкеләре – «тәрәзәләр» аркасында күпме вак балыкның, маймычларның исән-имин калуын да чуттан чыгарырга ярамый.

Рөстәм дә билендәге балтасын кулына алды... Берничә төштә бәке ясап, уеп бетергәч, беравык кара-кучкыл суга карап торабыз. Көтмәгәндә караңгы су төбеннән зур балта сабы хәтле чуртан сыңары килеп чыкмасынмы! Чыкты да оятсыз күзләре белән безгә текәлде бу. Икебез дә беравык аптыраудан катып калдык. Рөстәмдә балыкчы дәрте тизрәк уянды, балта түтәсе белән кизәнеп торып суга бер генә орды – күл патшасы яшен тизлеге белән гаип булды. Йөзе көмештәй ялтырап торган балта исә, хуҗаның кулыннан ычкынып, бәке авызына төшеп китте. Ай күрде, кояш алды чуртанны да, балтаны да. Чын мәгънәсендә «балтасы суга төшкән адәм» хәлендә калды инде дустым. Кәефе кырылуы озакка сузылмады тагын. «Сачок белән сөзеп алам мин аны. Монда тирән түгел», дип сер бирмәгән булып кылана. Сачок исә бәләкәй ятьмә, сөкә була инде.

Әрсез чуртан белән югалган балта вакыйгасы юл буе гәпләшергә, көлешергә азык бирде. Кайткач та, өйдәгеләрнең сорашкан булып, үртәшүенә сәбәп булды.

...Берничә көннән соң Рөстәм шалтыратты. Телефон аша ук сизелә – күңеле күтәренке, авызы ерык егетнең! «Сачок белән бер генә сөрдем ләмне, эләгеп чыкты бит балтам! Һи, анысы гынамы әле! Ышанасыңмы, аның белән бергә беләк буе чуртан да каптырдым, малай!» дип ашыга-ашыга куанычын уртаклашты ул. Шулай итеп, балта белән чуртан кыйссасы гомерлеккә хәтердә калды. Табигать төрле могҗизаларга бай, чын дусларын мәзәк хәлләр, кызыклы маҗаралар белән гел сөендереп тора ул.

**Илдус ДИНДАРОВ.**
*Нурлат*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЛАРЫ

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе залында Татарстан Мәдәният министрлыгының киңәйтелгән коллегиясе 2016 ел эшчәнлегенә йомгак ясады. Республикадагы мәдәни-агарту оешмаларының узган елгы эш нәтиҗәләре турында мәдәният министры Айрат Сибагатуллин доклад белән чыкты.

Коллегия утырышында күтәрелгән төп мәсьәләләр: мәдәниятне үстерү максатында республикага федераль казнадан акча бик аз керә, Казан мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлаучылар авылга кайтырга теләми, җирле хакимиятләр шәһәр, авыллардагы китапханәләрне тулыландыруда, китап фондын баетуда сүлпән эшли һ.б.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин мәдәният хезмәткәрләре киңәшмәсенә йомгак ясады һәм алдынгыларга хөкүмәт бүләкләрен тапшырды.

***

«Татмедиа» матбугат һәм гаммәви багланышлар агентлыгының 2016 ел йомгакларына багышланган киңәйтелгән утырышы булды. Киңәшмәдә агентлык җитәкчесе Айрат Зарипов, «Татар-информ» агентлыгы башлыгы Шамил Садыйков, «Сувар» газетасының баш мөхәррире Константин Малышев, Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин, Идел буе федераль округында элемтә, информацион технологияләр һәм массакүләм багланышлар идарәсе җитәкчесе Наталья Альхимович, Россия Федерациясенең элемтә һәм массакүләм бәйләнешләр министры урынбасары Алексей Волин чыгышлары тыңланды. Чыгыш ясаучылар матбугат тирәсендәге проблемаларны да читләтеп үтмәде. Бу җәһәттән сүз нигездә газета-журналларның икътисади яктан зур кыенлык кичерүе, тиражларның кимүе, кәгазь бәясенең, почта чыгымнарының артуы турында барды. Киңәшмәне йомгаклап, Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров чыгыш ясады һәм матбугат алдынгыларына хөкүмәт бүләкләрен тапшырды.

### ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Татарстан Фәннәр академиясе бинасында «Габдулла Тукай. Энциклопедия» китабын тәкъдим итү тантанасы узды. Аны Г.Ибраһимов исемендәге, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әзерләгән.

Тантаналы кичәне Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Сәлахов ачып җибәрде. Энциклопедияне әзерләү тарихы турында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, олы хезмәтне әзерләүче галимнәр җитәкчесе Зөфәр Рәмиев, галимә, язучы Рифә Рахман, институтның сәнгать бүлеге мөдире Рауза Солтанова, театр һәм музыка бүлеге мөдире Эльмира Галимова, Уфадан җырчы, сәнгать фәннәре кандидаты Идрис Газиев чыгыш ясады. Татар халкының фән һәм әдәбият дөньясындагы зур вакыйга уңаеннан галимнәрне Татарстан Президенты Аппаратыннан идарә башлыгы Данил Мостафин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, Казакъстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галим Җайлыбай, «Дәстүр» журналының баш мөхәррире Касыймхан Бәһманов, Кабарда-Балкар һәм Якут-Саха республикаларының Язучылар берлеге рәисләре Моталлип Беппаев белән Иван Мигалкин котладылар.

### ҖӘЛИЛГӘ – ЧӘЧӘКЛӘР

15 февраль – Муса Җәлилнең туган көнендә каһарман-шагыйрьнең Казандагы 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салынды. Бу чарада язучылар, сәнгать әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, ветераннар, мәктәп укучылары катнашты. Ул көнне Җәлилне ТР Милли музеенда да искә алдылар. Монда «Моабит дәфтәрләре»нең нөп нөсхәсе күрсәтелде.

### ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ТАРИХЫ

Казандагы Бауман урамындагы элекке Матбугат йортының Тукай клубында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин әзерләгән «Татарстан Язучылар берлеге» дип аталган китапны тәкъдим итү булды. Кичә җыентыкны дөньяга чыгарган Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин чыгышы белән башланып китте. Китапның язылу тарихы турында автор үзе сөйләде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов Р.Фәйзуллинга һәм нәшрият хезмәткәрләренә рәхмәтен җиткерде. Кичәдә Алмаз Хәмзин үзенең әсәрләрен укыды, Георгий Ибушев җырларын ирештерде.

## ЮБИЛЕЙ

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә 70 яшь тулу уңаеннан юбилей чаралары шагыйрьнең туган ягында – Түбән Кама җирендә башланды. Ул көнне әдипнең туган авылы Ташлык шаулап-гөрләп торды. Бәйрәмгә Казаннан академик Азат Зыятдинов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, бәйрәмдарның каләмдәшләре «Казан утлары» журналы һәм «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррирләре Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), Вахит Имамов, Алмаз Хәмзин, җырчылар Венера Ганиева, Рафаэль Сәхәбиев, Рамил Миндияр, яшь җырчылар Ранис Габбасов белән Гөлсирин Абдуллина, Разил әфәнденең 50 ел бергә гомер иткән хатыны Алия ханым кайтты. Әүвәл Ташлыкта, аннары Түбән Кама каласының Дуслык сараенда узган тантаналарда шәһәр мэры Айдар Метшин, Казаннан килгән кунаклар, «Җидегән чишмә» берләшмәсе вәкилләре, якташлары чыгыш ясады. Һәр чыгыш Разил Вәлиевкә карата зур ихтирам, олуг рәхмәт хисләре белән сугарылган иде.

***

Татарстан Республикасы Милли музееның әдәби салонында да Татарстанның халык шагыйре, дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиевкә 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда бәйрәмдарның иҗатына әдәбият галимнәре Дания Заһидуллина, Фоат Галимуллиннар югары бәя бирде. Юбилярны ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Сафиуллин, каләмдәшләре Рабит Батулла, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, Газинур Морат, Рүзәл Мөхәммәтшин һ.б. котлады. Г.Камал театры артисты Дания Нурлы шагыйрьнең шигырьләрен укыды. Кичә Рафаэль Сәхәбиев, Рөстәм Маликов, Муса Маликов, Тәлгать Әхмәтов башкаруында Р.Вәлиев сүзләренә язылган җырлар белән үрелеп барды. Кичәне әдәби салон хуҗабикәсе Флёра Дәминова алып барды.

Разил Вәлиевкә 70 яшь тулу уңаеннан бәйрәмнәр Казанның Иске Бистәсендә, Казан федераль университетында, ТР Милли китапханәсендә дә узды. Китапханәдә әдип язган китаплардан «Чорым минем – җырым минем» дигән күргәзмә ачылды.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Екатеринбургта Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Анда Татарстанның халык шагыйре, РФнең Дәүләт, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы әгъзасы Ренат Харис һәм «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты Айгөл Әхмәтгалиева катнашты.

## УТ КҮРШЕЛӘР ОЧРАШУЫ

Татарстан һәм Башкортстан республикалары вәкилләре Актаныш районында очрашты. Алар Такталачыкта шушы авылдан чыккан атаклы Мутин морзалар, аерым алганда, төрки сәхнәнең фаҗигале язмышка дучар булган кабатланмас артисты, татар һәм башкорт театрларына нигез салган режиссёрларның берсе Мохтар, аның туганнары – халык хокукын яклаган алпавыт Тимер, башкорт милли хәрәкәте лидерларының берсе Илдархан Мутиннар истәлегенә куелган стеллалар янында узган митингта катнашты. Аннары күренекле тарихи шәхесләрнең истәлеген яд итү Актаныш районы мәдәният йортында үткәрелгән кичәдә дәвам итте. Кунакларны Актаныш муниципаль районы башлыгы Фаил Камаев сәламләде. Әлеге чараларда Татарстан ягыннан – галимнәр Индус Таһиров, Альберт Борһанов, Гали Арсланов, «Казан утлары» журналының һәм «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррирләре Илфак Ибраһимов, Вахит Имамовлар, Башкортстан ягыннан Бөтендөнья башкорт конгрессы башкарма комитеты әгъзалары Алсу Сиргалина, галимнәр Салават Хәмидуллин, Рамил Рәхимов, Нурислам Калмантаев катнашты һәм чыгыш ясады.

## КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Казандагы 14нче гимназиядә галим, мәгърифәтче Ибраһим Хәлфин исемендәге фәнни-эзләнү конференциясе булып узды. Анда республикабыз мәктәпләреннән килгән 385 эш тикшерелде. Аларга КФУ галимнәре бәя бирде.

***

Казандагы 179нчы мәктәптә Г.Әпсәләмов иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференция булды. Биредә республикабыз мәктәпләреннән 250дән артык укучы катнашты. Әлеге чарада «түгәрәк өстәл»ләр эшләде.

***

Узган атнада Татарстан Фәннәр академиясенең президиум утырышы булып узды. Анда Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә «Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы» таныклыгы тапшырылды. Шунда ук ул Академиянең президиум әгъзасы итеп тә сайланды.

Шушындый ук мактаулы исем язучы, публицист Ягъсуф Шәфыйковка да бирелде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть АХИРА «Человек и Дьявол», рассказы Р.ГАЛИУЛЛИНА «Боссоойко», К.ХАСАНОВОЙ «Сундучный замок»; стихи Р.ВАЛЕЕВА, И.ВАЛИУЛЛЫ, Ф.ГАБИДУЛЛИНОЙ, Д.НАГИМУЛЛИНОЙ.*
*«Драматургия»: драма А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Тоскую по вам».*
*«100-я страница»: К.ФАТХУЛЛОВА. «На страже родного языка».*
*«Наши юбиляры»: А.АХУНОВ. «Учёный, наставник и личность».*
*«Литературная критика»: статья Т.Галиуллина, посвящённая поэзии 2016 года на страницах журнала «Казан утлары».*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Литературное наследие»: статья Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ, посвящённая фольклору татар Челябинской области.*
*«Публицистика»: Г.МУРАТ. «Это сладкое слово «свобода»…*
*«Наука»: Г.ХАЗИЕВА. «Татарские прозвища».*
*«Воспоминания»: Ф.ХАТИПОВ. « Воспоминания детства».*
*«Встречая юбилей»: А.ШАМОВ. «Один из экземпляров журнала».*
*На конкурс «Самый лучший рассказ»: Л.ИБРАГИМОВА. «Их замела метель…»*
*«Маленькие»: А.ШАКИРОВ. «Маленький Азгар».*
*Из фотоархива журнала.*
*«Страницы юмора».*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Рустам Минниханов». Картина художника Зуфара Гимаева; «Сказочный лес». Фото Марселя Галиева.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: tale by Ahir «Man and the Devil», stories by R.GALIULLIN «Bossooyko», K.KHASANOVA «Chest castle»; poems by R.VALEEV, I.VALIULLA, F.GABIDULLINA, D.NAGIMULLINA.*
*«Dramaturgy»: A.AKHMETGALIEVA. «Longing for you».*
*«100th page»: K.FATKHULLOVA. «Guarding the native language».*
*«Our anniversaries»: A.AHUNOV. «A scientist, a mentor and a person».*
*«Literary Criticism»: article by T.Galiullin dedicated to the poetry 2016 in the magazine «Kazan Utlary».*
*«Tukay and Tatar literature»: section is conducted by R.RAKHMAN.*
*«Literary Heritage»: article by L.MUKHAMETZYANOVA dedicated to the folklore of the Tatars of Chelyabinsk region.*
*«Publicism»: G.MURAT. «This sweet word «freedom»…*
*«Science»: G.KHAZIEVA. «Tatar nicknames».*
*«Memories»: F.KHATIPOV. «Memories of childhood».*
*«Meeting the anniversary»: A.SHAMOV. «One of the copies of the magazine».*
*For the contest «The Best Story»: L.IBRAGIMOVA. «They were covered by blizzard…»*
*«Small»: A.SHAKIROV. «Little Azgar».*
*From the photo archives of the magazine.*
*«Pages of humor».*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: «Rustam Minnikhanov». Painting by the artist Zufar Gimaev; «Enchanted forest». Photo by Marcel Galiev.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Рөстәм Миңнеханов».
*Зөфәр Гыймаев картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Әкияти урман».
*Марсель Галиев фотосы.*